
# КАЗАН УТЛАРЫ

2.1996





МУСА ҖӘЛИЛ
1906—1944

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**2**

**(880)**

**1996**

КАЗАН

## *Бу санда*

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

М. ҖӘЛИЛ. Серле йомгак. *Шигырь* ......... 3
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Ә горурлык хисе һаман шул ......... 4
Каһарман шагыйрьгә — чәчәкләр: С. ХӘКИМ, Н. НӘҖМИ, М. ДУДИН, С. ДАНИЛОВ, Ж. ЖАББАРОВ, Н. АРСЛАН, И. ЮЗЕЕВ, ЗӨЛФӘТ шигырьләре ......... 10

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Т. ГАЛИУЛЛИН. Тәүбә. *Роман* ......... 16
Ә. БАЯН. Дога. *Шигырьләр* ......... 83
Р. ГАТАШ. Җанның бер сәфәре. *Шигырьләр* ......... 89
Рөстәм ВӘЛИЕВ. Фининспектор һәм бабай. *Хикәя* ......... 97
Н. САФИНА. Мәңгелек сер. *Шигырьләр* ... 116
Б. РАФИКОВ. Соң түгел. *Шигырьләр* ......... 121

ПУБЛИЦИСТИКА

Р. СИБАТ. Текә күтәрелеш. *Документаль повесть* ......... 123
Без — тормыш театрының артистлары *(актив җәмәгать эшлеклесе, фольклорчы галим Р. Ягъфәров белән әңгәмә)* ......... 171

ХӘТЕР

Ш. МОСТАФИН. Әманәткә тугрылык ......... 146
И. САТТАР. Әтием әсәре ......... 155

ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

С. ШӘМСИ. Галиҗәнаб китап зарлары ... 158

АЧЫКТАН-АЧЫК СӨЙЛӘШҮ

«Мәгариф» — биш яшьлек аксакал *(«Мәгариф» нәшрияты директоры Мөдәррис Вәлиев белән әңгәмә)* ......... 177

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Таза орлыклар ......... 182

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕНДӘ — ТАТАР ШӘХЕСЛӘРЕ

Ф. ИБРАҺИМОВА. Фаҗигале язмыш ......... 188

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ......... 190

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Тәлгат Галиуллин**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«К 90-летию Мусы Джалиля»: Стихотворение М. ДЖАЛИЛЯ; статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА «А чувство гордости все тот же...»; «Цветы — поэту-герою»: стихи С. ХАКИМА, Н. НАДЖМИ, М. ДУДИНА, С. ДАНИЛОВА, ДЖ. ЗАББАРОВА, Н. АРСЛАНА, И. ЮЗЕЕВА, ЗУЛЬФАТА.
«Поэзия и проза»: окончание романа Т. ГАЛИУЛЛИНА «Покаяние»; рассказ Рустама ВАЛИЕВА; стихи А. БАЯНА, Р. ГАТАША, Н. САФИНОЙ, Б. РАФИКОВА.
«Публицистика»: документальная повесть Р. СИБАТА «Крутой подъем»; интервью с общественным деятелем, ученым-фольклористом Р. ЯГАФАРОВЫМ.
«Память»: статья Ш. МУСТАФИНА «Верность завещанию», размышления И. САТТАРА о творчестве отца — поэта-джалиловца Р. Саттара.
«Острая проблема»: статья С. ШАМСИ «Тяжелая судьба татарской книги».
«Откровенный разговор»: интервью с директором издательства «Магариф» М. Валеевым.
«Литературная критика»: статья Ф. ГАЛИМУЛЛИНА о творчестве писателя А. Гилязова.
Дневник общественно-политической жизни.
На наших обложках: фоторепродукция из картины художника И. Файзуллина. «Пророк Мухаммед»; литературный критик, директор издательства «Магариф» Мударрис Валеев.

## IN OUR ISSUE

«Commemorating the 90 th Anniversary of Musa Jalil»: M. Jalil's poem; R. Phaizullin's article «The feeling of pride is still the same». «The flowers are for writers-heroes»: the verses of S. Khakim, N. Nadjmi, M. Dudin, S. Danilov, J. Zabbarov, N. Arslan, I. Yuziev, Zulfat.
«Prose and poetry»: the sequel of T. Galiullin's novel «Confession», Rustam Valiev's story; the verses of A. Bayan, R. Gatash, H. Saphina, B. Raphikov.
«Publicism»: R. Sabit's documentary narrative «The steep slope»; the interview with the public figure, scientist, student of folklore R. Yagapharov.
«Memory»: Sh. Mustaphin's article «The faithfulness to the testament»; I. Sattar's reflection of the creative-work of his father, who is the follower of M. Jalil, poet.
«The sharp problem»: S. Shamsi's article «The Hard fortune of tatar book».
«Literary criticism»: Ph. Galimullin's article about the creative-work of the writer A. Gilyazov.
«The frank talk»; the interview with «Magariph» publishing house's director M. Valeev.
«The diary of the social and cultural life».
In our covers: the reproduction from I. Phaizullin's picture «The Prophet Mukhammed»; the literary critic, «Magariph» publishing house's director Mudarris Valeev.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 10.01.96 ел. Басарга кул куелды 6.02.96 ел. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70 × 108 ¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 11 275. Заказ Е-7.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1996 ел.

# Муса Җәлил

## Серле йомгак

Әкияттәге серле йомгак булып
Тәгәрәде тормыш сукмагым,
Озак бардым; ахры, көн батканда
Шушы йортка арып туктадым.

Әкияттәге дию патшасыдай,
Йорт хуҗасы чыкты каршыма.
Балта аскан, бөркет үләксәсен
Бүрек итеп кигән башына.

Әкияттәге төсле тимер капка,
Күз кадәрле тишек капкада.
Дию карап һәр көн шул тишектән
Корбаннарын санап мактана.

Дию өчен көн дә йөз учакта
Кәбаб кыза адәм итеннән;
Шушы йортта икән кара бәхтем,
Мине илдән тартып китергән.

Эх, сез, шомлы әбием әкиятләре,
Кая сезгә җитү чынлыкны?!
Сүз җитәрме сөйләп аңлатырга
Бу йорттагы вәхшәт, коллыкны!

Кая гына аяк атласаң да,
Саклый монда дию тозагы.
Һәр тыкрыкта үлем күләгәсе,
Һәр ишектә коллык йозагы.

Шундый тәртип монда: акылы барның
Балта белән башын чабалар.
Ишекләре бикле килеш яна
Карт аналар, бала-чагалар.

Дию өчен зифа билен бөккән,
Мәхрүм булып аштан, иректән,
Илләреннән куып китерелгән
Хөрмә кебек кызлар, егетләр.

Йөрәк елый таныш яңакларда
Канлы яшь һәм сулган төс күреп.
Күргәннәрем шомлы әкият кебек,
Кичергәнем авыр төш кебек.

Нәүбәт җитәр миңа, тик мин үлгәч,
Җырларымны минем кабатлар
Мин юлымда туктап назлап үткән
Гөлҗимешләр, гөлләр, наратлар.

Әкияттәге серле йомгак булып,
Җырым калды сүтелеп юлымда.
Сез табарсыз килеп шушы эздән
Минем соңгы йөрәк җырымда.

**Равил Фәйзуллин**

# Ә ГОРУРЛЫК ХИСЕ ҺАМАН ШУЛ ...

*
* *

*Төрле елда — төрле янулар.*
*Ә горурлык хисе — һаман шул!*

**Быел зурлап билгеләп үтелә торган әдәби юбилейлар байтак. Әле яңа гына Ф. Әмирханның 110 еллыгы булып узды, бу айда җәмәгатьчелек М. Җәлилнең 90 еллыгын ядь итә, апрельдә Г. Тукайның 110 еллыгы. Шуңа өстәп, исән-имин әдипләребезнең төрле дистә еллар уңае белән үткәреләчәк иҗат бәйрәмнәре...**

**Сөенергә генә кирәк! Билгеләп үтәрлек, кешеләргә күрсәтерлек, әсәрләре белән мактанырлык шәхесләребез, әдипләребез булмаса нишләр идек?.. Уйлап баксаң, һәр юбилей тантанасы — горурлык тойгысы кузгатучы Хәтер тукталышы бит ул.**

**Әхлак, этика, эстетик идеал кебек төшенчәләр, асылда тотрыклы булып, тиз генә үзгәрмәсәләр дә, барыбер, һәр заманның шул ук категорияләргә — үз бизмәне, үз мөнәсәбәте, үз сурәте. Элгәрге Олыларны хөрмәтләү мәсьәләсенә дә кагыла бу.**

**50 елларны хәтергә төшерик. Ул вакытта да юбилейлар, төрле тантаналар, искә алу кичәләре уздырыла иде. Шул исәптән, әдәби тантаналар да. Кемнәрнеке? Әлбәттә, Тукайныкы. К. Насыйри, Г. Камал, Ш. Камал, Х. Такташ кебек шәхесләргә игътибар зур иде. Фронтта һәлак булган Ф. Кәрим, Г. Кутуй иҗатлары да киң пропагандаланды. Шул елларда бу рәткә Сталин премиясе алган язучылар — Г. Бәширов, К. Нәҗми килеп кушылды. Ул вакытта Г. Ибраһимовлар, К. Тинчуриннар юк, Х. Туфаннар юк. Бәйрәмнәре генә түгел, исемнәре дә «онытылган» иде.**

**Менә берчак, тоталитар режим тетрәнеп китеп, җәмгыятьтә демократик шытымнар күренә башлаган 56 елларда «татарларның әле мондый шәхесе дә бар!» дигәндәй Муса Җәлил пәйда булды. Җәлилнең кайтуы — татар әдәбияты өчен илаһтан иңгән вәхи кебек кабул ителде. Әдәбиятыбызны дөньяга танытуда зур ыргым ясалды. Җәлил исеме белән халкыбызның иҗтимагый рейтингысы күтәрелде. Фани дөньяда кырык ел да яшәмәгән Җәлил инде менә кырык ел (каһарман шагыйрьгә әверелгән чорыннан бирле. Хәер, аның сугышка кадәр язган иҗаты да — данлы сәхифә) буе әдәбиятыбызның байракчысы булып, сафыбызның алдында бара.**

**Дөрес, соңгы дистә ел эчендә безнең тарихи рухи хәзинәбез бермәбер баеды. Инкыйлап еллары вакытында аударылган «алтын баганалар» яңадан торгызыла. Халыкка бөек Гаяз Исхакый иҗаты кайтты. Бүгенге татар аңына Р. Фәхретдин, С. Максуди, Г. Баттал кебек акыл ияләренең фикер-идеяләре сеңә башлады...**

**Йолдызлар бер-берсен капламыйлар. Аларның күләгәләре юк. Рухи күгебездә Җәлил дигән йолдызның күзәнәкләргә үтә торган үз нуры, үз яктысы бар. Җәлил шәхес буларак та, шагыйрь буларак та, каһарман буларак та бик кирәк. Һәр заман өчен. Безнең өчен.**

*24 январь 1996.*

**P.-S:** ***Шушы төштә нокта куйгач, элегрәк елларда Җәлил турында уйланып, кыска-кыска гына тезмә һәм чәчмә формадагы публицистик язмаларым искә төште. Аларны да журнал укучыларына тәкъдим итәргә булдым.***

*
* *

## Бердәнбер юл түгел тормышта...

Үлемнәре белән Үлемсезлек
Яулап ала безнең шагыйрьләр.
Кемдер сорар: кая дәлилең?
Мин эндәшмим.
Каберләре әйтсен
Тукай,
Кәрим,
Кутуй,
Җәлилнең...

Үлеп күрсәттеләр безнекеләр!
Гомерләре булды, һай, кыска!
Ә бит үлеп үлемсезлек яулау —
Бердәнбер юл түгел тормышта.

3 январь, 1968

*
* *

## Горурлык

Горурлык. Яшәүнең мәгънәсен, шәхеснең кешелек дәрәҗәсен билгели торган төшенчәләрнең берсе бу. Горурлык сүзенең фәлсәфи асылын аңлаган зат Җирдә күкрәк киереп нык басып тора, башын югары йөртә; Кояш һәм Күк астында үзен тулы вәкаләтле хуҗа итеп тоя; дөньяга, яшәешкә үз сүзен әйтә; инанган идеаллары өчен көрәшә, сугыша... Җенес яки аерым шәхес горурлыгы, гаилә-ыру горурлыгы, профессия яки һөнәр-кәсеп горурлыгы, ил-халык горурлыгы, дөнья горурлыгы...

Күпләр кебек, бүген мин дә горурмын. Чөнки горурланыр өчен ныклы нигез, хаклы сәбәпләр бар. Горурландырырлык шундый исемнәрнең берсе — Муса Җәлил. Сокланулы хисләр кичереп һәм таң калып, инде ничә дистә еллар күп илләр, күп халыклар искә ала аны.

Зур залларда тантаналы кичәләр үтә.

Илнең төрле почмакларында туганнарының истәлекләре, көрәштәшләренең тетрәткеч сүзләре яңгырый.

Типография конвейерларыннан шагыйрьнең яңа басмалары агыла.

Укучы балалар, ил чигендә торучы солдатлар, диңгез-океан киңлекләрендә йөзүче матрослар, акыллы машиналар төзүче эшчеләр, кыр хуҗалары — игенчеләр, студент яшьләр — мәктәп классларында, кызыл почмакларда, тулай торакларда аның шигырьләрен йотлыгып укыйлар.

Дистәләгән тәрҗемәчеләр аның шигырьләрен төрле телләрдә яңгырата.

Мәгъруур көйләр чыгарып, оркестрлар уйный. Аңа атап язган җырлар, симфонияләр, опералар күңелләрне айкый, үз җырлары бәгырьләрне телә, уйландыра, көрәшкә әйди.

Экраннарда аның образы.

Мәйданнарда сурәтләре.

Һәйкәле янында кешеләр агымы. Тере чәчәкләр...

... Әйе, бу бер үзгә бәйрәм, зур тантана. Бу — без шаһит булган бүгенге көн. Ә аңа хәтлесе, бүгенге тантананың ерак яралгысы, моннан утыз елдан артык элеккесе — газаплы көрәш, үлем белән якалашу, рухи ныклык, корыч ихтыяр. Туган илгә тугрылык, җиңүгә ышану. Палач балтасы астында үткән еллар, айлар... Бүгенге тантана тавышлары концлагерьлардагы әсирләрнең теш кысып ыңгырашу авазларына, бүгенге затлы кәгазьләргә матур хәрефләр белән басылган юллар — фашист өнендә аннан-моннан тапкан кәгазь кисәкләренә карандаш белән тырналган сүзләргә барып тоташа. Кимлек-хурлыкларда, салкын таш капчыкларда, гильотина балтасы асларында сынмаган рух, бүген бөтен халык рухына әйләнеп, бөтен зурлыгында, бөтен иркенлегендә тантана итә.

Үзенең иң яхшы сыйфатларын хәлиткеч сынауларда егетләрчә күрсәтә алган улларына халыкның рәхмәте чиксез. Халык андый шәхесләрне мәңгегә йөрәгендә саклый. Күңеленнән ташып чыкканын Җирдә — Кояш астында материальләштерә. Табигатьтән ул шәхес-зат төсләр ала, кәгазьләргә, киндерләргә аның сурәтен төшерә, аның исемен ташларга уя; җилләрдән, камышлардан, диңгезләрдә тавыш-авазлар алып, музыка аша, җырлар аша аны данлый; ком-ташларны өеп, биналар, урамнар, проспектлар, калалар төзи дә аларга аның исемен бирә; таулар күкрәгеннән гранит-мәрмәр ташларын алып шомарта да аның сынын мәйданнарга бастырып куя; килер буыннарга батырлык васыяте итеп аның сүзләрен китаплар рәвешендә дөньяга тарата... Муса Җәлил халыкның әнә шундый зурлавына лаек булган кеше.

Ә аның батырлык чыганагы кайдан килә соң? Әлбәттә, халыктан. Ул халык улы, хезмәт һәм икмәк тәмен яхшы белгән катлаудан — түбәннән күтәрелгән талант, халыкның рухи ихтыяҗын яхшы тойган әдип ул үз талантын һәрчак ил ихтыяҗы белән бергә бәйләп алып бара алган шәхес. Ул — һәрвакыт тормышның, көрәшнең алгы сызыгында. Ул — яшьләр хәрәкәте үзәгендә, ул — культура революциясе елларында интеллигенциянең алгы сафында, ул — язучылар оешмасының башында, ул антифашистик хәрәкәтнең иң хәвефле урыннарында... Менә корыч ничек чыныккан!

Мин горурмын. Шагыйрь сүзләре белән әйтсәк: «Бер горурлык хисе яна миндә». Муса Җәлил — шагыйрь. Зур иленең төрле почмакларында, ерак-ерак авыл-калаларында йөргәндә, чит мәмләкәтләрдә сәяхәт вакытларында башка милләт вәкилләре белән очрашканда, үзеңнең кем, кайдан икәнлегең белдерергә кирәк булганда башта ук әйтелгән сүзләрнең берсе итеп Җәлил исемен телгә аласың. Бу исемне әйткәч, күп нәрсә ачыклана төшә. Бу исем читләрдә йөргәндә, татар халкын белдертә торган үзенә күрә бер пароль, паспорт шикелле яңгырый. Шагыйрь исеме аркылы халыкны таныйлар, исәпләшәләр, бәялиләр. Безгә, татар әдәбиятының бүгенгесен дәвам итүчеләргә, ифрат зур бер дәрәҗә дә һәм гыйбрәт тә бу. Шул ук вакытта уйга калдырырлык җаваплылык та. Менә чын язучының иҗтимагый тормышта тотарга тиеш урыны! Муса Җәлил — аның бер өлгесе. Заманның алгы сафында бул, фидакарь хезмәт ит, ян, олы идеаллар өчен көрәш, кирәксә — башыңны куй...

Ил Муса Җәлил юбилеен билгеләп үтә. Телләрдә батыр шагыйрьнең исеме. Шулай да бу хосусый тантана гына түгел. Без Муса Җәлил белән бергә, аның көрәштәшләрен дә, ил азатлыгы өчен гомерләрен биргән миллионлаган патриотларның исемнәрен дә искә төшерәбез, сугыш кырларыннан кайтмый калган бабаларыбызны, әтиләребезне, якыннарыбыз-

ны да яд итәрбез. Батырлык япа-ялгыз була алмый. Горурлык та шулай ук. Без бүген күмәк горурланабыз. Чөнки бу уртак горурлык, миллионлаган кешеләренең гомум горурлыгы. Иң куанычлысы: горурланырлык кешеләр тудыручы халык бар, ул — мәңгелек, аның рух чишмәсе бетмәстөкәнмәс.

*февраль, 1976*

*
* *

## Еллар үткән саен күтәрелә

Хәтердә: моннан берничә ел элек, Җәлил көрәштәшләренең берсе белән, Кремль калкулыгыннан — хәзерге 1 нче Май мәйданыннан Казан елгасына, Елан тавы ягына, Идел киңлекләре тарафына, сүзсез генә бик озак карап торган идек. Вакыт — кичке чак, шәфәкъ чагы. Тын, моңсу вакыт. Кабаланмаган кеше өчен уйландыра торган вакыт. Офыкта кызгылт төсләр мәхшәре. Һәм шул алсу кызыллык Казан суында үзгә бер киң коридор ясап сузылган да ак Кремль диварларына кадәр күтәрелгән. Бөтен тирә-юньдә әлеге шул алсу кызыллык чагылышы — Җәлилнең бронза сынында да, агач ябалдашларында да, ак манарадагы сәгать телләрендә дә, сөзәк дамбаның шомарып беткән ташларында да. Скверлардагы кызыл гөлләр, үзләренең кызыллыкларына яңа кызыллык өстәлгәч, бөтенләй яңа бер кайнарлык белән дөрлиләр шикелле. Һәммә җирдә кызыллык. Без басып торган һәм шул мәгъруր һәйкәлне күтәреп торган туфрак, җир үзе дә кызыл төстәдер кебек... Хәер, символик мәгънәдә болай фараз итүдә дөреслек тә бар. Күп яуны сынаган, күп кан сеңдергән туфрак бит ул. Тарих түрләрендә дә, безнең гасырның шанлы революция елларында да. Ветеран агайның йөзенә күз сирпеп алам. Минем уемда — менә шушы кызыл төсләр һәм шул төсләр аша ассоциатив чагыштырулар, параллельләр... (Соңрак мондый тезмә юллар да язылды:

Казан кремле янында
сүзсез басып тордык
бер җәлилче ветеран белән

Кан өстендә — Җәлил һәйкәле.

Казансуда,
Иван явы килгән якта
батып тора кызыл офыкта
канлы кояш.)

Ә менә гомерендә күпне күргән, күпне кичергән бу агай ниләр уйлый икән? Теләгемне күңеле белән сиздеме, әллә үз уеның табигый агышы шулай идеме, ветеран агай, борылмыйча, үз турына караган килеш, салмак һәм нык тавыш белән әйтеп куйды: «Муса турында менә шулай биектән торып уйларга кирәк шул!..»

Чыннан да, Җәлил язмышы һәм иҗаты, аның кылган гамәле һәм батырлыгы хәзер Дөньяның иң биек мөнәбәрләреннән торып, кешелек акылы ирешкән иң югары фәлсәфи категорияләр белән анализланырга, бәяләнергә тиеш. Еллар үтә. Төрле рухи һәм җисми үзгәрешләр кичерәкичерә кешелекнең янә бер гасырын очлау ягына барабыз. Шунысы ачык: еллар үткән саен халыклар күз алдында Җәлил күтәрелә генә бара. Исем түгел, эш күтәрә аны, Матурлык һәм Батырлык елъязмасына керткән өлеше күтәрә... Әйе, еллар үтә. Җәлилнең һәм көрәштәшләренең үтере-

лүләренә дә инде байтак гомер үтте. Аның үзен күргән, аралашкан, якын белгән кешеләр дә көннән-көн азрак калып бара. Хәзерге яңа буыннар — яшьләр өчен, гәрчә алар шагыйрьнең тормыш юлын китаплар һәм башка чыганаклар аша шактый ук яхшы белсәләр дә, Җәлил — беренче чиратта рухи яктан — тарихи каһарманлык эшләгән кеше буларак якын һәм кадерле. Еллар үтү белән шәхеснең бәндәлеге онытыла, рухы кала, игелеге, кешелеклеге кала, батырлыгы, фидакарьлеге, тугрылыклыгы кешеләр хәтерендә яңа яхшы төсмерләрдә яңара. Җәлилнең тормышы һәм үлеме хәзер инде яшәеш факты булып кына түгел, ә тарихи вакыйга булып танылды.

Муса Җәлил бөеклек баскычына шагыйрь фидакарьлеге һәм солдат батырлыгы күрсәтеп күтәрелде. Шагыйрь батырлыгы. Солдат батырлыгы. Үлемсезлек өчен, ихтимал, берсе генә дә җитә кебек. Ике төр батырлык. Ә Җәлил мисалында бу батырлыклар — органик бербөтен, алар, гүя, аның асылын ача торган ихтыяҗи чаралар. Җәлил, гомумән, күп кырлы, күп яклы шәхес. Ә кирәк чакта, хәлиткеч сынау вакытында, ул үзенең иң асыл ягы белән ачыла: бөтен көчен һәм рухын бер максатка — Илгә һәм Поэзиягә тугрылыклы булып калуга юнәлтә. Кайчак, сирәк кенә булса да, Җәлил турында мондыйрак фикер дә ишетелгәләп куя: ул — герой да, шагыйрь дә; геройлыгы зурмы, шагыйрьлегеме? Янәсе, геройлык күрсәтмәсә, иҗаты белән Җәлил бөек шагыйрьләр рәтендә йөрер идеме? Мондый сорау һәм бербөтен күренешне аерым бүлеп карау, әлбәттә, шагыйрьнең иҗтимагый тормышын һәм мирасын тиешенчә белмәгән очракта гына туарга мөмкин. Муса Җәлилгә табигать күпне биргән. Шуңа өстәп Җәлил үзе дә табигать бүләкләренең ни бәһа икәнен яхшы аңлаган, саулыкның, вакытның, хезмәтнең кадерен һәм ләззәтен бик яхшы белгән. Сез аның күптән түгел генә чыккан дүрт томлык китапларын ешрак ачып укып карагыз! Дөньялыкта шактый аз яшәп киткән шагыйрьнең безгә калдырган рухи һәйкәле бит алар! Шигырен укыйсыңмы, мәкаләсен яки публицистик чыгышынмы, Җәлилнең кабатланмас шәхесе күз алдына килеп баса. Ул — тынгысыз, ул — эш кешесе, ул — һәрвакыт динамик хәрәкәттә, ул — оптимист, ул үз эшенә нык инанган... Ул томнарда Муса Җәлилнең татар әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендәге титаник хезмәте һәм, гомумән, культурабыз тарихындагы урыны бик ачык күренә.

Күп эшләгән шагыйрь!
Нык янган!
Ташка басып чыгарганы —
йөзләп табак...
Дүрт томлыгы тора киштәмдә
күзне иркәләп,
җанга рух биреп.
Ә калган томнары —
төрмә, вәхшәт йотканнары —
күңелемдә йөри әрнешеп...

Муса Җәлилнең әдип буларак зурлыгы, олылыгы бәхәссез нәрсә. Очраклы хәлме: иленең иң зур бүләге булган Ленин премиясен шагыйрьләр арасында беренче булып Җәлил шигырьләре алды бит! Бу — аның поэтик батырлыгын ил һәм дөнья күләмендә тану һәм билгеләү булды.

Әйе, Муса Җәлил батырлыгының мәгънәсе вакытлар үтү белән һаман зурая бара. Аның батырлыгы — үткән өчен генә түгел, хәзер дә, киләчәк өчен дә бик кирәк батырлык, ихтыяҗи батырлык булып чыкты. Җәлилчеләр көрәше — Кешелекнең фашизм кебек афәтне җиңә алу мөмкинлегенең бер дәлиле, җиңә алу тантанасының бер чагылышы иде. Әмма тынычланырга әле иртә. Фашизмның да, шовинизмның да беткәне юк. Киләчәк өчен төрле социаль системалар, кыйтга-континентлар, ил-дә-

үләтләр арасында аяусыз көрәш бара. Тупас көчнең канаты һаман җәюле. Геноцид хәлләре, яман чир кебек, аз санлы халыкларның җанын кимерә бирә... Көрәш кискенлегенең, рухи киеренкелекнең кимегәне юк. Димәк, көрәшчеләр кирәклеге, Җәлил кебек гуман сәнгатен һәм гомерен салып көрәшә алырлык шәхесләрнең һаман саен күбрәк кирәклеге торган саен ныграк сизелә. Кешелекне кешелеклегенә чакыру, аның вөҗданын уяту, җир йөзендәге җаннарның мөмкин кадәр күбрәген бөек идеалларга хезмәт иттерү... Тере материянең йөрәген саклау, җанын пакьлау ... Менә хәзер безнең Яшәеш килеп терәлгән глобаль проблемалар. Мондый проблемаларны Кешелек файдасына чишәр өчен Җәлил кебек интернациональ күңелле, көчле рухлы чын көрәшчеләр кирәк. Миңа калса, менә шуның өчен дә төрле милләтнең акыл ияләре — дәүләт эшлеклеләре, философлары, шагыйрьләре — Җәлил турында үзгә бер патетик тойгы йөртәләр. Үзебездә бер хәл, инде шушы соңгы дистә еллар эчендә тугандаш халыклар телендә Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында күпме җыр, шигырьләр, пьеса, поэмалар, повестьлар туды, күпме сынлы сәнгать һәм сәхнә әсәрләре иҗат ителде. Хикмәт — җәлилчеләрнең батырлыгына дан җырлау гына түгел, төп максат — киләчәк буыннарда Җәлил кебек ватанчыл, илсөяр тойгылар тәрбияләү, аларны чын кешеләр итеп үстерү.

Җәлил — татар халкының бер газиз улы. Әгәр ул бөтен дөнья таң калырлык батырлык үрнәге икән, димәк (батырлык та, чын сәнгать тә буш урында, нигезе булмаган җирдә туа алмый), аны тәрбияләп үстергән халык үзе дә — олы халык, чын сәнгать тудырырга һәм үлемсез батырлык күрсәтергә сәләтле халык, рухи потенциаль мөмкинлекләре зур халык.

Безнең өчен, бүгенге татар әдәбиятын үстерү эшенә күңелләребез белән алынган кешеләр — язучылар өчен, Җәлил шагыйрь һәм әдип буларак аеруча кадерле. Җәлил — зур тарихи поэтик мирасны нык үзләштергән, поэтикабызны яңа шартларда үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән шәхес. Әгәр аның шагыйрьлек һәм гражданлык батырлыгы турында олы сүзләр сөйләп, аның традицияләре турында бик еш яза килеп тә, бүген аның юлын, иҗтимагый идеалларын конкрет эшебездә, конкрет хезмәтләребездә дәвам иттермәсәк, без бер яклы һәм рухи фәкыйрь кешеләр булыр идек. Шөкер, бүгенге татар поэзиясе туктаусыз үсештә. Тукай Җәлилләр эстафетасын яңа буыннар ышанычлы адымнар белән яңа сыйфатларда дәвам иттерә. Без бүген, иманнарыбызга хилаф китермичә, хәзерге заман поэзиясенә үзләреннән лаеклы өлеш кертә алырлык байтак исемнәр саный алабыз. Димәк, Җәлил шагыйрь буларак та һаман безнең белән, ул — күңелләрдә, йөрәкләрдә, рухы һаман исән, сау-сәламәт!

*Октябрь, 1980*

## Сибгат Хәким

* * *

Төштә нәрсә күргәнлеген беләм
Мусаның мин үләр алдыннан:
Туган авылы... Әнисе мич яккан,
Кабартмалар пешерә ак оннан.

Пешерә дә канат белән майлый,
Чүмәлә күк өя табакка.
Юрганыннан чыккан аягыннан
Тартып китә: пеште кабартма...

Юл мәктәпкә, кырга, болыннарга,—
Алда якты юллар ачылган,
Чыжлый таба, Муса уянган да
Карап ята юрган астыннан.

Өйдә әрем себеркесе исе,
Үзе җыйды, үзе бәйләде;
Оренбурның яшел далалары,
Оренбурның ямьле җәйләре.

Әниеңә эшкә ярый идең,
Әниеңә ике күз идең,
Елый төштә: азат, ирекле бул,
Хуҗасы бул, себер үз өең...

* * *

Йөрәге белми куркуны
Халкына анты барның,
Төптән уйласаң, Мусалар —
Уллары Дантеларның.

## Нажар Нәҗми,

*Башкортстанның халык шагыйре*

### Кичер мине

*Муса Җәлилгә*

Демблин, Радом, Берлин... Шул юллардан
Алып барды сугыш мине дә.
Шул юллардан дошман чигенә-чигенә
Алып киткән икән сине дә.

Бер үк юлда ике төрле язмыш...
Ә мин шунда исән калганмын.
Әйтерсең лә, дошманнарны куып,
Мин тик сине эзләп барганмын.

Хәтерлимен төрмә коймаларын,
Бәреп кергән тимер капканы.
Үз күзләрем белән күргәнмен мин,
Үз кулларым белән тотканмын мин
Сине харап иткән балтаны.

Бу хәтерләү нигә кирәк хәзер?—
Синең даның шуңа калганмы?!
Палачларга сине бирмәс идем,
Кичер мине — соңлап барганмын.

## Михаил Дудин,

*рус шагыйре*

### Муса Җәлил истәлегенә

Йөрәгенә төбәп аткан чакта,
Дага белән таптап чапканда,
Киләчәккә оча канатлы җыр,
Азатлыгын илнеңякларга.
Җыр — югалмый! Беркем әйтә алмый
Ирек җыры кайдан алынган?!
Эстафета-җырны алган Пушкин
Билгесез бер җырчы җаныннан.
Үткәннәргә үпкәм юк та кебек,
Хәтер генә тынны буа бит.
Сагынадыр Себер яшь Тукайны,
Ә Җәлилне — кыскан Моабит.
Якынлаша палач баш очына
Һәм күкрәккә мылтык терәлә.
Ап-ак карлар кайный кайнар каннан,

Машук ташы кинәт тетрәнә.
Һәм балтага Фучик башын куя,
Җәлил баса пуля каршына.
Ә җыр җирне азатлыкка әйди,
Канатлары чорны тарсына.
Тәрҗемәләр аңа кирәк түгел —
Ул үзенә урын табачак.
Ил җанында, халык язмышында
Җыр — мәңгелек — исән калачак!

*Роберт МИҢНУЛЛИН тәрҗемәсе*

## Семен Данилов,

*якут шагыйре*

### Муса Җәлил истәлегенә

Үлем угы тиеп җиргә аугач,
Кул-аягын каерып, богаулап
Караңгы һәм тынчу, тар зинданга
Ыргыттылар аны җыйнаулап.

Кан түкергән хәлдә: «Канга — кан» дип
Кычкырды ул бөтен көченә...
Күрде гүя шулчак алсу байрак
Элүләрен рейхстаг өстенә.

Баш идермәк булып кыйнауларның
Чыгарлыкмы икән санына?!
Сүзләрендә тоеп аның көчен,
Теләделәр сатып алырга.

Сатылмады! Көрәш җырыннан тыш
Җирдә яшәү мөмкин түгел лә!
Горур карап барды солдат шагыйрь
Авыр, ләкин матур үлемгә.

Үлеме белән җиңде үлемне ул,
Үлемсезлек шушы түгелме!
Җирдә мәңге исән калыр өчен
Халкы йөрәгендә терелде.

Тормышта да, инде соңгы тапкыр
Күргәндә дә кояш нурларын,

Без җырлыйбыз!
Соңгы сулышта да
Без җырларбыз көрәш җырларын!

*Рәшит Гәрәй тәрҗемәсе*

## Җуманияз Җаббаров,

*үзбәк шагыйре*

### Мәңгелек

*Муса Җәлилгә*

Яшен сукты биек таш кыяны,
Яралады пуля бөркетне.
Әмма илгә калкан булган ирне
Яу кырында берни өркетми.
Җаны — мәңгелек!
Даны — мәңгелек!
Аңа — гөл! Аңа — җыр! Аңа — дан!
Батыр ир үлми,
Ул үлә белми,
Батырлык туачак яңадан!
Үз улына көч һәм кодрәт биргән
Туган илен улы юксына.
Аның карашыннан зиндан ава,
Тимер балта эри, ук сына.
Сүзе дә корыч,
Үзе дә корыч,
Өйрәник җиңелеп калмаска.
Батыр ир үлми,
Ул үлә белми —
Батырлар туачак алмашка!
Шигырьләре аның — яңа матдә:
Анда нур да, рух та, көч тә бар,
Дусларына дигән мәхәббәт тә,
Дошманнарга дигән үч тә бар.
Ул халык даны,
Илем вөҗданы,
Ул данны җир меңгә тапкырлар.
Батыр ир үлми,
Ул үлә белми —
Туачак Җәлилдәй батырлар!

*Роберт МИҢНУЛЛИН тәрҗемәсе*

## Нури Арслан

### Уникe батыр турында баллада

*Татарлар елмаеп үлделәр.*
Ланфредини истәлегеннән

Таш утрау шикелле бу төрмә,
Таш койма әйләнә-тирәсе.
Белделәр бу ташлар мәйданга
Бүген дә корбаннар киләсен...
Дарларга уникe батырның
Ашуын бу ташлар күрделәр,
Таң калып тетрәде диварлар:
Батырлар елмаеп үлделәр...

Еракта, Идел-Йорт җирендә
Уникe батырның иле бар.
Кайтмаслар тик илгә егетләр:
Каршыда таш койма, шомлы дар.
Җәйге таң. Зәп-зәңгәр күк йөзе...
Яшәргә иде!.. ди күңелләр.
Тик шәфкать сорамый дошманнан,
Батырлар елмаеп үлделәр,
Татарлар елмаеп үлделәр.

Йодрыктай йөрәккә никадәр
Кайгылар, газаплар сыялар.
Сыймады батырлар йөрәге—
Чатнады таш-пулат коймалар.
Хисләре буйсынмый богауга
Киң-иркен күкләргә менделәр,
Һәм үлмәс җыр булып калдылар!—
Мусалар елмаеп үлделәр,—
Батырлар елмаеп үлделәр.

## Илдар Юзеев,
*Татарстанның халык шагыйре*

### Читләрнең үз бәясе

*«...Иң башта Корьәнне Алишка суздым.
Ул, акрын гына торып, кулын Корьәнгә салды
һәм елап җибәрде»...*
Усман мулла истәлегеннән

«Татарлар елмаеп үлделәр...»
Читләрнең үз бәясе.

Биш минуттан — гильотина, —
Килерме елмаясы!

Таш бәгырь булу мөмкинме
Әҗәл янда дәшкәндә,
Милләтнең изге китабы —
Коръән бәхилләшкәндә?

Киткән алар — бу дәһшәткә
Түзәргә кирәк ничек? —
Читләр алдында — елмаеп,
Коръән алдында — үксеп...

## Зөлфәт

* * *

Җырлый белмиләр бөркетләр,
Сугыша белми былбыл,
Җырдан сызланмый бөркетләр,
Сугышта үлми былбыл.

Муса кайсы шул кошларның?
Җанына сыйган Җир, күк...
Сугыша белгән былбыл ул
Һәм җырлый белгән бөркет.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Тәлгат Галиуллин**

# ТӘҮБӘ

РОМАН

## 15

Зөлфия белән уңышсыз очрашудан соң, Шөреп вакыйгаларны ашыктыруны кирәк тапты.

— Өйләнешик без, Регина,— диде Сәнгат тыныч кына.— Минем дөньяда синнән якын кешем юк. Әбием, әнием, сеңелем, яраткан хатыным бул.

Регина Шөрепне әти-әнисенә күрсәтмәгә, өйләренә алып кайтты. Әтисе милиция полковнигы икән. Эшенә чиксез бирелгәнлеге, үз-үзенә хөрмәт белән каравы кояшта янган тулы битенә, таза гәүдәсенә ташып чыккан. Яше — иллеләр тирәсе булыр.

Чыннан да, Җәүдәт Габдуллович — милициядән башка эшне белми, үзгә һөнәргә ихтыяҗ да сизми торган, белгечлегенә табынган шәхесләрнең берсе, югары мәгънәдәге мент иде. Арттан төртеп барырдай йонлач кулы юк, үз көченә генә ышана, баскычтан-баскычка, як-ягына каранакарана атлый-атлый, үзе өчен мөмкин булган иң абруйлы дәрәҗәгә ирешә.

Ерак авыл районында аеруча тырышып эшләде. Хатыны Казанда яшәү хыялы белән шашты. Ә башкалага күчүнең юлы икәү генә: төрле дәрәҗәдәге җитәкчелеккә ярау һәм артыңнан кара таплар калдырмау. Табигатьтән килгән тазалыгы да ярдәм итте. Көн белән төнне аермыйча эшләде дә эшләде. Аны күрделәр, Казанга алдылар. Берничә ел тыныч яшәп калды. Заманалар кискен үзгәреп куйды. Дөньяны мафия, оештырылган җинаятьчелек, урлашу басып китеп, тормыш дилбегәсе алыпсатарлар, җилкуарлар кулына күчкәч, ул җайлап кына пенсиягә китү ягын кайгырта башлады. Әмма мәсьәлә ул теләгәнчә килеп чыкмады. Аны җаны сөймәгән халык белән көрәшү өчен махсус оештырылган идарәгә бүлек башлыгы итеп куйдылар. Мөмкинлек ачылганны, форсат кулына килеп кергәнне көтеп кенә торгандай, баш-аягы белән шул эшкә чумды Җәүдәт Габдуллович. Күп нәрсәне ачыкларга, ата каракларны фаш итәргә өлгерде аның бүлеге.

---

[1] Ахыры. Башы журналыбызның 1 нче санында.

Мәгәр тиздән кыен шөгыльгә алынганлыгын аңлады ул. Һәр операцияне зурдан кубып, югары оешмалардан рәсми рөхсәтләр алып башласа да, әмма ләкин мафия көнен, сәгатен алдан белгән булып чыга. Җәтмәгә гел вак-төяк балык, чабак-мазар эләгә. Җитәкчеләрен санакларыннан алып булмый. Симез налим балыгы сыман, кулдан оста шуып чыгалар.

Әлмәт шәһәрендә Әбсәләмов бандасы фаш ителгәч, тәҗрибәле белгеч буларак, полковник Җәүдәт Насыровны шунда җибәрделәр. Калада тәртип саклау өчен җаваплы әһелләр, җирле мафия белән аралашып, сатылып, мәш килеп бетkәннәр. Аларны бу эштән тулысы белән читләштерергә туры килде. Казаннан килүчеләр тикшерүне бик кискен, коры һәм дуамал башлап җибәрсәләр дә, әллә ни майтара алмадылар. Оештыручыларын кемдер алдан кисәтеп, тегеләр булган малны учлап, хәтта иң яраткан сөяркәләрен дә алып, Санкт-Петербургка хәтле олаккан булып чыктылар. Аннан Анталиягә, Гавай утравына юл тотканнар, дигән хәбәр килде. Килде-китте, йомышчы каракларны җыюдан ары китә алмадылар.

Бүген дә өенә кәефсез кайтты. Министр урынбасары Әскар Әлмиев белән бик үк җылы булмаган очрашудан дөреслекнең җиңәсенә, илдә тәртип урнашасына ышанычын бөтенләй югалтып кайтты. Яшисе килми башлады.

Бу сөйләшүгә Насыров алдан әзерләнеп, тиешле кәгазьләрен күтәреп, дәлилләрен әзерләп барды. Исәнлек-саулык сорашуга вакытны әрәм итмичә, мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

— Мин үземә мәгълүм җинаятьчел төркемнәргә каршы эш кузгатырга рөхсәт бирүегезне сорап кердем.

— Хуш! Мин каршы дип уйласаң, бик нык хаталанасың. Президент Указын без үтәргә тиеш. Мәслихәт. Кемнәрне күз алдында тотасың инде? — диде кабинет хуҗасы.

— Хәзер санап үтәм. Сакманов, Башорин, Ваһапов кебек китларны селкетә башларга кирәк, дип саныйм. Вакыт җитте алар белән көрәшергә.

— Син бигрәк иске, коммунистлар хакимияте заманыннан калган сөрсегән, яманаты чыккан терминнар белән эш итәсең: көрәш ачарга, юкка чыгарга!.. Урамга кара. Егерменче гасырның туксанынчы дистәсе бара бит, дустым. Яңачарак фикерләргә вакыт. Без инде егерменчеутызынчы елларда, соңгы сугышта ничаклы асыл егетләрне, акыллы башларны харап иттек. Син тагын илгә большевиклар таккан террор юлына басарга чакырасың. Синдәге мылтыкның аларда да барын онытасың! Хәзер акыл, баш белән эш итеп кенә җиңеп була явызлыкны, Җәүдәт Габдуллович!

— Соң нишләргә, кул кушырып утырыргамы? Бирегез бәрәр киңәш.

Урынбасар, йомшак кәнәфиеннән торып, салмак кына йөренеп алды, сирәк ефәк чәчләрен бармаклары белән төзәткәндәй итте.

— Дөрес сорау бирдең! Бердән, безгә аларны үзебезгә якынайтып, малларын республикага, син һәм мин яраткан халкыбызга хезмәт иттерергә кирәк. Байлыкны бөтен Рәсәйдән, дөньядан бирегә ташысыннар. Аларны көч, усаллык белән егып булмый, акыл, зирәклек, хәйлә белән үзебезнең якка аударырга кирәк. Икенчедән, аларны маңгайга-маңгай орыштырып, үзара сугыштыру фасылын (урынсыз булса да, матур сүз тапканына елмаеп куйды) да күз уңыннан ычкындырырга ярамый. Берберсен үтерешеп бетерсеннәр,— диде монологыннан канәгать калып. Тынлыктан соң янә өстәде: — Өченчедән, башкарган эшебезне кечерәйтеп күрсәтү — дошман тегермәненә су кою, ялган демократлар кулына утлы корал тоттыру. Укыштырып яшәргә кирәк вакытлы матбугатны. Газеталар җинаятьчелек белән көрәш идарәсенең 7 миллиард сумны саклап калуы турында бик хаклы хәбәр итә. Казан, Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләрен калтыратып торган 47 группировканың оештыручылары җавапка тартылды. Күпме корал алынган, наркотиклар юкка чыгарылган. Халык ипиен болай гына ашап ятмыйбыз икән. Мескенләнүең мина ошамый.

Мәсьәләне хәл итәргә алынмаганда, сүз күбәя, дип зиһенләп алды Җәүдәт:

— Мин дә килешәм. Тик ятмыйбыз. Тик мафиянең эш алымнарын үзгәртүенә, елан төсле тиресен алыштыруына игътибарны юнәлтәсе иде. Горбачев дәверенең беренче чорында гына сугышты алар үзара. Урам, квартал, хатын-кыз, машина бүлешә алмыйча атыштылар. Алары давыл диңгездән бәреп чыгарган чүп-чар, йомычка, күбек кенә булды. Хәзер җитәкчелеккә тормышның ачысын-төчесен татыган, хакимият, хөкем органнарында чирканчык алган, дәүләт структураларында үз кешеләре булган асслар килде. Боларны кулга төшерү сират күперен кичүдән дә кыен.

Кызып киткән нотыкчыны кулын күтәреп бүлдерде урынбасар. Үзе мәгънәсен тәгаен аңлап җитмәгән тирән фәлсәфәгә кереп бара түгелме соң бу иптәш? Йомырка тавыкны өйрәтә башласа, ахыры хәрти бетәсен көт тә тор.

— Менә шул, шул. Син мафиоза дигән арадашчы оешмаларга тәҗрибәле, акыллы кешеләр килде. Бу — факт. Алар белән эшне дә индивидуаль рәвештә, һәркайсы белән аерым-аерым алып бару отышлырак булыр.

Күрсәтмә бирергә өйрәнгән бармагын өскә күтәреп, дәвам иттерде:

— Синең киңәшне тыңлап, мылтык күтәреп киттек ди, 1917 елдагы кебек. Мафия сунарчыларының бездән остарак атуын искә алып, күп корбаннар исәбенә кулга алдык, ди, шул ук син атаган кешеләрне. Бер ай, кырык көн тоттык, ди аларны төрмәдә. Шуннан ни...

— Прокуратура, суд хөкем чыгара. Срок бирә.

— Хөкем чыгармый. Чыгарып җибәрә. «Из-за отсутствия достаточных улик» дигән гениаль маддәне беләсеңме син?

— Беләм,— диде ник кергәненә үкенә язып, тәмам йомшый барган полковник. Әлмиев аны кабинетыннан тиз генә чыгармаячак иде.

— Син атаган кешеләрне алыйк?

— Мин держаханы кычкыртып, оятсыз рәвештә талаучыларны гына атадым бирергә. Бармагын тыккан, кулын тыгар, кулын тыккан аягын тыгар, дигән иман белән яшәүчеләрен генә китердем.

— Тукта әле! Кара төндә йолдыз таба бел! Мисалга Нургали Борһанович Ваһаповны алыйк. Булган, эшчән, аралашучан шәхес. Болгар мәчетен салуга күпме акча бирде. Картлар йортын үз исәбенә ремонтлады.

Министр урынбасары Ваһаповка яхшы мөнәсәбәтен, уңай карашын яшерүне кирәк тапмыйча сөйли. Әйтерсең лә куян баласын сыйпый...

— Әзер машинаналарны сатып, Оргсинтез заводын кычкыртып талап, кыскасы, бездән урлаган малны кызганып торсынмы? Барысы күзгә төтен җибәреп, гарип күздән яшь агызу өчен эшләнә.

Әлмиев аны тыңламый иде. Ул, күрәсең, ниндидер күңелле, могҗизалы вакыйганы исенә төшереп, шунда очып киткәндер. Хатирәләр дөньясына. Җәүдәт исә очрашу башында биргән соравын кабатлады. Бүлмә хуҗасы шунда гына, аңына килгәндәй:

— Нәрсә дидегез? Гафу итегез,— дип куйды.

— Бераз селкетеп алырга ярыймы, дим әлеге боссларны?

Печән биреп салам алгандай, җавап теләмәгәнчә булды.

— Халыктан ераклашкан, гамәлдә саташкан бәндә булып барасың түгелме? Тормышта маягыңны югалтасың түгелме? Саламторханнар заманы күптән үтте, дустым. Бер дә юкка кулга камчы тоту заманасымы соң бүген? Кыскасы, энҗе кебек кыйммәтле киңәшләреңне үзеңдә тот!

Өскә бөгелеп торган күз уемнары, чыгынкы яңагы уйнаклап алды хуҗаның. Тумыштан кысыграк күзләренә зәһәр елмаю чаткылары кунды.

— Йөрәгең кеше өчен янсын, көйсен, ачык һәм гаҗиз булсын! Ә син кешеләрдән гел крамола эзлисең, һәркемдә карак, бур күрәсең.

— Дөньяда минем өчен иң мөһиме — дөреслек,— дип үҗәтләнде Җәүдәт.— Шуның өчен ахыргача көрәшәчәкмен.

— Акыл, зиһен җегәрең ялгыш юлда, мунча алдында гына капшана. Тирәнгәрәк чумарга вакыт, иптәш полковник. Ярый, син атаган кешеләр турында. Шул ук Нургали Ваһаповны табигый берләшмәләр заводына рәсми хуҗа итеп билгеләү турында да фикер өлгереп килә Республика җитәкчелегендә. Халык үзен ярата.

Кечкенә өстәлгә тәртипле тезеп куелган биш-алты телефон аппаратына күз атып, тавышын акрынайтып өстәде: — Сөяркәсе чибәрләрнең чибәре, хатынын рәнҗетми... диләр. Сочига ялга беренчесе белән барса, икенчесен Карловы Варага култыклап алып китә. Аның кебек яши белергә кирәк әле безләргә!

Фикереннән ифрат канәгать калып, киң кулы белән авызын каплап, рәхәтләнеп көлде, аяк астындагы чүп чиләгенә тәмләп төкерде. Фикер дилбегәсен үз кулында тотуы, әңгәмәдәшеннән өстенлеге аңа ләззәт бирә иде. Ул — ял итә.

— Тагын кемне атадың әле? Әйе, иптәш Башорин. Соң бит Иван Пантелеймонович безгә ничә йөз вагонны бушлай ремонтлап, рельска куеп бирде.

— Йөк белән килгән вагоннарны урлап бушату исәбенә.

— Алай кешене тоташтан гаепләргә ярамый. Шуны раслый аласыңмы? Кулларыннан тоттыңмы? Эндәшмисең. Әйтер сүзең юк. Сәет Сакмановка килгәндә... Хәтерем ялгышмаса, ә минем ул абзыкай сирәк хаталана,— дип чигәсенә бармаклары белән кагылып алды.— Сакманов сиксәненче еллар ахырында иң булган участковый милиционер дигән исемгә лаек булды түгелме?

— Әйе, начар эшләмәгән ул. Аны БХССка күчерү нияте дә булган. Шул ЧП килеп чыкмаса...

Әле генә зиһененә сокланган бүлмә хуҗасы сорап куймасынмы:

— Ничек янды әле ул Сакманов?

— Канализация коесында яңа туган үле балага тап була. Анасын таба. Республика үзәк хастаханәсендә эшләүче медсестра булып чыга теге зәхмәтлесе. Иләмсез яман тавыш куба. Өстән әмер төшә: тикшерүне туктатырга, мәсьәләне ябарга, хатынны тынычта калдырырга... Сакманов берәүне дә тыңламый, дөреслек эзләп, министрга хәтле барып җитә. Үзенә каршы хикмәт башлана. Хатыны белән аерылган икән, яшергән, чат саен сөйләп йөрмәгән, шуны сылтау итеп алып, эшеннән куалар.

— Кешенең язмышы белән ничек уйныйбыз,— диде Әскар Әлмиев тавышына үкенеч төсмере иңдерергә тырышып.— Кадрларны бәяләү җитешми шул әле безгә. Егетнең биографиясен бозган олы абзый хәзер үзе дә пенсәдә.

Кара син аны, бәллүр савытны ничек ялтырата! Койрыгын болгатып карганың сырын ашаган хәйләкәр төлкең бер якта торсын. «Сакманов эше»нә нокта куюны Әлмиевкә йөкләгәннәр иде. Аның тәкъдиме вә рөхсәте белән участковыйны халык хуҗалыгына озаттылар.

— Сакманов барыбер безнең коллега,— дип дәвам итте сүзен Әскар.— Синең аңа, Җәүдәт Габдуллович, берәр шәхси үчең бармы? Матур апаңны тартып алдымы? Анысын булдырыр, чибәр, таза ир. Елдан-ел яшәрә генә бара.

— Бернинди үпкәм юк. Хатын-кыз белән чуалырга вакытым да, теләгем дә юк. Үземнеке дә үгиләнеп бара инде.

«Сакмановны теге вакытта, КамАЗ машиналары белән тотканда, ычкындырдым. Умыртка сөяген сындырып була иде. Йомшаклык күрсәттем»,— дип үкенеп алды кунак. Хәзер терсәкне тешләүдән ни файда.

— Ярый, ярый. Дошман сизгән керпе кебек энәләреңне кабартма. Безнең киеренке эштә бераз тел шомартмасаң, акылдан язарсың.

Җәүдәт «киеренкелеккә» игътибар итте: бүлмәдә ул ике сәгатьтән артык утыра, бер тапкыр да телефон чылтырамады, беркая да чакырмадылар, керүче, чыгучы булмады. Тыныч урыннар бар инде элеккеге Советлар илендә, дип уйлап куйды. Исенә төште. Абзый министр булу турында хыялланып йөрде бугай. Яшьрәк кешене куйдылар. Аны исә үзгә, тынычрак эшкә күчерәләр, дигән хәбәрне сарафан радиосы колакка ирештерде. Менә кая икән чикләвекнең төше. Берәү белән дә дошманлашасы килми.

— Сакманов бик зыялы, тәртипле егет. Республикага шикәр, мебель кайтаруга булышты. Украина, Прибалтика эшкуарлары белән элемтәләр урнаштырды,— дип дәвам иттерде сүзен кабинет хуҗасы.

— Коры сөт белән үткән ел тоткан идек инде без аны. Майлап ычкынды.

— Мин ул материаллар белән таныштым. Алган, саткан, озаткан, дисең, бер генә кәгазьдә дә аның фамилиясе, имзасы юк.

— Шыр тилемени ул эз калдырырга! Аның киңәшчеләре яхшы күренә. Безнең арада да ярдәмчеләре юкмы икән әле?

— Мин дә кайчаннан бирле шул хакта туглыйм, Җәүдәт Габдуллович! Без һаман искечә уйлыйбыз. Яңарырга кирәк безгә, яңарырга! Үзгәрергә вакыт безгә, үзгәрергә! Соңгысы: сез атаган кешеләр түл җыеп, баеп кына киләләр.

— Каян чыгып шулай хөкем итәсез? Һәркайсында әллә ничә машина, дача, акчаларының исәбе-хисабы... безнең өчен карурман.

— Болар әле сәясәттән читтә торалар, депутатлыкка да дәгъвә итмиләр. Теләсәләр кая да үтәрләр иде, сүзсез. Мафия артык баеса, симергән эт кебек, хуҗаларына ташлана, икътисадый, сәяси эшләргә тыкшына башлый. Сергей Бабурин мисалы сиңа җиткәндер.

Аудиенция тәмам дигәнне аңлатып, хуҗа олы, таза кулын полковникка сузды һәм телефонны күтәргән булып калды. Янәсе, эш күп, шалтыратасы бар.

Авыр һәм, Җәүдәт фикеренчә, файдасыз, төссез сөйләшүдән соң ял итү турында хыялланып, өенә кайтты. Туган бусагасын атлап керсә, кызы әнә йөзеннән, йөрешеннән, җилкә сикертүеннән үк кем икәнлеге күренеп торган бер мокытны ияртеп кайткан булып чыкты. Эч пошканнан гына түгел, җитди ният белән икән.

— Әти, таныш бул! Бу — Сәнгат исемле егет булыр. Әни белән сөйләштек инде.

Егеткә кулын бирмәде. Башын каккандай гына итте.

— Соң, шуннан?

— Без Сәнгат белән инде берничә ай таныш. Бер-беребезне яратабыз. Өйләнешергә булдык.

«Кызым, бер дә кәефем юк, башка вакытта гәпләшербез»,— дип куып кына чыгармакчы иде дә... Аш-су бүлмәсеннән хатыны килеп чыкты.

— Яхшылап сөйләш, Җәүдәт, яшьләр белән. Регина — бердәнбер кызыбыз.

Әйтерсең лә ул хатынының бер бала китергәч, иң оста табибларга, имче-томчы карчыкларга күрсәтеп тә башканы таба алмаганын, шуңарга кызларының кирәгеннән артык иркә, үзсүзле булып үсүен, атасын тыңламыйча, белгечлек тә, белем дә бирми торган «бию бүлегенә» башын тыгуын хәтерләми. Җәүдәт кызының инде эчкәләп, тартып йөргәнен белә, ир-ат белән йоклап йөрү ихтималын да сиземли. Тавыш күтәрүдән файда юк. Әнисе һәрвакыт кызы яклы.

Өендә аны көтеп, аңлавынча, кызының кулын сорарга килгән егетне ул, ата булудан бигрәк, милиционер һөнәре яссылыгыннан ошатмады. Табигать биргән көчен кая куярга белми интеккән егетләрне хәтерләтә. Бәлки, ялгыша торгандыр?

Регина барыбер үзенчә эшләячәк. Дөнья куып, тәртип урнаштырам, дип тилереп йөреп, кызын кулдан ычкындырды тәки. Бу илдә әдәп-тәртип урнаштыру — ахмак дәрвишләр хыялы икән ул.

— Ярый, сөйләшик! Өйләнешү, гаилә кору, ике кешенең гомерлеккә бергә кушылуы — ничаклы җитди әйбер, олы адым икәнне беләсездер, дип уйлыйм.

— Әткәй, бу мәсьәләдән без хәбәрдар. Мин мәктәптә укый башлаганда, совет кешесенең әхлак кодексы гамәлдә иде. Ятладык без аны. Хәзер дә хәтерлим. Исеңә төшеримме?

Кызының төртмә холкын яхшы белсә дә, җаваплы сөйләшү алдыннан кылануына ачуы килә башлады. Үзен тынычландыру өчен, гадәтенчә, сул кулы белән күз керфекләрен уып алды.

— Егетем, үзегез турында сөйләп җибәрсәгез иде?

— Имтихан аласыңмы? — диде кызый.

— Әти-әнисез генә, әби белән үстем. Белемем — ун класс. Регина укырга кертәм, ди әнә. Мин риза.

Биографиясенең милиционер өчен четерекле, кызык өлешен атлап үтеп, хәзерге тормышына бәя бирде егет:

— Уртак предприятиедә ремонт эшләре белән шөгыльләнәбез. Плотник. Столяр. Шофер мин үзем.

— Хатынығызны кая төшерергә уйлыйсыз инде?

Булачак бабасының сүз сөрешен Шөреп аңламады. Регина пырхылдап учына көлде. Әтисенең җитди итеп кылануы аңа кызык тоелды. Менә кайда ул кино! Билетка акча әрәм итеп йөрисе дә юк.

— Торырга урыныгыз бармы, диюем.

— Арендага алган бер бүлмәле квартирам бар. Ике ел торып була әле анда. Аннан берәр җае чыгар.

Өстәл әзерләп йөрсә дә, колакларын бу якта калдырган ана янәдән йөгереп чыкты:

— Кызымны беркая да җибәрмим. Үз янымда торачаклар. Оныкларымны багасым килә...

Регина янә көлеп җибәрде.

Җәүдәт Габдулловичның ачуы чыгырыннан ташып чыкса да, түзде, өстен алыштырган булып, вакытны суздьı.

Кыз хаклы иде. Милициядә хезмәт иткән ирнең өендә — хатыны тулы хуҗа.

Эшендә ул теләсә ничек сүгенергә, кемнедер әрләргә, тукмарга, ялгыз камерага ябып куярга мөмкин. Ә өендә ул бөтенләй башка кеше. Мүкләнгән күл суыннан да тыныч тота ул үзен хатыны янында. Пенсиягә якынлашкан саен, аның хәләл җефетенә буйсынуы арта гына бара.

Фирка аппаратында, хакимият оешмаларында эшләүчеләрнең хатыннарына игътибар көчле. Теләсә нинди маяк уты — шикаять күтәп алына. Шуның аркасында юкка чыккан гаярь егетләр җитәрлек. Бу тәртип иң өстә утыручыларга гына карамый. Ирен бу кәнәфидән ычкындырсалар, үзенә ни буласын яхшы чамалый ханымнар. Шуны аңларлык кына акыл була зиннәтле, кайгы-хәсрәтсез хәятка өйрәнгән баш миендә.

Урта кул түрәгә хатыны белән бил алышу файдасыз, тигезлек таләп итү — чеп-чи тилелек, ахмаклык. Әнә, аерылып карады бит Сәет. Алдан күрмәмешкә салындылар, ике ел узгач, ире инде Рушаниянең түсен, килеш-килбәтен, фигылен оныта язгач, исенә төшереп, эшеннән куарга сылтау таптылар.

Милиция әһеле, онытылып китеп, хатынына катырак кагылса, соңгысы бу хакта, шуны гына көтеп утырган нәчальствога җиткерсә, ул чираттагы йолдыздан колак кагарга һәм пенсиясез калырга мөмкин. Дан һәм олы акча белән ялга чыккач яисә халык хуҗалыгына эшкә күчкәч, хатыннан үчне алырга хыялланып яшәүчеләр аз түгел милиция сафында. Мәгәр мүкләк сыерга мөгез үсми. Буйсынырга, тыңларга, үтәргә күнеккән килеш адәм баласы теге дөньяга китеп бара. Ир икәнен оныткан ир ирексез булыр, ди халык.

Җәүдәтнең хатынына каршы сүз катмавы аңлашылса булыр.
— Үзегез карагыз,— дип күрше бүлмәгә кереп китте.
Соңыннан Шөрепнең урка гына түгел, кеше үтерүче икәнлеге дә ачылгач, Регина белән тормышлары барып чыкмагач, барыбер Җәүдәт гаепле булып калды.
— Син аның кем икәнен танырга тиеш идең. Гомерең буенча бандитлар белән эшлисең. Сөйләшергә теләмәдең. Үз җаең кестәктә,— дип, хәләл җефете бик нык әрләде аны. Милиционер хатыны гел хаклы.
Шөреп аны картайтты, вакытыннан алдан пенсиягә озатты.

## 16

Җепшек кышның эчпошыргыч яңгырлы көне. Һавалар хәзер базар бәяләре кебек. Кыш дип зурлап тун киеп чыксаң, яңгырга тап булып киемне әрәм итәсең, чиллә җитте, дип алданып, кыска җиңле күлмәк элсәң, ычкынганмы әллә теге абзый, дип тәртеп күрсәтәләр. Сөякләрне туңдырып үтәли җил исә җәй айларында.
Мондый вакытта конторада кәгазьләр караштырып утыру хәерле. Шуның өстенә, шәһәрнең иң абруйлы авторитеты Ваһапов сәгать унга килеп чыгарга рөхсәт сорады. Килүенең серен әлегә белми Сәет.
Полиэтилен белән күпме кеше баеды, күпмесе шунда пычранып, төрмә ишеген шакымыйча керде. Табкушылма урнашкан төбәкнең ярты милициясен утыртып бетерделәр. Шунда кул җылытучы Нургали җәтмәгә эләкми, шуып чыга. Тугыз баллы штормда да кыя төсле, җил-яңгырга күкрәген куеп тора бирә. Дөрес, ул үзе җил төсле. Дөньяның астын-өстә китерергә, зил-зилә куптарырга мөмкин. Ә үзен аның тотып алу түгел, күреп тә булмый.
Ваһапов элек Казан заводларының берсендә эшли. Берәүгә дә тәлинкә тотмыйча, коммунистларны мактап сәхнәдән нәгъррәләр ормыйча, сасы цехның һавасын иснәп, җае белән яши бирә. Үз вакыты сукканны әллә ничәнче тоемы белән сизеп ала һәм рәсми эштән китеп, берничә яраннарыннан гына торган кече предприятие ача. Кая нәрсә ятканны, кемгә сатасын, кемнең кесәсенә ни куясын, кайсы түрәне майлыйсын яхшы белә. Мәче мыегы ялгышмый. Нургали тиз арада шәбәйде. Шәме каты җилдә дә сүнми торган хәлгә килде.
Хөкүмәт һәм халык малы, тота белсәң, күпләргә җитә ул. Әнә әзербайҗан егете Чаллыда күргән-белгән татар мөкиббән китеп сөйли торган, полиэтиленнан әйберләр ясау буенча менә дигән завод салды. Чималны Казаннан ташый, табыш малын туган иленә озата тора.
Нургали Ваһапов исә туган халкына хезмәт итә. Үзе белгәнчә...
Малны, акчаны саный белүе, хәтта комсызлыкка барып җиткән кысынкылыгы коткара, диләр үзен. Аңа карата «саранның башына байлыгы җиткән» мәкале туры килми. Аннан килеп, бөтенесенә юмарт булып кына, оҗмахка юл ярып булмый. Үзе белә торгандыр. Бусы — ташыган чиләктән түгелгән су гына. Гайбәт чүпрәсе.
Китне көтеп утырганда, бүлмәгә Фердинанд бәреп керде. Гадәтенчә, ашыга, кабалана, тотлыга.
— Күңелсез яңалыклар атькє келим, Сәет Яруллович,— диде ул, кул биреп.
Фердинанд — «Игелек»тә иң кызыклы шәхесләрнең берсе. Яше кырыкка җитеп килә. Чем кара чәчләрен урыны белән кырау уртлаган. Холкы — берсе алга чыгып, икенчесе бөкерәеп эчкә баткан тешләре кебек каршылыклы. Әйтерсең лә табигать Фердинандны яратканда берсе икенчесен юкка чыгарган, капма-каршы торган сыекчаларны бер казанга салып кайнаткан.
Аның башы һәркайчан хыялый, гамәли, тормышчан һәм буш хыяллар белән тулган булыр. Өметен, фикерен үзендә тотмый, хезмәттәш-

ләре, фикердәшләре белән иркенләп бүлешә. Чөнки ниятләренең күбесе уйдырма, үтәлми торган булып чыга.

Үтә ярсып, бер шөгыльгә алына да, хатыны яисә башка кеше рәвешендә берәресе читтән төртеп тормаса, суына, бөтенләй ташлый, шул мизгелдә үк янасын башлый. Гомер буена ике яклы үткен пычак өстеннән йөреп, шактый четерекле эшләрдә катнашса да, чынында куркак кеше. Сәет кебек көчле арка тәрәген тоеп яшәү кирәк аңа.

Фердинанд җил-давыл булып бүлмәгә үтүгә, Сәет кечтеки бер вакыйганы исенә төшереп, ирен кырыйлары белән генә елмаеп алды. Кичләрнең берсендә Фердинанд Сакмановның өенә шалтырата.

— Эшләр шәп түгел әле, Сәет Яруллович.

— Кем рәнҗетә?

— Милициягә чакыру килгән, дир.

— Кайчанга?

— Берсекөнгә, сәгать унга. Үзем үдә юк идем. Хатын, дура, кул куеп алып калган. Бармаскамы әллә? Командировкага китте, дир атьерләр.

— Алай житди булмый инде ул, Фердинанд. Кирәк булса, милиция барыбер эзләп табачак,— диде Сәет тыныч кына.— Нәрсә өчен дип уйлыйсың?

— Бер малайга Бөгелмә ягы совхозыннан коры сөт алырга паспортымны һәм доверенность биргән идем. Ул егетләрнең башка эш өчен, артларына төшкәннәр, дир. Шуның буенча чакырмыйлар микән?

— Нишләп әле син теләсә кемгә документлар бирәсең? Бу — минем өчен яңалык,— дип бик нык ачуланды Сакманов үзен.

— Бик зур хата эшләдем дир, Сәет Яруллович. Гафу итәрсез инде, больше кабатламам. Сездән башка ярдәм сорар кешем дә юк,— дип, салпы якка бер учма салам кыстырып куйды.

Ярдәм итми кая барасың. Подполковник Салих Гаяров белән сөйләшеп, теге шактый майлап-җайлап, мәсьәләне зурга җибәрмәде.

Тагын нәрсәдер булган, димәк. Дөрес, Фердинандның чебеннән фил ясый торган гадәте бар. Житди әйбер булуы да ихтимал. Бәла, төн пәрие кебек, әдәм баласын сагалап кына йөри.

— Мансур безгә каршы бик каты эш алып бара,— диде Фердинанд. Минем белән сүләшми дә...— Әйе, «Игелек» һәм аның хуҗасы белән араны кискен рәвештә өзеп бара элеккеге официант.— Нәрсә әйтергә дә белмим, абдыраган, Сәет Яруллович. Мансур юл бирге келәми,— дип дәвам итте сүзен Нигъмәтҗанов.

Чуаштанда туып-үскән егет дулкынланганда, борчылганда мишәрчәгә кереп китә. Бүген аның кирәгеннән артык каударлануына игътибар итте Сәет. Шаяртып карарга булды:

— Марҗаң янына йөри башлаганмы әллә?

— Юк ла! Анысына түзеп булыр иде.

— Соң нәрсә?

— Мин касы сөт заводына, шул әрбир белән эш итүче колхоз-совхозга барып чыксам, ул шунда... Кемдер минем графикны аңа алдан атьеп куйган да, ул минем нурлы йөзне күрергә махсус шунда төшеп тора диярсең.

— Сөт аламы?

— Ниндидер кәгазьләр тотып йөргән була. Беренче очрашуларда өстән-аска карап, миңа бик зур изгелек кылган кеше кебек, исәнләшә иде дир. Соңгы вакытта күрмәмешкә салыша башлады. Мин трест управляющиеның кабул итү бүлмәсендә көтеп утырам. Ул килеп тә керде, кереп тә китте. Мине кабул итмәде, кәгазьләремә кул куймады теге чукынчыгы.

— Димәк, син бугазларына сөяк булып кадалгансың. Сак бул, Фердинанд, сөтсез яшәрбез, синсез дөнья сансыз булыр!

Чыгып китәргә җыенган Нигъмәтҗанов янә урындыкка сеңде.

— Тагын бер нәрсәне атькем кели дир, Мансур үзенә яңа «крыша» тапкан. Элеккеге сакчыларына расчет биргән.

— Кем инде аның яңа түшәме.

— Сез аны белмисез дир. Бик явыз адәм. Андрей Северцев.

Сәет сискәнеп киткәнен сизми дә калды. Умыртка баганасына резина таяк белән китереп тондырдылар диярсең. Башы умарта күчедәй гөжләп китте. Чыннан да, дөнья куласа, бер әйләнә, бер баса дигәннәре дөрес икән шул.

Фердинанд Мансурның «түшәменә» бәя бирүен дәвам иттерде.

— Ул тяп-ляп төркеменең элеккеге хуҗасы дир. Утырып кайтты. Биш ел тирәсе. Кайсыдыр поселокта үскән. Караклар дөньясы белән связьлары зур дир. Үзенә элекке дусларыннан, яшь рокерлардан яңа төркем корган. Имансызлар, явызлар.

— Сакласыннар Мансурны көне-төне,— дигән булды Сәет, йөрәген озын тырнаклы кара мәче таласа да.

Фердинанд болай да борчулы, әсәренгән, аңа Северцев белән «танышлыгын» сөйләсә, бөтенләй коелып төшәр. Егетнең куркырга һәвәслеген белә...

— Безгә аның белән очрашырга туры килмәгәе... Мансур шундыйрак политика алып бара. Кеше канын агызуны чебен үтерүгә дә санамаган тяп-ляп калдыкларын яллавы хәерлегә тегел дир.

Фердинанд белән эш бүлмәсендә соңгы күрешүе булып чыкты Сәетнең. Дөрес, телефон аша берничә кабат аралашып алдылар эш буенча. «Игелек»нең үсешенә шактый өлеш керткән, үзенчәлекле мишәр егетенең кәефе начар иде. Адәм баласы киләчәген сизенә, күрәсең.

Фердинандтан соң Ваһапов килеп керде. Сары тут йөзле, чалара башласа да төсен җуймаган, тырпаеп торган кара чәчле, таза гәүдәле, олы куллы, иллеләр уртасындагы Нургали бүлмәгә хуҗаларча атлап керде.

— Нихәл, братишка,— дип, күптәнге танышыдай кочаклап күреште. Үзеннән бер кая да калдырмый торган җирән чәчле, усал күзле җан сакчысы да кереп утырды почмакка.

— Аңа игътибар итмә! Немецмы, яһүдме малае, татарча белми ул,— дип аңлатты кунак.

Тынгысыз адәм икән. Аркасы, җилкәсе гел уйнап тора. Өстәлдәге карандашны кулына алып, тәгәрәтә, әйләндерә, тугландыра башлады. Караваево, Соцгород якларының рәсми булмаган хуҗасын Сәет ниндидер банкетта очраткан иде. Якыннан танышканнары булмады. Нәрсә китерде шундый атаклы кешене аның офисына?

— Эшләр барамы соң?—дип сораган булды Сәет, сүзне ялгап китү өчен генә.

— Начар, братишка, һәр яктан налоглар белән китереп кыстылар.— Кое төбедәй тирән утырган күзләрен кыса төшеп, өстәп куйды:

— Ходай тәгалә мәрхәмәтеннән ташламый. Ипи, тозлык биреп тора. Минем, браток, сиңа йомыш төште.

— Тыңлыйм сезне, Нургали әфәнде.

Әтисенең исемен белми иде. «Әфәнде» сүзен кит йотып җибәрде. Игътибар итмәде. Энәләрен тырпайтмады. Өстәл аша иелеп, колагына якынлашты:

— Яхшы мылтык кирәк миңа, беләсеңме, браток.

Сәет башын җүләргә салырга булды. Астан чеметтереп алды.

— Сездә туплары, пулеметлары тулып ята торгандыр әле. Шәхси самолетыгыз очып китәргә әзер тора, дип ишеткән идем озын колаклардан.

Чыраен сыткан булса да, кит канәгать иде, Сәетнең кинаясен игътибар бөҗрасына алмады. Түбән агымнарны, вак-төяк йомрыларны кабул итми бу кеше.

— Миңа «Тигр» атлы мылтык-винтовка кирәк. Икәү. Берсе—үземә. Икенчесен бик сораганнар иде. Отказ бирә алмадым. Вәгъдә дә бирмәдем. Тырышырмын, дидем.

Төсле карандашны өчкә сындырып, өстәде:

— Тормыш ул, браток, кырыкка бөгә.
— Мин бит урындык, көрәк, бишек, сәндерә ясыйм. Корал заводым юк.
Нургали карандаш кисәкләрен шома өстәлгә ташлап, кычкырып көлеп җибәрде. Көченә, абруена инанган хуҗаларча, өстәп куйды:
— Бәясендә тормам. Бер машина полиэтилен дисеңме... Мәгъшукаң ничәү? Теләсәң, Наташа белән түли алам.
— Сез аларны үзегездә әзерлисезме? Наташаларны диюем...
— Әзерләмибез, ясыйбыз, браток.
Тавышы көчле, әмма ничектер майламаган ишек, көйләнмәгән уен коралын хәтерләтеп, шыгырдап, калтыранып чыга.
Сәет диван, өстәл, суыткыч һәм сейфлар урнашкан күрше бүлмәгә үтте. Кире чыкканда кулында кыска матур күн капчык-футляр иде.
— Миннән бер истәлек. Бу системаның соңгы казанышы. Икенчесе — теге атнада,— диде Сәет.
Ваһапов һәдияне саклык белән кулына алды. Җирән җан сакчысына тоттырды. Бумажнигын чыгарды.
— Күпме кирәк? Доллар белән түлимме?
— Мине аңламадыгыз. Безнең очрашу турында бер истәлек булсын. Киләчәктә дә күрешеп, бер-беребезгә ярдәм итеп яшәргә насыйп булсын. Фани дөньяда бер тапкыр яшибез!
Соңгы җөмләләре бераз күтәренкерәк чыкса да, Сәет ваклашмыйча, акча яисә башка нәрсә алмыйча, шул юлны сайларга башы җитүдән канәгать иде. Ваһаповның саранлыгыннан да, шундыйрак рухтагы бүләк алырга яратуыннан да хәбәрдар иде Сәет. Яхшылыкны беркайчан онытмый, дигән хәбәр дә саескан койрыгында килеп ирешкән иде аңа.
Ваһапов түшәмне калтыратып янә бер көлде дә киң кулын сузды:
— Рәхмәт, браток. Бурычлы калмам. Теләсә нинди эш белән мөрәҗәгать ит. Югары Советка депутат буласың киләме? Теләсәң, әйт!.. Ярый, җирәнкәем, киттек. Сәгать унбергә Камбинга сугылырга вәгъдә иткән идем.
Сәетне гади генә итеп кочагына алды да, чыгып та китте.
Хуҗа лып итеп кәнәфиенә сеңде: «Вампир икән, мылтыкны гына түгел, хәлне дә суырды».
Әмма шул вакыйгадан соң Ваһапов үз канаты астына алды аны. Хәтәр сынау вакытларында гел ярдәмгә килә торган булды.
Фердинандның борчылуы юкка гына булмаган икән. Мансур элеккеге хезмәттәшләре, коммерция эшен бергә башлаган якыннары белән араны кискенләштерү аша өзүгә алып барып, Сакмановны бергә корган, шактый байлыгы булган оешманы тотучылар исемлегеннән сызып ташлый. Димәк, бергә әзерләгән савым сыердан читләштерә. Бу тискәрелек, ахмак кирелек вә зур этлек иде.
Нәтиҗә белән ашыкмыйча, күзгә-күз терәшеп, аңлашып, сөйләшеп карарга булды «Игелек» хуҗасы.
Әүвәл теге төрле сылтаулар табып, очрашуны кичектерергә, булдырмаска мәтәште. Сәеттән котылу җиңел түгел иде анысы. Эзләп тапты. Мәгәр кырык яшьлек ирләр аңлашуы килеп чыкмады.
— Мансур Маулетович, мин сине аңламый башладым.
— Нәрсәне аңламыйсың, сора?
— Минем белән очрашудан тайчынасың. Качышлы уйнаган балачага төсле кыланасың. Мин дүрт дистәне вакладым, иншалла, син дә шул тирәгә үрмәлисең. Үзебезне солиднорак тотарга кирәк кебек. Бер-беребезне яхшы беләбез кебек. Утны-суны бергә кичтек, җиз торбасыннан да чыктык.
— Менә бит, килдем очрашуга. Миңа ни претензияң бар?
— Ни өчен мине бергә корган уртак АОның учредителеннән төшереп калдырдың?
— Кем әйтте?

— Киләсе ел өчен төзеп, исполкомга тапшырган кәгазегезне очраклы рәвештә күрдем. Күзләрем шар булды. Сакманов урынын Голубин алган.

— Ул — безнең яңа крыша һәм арадашчыбыз. Ә син анда булырга тиеш. Соңгы мәртәбәсендә Альберт караган иде.

— Алдашма, мин аның белән сөйләштем,— дип кырт кисте Сәет.

Почмакка китереп кысылган Мансур чыгынкы маңгаена бәреп чыккан тирне учы белән сөртеп алды. Тирәндә утырган соры күзләреннән бәс салкынлыгы бөркелә. Күзләр тирли белми, тозлы су гына коя ала.

Гәүдә ягыннан тазарак булса да, сугыш чукмары Сакмановтан курка иде ул. Турысын ярып салырга кыюлыгы җитмәде. Төлке хәйләкәрлеген дә булдыра алмады.

— Соң ни, Сәет Яруллович, компьютер төшереп калдыргандыр. Кертербез!

— Компьютерың бик акыллы икән! Кемгә нинди мөнәсәбәтеңне белеп тора. Яраткан кешеңне кертә, кирәге беткәннәрне сызып атамы?

— Алай ук югары тонда сөйләшү кирәкмәс. Безнең дуслык шунда гына кайтып калырга тиеш түгелдер?

Астыртын ниятен ачудан көйрәп янган күзләре сатып тора.

— Дуслык ул зур нәрсә. Аны сатып була. Әмма, хәтер капчыгыңа салып куй, сатып алып булмый!

Мансур, шөбһәгә төшеп, җилкәләрен сикертеп, киеренкелек бозын ватарга тырышып караса да, Сәет сүзне артык куертып торуны кирәк тапмады. Кара өстәлгә кәгазь ташлады.

— Банкта минем яңа счет. Минем өлешне тиенен тиенгә китереп күчер. Соңыннан үпкәләштән булмасын!

Яңа «крыша» һәм дуслар тапкан, югары кланда таныш-белешләр булдырган Мансур, арка терәгенә ышанып, Сәетне исемлеккә кире кертмәде, акчасын күчермәде. Үз өлешенә тиешле берничә дистә миллионга Сәетнең исе китми. Аның белән генә баемасын да, хәер эстәргә чыкмасын да белә иде ул.

Эш башкада. Ышанычлы шымчылары хәбәр итүенчә, аны читкә тибәргән оешма аша Украинага шикәргә берничә миллиард акча күчерергә җыеналар. Сумманы дәүләт бирәчәк икән. Бу уеннан майлы калҗаның зур өлеше арадашчы акционерлык җәмгыятенә төшәчәген Сәет яхшы аңлады. Артык авыз, артык шаһит булмасын дип, аны уеннан төшереп калдырганнар...

Сәетнең фаразы пәйгамбәрләрчә булды. Чөгендер шикәрен эзләп, чит илгә чыгып киткән татар акчасы әллә кайларда адашып калды. Дөресе, адашмады, алдан уйланылганча, тиешле кесәләргә кереп урнашты. Шикәр төягән вагоннар исә Казанга килеп җитмәде.

Яман эшнең сасысы чыкмыйча калмый. Озын колак белән озын телләрне тынычландыру өчен бер «винтик»ны — база мөдирен берничә айга утыртып чыгарган булдылар. Зинданнан ул тагын да матураеп, тазарып чыкты. Җәмәгатьчелекнең дикъкатен грек хәлвәсенә, венгр күркәсенә, испан коньягына юнәлтеп, мәсьәләне яптылар.

Тик бу зур өлештән Сәетнең генә мыегы чыланмый калды. Үпкәләде, рәнҗеде элеккеге дусларына. Гафу итә, кичерә алмасын аңлады..

## 17

Сәет өй кешесе булып киткәнен сизми дә калды. Җанының колы — аягы гел шул якка каера. Йөрәк парәсе, студенткасы — Зөлфия шунда яши хәзер. Бай җиһазлы булса да, аңа фатиры шыксыз, ямьсез күренә иде. Хәзер бөтенләй үзгә әхвәл.

Авылга кайтып хур булгач, әнисе өстән төшерелгән күрсәтмәне үтәп, тырт-пырт кына сөйләшүеннән кәефе кырылган иде. Зөлфиянең җаны-

тәне белән аңа бирелүен, ярарга тырышуын күреп, аңлап, сизеп, барысына да кул селтәде.

Зөлфия — аның бүгенгесе, өмете, киләчәге. Чибәр кыз аны ярата бугай. Мавыгуы узмасмы? Балалары булса, өйгә үзе хуҗабикә булып алып, гаилә мәшәкатьләрен дә бүлешсә, беркая да китмәс. Ир үзе дә Зөлфияне рәнҗетмәскә тырышыр. Бусы — аның үзеннән, дөресрәге, икесеннән дә тора.

Башка яссылыктагы бер уй аның күңелен көйдереп, җанын бимазалап тора. Аларга яшәргә бирерләрме? Көнлекче көнчеләр күбәйгән замана. Сәетнең яши-яши дуслары сирәгәя, дошманнары арта баруы да табигый иде. Яшәү өчен гел көрәшергә, кемнедер юлдан алып ташларга туры килә. Әгәр шул явызлык, үч Зөлфияне сайласа? Тәне буйлап гасабилы калтырану узды. Тизрәк бусаганы узып, Зөлфияне кочагына аласы килде.

Аның янында барысы да онытыла, хатынының кайнар тәне, татлы сүзләре, дымлы ирене генә кала.

Зөлфия Сәетне көннән-көн ныграк ярата, кешелек сыйфатларын тирәнрәк аңлый, бәяли бара. Ул аны бик күптәннән, үзе тугачны ук белгәндер дигән хис яши аның күңелендә. Сәеткә күңеле эчке җанлы җепләр белән ныграк бәйләнгән саен, аның турында күбрәк беләсе килүе дә табигый ихтыяҗ иде.

— Сәетҗан, үзең, үткәнең турында сөйлә әле. Минем барысын да беләсем, тавышыңны тыңлап утырасым килә.

— Чалбарны үтүкләп бир дигәч, вакытым юк, иртәгә зачет дип котылдың. Мине сөйләтергә араң бар. Әһә, аңыштым...

Сәет яшьләр җәһәтлеге белән урыныннан сикереп торып, уң кулының күрсәткеч бармагын өскә күтәрде.

— Иртәгә мәдәният институтында минем биографиядән зачет икән. Шалтырат группадаш кызларыңа — килеп тыңласыннар. Ялан-ялан кабатлап тора алмам.

— Ну, Сәет. Шаяртма инде. Сөйләмәсәң, чалбарыңа икешәр сыр ясап бирәм, бер балагын кыскартам.

— Сырның мин бер төрен генә, голланд бабайлар ясаганын гына яратам шул, матурым. Үткәнне искә алмыйм инде, онытыйк! Ул бит бер яклы урам, аның буйлап кире кайтып булмый. Узып киттең, бетте.

Зөлфия Сәет белән килешмәде, хатын-кызларча үҗәтләнде, шәхси тормышы турында күбрәк сөйләвен сорады, үтенде, ялварды. Әлеге ир кавеме белән шактый аралашса да, әш кешесе буларак, рухи халәт нечкәлекләренә керешеп-нитеп тормаган Сәет чибәр затларны кайсыдыр яссылыкларда аңлап җиткерми иде.

Чынында, адәм баласына тук тормыш, затлы кием, биек түшәмле, кайнар сулы иркен бүлмәләр янына кимендә тагын бер нәрсә — рухи таяныч, якыныңа охшашлык кирәк. Зөлфия дә Сәетнең тормыш мәҗмугасы белән күбрәк шул яктан килеп кызыксына. Ул — аның иң яраткан, иң кадерле хатынымы? Киләчәк хаяте өчен ышанычлымы аның ире?

— Сәетҗан, сизеп торам, сине Рушанияң бик рәнҗеткән, иеме? Мин алай итмәм, йәме?

Күп бел, аз сөйлә, дигән бер акыллысы. Күңелендә сөенечле һәм көенечле төерләр булып утырып калган вакыйгаларның барыбер бик азын бәян итте ул Зөлфиясенә.

Рушанияне искә алды әнә. Аның белән беренче очрашулары, сөешеп яшәүләре, аннан авыр, ямьсез, чырайсыз аерылышулары һаман күз алдында. Ничек аның барысын да сөйлисең? Зөлфиянең кочагында эрегән ире хакында күбрәк беләсе килүе дә кешеләрчә аңлашыла. Әнә дымлы иреннәрен сабыйларча турсайтып, чын-чынлап үпкәләргә җыена. Сәет хатынын янына утыртты, алдан бер кисәтү ясап, сөйләп китте:

— Син, матурым, беркайчан да үпкәләргә тырышма. Файдалы әйбер түгел ул. Тиз картайта, дошманны яшәртә. Тәк вот. Тәтеш районында туып-үскәнемне, ике абыем, бер сеңелем барын беләсең. Аларын күргәнең бар. Әти-әнинең кара җир астында икәнлеге дә сиңа мәгълүм.

— Ничек хәрби булып киттең?

— Унынчыны бетергәч, бер ел тракторист ярдәмчесе булып эшләдем. Элеккеге заманнар булса, күкрәккә сугып, мактанып йөрер идем. Колхозның комсомол оешмасы секретаре итеп сайлап куйдылар. Яратып, җанымны, бөтен барлыгымны биреп эшләдем. Армиягә китәргә чират җитте. Комсомол җитәкчесенә привилегия бар икән. Мәскәү белән Ленинградтан кала, теләсә кайсы хәрби училищены сайла, диделәр. Үзләре исә Симферопольнең хәрби-сәяси югары мәктәбен тәкъдим иттеләр. Абруе зур. Кырымда урнашкан, умач белән бәрәңгедән туйгансың, анда гарык булганчы җиләк-җимеш ашарсың, дип тә өстәделәр.

Тәртип өчен генә керү имтиханнары алган булдылар. Укып киттем. Татар мәктәбен бетергән малайга беренче елны кыенрак булса да, иптәшләремне бик тиз куып җиттем һәм «диплом с отличием» алып, чак-чак кына Мәскәү хәрби академиясенә эләкми калдым. Шунда бер ЧП килеп чыкмасынмы!

— Татар булганың өчен җибәрмәгәннәрдер әле?

— Анысы да үз өлешен кертkәндер. «Сәяси сукырлыгым» өчен яндым.

— Ул нидән гыйбарәт булды инде? Минем дә тиздән дәүләт имтиханы бирәсем бар.

— Хәзер заманалар үзгә. Фикер иркенлеге чоры килде. Телеңә ни килсә, шуны такылда. Дәүләт сынавында миңа Икенче Бөтендөнья сугышының соңгы чорын бәяләргә кирәк иде. Данлыклы совет армиясенең хәрби көче, даны үсүе, фашизмны юкка чыгаруга керткән бәяләп бетергесез өлеше белән беррәттән, соңгы ике елда бик күп хаталар да ясалды, дидем.

Йокымсырап, эсседән әлсерәп утырган дәүләт комиссиясе әгъзалары, борча тешләгәндәй, уянып киттеләр:

— Нindирәк хаталар инде алар?

Мин, әлбәттә, шома гына җавап бирә алган булыр идем. Ул вакытта инде шәхес культы фаш ителгән. Шуңа киная ясарга мөмкин иде. Чабудан шайтан тартты. «Без белем алып яткан шәһәрдә бу илнең төп халкы — Кырым татарлары яшәргә тиеш, аларны тарихи үз җирләренә кайтарырга вакыт», дип сөйләп китмәсенме абзаң. Комиссия рәисе, як-якка салынып төшкән озын мыеклы генерал Куропатенко, миңа өстәл сугып кычкырды:

— Без монда белиберда тыңларга җыенмадык. Чыгып китегез! — диде.

Имтихан беткәч, мине чакырып кертеп, чиратлашып вәгазь укыдылар. Сәяси яктан начар әзерләгән өчен берничә укытучыга шелтә эләкте.

Бик авыр кичердем мин бу вакыйганы. Өч көн бик начар йокладым. Курсантлар минем белән исәнләшми, күрмәмешкә салыша башладылар. Төшемдә әнине күрдем: тирә-якта кояш яктысы, чиккән күлмәктән түшәктә утыра әнкәй һәм мине үз янына чакыра. Аягымны күтәрә алмыйм, әллә ничәшәр потлы гер асканнар диярсең, үрмәләп тә бара алмыйм. Иртән телеграмма алдым, әниеңне фәлән-фәлән көнне күмдек, инде кайтып йөрмә, дигәннәр. Мин Кырым татарларына азатлык даулап йөргән көнне әнием фани дөньяны ташлап киткән икән.

Инде бишенче көн дигәндә, урамга чыктым. Бөтен тәнемдә бушлык. Башыма киледә төялгән пыяла, аякларыма дыңгычлап арыш саламы тутырганнар диярсең! Йортлар күчеп йөри, кешеләр аяклары белән һаваны кисеп, башларында тырк-тырк сикереп йөриләр. Җаным, зиһенем агачларны, машиналарны, кешеләрне күнегелгән, өйрәнелгән мәгънәдә кабул итүдән ерагайган иде. Дөнья миннән башка яши алмый, ул минем кабул итүемдә генә бар, дигән фикер миемне бораулый. Зәгыйфьләнгән аңым, гариплəнгән йөрәгем аларны кабул итми. Димәк, бүген кешелек яшәешеннән туктаячак. Үлем, мәңгелек, җир шары — барысы да минем теләккә бәйле. Мин акылдан язып, ычкынып баруымны аңладым.

Гимнастерка кесәсеннән булавка алып, кулыма, аягыма чәнчеп карыйм, канга охшаган кызгылт сыекча бәреп чыга, авырту сизелми. Ничек итеп барысын да онытырга, әни янына китәргә? Башка чара уйлап таба алмагач, кафега кереп, ике стакан тутырып ак аракы эчтем. Урамга чыгып, эскәмиягә утырганымны хәтерлим... Башкасы хәятнең теге ягында калды.

Икенче көнне иркен диванда уянып киттем. Ап-ак түшәм. Мин кая? Кем белән? Казармада кунарга тиешле кеше бит мин.

— Курсантик, уяндыңмы? Хәзер чәйләрбез.

— Сез кем? Мин кайда?

— Исемем минем Марина. Марина Сергеевна.

— Ничек мин сезгә килеп эләктем?

Күтәрелеп карыйм. Яшь, чибәр ханым. Коньяк кешеләре өчен табигый тазалык, тулылык, муллык бөтен тәнендә. Аксыл чәчләре тәлгәшләрдәй салынып төшкән. Яныма утырып, сөйләп китте:

— Кичке сменадан өйгә кайтып барышым иде. Күрәм: эскәмиядә башын артка ташлаган курсант утыра. Йөзе мамыктан ак. Җан әсәре күренми. Мин үзем медсестра. Үлгән дип торам. Пульсыңны көчкә эзләп таптым. Колагыңа кычкырып, төрткәләп уятып карыйм. Файдасыз. Шунда патруль килеп чыкмасынмы! Исерек икәнеңне аңлаган идем. «Миңа кем ул, чәнчелеп китсен», дип уйларга да мөмкин иде. Соңгы мизгелдә кызганып куйдым: яшь, чибәр егет, әрәм була.

— Сез кем буласыз? — ди офицер.

Телемнән «хатыны» дигән сүз ычкынганны сизми дә калдым. Ялганны дәвам итәсе калды.

— Минем бүген туган көнем иде. Әзрәк кунак булдык. Ял иттерәм дә, аннары казармага илтеп куям.

— Исеме ничек? — ди бу мине тикшерепме, тәртип өчен генәме. Телгә килгән беренче исемне әйттем: — Саша.

Кесәңә тыгылып курсантлык кенәгәңне алды.

— «Саит Сакманов. Курсант пятого курса Симферопольского военного-политического училища», дип укый бу.

— Аның исеме Саша түгел ич, — ди.

С хәрефе килеп чыккач, илләм шатландым. Саит — урысча Саша, Александр була инде ул, дим. Тиз генә өйрәнеп булмый аларның исеменә дип, сиптерәм генә буш сүзләрне.

— Милләте буенча кем ул? — дип төпченә нидер сизенгән капитан, арт аягын эт алгыры. Уйлап торырга вакыт юк. Исем, фамилияң буенча славян түгеллегеңне чамаладым.

— Мөселман милләтеннән, — дим.

— Андый милләт юк.

Мин шунда өлгергән карбыз кебек шартладым. Сезнең миннән допрос алырга ни хакыгыз бар? Ирем белән сөйләшеп, һава сулап утырырга да ирек бирмисез. Хәрбиләрне китереп тутырдылар. Эшсезлектән интегәсез, дип тузынып тузынам. Патруль шыпын-шыпын ычкыну ягын карый. Юк, мин әйтәм, болай килешми. Миңа иремне өйгә алып кайтырга булышыгыз. Бер солдатыгызны бирегез.

Шунда патрульнең шәһәрдә йөрергә рөхсәт кәгазен — увольнительниеңне сорарга башына килде. Бер ялган икенчесен тартып чыгарып кына тора икән: «Кәгазь минем квартирада калды», дим. Күзне дә йоммыйм. Үзем шөллим: ияреп кайтып, рөхсәтне таптырсалар? Курсантны лаякыл булганчы эчерткән, гомумән, якын кешем дип ялганлаган өчен үземне дә алып китәргә мөмкин иделәр. Яманны да, яхшыны да бер үк кояш яктырта бит. Болытлар җиңел таралды. Бәхетле бала икәнсең. Иң гаҗәбе шул: капитан миңа ышанды, сине китереп куешырга бер солдатын да бирде. Үзем чишендереп яткырдым.

Хатын мине чәй эчереп, киемнәремне чистартып озатканда, әйтеп куйды: «Бүген минем чынлап та туган көнем. Килә алсаң, көтәм. Берәүне дә чакырмыйм. Кичәге кебек күп эчмәбез».

Урамга чыктым. Күңел болгана, баш авырта. Әмма дөнья үз урынына кайткан. Аракымы, соры чәчле, зәңгәр күзле, тулы гәүдәле хатынмы, төнге патрульме, әллә барысы бергәме — мине акылдан язудан коткарып калганнар. Вакыт узган саен ул хәлләрнең сурәте тагын да камилләшә, әмма тормышчан эчтәлеген югалта бара. Кайвакыт, болар барысы да минем белән булган могҗизалармы соң, дип тә уйлап куям.

Сәетне Зөлфия, авызын ачып, тирән суларга да куркып тыңлап утыра. Яртылаш кочагыннан чыкты да сорап куйды:

— Син ул хатын янына тагын бардыңмы?

— Сары йорттан, психбольницадан коткарып калган кешене болай гына ташлый алмадым. Мин аңа рәхмәтле идем. Аның мине ошатуын, бергә яшәү турындагы тәкъдимен, тәгъдирдә шулай язылгандыр, дип кабул иттем: ярты ел гына бергә торып калдык.

Сәет Марина белән бик тату, яратышып, сөешеп көн итүләре, коньяк дәртенең эссе мич шикелле, яндырып-яндырып алуын, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрнең могҗизалы серләренә шунда өйрәнүен, аның назлы кочагын, олы күкрәген һаман да онытмавын сөйләмнән төшереп калдыруны мәхкуль күрде. Баланың күңеле кителмәсен. Көнчелек кыңгыравы хәзердән уянмасын.

— Иң яхшы укучылардан берсе булган курсантка көчкә-көчкә диплом бирделәр. Юнәлеш — бары тик тугандаш Манголстан. «Өчле»гә укып, азып-тузып, башы сыра подвалыннан чыкмаган малайларга хезмәт итү урынын сайлап алырга мөмкинлек бар. Ә миңа — ярамый. Шунда безнең илдә дөресен сөйләгән, хакыйкатьне ярып салган кешегә яшәү юклыгын, сәясәтнең пычрак нәрсә, көчленең кулында курчак фәхеш икәнлеген аңладым. Политикадан читкә киттем. Митингларның, урамда азатлык, бәйсезлек дип кычкырып йөрүләрнең файдасыз, киләчәксез нәрсә икәнен күптәннән аңладым. Көчленеке замана. Әнә бит урысның бөек шагыйре Блок караңгы, куркыныч, хәшәрәт дөнья белән сугышуның мәгънәсез, өметсез бушлык икәнен аңлагач, «дөреслек — шәрабта», дигән иманга килгән. Соңрак Христоска килеп чыккан... Күңелләрем тулып китте әле, хатын, әзрәк коньяк салып бирәсеңме?

Зөлфияне Монголиянең комлы бураннары, барханнары, пычрак юрталары, сәяси тотнаксызлык мәсьәләләре борчымый. Яшь күңеленең кытыгын бер генә нәрсә бимазалый: Маринаны Сәет ни дәрәҗәдә яраткан, ничек аерылышканнар һ. б. һ. б.

— Синең инде, ак түшле кара карлыгачым, Марина Сергеевна белән ничек булып бетте, дип сорарга кече телең кычытып тора.

— Исем китте синең урамда исерек килеш тапкан себерке хохлушкаңа!

— Алай пырдымсызланма, Зөлфия. Ул синең өчен саклап калган мине.

Каты эчемлекләр белән артык дус түгел иде Сәет. Ул аны кирәккәндә һәм кәеф сихәтләре сораганда гына авызына ала. Әрмән коньягын аз гына тәмләп куйды да, сүзен дәвам иттерде. Үткәннең буразнасы буйлап атлау, истәлек-хатирәләрне яңарту үзенең бүгенге халәтен аңлау өчен кирәк иде аңа. Синең язмышыңа, тормыш юлыңа битараф булмаган якын кешең кырында утыру — пыскып янган учакка коры чабык-чыбык ташлау кебек илһам биреп, дәртләндереп тора.

— Марина апаңа Монголиягә бергә китәргә тәкъдим иттем. Риза булмады. Кем инде кояшлы, җимешле, оҗмах түре — Кырымны ташлап, тешләрдә һәрдаим шыгырдап торган вак ком ашарга чыгып китсен! Бигрәк тә үзеннән алты елга яшь татар малаена ияреп. Мәктәпкә йөри торган кызы да бар иде.

Рәнҗешмичә, үпкәләшмичә, зыялы кешеләрчә аерылыштык.

Нәзакатьле, ап-ак кулын Сәетнең җилкәсенә куеп, Зөлфия янә сүзгә кушылып китте:

— Миннән алай гына котыла алмассың, Сәетҗан. Күңеленә беркетеп куй. Янәсе, алар зыялы кешеләрчә аерылышканнар.

Сәет аның стаканда давыл чыгаруын яратуга юрап, хуплады гына. Дымлы иреннәреннән үпте дә дәвам итте:

— Барып урнашкач, адресымны җибәрдем. Берничә тапкыр сәлам хатлары алыштык. Бер елдан открыткасы килде. Хәрби пенсионерга кияүгә чыгам, дип язган. Диңгездәге ак пароходлар төсле, икебез ике якка киттек.

Сәет Монголиядәге ямьсез, җилле эсселек, шапшаклык, юынырга су җитмәү, совет армиясенең анда урнашкан өлешенә игътибар булмау, политсоставның ахмаклыгы, чарасызлык тудырган эчкечелек турында бәйнә-бәйнә сөйләргә җыенган иде. Зөлфияне мәсьәләнең ул ягы бөтенләй борчымый икән.

— Икенче хатының Рушания белән ничек таныштың? Күпме бергә тордыгыз? Аны да өзелеп яраттыңмы?

— Ашыкма инде, кычыткан чыпчыгы...

Яңа бер чагыштыру ычкындырганын Сәет сизми дә калды. Зөлфия аңышмый калыр, дип өметләнгән иде дә, ир-зат хыялы фәрештәнең амин дигән вакытына туры килмәгән икән.

— Нәрсә дидең әле, кабатла!

— Кычыткан чыпчыгы дигән кошчыкны үлепләр яратам мин.

— Син аны каян белдең?

— Нәрсәне?

— Минем әтинең кушаматы ич ул. Авылдан ишетеп кайттыңмы?

— Әйе, мулла абзый колагыма әйтте. Никах укыганда. Сиңа артык кабатламам, матурым. Әтиеңә туры килә, үпкәләмә!

Кая инде Зөлфия үпкәләсен ди, тузга язмаганны. Авылга кайтулары исенә төшкән саен, җир ярылса, шул тишеккә кереп югалырдай булып ояла Зөлфия.

— Ике ел хезмәт иткәннән соң, ялга кайттым. Әтине җирләдем. Казанга килеп, Болак урамындагы аэрофлот кассасына чиратка бастым. Алдымда өлкән яшьтәге бер хәрби белән сылу гына кыз басып тора. Зал халык белән шыгрым тулы. Эссегә түзәрлек түгел. Миңа яны белән баскан подполковник зәңгәрсу кульяулыгын манма су ясаганчы юан, сырлы муенын, битен, маңгаеның чәчсез дәвамын сөртте дә минем якка борылды. Йөзенә солдафонлык кырыслыгы типте.

— Иптәш өлкән лейтенант, Сез ни өчен миңа честь биреп, исәнләшмәдегез?

Касса янында рәсми олылау кирәклеген уйлап та җиткермәгәнмен. Гадәттә, өлкән әфисәрләр белән урамда очрашканда, арканы катырып, козырекны капшыйсың, монда кирәкме икән? Бу мәхшәрдә бәхәсләшеп торасы килмәде.

— Гафу итегез, иптәш подполковник, Сез икенче якка карап тора идегез,— дип, юри аякларны бер-берсенә шак-шык итеп бәреп, кулны фуражка янына тондырдым.

Канәгать калды. Янында торган кызы минем шаярып кылануны аңлап елмайды.

— Шул, шул.

Өстенә акка кызыл борчаклар сибелгән күлмәк кигән кызы минем якка борылды.

— Папочка, бәйләнмә инде кешегә. Болай да эссе. Ялдадыр әле ул үзе.

Сәет кызның уймак чаклы гына кечкенә, нечкә иреннәре, энҗе тешләре арасыннан чыккан тавышының ягымлы, күңелгә ятышлы булуын, билдән аска киңәеп киткән гәүдәсенең төз аяк, челтәрле күн сандалиеннән күренеп торган буяулы бармакларның үзенә ошап куюын Зөлфиясенең колагына иңдерүне кирәк тапмады. Күп белүнең исәнлеккә әллә ни файдасы булмавын белә иде ул. Болай да йөрәге талымсызланып, чарасызланып тибә.

— Сөйләшеп киттек. Пединститутны тәмамлаган. Әтисе диплом алу шатлыгын уртаклашырга килгән. Исемен инде беләсең.

Сәет бергә басып тору вакытын озайту нияте белән, байтак кешене чиратсыз кертүләрен, акрын гына бармак очына үрелүләрен, кызның дулкынланып китеп, аның кулын кысуын, түгәрәк бит очларының тагын да алсуланып китүен күп ноктадар эчендә калдырырга булды.

Икесенең дә самолетлары иртәгә генә очасы икән. Вакыт күп. Кызның әтисе кунакханәгә урнашкан, арыган, алҗыган, тиз генә кереп ятты. Яңа танышлар исә төне буенча шәһәр сакладылар.

Бер-берсе турында күбрәк беләсе килү дә табигый иде. Әрсезлек җиле егет ягыннан исте.

— Үзегезгә охшаган булса, фамилиягез бик матурдыр?

— Фамилияне үзең сайлап алмыйсың, бугай. Ул — йөзек кашы да, алтын муенчак та түгел. Ничек булса, шулай дип әйтәм.

— Чыны?

— Ханова.

— Ә сезнең?

— Мин — Сәет абый Сакманов булам.

— Абау, каян килгән абый. Безнең яшьләр бер чамадыр.

Өстәп куйды:

— Сез чувашмы әллә?

— Сәет атлы чувашны белмим мин. Фамилиягә килгәндә... Училищега килгәндә, мин Сакмаров идем. Сакмар суын, елгасын беләсездер?

— Таныш булмаса да, ишеткәнем бар.

— Шул. Миңа диплом, паспорт, хәрби билет язганда, «р» хәрефен «н»га чукындырганнар. Алдан үзем дә игътибар итмәдем. Соңыннан... Кул селтәдем.

— Барыбер түгелмени?

— Кеше кайчан картая? — дип үз көймәсен башка якка борды егет.

— Хатын-кызның яшен сорамыйлар. Ә ир-ат үзен ничек хис итсә, шул яшьтә була, диләр. Кайдадыр укыган идем.

Күзләрен ялт-йолт иттереп, Сәеткә карап алды да:

— Үз-үзегезгә кул салу фикере килгәне юкмы башыгызга?

Сәет шаяртуны кабул итте.

— Кулны мин рәхәтләнеп сезнең җилкәгә, аркага, билегезгә салыр идем. Ни ләззәт бар үз кытыршы кулыңны үзеңә салудан!

— Юк ла! Бу фани дөньядан китү, үз-үзеңне үтерү турында сүз алып барам.

Сәет, туарылып китеп, кызны әрләргә, дөнья матур, дөнья киң, ә без шундый яшьләр, күгәрченнәр күк гөлдер-гөлдер шаярышып, шатланышып яшәргә тиеш, каян килгән сезгә, күбәләктәй кызга, кара фикер, дип тузынмакчы булган иде дә, вакытында акылына килде. Аның янында бит политзанятиедән качкан солдат атламый. «Укымышлы шәһәр кызы бара кырыңда, Сәет. Ул сине сыный бугай».

— Гомеремдә бер тапкыр булды андый хәл,— диде ул җитди итеп.

— Кайчан? Сезне нәрсә мәҗбүр итте андый упкынга?

— Бүген. Касса янында!

Инде хәзер кызга, күзен теннис шарыдай түгәрәкләп, гаҗәпләнү мизгелен кичерергә туры килде.

— Ни өчен? Шаяртмагыз!

— Билләһи! Сез билет алуга мине ташлап китсәгез, Ханова икәнегезне белми калсам, ишек тупсасына барып асылынмакчы идем.

— Егетлегегез өчен рәхмәт. Мактыйм.

— Миңа да бер сорау мөмкинме?

Кыз, сәхнәдә уйнаучы артистка төсле, муенын борды, озын керфекләрен килешле итеп какты. Тотышында үз бәясен белеп яшәве сизелә. Янәсе, вали соравыңны.

— Ир-ат затында Сезгә күбрәк нәрсә ошый?

Уйлап торгандай итте кыз.

— Күзләре. Күзләре ахмак булса, башкасының әһәмияте юк.

— Минем бу тормышта гамәлгә ашмаган бер генә теләгем калды. Болай дөньям кырмыска түтәле төсле түм-түгәрәк.

— Хыялыгыз белән уртаклашыгыз. Җиңелрәк булыр. Чирен яшергән тиз үләр, ди.

— Күзләрем сезгә ахмак булып күренсен иде.

Кыз рәхәтләнеп көлде.

— Хәйләкәр икәнсез. Минем дә сезнең өчен бер табышмагым бар.

— Рәхим итегез!

— Безнең группада бер кыз «рәхим итегез белән сату итегез», дип җибәрә торган иде. Ярый. Менә сез офицер кеше. Нәрсә ул кыюлык?

Бу ни дигән сүз? Һаман тикшерәме, ирештерәме, имтихан аламы, белемен күрсәтәсе киләме? Мондый дежур сорауга җитди җавап биреп булмый ич.

— Башкага тиешле каешны үзең ашау,— дип уйлыйм.

Инде кыз бөтен гәүдәсе белән Сәет ягына борылды.

— Браво! Наянлык бу юлы да коткарды сезне. Судан коры чыктыгыз. Ә мин юмор хисемне каядыр төшереп калдырганмын бугай,— дип иркәләнеп алды.

— Шаярту, тоз шикелле үк, чамасын белеп куллануны ярата,— дип өстәде Сәет.

— Ике килгән яшьлегебез түгел. Бераз шаяртмагач та, шомартмагач та нәрсә кала бу дөньяда?

— Мәхәббәт кала.

— Әйдә, без аны калдырмыйк. Ялгызак киек каз кебек каңгырып йөрмәсен, үзебез белән алып китик,— дип, кызны җилкәсеннән кочып алды.

Тегесе карышмады. Сәетнең бөтен тәне тоз сипкән учак кебек чыртлап яна башлады. Башы әйләнеп китте, авызы кипте, йөрәге чабыш аты кебек тибәргә кереште. Чигәләренә менгән кан тышка бәреп чыгардай булып кызышты. Әлегә чаклы бер генә хатын-кызны да шулай теләгәне юк иде аның.

Төне буена, иреннәре кара янганчы үбешеп йөрүләре, өйләнешергә, гомерлеккә бергә булырга вәгъдәләр бирешүләре турында да Сәет сөйләмнән төшереп калдырды.

Бик төксе, төссез, үкенечле тавыш белән генә Сәет Зөлфиясенә түбәндәге хәбәрне җиткерде:

— Өч айдан соң мин Уфага кайтып, туй шикелле тыйнак кына нәмәстәкәй ясап, Монголиягә алып киттем аны. Бер елдан соң кызыбыз Гүзәл туды. Тагын биш ел хезмәт иттем дә, ком даласында, капитан дәрәҗәсенә җитеп, чираттагы кыскартуга эләгеп, Казанга кайттым. Бер ел эчендә ике бүлмәле квартира бирделәр. Рушания белән рухи якынлык таба алмадык.

Сәет икенче хатыны белән аерылышу чорын искә төшереп, үз алдына елмаеп куйды. Зөлфия сизми калды.

Тезгә-тез терәшеп, үзләре генә белгән назлы сүзләрен әйтештеләр дә, башка очрашмаска сүз куешып, аерылыштылар. Инициативаны хатын үз кулына алды:

— Сәетҗан, без аерылышыйк.

— Ник дисең инде?

Андый тәкъдимне күп тапкыр ишеткән Сәет хатынының сүзләрен бу юлы да җитди кабул итмәде.

— Мин моны чынлап әйтәм. ЗАГСка гариза да илтеп бирдем инде. Синнән ризалык кына кирәк.

Ир-ат халкы гаилә мәсьәләсендә җитди борылышларны яратмый. Ул — тыныч су өстен ошата төшә. Сәетнең сул якта, кулбаш астында урнашкан йөрәге борчылып, лепелдәп куйды.

— Кирәкмәс иде, хатын, мәшәкатьле эш, диләр.
— Сиңа ни, беренче аерылышуың түгел. Шәт, соңгысы да булмас.
— Миңа нәзерең шулмы?
— Ул гына түгел. Син мине яратмыйсың. Күз карашыңнан, үзеңне төрткәләп, көчләп диярлек иркәләвеңне сизәм. Бурычка алынган наз кирәк түгел миңа.
— Яшьләрчә дәртле мәхәббәт мәңгелек була алмый. Синең алда кәҗә тәкәсе кебек сикереп, борылган саен үбешеп йөреп булмый ич инде.
— Эш анда гына түгел.
Сәет Рушания белән уртак тормышын үсеп килгән кызлары хакына сакларга, яхшыртырга тырышып карамады дип раслау дөреслеккә хилафлык булыр иде. Хатыны юк-барга битәрләгәндә дә үзен зыялы тотты. Әмма аның тырышлыгы корылмаган мылтыктан ату гына булды.
Уртак түбә астында яшәүче ике кеше арасына чөй кагылса, кара мәче үтсә, юк кына әйбер дә олы низагъ чыгуга җирлек була ала икән. Сәет бер тапкыр: «Сары кофтаңны ташла әле, кайгы төсен җенем сөйми»,— дип ычкындырганын сизми калды. Бәлки, шаяртып кына әйткәндер. Әдәбият тарихын яхшы белгән кеше сары төскә уңай карашын үз файдасына борып җибәрә белер иде билгеле.
Хатыны исә, шуны гына көтеп торгандай, тавыш күтәрүне кирәк тапты:
— Ниндиен киим соң? Миңа нәрсә алып биргәнең бар! Синең белән шул пычрак төскә калдым да инде.
Ханым, дәлилләр эзләп, кире чыгып булмаслык сазлыкка кереп чумды.
— Гайрәтем кайтты, күңелем чикте синнән! Синнән әшәке ис килә, мангул мажигы сасысы...
Илләм явыз итеп җавап кайтарасы килсә дә, Сәет телен тешләү белән чикләнде. Ямьсезләнүнең файдасыз икәнен аңлады. Шундый бәрелештән соң, киң ятакны бергә җылыту көн тәртибеннән алып ташланды.
Табигый сәләткә ия күпчелек кебек, Сәет начар сәясәтче иде. Кешеләр белән мөнәсәбәттә ачыктан-ачык әйтүчән холкы аңа кайгы-хәсрәтне аз китермәде. Турыдан әйткәннең туганыңа да ярамаганны белә торып, еш кына үзен тыя алмый интекте. Бер-ике тапкыр парламентчарак нотык тотса, бәлки, яшәп тә калган булырлар иде. Тәккәбберлеге астан бәреп торса да, Рушания тулаем начар хуҗабикә түгел ич.
— Гаеп кемдә икәнне аңлыйсыңмы соң?—дип сорады хатыны.
— Әлбәттә, миндә,— диде участковый милиционер.— Нинди әһәмияте бар инде аның.
Сәетнең артык карышасы килмәде. Теләсә нишләсен. Шулай да тәкъдимне кабул итмәгән, килешмәгән булып кыланды.
— Безнең уртак кызыбыз бар.
— Бала үсәр ул.
— Аның ятимә булуын телисеңме?
— Атасын да алыштырырмын, борчылма. Тамагы тук, өсте бөтен булыр.— Уйланып торгандай итте дә, өстәп куйды:— Бәлки, нормальный әтисе дә булыр.
Сәет лып итеп урындыкка утырды.
— Әтиең чит илдә эшли диярсең кызга. Акча җибәреп торырмын.
Бу инде Сәетнең аерылышуга ризалык бирүе иде. Ул шунда ук өеннән чыгып китте. Иртән телефоннан шалтыратты. Тавышыннан хатынының төне буенча елап чыкканын аңлады.
— Уфага килергә ярармы соң?
— Юк, кирәк булмас.
Шыңшуын дәвам итеп, әтиләренең адресын, телефонын бирде Рушания. Бераз үгетләсә, аерылышмаска, гафу итәргә дә риза икәнен сизенде Сәет. Әмма ир янәдән буйдак тормышка керүгә ризалашкан, хәтта шуны тели иде инде.

Өстәмә түләү исәбенә, аларны бер атнадан ике якка аерып та куйды рәсми оешма. Мулла укыган никах белән уртак байлыклары — кызлары гына калды. Нарасыйдан ризалык сораучы булмады.

— Сәбәбе тирәндә ятса да, аерылышу өчен кирәге чыкты Уфаның, әтисе үлгәннән соң, берүзе калган әнисе янына яшәргә күчеп китте. Миңа Казан якынрак иде. Аерылыштык,— диде Сәет Зөлфиясенә.

— Кызыңа квартираң бүләгең дә, истәлегең дә булсын. Башка әйберең кирәкми,— диде Рушания.

— Ризалаштым. Соңыннан «Волга» акчасының яртысын алды, алиментка да бирде барыбер. Гаеплене эзләмим. «Мин яман»,— дип әйткән кеше юктыр бу дөньяда. Аны югалтмаган булсам, сине тапмаган булыр идем.

Бер ел экскурсияләр бюросында лектор сыйфатында эшләдем, аннан участковый милиционер булып урнаштым. Анысы инде үзгә операдан. Ә син, матурым, зачеткаңа утыр!

Рушания ташлап киткәч тә, Сәетнең кызыклы, мавыктыргыч романнары аз булмады. Ике тапкыр авызы пешкәч, өйләнергә ашыкмады. Безнең илдә өйләнүе җиңел, ә аерылышуы җиде тәмугка тиң. Сүз әле бу эшнең шәкил ягы турында гына бармый. Аерылгач, ике якның да кешелеген бетерә, изә торган квартира, шкаф, савыт-саба, кашык бүлешү башлана. Балалар гына артык булып чыга.

## 18

Мансур һәм аның яңа дусларының үзен тынычта калдырмаячакларын белеп, аңлап, сизеп яши Сәет. Һавада яшенле, болытлы яңгыр алдыннан була торган тынчу, киеренке авырлык. Сакманов үзенә урын таба алмый. Юк-бар шөгыльләр эзли. Фердинандны үтергән көнне ул, яңарак кына эшкә алынган берничә егетне чакырып, Әхмәдиша абзый өендә әңгәмә уздырды. Беренче кат ишеткәндәй, йөртүчесе Замир да колакларын турсайтып, дөньясын онытып тыңлап утыра. «Янарал» исә уенын-чынын бергә кушып сөйләргә ярата. Аның бу гадәтен белмәгән кеше шаярту белән чынлык арасындагы чикне сизми калырга да мөмкин. Замир белә. Әмма эндәшми.

Урамда котырган вак буранга күз салып, «бабайга эшне арттыра, машиналар юлда калмаса тагын» дигән вак кайгысын башыннан куып, дәвам итте:

— Үземне күтәреп әйтүем түгел, егетләр, минем мактанырга яратканны Замир абзый гына белә. Ун елдан артык баранка әйләндерәм, ГАИ әһелләренең миңа чын-чынлап бәйләнгәне юк. Вак-төяк штрафы булгалый. Әмма тирән каршылыкка кергәнемне хәтерләмим. Машинаның тәгәрмәче тигез юлдан тәгәри. Сине инспектор сыбызгысы туктатты. Нишлисең?

— Документларны алам да, җәһәт кенә янына йөгерәм,— ди егетләрнең берсе.

— Зур хата эшлисең. Кәгазьләрең һәм үзең тәгаен тәртиптә булсаң,— Сәет муенына чиертеп күрсәтә,— аның кырына атылырга ашыкма. Артка да бирмә. Тәрәзәңне ачып, йөзеңне шатлыклы елмаюга охшаган нәмәстәкәй белән бизәп, утыра бир урыныңда. Үзе килеп алсын праваңны, техталоныңны, путевкаңны...

— Ачуын чыгару гына булмасмы?

— Ул болай да сине якын күреп, яхшылык теләп туктатмый. Нәтиҗәсе шул ук булачак.

Инспекторның күкрәгендә ГАИ дип язылган тимер билгесе, жетоны булмаса, документын күрсәтүне сорагыз, фамилиясен баш дип аталган компьютерга салып куегыз. Текә борылышта да төшеп калмаслык итеп. Документыгызны алып калса, кем икәнен, кайсы бүлектә эшләвен язып алыгыз.

— Әгәр мент тенти башласа, үзеңне ничегрәк тотарга?

— Әбинең чүлмәген егып, каймагын ашаган тәүфыйклы песи кебек ыспай гына янында басып торасы. Перчатка куя торган тартманы, багаж бүлеген, җилкәгә элә торган сумканы, махсус сорамаса, үзең ачып салырга ашыкма. Ник дисезме? Хөкүмәт чыгарган кануннарда «машина хуҗасы яки йөртүче үзен-үзе тентергә яки тикшерергә тиеш», дигән маддә юк. Аңа кирәк икән, үзе ачсын. Син шул мәлдә, тартмасаң да, тәмәке кабызган бул. Бер суырудан гына тончыгып үлмәссең.

— Багажникны ачуны таләп итсә?

Сорауны җавапка лаек дип тапмыйча, кешегә дә санамыйча, Сәет Ярулловичдәвам итә:

— Соңыннан, сасысы чыкса, хәйләкәр инспектор «ул үзе күрсәтте, үзе ачты», дип котылырга мөмкин.

— Газ пистолетын кая йөртергә? — дип сорый бер әрсез ач күзлесе.

— Үзегез беләсез, бездә корал йөртү тыелган. Үтерү әсбаплары ирекле сатылса, ярты халыкны кырып бетергән булыр идек. Үсеш дәрәҗәбез түбән. Безнең оешмада корал йөртү миңа гына рөхсәт ителгән. Үзегез ни өчен икәнен беләсез,— дип хәйләкәр елмайды:— Әгәренки, олы дәүләт бурычын үтәү өчен ул синдә була калса, аны кул тормозы янында, кара шакшы пычрак чүпрәк эчендә тотасы.

— Милиция туктатса?

— Машинаны ашыкмыйча гына җиргә сеңдергән арада, пистолетны кулың чит итәк астына кергән җитезлек белән чалбар балагына тыгасы! Шуңа күрә рульгә утырганда ыштан киясе була.

— Аннан төшеп китә ич ул,— ди бер наданы сөйләкнең дөресен юмор боткасыннан аера алмыйча.

— Көпшәсен, егетем, ботинкага, кроссовкага, алары булмаса, оекбашка тыгасың, өске өлеше тар балакта кала. Ыштан төбенә салу сәбәпле җайсыз атлаган бәләкәй малай үрнәгендә, машина һәм инспектор тирәсендә йөрештергәндәй буласың.

— Барыбер сизенсә?

— Пушканны алса, димәкче буласыңмы?

— Әйе.

— Мондый борылыш Замир белән минем, Әхмәдиша абзый ярдәмендә язылган шартнамәдә каралмаган. «Минеке түгел, юлда таптым. Әнә теге комок каршында ята иде, Сезгә илтергә барышым иде, ярый әле, йөрәк парәләрем, үзегез очрадыгыз», кебек чүпне чүмәлә өстенә өясең. Иң мөһиме, бер дә тукталып тормыйча, туктаусыз лыкылдарга, тикшерүчене арытырга...

Шулай, шаярып, дусларча сөйләшүләрдән соң, Сәет белән егетләре арасында үзара аңлашу, якынлык арта бара. Ләкин ул бервакытта да чикне чыгарга, үзенә ахыргача якынаерга бирәүгә дә ирек бирми, пәйгамбәр белән мөридләр арасындагы чикне сиздереп тора.

Тәҗрибәлерәк егетләр хуҗаларын эчтән елмаеп тыңлыйлар. ГАИ белән мөгамәләнең ышанычлырак юлы бар. Документлар урынына учына тыгыз итеп бөгәрләнгән акча өемен төртәсе... Тегесе артык честный булып кыланса, Сез взятка бирә, дип уйладыгызмы, миндә андый акчалар каян килсен, бу — штраф, дисең. Милиция белән эш йөртүнең юллары күп инде аның.

Ә егетләрнең әле хуҗалары белмәгән үз серләре дә җитәрлек. Сәет бик аралаштырмаска тырышса да, яшәү өчен көрәш аларны якынлаштыра. Машиналары кара-каршы очрашып, узып киткәндә, сул кулларын киң җәеп, алгы пыялага куялар, үз кешеләрен яклап «разборкага» баралар, кабан дуңгызлары кебек, аркага-артны куеп сугышалар. Пахан еш кына яшь хатыны кочагында йоклап кала. Эш зурга китсә, аның кирәге чыга.

Чит кешене беркайчан да утыртмыйлар, «бомбить» итмиләр, ягъни пассажир йөртеп, акча эшләмиләр. Бусы — билгеле бер каста, клан әгъзалары өчен иң оят нәрсә. Андый йөртүчегә кул бирмиләр.

Егетләре белән күңелле генә гәп корып утырганда, Әхмәдиша карт йөгерә-атлый килеп керде.

— Сәет Яруллович, сезне телефонга... Ашыгыч.

Фердинандның хатыны шалтырата икән. Еш-еш сулый, елаганы сизелеп тора.

— Фердинандны үтергәннәр,— диде дә туктап калды.

— Кайда, ничек?

— Урамда атып үтергәннәр. Машинасы янында. Машинасыннан чыгып барганда. Шулай буласын белгән идем мин...— дип тагын үксергә кереште.

Олы фаҗига турында хәбәр алганда, ни әйтергә белми аптырап каласың. Юатудан файда юк, иң кирәкле сүзләре табылмый әле аның.

— Кадрия ханым, кайгыгызны уртаклашам... Күмүне оештыруны үз өстебезгә алабыз. Хәзер ул кайда?

— Моргта инде. Кайда булсын!

— Хәзер мин ярдәмчемне кереп алам да шунда китәм. Сезне ташламабыз. Хәзергә хушыгыз!

Замирны чакырып алып, аңа, башка егетләргә күмүне оештыру буенча эшләр кушты да, җир астындагы гараждан чит ил машинасын алып, үзе рульгә утырып, төп офисына юл алды.

Эчкә узып торасы килмәде, сигнал бирде. Таныш тавышка Хәлил килеп чыкты. Сакманов ярдәмчесенә карап алды. Инде берничә ел җылы бүлмәдә, кайгы-хәсрәтсез утыру, вакытында өенә кайтып ашап килү, тәмле-томлы белән берничә кат чәй эчеп алу Хәлилнең тиресен шомарткан, чистарткан.

Кайбер кеше, мөмкинлеге, сәмәне була торып та, үзен карамый, кулына нәрсә эләксә, шуны кия. Нигъмәтуллин андый кеше түгел. Ул пычрак күлмәк, исерек итекче кулында булган туфли, химчисткада изелгән кәчтүм кимәс. Күрәсең, житешмәгән белемне, мәсьәлә хәл итүне, табигатьтән килергә тиешле җорлыкны затлы кием белән тулыландыра, шулар исәбенә үзен расларга тырыша. Кем ничек булдыра ала инде. «Кайгысыз адәм баласы бар бит бу дөньяда»,— дип, җиңелчә көнләшеп куйды Сакманов.

— Тачкаң матур,— диде Хәлил эчкә кереп утырып.— Бик йомшак чаба. Утырып баруы да бер чәркә шотланд виские җибәргән төсле рәхәт. Мондый машина астына кереп үләргә Анна Каренина да риза булыр иде.

Һәм гамьсез генә юк-бар турында сөйләнүен дәвам итте.

— Әлбәттә, шәрабы гади булмасын. Унбиш ел имән савытта ятканы лязим. Бездә кайчан шулай нык, матур, урыннан күтәрелеп китә алырдай, төрекләр әйтмешли, араба ясый алырлар икән?

Хәлил чүәкчеләр белән Төркиядә булып кайткан иде. Кирәксә-кирәкмәсә дә, төрек сүзләрен кыстырып җибәрергә, белдеклелеген күрсәтергә ярата.

— Төрек теле чок гүзәл тел инде. Солтаннар теле.

— Синең бабаңнар телендә ханнар сөйләшмәгәнме?

— Ул күптәннән булган. Хәзерге хуҗалар урысча гына бәрәләр. Төрек теле, гомумән, кызык ләтчә. Иртән хатынга кычкырам: «Миңа бер-ике бардак китер әле»,— дим. Ул күзен тондырып карап тора. Миңа нибары ике чәшкә чәй кирәк. Караватымны таба алмыйм. Кая куйдыгыз, дим. Ул янә берни аңламый. Ә миңа нибары галстук лязим. Мин эре генә, дуракта яисә тукталышта очрашырбыз, дип чыгып китәм.

Хәлилнең тагын бер сәер гадәтен яратмый Сәет. Элек андый түгел иде сыман. Яши-яши кеше үзгәрә, мохиткә җайлаша, якыннарының гадәтләрен сеңдерә килә икән. Үзен гел алдыйлар, ялгыш юлга этәрәләр, төп башына утырталар, дип уйлыймы инде шунда, иң гади әйберне дә аңламаганга, ишетеп җитмәгәнгә салыша, кабатлап сорый.

— Нәрсә дидең әле, хуҗам?

Соңгы сүзгә юри басым утырта.

Сәет соравын, фикерен элек ике-өч кат иренмичә кабатлый иде. Үзенә кирәген аңлый, ишетә иканен сизенгәч, теге кат-кат сораса да, кабатламый башлады.

— Кәпчә дидем, Хәлил бәй.

Керфексез соры күзләрен түгәрәкләп, Хәлил мәҗбүри булмаган сөйләшүен булә. Сәет тизлекне юри арттырды.

— Ашыкма, Сәет Яруллович, ГАИ радар белән тора.

— Штраф түләрбез. Ул мәхлүкләргә дә яшәргә кирәк. Әнә Фердинанд теләсә нинди сумманы чыгарып салыр иде дә... Инде булдыра алмый.

— Нәрсә булган аңа? — диде Хәлил һаман да ваемсыз гына. Һәрхәлдә, Сәеткә шулай тоелды.

— Атып үтергәннәр. Хәзер аны алырга моргка барабыз. Син күптән беләсеңдер дип уйлаган идем.

Ни хикмәттер, Хәлил бәй хәбәрне артык каударланмыйча кабул итте, утыргычтан егылып төшмәде.

Бу үлемне авыр кабул иткән, дәвамы буласын сиземләгән Сәет тынып калды. Аңа кыен иде.

## 19

Мансурны юлдан алырга дигән ныклы карарга килде Сәет. Ысулы бер генә... Оҗмахка озату. Карар кабул итү белән аны үтәү арасында таныш булмаган юл ята. Шөреп кебек нык куллы сунарчы өчен дә каты чикләвек булып чыкты бу шөгыль. Яши торган өе янында Мансурның үзе белән генә «күрешү» илләм кыен иде.

Өстән иңә торган күрсәтмәләрдән котылып, тулы мөстәкыйльлеккә чыккан ресторан хуҗасы эшкә үзе теләгәнчә, төрле вакытта йөри. Бер көнне фатирыннан сәгать унда чыкса, икенче иртәдә унберда генә кузгала. Бер очракта гап-гади кешедәй җәяүләп кенә китсә, икенче мәлдә үзен машина кереп ала.

Кичләрен соң кайта, үзе генә булмый, дуслары китереп куя; күп очракта шаулаша-гөрләшә өенче катка ук озатып куялар. Машинада, кагыйдә буларак, һәрвакыт диярлек, чәчбикәләр була. Соңгыларын өенә алып менми, машинада калдыра. Авылдан алып килгән дини әнисеннән курка, диләр. Утыз җиде яшькә җитеп, бер тапкыр да рәсми өйләнмәгән икән. «Әнисенең дөмеккәнен көтә»,— дип усал елмаеп куйды Шөреп, тар маңгаендагы сырларын уйнатып.

Күз кырые белән генә машинадагы кызларга карап аласы килә. Якын килергә ярамый, хәтерләп калулары бар. Пахан аны кат-кат кисәтте: сине йорт тирәсендә кеше түгел, эт тә күрергә тиеш түгел.

Урамның икенче ягында үскән карт өянке төбен Шөреп икенче атна инде саклый. Агач аңа күптәнге танышы кебек якын. Һәр каерысын белә, аскы, өске ботакларын кат-кат санап чыкканы бар.

Айның тоныкг, төссез карашы йортларны, асфальтны ваемсыз гына сыйпый. Шөрепнең үткен күзләре һаман биш катлы кирпеч йортның урта керү юлында... Мансур кичке унберда генә кайтты өенә. Бер бүлмәдә азга гына ут алынды. Тиз сүнде. Тамагын эшендә туйдыра, газета-мазар укып күзләрен туздырмый.

Өстәрәк шадра йолдызлар күз кыса. Аларга ни... Кеше үтерәселәре юк.

Пахан Мансурны алырга бер ай вакыт биргән иде. Икенче атна үтеп бара. Шөрепнең тәгаен көнне билгеләгәне юк әле. «Барыбер котелогыңны ватам мин синең, иптәш директор»,— дип зәһәрләнсә дә, бернигә дә исе китмәскә өйрәтелгән кеше дә тынычсызлана, борчыла, чарасызлыктан пошына башлый икән. Жирәбәнең Мансурга чыгуы очраклы гына булмады.

Көтмәгәндә, уйламаганда коры сөт табу. Балтика илләренә алып барып сату өчен җаваплы Фердинандны кичке эңгер-меңгердә киң урамнарның берсендә атып үтерделәр. Шунда урнашкан кибеттә эшләүче җирән чәчле, озын нечкә борынлы, зәңгәр күзле кыз белән роман кайнатып йөргән вакыты иде мәрхүмнең. Кайсы көнне, сәгать ничәдә гадәттә очрашуга килүен санап чыгарганнар да, машинасын бикләп ятканда, икенче машинаның арткы утыргычыннан винтовкадан өч пуля сеңдергәннәр. Берсе башына, берсе аркасына, өченчесе кулына эләккән.

Сату-алу, алыш-биреш өчен яратылган, замана баласын олылап күмделәр. Ләкин аны берәү дә кире кайтара алмый. Ике нәрсә кала. Урыны оҗмахта, яткан туфрагы мамык булсын, дип теләк теләү, Коръән чыгару, көннәрен уздыру яисә аккан каны өчен үч алу.

Фердинандны юлдан алып ташлауны Мансур оештырганны аңлады Сәет. Әлбәттә, ул үзе мылтык күтәреп урамга чыкмагандыр. Еланның аягын күрмәссең. Оештыру — аның эше булуында шик юк...

Бу үлемне түләүсез, заяга калдырсаң, Мансур үзе дә, башка кланнар да дөрес аңламаслар. Шөрепне дәшеп алды. Ишекләрне яхшылап япты.

— Фердинандсыз да калдык, Сәнгат,— диде Сәет тавышына мөмкин чаклы үкенү, сыктану, рәнҗү, сагыну төсмере бирергә тырышып.

Хисләрен аңлы рәвештә тезгәннән ычкындырып, араларыннан изге бер кешене тартып алган билгесез көчне катлы-катлы итеп сүгәргә керешә: «Эттән яралганнар. Җирәнгеч, тузбаш еланнар, үләт шакаллары! Тотып суалчан урынына изәсе дә, җимгә чуртанның азау тешенә куясы, бабайлар гөрзие белән умыртка сөякләрен ватасы...» Озак итеп, тәмләп, туйганчы тезде ямьсез сүзләрне.

«Мин болай ук булдыра алмыйм», дип, күзләре дүрт булып, көнләшеп утырды Шөреп. «Төрмәдә утырмаган, ә каян өйрәнгән? Килешеп тора үзенә сүгенү». Паханга хөрмәте артты.

Күңелен урынына куеп, тын тарткач, Сәет сүзен житди итеп төгәлләде:

— Миңа озак вакытлар ул житмәс. Ышанычлы, төпле, булган егет иде. Хәзер минем уң канатым, өметем булып син калдың.

— Рәхмәт, шеф!

Әңгәмәдәшенең күңелендә кирәкле хисси җай, уртак кайгы хисе тудыргач, Сәет сүзнең икенче өлешенә күчәргә булды.

— Мәрхүм сине хөрмәт итүе, энесе кебек яратуы турында сөйләп утырган иде берничә көн элек.

— Чынлапмы?

— Шаяртып утырырга мин бала-чага түгел. Вакыты да ... үзең беләсең.

— Анысы хак.

— Синең аңа мөнәсәбәтең ничек?

— Ул сезнең ярдәмче, яше буенча олы булырак, безнең буынны бик якын китермәде үзенә.

— Горурлыгы бар иде аның. Шуның аркасында дошманнары да житәрлек булды. Дуслары күп булган, абруйлы кешене яратмаучылар, хәтта күрәалмаучылар табылмаса, аңлашылмас иде.

— Мин ул ягын артык белмим,— диде студентлар белән аралашу барышында сөйләшергә ярата, шуннан тәм, ләззәт таба башлаган Шөреп.— Фердинанд абыйның миңа мөнәсәбәте җылы иде.

— Аның якты истәлеген аяк астында таптатабызмы, әллә үч алабызмы?

— Кемнән аласың? Милиция таба алмады. Кибеттән йөгереп чыккан хатын да, өч бер үк төсле «девятка»ларның төрле якка таралышуын гына күреп калган.

— Турыдан-туры мылтыктан аткан кешенең юнәлтүчесе, өйрәтүчесе, ахыр чиктә, яллаучысы була.

— Җәзаны аткан кеше алырга тиеш.

Сәет сүз агышына үзгәрәк юнәлеш бирергә булды:

— Кулыма пистолет эләкте дип урамда, төнге бердә шатыр-шатыр эт атып йөрүче тилеләре җитәрлек.

Шөрепнең маңгаеннан, күз төпләреннән салкын тир бәреп чыкты. «Шпионнарын бөтен җиргә куйган. Бернәрсәне яшереп калып булмый. Шашынып йөрүем турында хәбәр килеп җиткән».

Тирәнгә кереп, әрли башлар дип шөлләп, ризалашырга ашыкты.

— Мин әзер! Тик кемне, кайчан?

Ирексездән, эре тешләрен күрсәтеп, елмаерга итте.

— Минем төп вазифам да шул түгелме соң? Шуның өчен эшкә алдыгыз, квартира бирдегез, машинага утырттыгыз. Мин барсын да аңлыйм.

Сәет аның сүзләрен игътибарга алмады.

— Бу задание аерым очрак. Санап тотсаң, әҗере сиңа озакка җитәрлек булыр.

«Өстәмә түләрлек булгач, важный персонадыр, малай». Ә хуҗа шәрехләвен дәвам иттерде:

— Эшне уңышлы башкарып чыга алсаң, мин анда шикләнмим, өч бакса долларны кулыңа аласың да, вакытлыча күздән югалып торасың.

— Мин инде булып кайткан тарафларгамы? Кире анда эләгәсем килми. Хәзер мин семейный кеше.

— Юк ла! Мәскәүгә китәсең. Торыр урын бар. Калганы үзеңә бәйле. Бир кулыңны. Ирләр булыйк, дигән бер татар шагыйре.

— Аңа сөйләнүе җиңел. Кеше атасы юк.

— Хәзер тыңла,— дип Сәет кайчан, кемне әтмәлләргә кирәклек турында бик тәфсилле сөйләде. Карточкаларын күрсәтте. Пахан белән бергә төшкәннәре дә бар. Икесе дә чибәр, таза, суксалар үгез башын тишәрлек ирләр. Исән калганы иркенрәк яшәсен өчен, берсе фани дөньяны үз теләгеннән башка ташлап китәргә тиеш. Һәм немедленно.

Сөйләшеп, аңлашып беткәч, Шөрептән сорап куйды:

— Курыкмыйсыңмы?

— Минем әби курыкканга куш, койрыгы белән биш, ди торган иде.

— Курыкмаска әбиең өйрәткән булып чыгамы?

Шөреп төрттерүне аңлады. Сыртын кабартты, шырпысын кабызды:

— Әбигә сүз тидермәгез. Ничек диләр... Изге җан ие.

Олы юлга чыгар алдыннан кәефен күтәрү өчен әйтелгән шаяртуның кабул ителмәвен күреп, Сәет Шөрепне тынычландырырга ашыкты.

— Ярый, ярый. Дусларча гына.

Папкасына кулын тыгып, санамыйча диярлек акчалар тартып чыгарды. Эндәшми генә, егетнең учына тоттырды. Әйтерсең лә канга буялган кулларын салкын су белән юарга сабын бирә.

— Бусы — аванс. Хәерле юлга. Ходай белән әбиең сакласын үзеңне!.. Калганы, эш беткәч.

— Ярый, мин олактым!

— Юк, син олакма, җиңүче булып кайт!

...Шөреп ике атна инде шул эш белән мәшгуль. Олы түрәләрнең җан сакчылары кебек, Мансурның өен карауллый. Максатлары гына үзгә.

«Юньсез, иң әшәке эшләрне Пахан миңа тапшыра. Әллә ышана, әллә миннән котылу җаен карый. Кем белсен, сүзенең төбендә ни ятканын. Мансур дигәннәре кирәкле кишер яфрагы, күрәсең. Америкада да бер баш сөяге өчен шуннан артык түләмиләр, дип ишеткән идем».

Паханның белмәгән нәрсәсе юк. «Мансурның башы үгезнеке кебек зур. Маңгаена төзә,— дигән киңәшен биргәч, үз алдына уйлангандай, исенә төшергәндәй өстәп куйды:— ЧК, соңыннан КГБ подвалларында гел маңгайга атканнар. Сере бар икән: кеше тиз үлә, күзләрендә атучының сурәте калмый».

Хуҗасына каршы килеп, тәкъдимнән баш тарта алмаса да (өч мең доллар бит әле ул), Шөреп бик теләп алынмады бу эшкә. Аякларын

тартмаган юлга чыкма икән. Ике атна карт өянке төбен юешли, тәгаен карарга килә алганы юк әлегә.

Әүвәл ул үзендә Мансурга карата шәхси үч ялкынын дөрләтә алмыйча интекте. Фердинандны, көттә кыланчыкны үтерергә ул кушкан, ди. Шуннан дөнья үзгәрдеме, күчәре тирәсендә әйләнүдән туктадымы?

Пахан: «Сине ул ярата иде»,— дип салам кыстырган булды анысы. Үзеннән башка берәүне дә кешегә санамый иде Фердинанд. Үзе юкта хәтта Паханны да... Янәсе, ул укыган кеше, университет бетергән, фәннәр кандидаты. Ләхет ул, дустым, мөселман дине кушканча, күмелгән һәр кеше өчен бер төслерәк алына. Дипломнарыңны кочаклап ят әнә кара җир астында. Ә без Региналы тез башында иркәлик...

Мансур квартирасының бер тәрәзәсендә шәүлә күренде. Шөреп бинокльен алды. Чәчәкле яулык бәйләгән баш юлны күзәтә. Озак басып торды җансыз сын булып. Малаен шулай зарыгып көткән изге ана Шөреп күңелендә коточкыч ачу, нәфрәт хисе уятты. Ул калтырана башлады. «Бай кешене аналары көтә, тапкан хатын мине мәче баласыдай ташлап киткән, хәзер башкаларны иркәли, хөрмә ашата».

Тәрәзә төбен саклаучы карчыкка, барча аналарга нәфрәте, котырынган диңгездәге дулкыннар төсле, ирекка ыргылды. «Тиздән чәчләреңне дию периедәй тузгытып, җансыз улың янында җылап утырырсың! Балдамайда йөздең, җитте».

Як-ягына карануыннан туктамыйча, хыялында туган явыз манзарадан канәгать калып, усал елмаеп куйды. Аңа, салкын гәүдәдән бигрәк, үлгән кешенең якыннары — әтисе, әнисе, бала-чагаларының интегүе бирә иде чын ләззәтне.

Хаста кешенең йомшак ястыгында җан тәслим кылуы бер хәл. Туганнары афәтнең якын арада киләсен белеп, сизеп, аңлап, «тиздән тереләсең, җайлашып, хәл тартып барасың», дип тынычландырудан үзләренә дә таяныч табып, саубуллашып кала алалар. Язмыштан узмыш юк. Тәңре үзенә алмаган адәми затның әле туганы юк.

Анасы иркәсендә типтереп яшәүче Мансурга карата күңелендә ризасызлык колмагы үрләде, үч аласы килү нөктәле үпкәгә үсте. Ике атна эчендә Шөреп үзе өчен ифрат кирәкле бер нәрсәне ачыклый алды. Мансур дүшәмбе көнне өеннән нәкъ сигез дә утызда чыга икән. Күрәсең, атна башында аларны кемдер, олырак зат тугызга җыелышка, планеркага чакыра. Шул көнне тамгаларга да, бу тирәдә артык чуалмаска. Урам йомышы белән чыгарылган бәләкәй эт инде ничәнче кат Шөрепкә өрәөрә ташланды. Өлкән яшьтәге хуҗа ханымның күз карашында чит, ят егеткә артык җылы мөнәсәбәт сизелмәде. Сузарга ярамый...

...Дүшәмбе көнне тугызынчы егерме биш дәкыйкадә, Сталин чорында тыныч, иске урамда салынган биш катлы ак кирпеч йортның кырый керешенә яшел «Жигули» килеп туктады. Аннан уртача буйлы, киң җилкәле милиционер чыкты, кыска аяклары мөмкинлек биргәнчә, эре-эре атлап, эчкә үтте. Беренче катның яртысына җитеп тукталып калды. Фуражкасын салып, андагы рәсемне өйрәнә башлады. Кечкенә эт белән өлкән яшьтәге ханым урамга уздылар. Эт милиционерны иснәде, нигдидер серне сизеп тә, берәүгә дә әйтмим, дигәндәй күтәрелеп карады да, урамга кәнтерекләде.

Мизгеле мәңгелек булып тоелган тынлык урнашты. Ниһаять, өченче катта ишек ачылды, мыгыр-мыгыр иткән сөйләшү ишетелде, икенче кат мәйданчыгында өстенә кара-зәңгәр шевиот костюм, галстук белән ап-ак күлмәк кигән, төрек, әзербайҗан фильмнарында баһадирны, олы хуҗаны, һич югында елгыр бизнесменны уйнаучы артистларны хәтерләткән чибәр, мәһабәт ир пәйда булды. Очы тар, ялтыраулы кара күн аслы ботинкаларын таш баскычка хуҗаларча басып аска төшә.

Ваемсыз гына милиционерга карап алды. Таныш булмаган ментның монда буталып йөрүенә гаҗәпләнеп тә өлгермәде, кыска көпшәле кара наган хөкем әһеленең кесәсеннән кулына сикерде. Шартлау тавышы

яңгырады. Олы гәүдә абынгандай итте, егылмады, уң кулы белән болдырга тотынды, икенче пуля корсагына килеп кадалды. Пистолет янә галифе чалбар эченә чумды.

Олы гәүдәнең гөрселдәп ауганын көтеп торырга көче җитмәде. Үзен-үзе үтерүче биектән ташланган кебек, күзләрен яман усаллык белән ялтыратып, урамга атылып чыкты. Машина киткән булып, пулялар алмыйча, йөз егерме килолы Мансур арттан килеп чыкса? Шөрепнең бөтен тәнен мәгънәсез, миһербансыз курку чолгап алды. Бозлы судан чыккандай, калтырана башлады. Машинаның газ биреп торуын күргәч тә, аның кемгәдер, нәрсә өчендер явыз ачуы килде. Кычкыру, кемнедер кыйнау теләге уянды.

Йөртүче Ринат эшнең уңышлы чыгуын, Шөрепнең гәүдәсе буйлап юан бау төсле җансыз салынып төшкән куллары буенча аңлады. Көпчәкләр ыңгырашкан, эт чыелдаган тавышлар артта калды.

## 20

Сәет бүген Әхмәдиша карт йортына гадәттәгедән иртәрәк килеп туктады. «Волга»сыннан төшкәндә, Замирга: «Эчкә узмассың, озак тормыйбыз»,— дип күрсәтмәсен бирде дә тар капкадан эчкә үтте.

Яшел «Жигули» махсус мәйданчыкта тора. Үзе белән бер яшьләрдәге кара чәчле, тәбәнәк буйлы егет белән Шөреп тар такталардан ясалган агач эскәмиядә тәмәке көйрәтеп утыра. Сәетне күргәч, торып бастылар. Икесе дә аның артыннан өйгә иярмәкче булганнар иде, үзе белән Шөрепкә генә узарга рөхсәт бирелде.

— Саумы, егет,— дип, ни өчендер күзенә карамаска тырышып, Сәет кулын сузды.

— Хәлләр ярыйсы.

— Йомыш үтәлдеме?

— Сорап торасың тагын,— диде Шөреп, авызын ерып.

— Төрлечә була. Соңгы вакытта ул бронежилет киеп йөри, дигәннәр иде. Фердинандны үтергәннән соң...

— Аны бит маңгайга элеп булмый. Үзең өйрәткәнчә, беренче патронны шунда сыладым тәмләп.

Сөйләшүе ошамый. Кыюлык өчен төшереп алган булырга охшый. Хәер, йөзе кызылны кызартып булмый. Артык иркен, йөгәнсез тота үзен. Сәеткә «син» дип эндәшкәне юк иде әле. Мондый мөрәҗәгать Хәлил белән Әхмәдиша бабайга гына рөхсәт ителә. Алары да якынлык алмашлыгын хуҗаның кәеф вә сихәт-нәсихәтләренә карап кына эшкә җигәләр. Дулаган, кәефсез чагы булса, гел инглизләр төсле: сез дә, без...

Чыраен чытты Сәет, түзде. Ирен читләренә керпеле елмаю чыгарып:

— Сүз нәтиҗә турында барырга тиеш.

— Соң әйттем бит инде,— диде Шөреп шул ук тонда.

— Әйдә, яхшылап сөйләп бир!

— Нәстәсен сөйлисең инде аның? Гадәти эш. Иртәнге тугызынчыда Ринат белән подъезд каршына солидно гына килеп туктадык. Лейтенант абзаң солидно гына кереп китте. Нәкъ вакытында чыкты мәхлук. Ике тапкыр бәрдем тегеңәргә. Беренчесен, үзең өйрәткәнчә, маңгаена, икенчесен — корсагына.

Шунда ук, сүз-фикер сөрешеннән читләшеп, немец пистолетын мактый башлады.

— Ясый беләләр икән үтерү коралын фашист калдыклары, малай, минсиңайтим...

Сәет аның халәтен аңлый, бүлдерми тыңлый. Эт белән кода булсаң, сөяк белән туй итәрсең.

Пистолетны, үзен, йөртүчесен мактап эчен бушаткач, егет тынып калды. Сәет өчен күп нәрсә ачык түгел иде әле. Эз, тамга калдырмаганмы?

— Сезне өй эчендә, урамда беркем күрмәдеме? Узып баручы кешеләр очрамадымы? Әнисе озата чыкмадымы?

Әүвәл «юк, якын-тирәдә эт тә юк иде» дисә дә, исенә төшердеме, әллә алдан яшерергә уйлап та, хәзер дөресен әйтү яхшырак булыр дигән фикергә килдеме, кинәт ычкындырды:

— Эт йөри иде урамда.

— Нинди эт?

— Кечкенә. Менә шуның хәтле генә, ләң-ләң.

— Соң? Ул сезне өреп озаттымы?

— Көпчәк астына килеп керде, үлгәндерме, юктырмы, әйтә алмыйм, чинап калды.

— Үзе генә йөри идеме?

— Әйе.

— Берүземе?

— Берүзе дип, хуҗасы белән чыкканнар иде прогулкага.

— Хуҗасы кем?

— Шул подъездда, дүртенче катта торучы хатын.

— Ул сезне күрдеме?

— Каян белим. Күрсә, безне танымый ич ул әби.

Сәетнең эченә билгесез юртак шом үтте. Шөрепнең чиста эшләп чыга алуына алдан ук ышанмаган иде ул. Тәвәккәллеге бар. Тик уйлап, алдын-артын карап эшләргә җыйнаклыгы җитми. Эт белән әби мәсьәләләрен ачыкларга кирәк. Башын яшергән башсыз калыр.

Сөйләштерә торгач, шул чаклысы да ачыкланды. Болонка белән әби аны агач артында посып торганда да күргән булганнар икән. Анда да эт Шөрепне кабул итмәгән, янына килеп, тавыш чыгарган.

— Апа мине танырга тиеш түгел. Беренче тапкыр мин свитер белән чалбардан идем. Хәзер милиционер киемендә.

Янә фикер йомгагының очын югалтып, читкә китте Шөреп:

— Милиция формасы миңа килешә икән. Шунда эшкә урнаштырмыйсыңмы соң мине? Кирәкле сүзне әйттерә белер идем мин бандюгадан! Их, мин аларны...

— Шоферың ни эшләгәненне, кемне үтергәненне беләме?

— Юк.

— Аткан тавышны ишеткәндер?

— Миңа ташланган овчарканы атып үтердем, дидем.

— Ышандымы?

— Эткә эт үлеме, диде. Курыкмагыз! Минем белән утырган ышанычлы малай.

Сәет, күрше бүлмәгә кереп, сейфтан өч мең доллар акча алып чыкты. Шөрепкә бирде.

— Биш йөзен шоферыңа бир! Өстәп менә шуны куш,— дип, куен кесәсеннән бер пачка Рәсәй акчасын чыгарып салды.

— Тиз генә озат аны. Монда юлны онытсын! Үзең кире әйлән!

Шөреп урамга чыгып керде.

— Тәртип, егет китте. Авызы — йозак.

Сәет кесәсеннән ике билет чыгарды.

— Син бүген кич «Татарстан» поезды белән Мәскәүгә китәсең. Барып житүгә, бу билетны чәйнәп йотасың. Монысын үлгәнче саклыйсың. Шулай ук Мәскәүгә. Тик өч көн элегрәк киткән поездныкы. Аңлашылдымы?

— Нәстәсен аңламаска инде аның. Төрмәдә гел дураклар утырмый,— диде Шөреп үпкәләгән тавыш белән.

— Менә сиңа адрес. Ачкыч. Безнең квартира ул. Хәлеңне белешеп торырлар. Хәзер сиңа ярдәмгә берничә егет бирәм. Яшел машинаны юкка чыгарырга кирәк булыр.

— Минем машинанымы?

— Ул синеке түгел инде. Мәскәүдән кайткач, яңаны бирербез. Хәзер үзең дә сатып ала аласың.

Сәет машинаның номерларын, бөтен документларын алып, тимер кайчы белән вак кисәкләргә үзе турады.

— Әүвәл мотордагы, кузовтагы саннарны сытыгыз. Машинаны сүтеп, яшел буяуны наждак комы белән ышкып төшерегез. Элеккеге машинаның эзе дә калырга тиеш түгел.

— Запчастька алырга ярыймы? — диделәр.

— Машина бөтенләе белән шунда китәргә тиеш. Шөреп аның кешелеген калдырмаган инде. Металлоломга гына тапшырасы.

Сәет, бөтен тормыш тәҗрибәсен туплап, тап калдырмаска тырышса да, яманның кәсафәте, ягъни шаукымы, бәласе бер чакрым алдан йөри икән. Шуннан соң булган кыйты хәлләр Сәеткә авыр тәэсир итте. Тирәюнендә ниндидер киеренке, аңлашылмый торган, хәтта куркыныч халәт урнашты. Билгесезлек пәрдәсе томанлы һәм ямьсез иде. Кул эшкә бармый. Башны акыллы фикерләр, борылышлар читләтеп үтә. Чакма ут алмый.

Үзен кая куярга белми аптырап, каңгырып йөргән көннәрнең берсендә күңелсез хәл килеп чыкты. Яманга якын килсәң, карасы йогар. Бусы да Шөреп калдырган эз булып чыкты.

Сәетне Әхмәдиша бабай йорты янында кыска буйлы егет каршы алды. Кара чәче, йөзе, гәүдәсе мин татар токымыннан дип тора. Кайдадыр күргәне бар иде кебек Сәетнең аны...

— Сәет Яруллович, исәнмесез!

— Сезне кем дип белик? — диде көтелмәгән очрашуга артык сикереп төшмичә. Мондый күрешүләрнең берсе дә шатлыклы хәбәр, сөенеч алып килмәгәнен үз тәҗрибәсендә кат-кат сынаганы бар Сәетнең. Рәхмәт әйтер өчен көне буе урамда көтмиләр.

— Мин Сәнгатнең шоферы Ринат булам.

— Машинасын үзе йөртә иде ул, — дигән булды хуҗа бу егетнең кем икәнен генә түгел, ни өчен килгәнен дә чамалап. «Шөреп аның белән исәп-хисапны ясамаган яисә егет боларны куркытып, тагын да күбрәк каерып, киләчәктә дә суырып, имеп ятырга мөмкин булыр, дип юлга чыккан. Комсызлык, тормыш биргән форсатны кулдан ычкындырмау — адәм баласының иң начар сыйфатлары түгел. Зонадан чыккан кеше башкача фикерли алмый. Үзенчә хаклы. Аны үзгәчә яшәешкә өйрәтмәгәннәр.

— Теге көнне мин аның белән эшләдем.

— Нинди «теге көнне»? Сәнгат үзен урамда тешләгән этне аткан, икенчесен син көпчәк астына алган дүшәмбене күздә тотасыңмы?

— Алай ук тегел. Дөрес сүләмисез!

Сәет аны ишетмәмешкә салышты.

— Сезнең кайларда,ниләр кыланып, башбаштакланып, синең дустың Сәнгатнең маймылланып, милиционер формасы киеп, кеше куркытып йөрүен мин соңыннан гына ишеттем, кем, тәкъсир.

Юри озын итеп, бутап, катлауландырып сөйләде Сәет. Утырудан калган гадәте булса кирәк, әрсез егет бармакларын тартып шартлата. Ә күзләрендә имансыз, денсез салкынлык. Әзерлексез кешене туңдырырга мөмкин.

— Сез нәрсә, абзый! Мине тилебәрән орлыгы ашаган дип беләсезме әллә? Бер шашкан эт ату өчен атналар буенча агач төбендә утыралар диме? Шул көнне, Сездән киткәч, уңышны матур гына чылаттык. Шөреп барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Газетада «Убийство в своем подъезде», «Мафия расправляется» дигән заметкаларны укыдым. Кемне үтергәнебезне дә беләм.

Шөрепкә таянма, суга таян икән. Аның белән иплә кенә араны өзәргә кирәк. Бу егеттән ничегрәк котылырга? Мансур янына озатсаң, сасысы чыгар. Бик яшь тә.

— Сезгә, егетем, миннән, бездән, — ул кулын киң җәеп, биек бетон стенага, тимер белән тышланган капкага күрсәтте, — ни кирәк?

— Эшем өчен түләү!

— Нинди эш өчен?
— Теге абзыйны атарга барганда, машинада мин идем.
— Мин сезне белмим, белергә дә теләмим. Кем белән сөйләшкәнсез, шуның янына барыгыз!
— Шөреп миңа 500 доллар һәм 500 мең сум обищайт иткән иде. Соңгысын отстегнул. Американ акчаларын хуҗаның үзеннән барып алырсың, үземә дә тамызмады, диде. Тиешлемне алырга килдем...
Шөреп үзенә турылыклы калган. Парын төп башына утырткан. Вәгъдә ителгән акчаны биреп булыр иде. Шулай тиеш тә. Ләкин Сәет, иншалла, бу халыкны үгәли күрә. Бу — дәгъваның башы гына. Уркаларны бер ияләштерсәң, алар әрсез урам эте, хәерче чегәннәр кебек тенкәнә тиячәк, ник туганыңа үкендерәчәк.
— Егетнең байлыгы кесәдә түгел, йөрәктә икәнен беләсеңдер, егетем. Бусы — бер. Икенчедән — мин ни өчен сиңа түләргә тиеш әле? Урамда кеше этен таптаткан өченме? Әби сезне эзләп тапса, кирәгегезне бирер әле. Табачак та!
— Ни өчен түләргә? За заказное убийство.
Көлгәндәй итте егет. Янәдән бармакларын шарт-шорт китерде.
— Егетем, кем белән килешкәнсең, шуңардан акчасын да ал! Әгәр тагын бер тапкыр бу йорт тирәсендә күренсәң, баш сөягең әнә шул карачкы янында эленеп торыр,— дип, кош-кортны куркытырга куйган сәләмә бүреккә ишарә ясады.
Ринат йөзен күтәреп, өскә караган арада, Сәет аның ияк астына китереп сылады. Кизәнмичә генә сукса да, Шөрепкә һәм каршындагы егеткә, әшәке дөньясына зәһәр ачуы йодрыкка күчкән иде. Егет тузанлы юлга барып төште.
Бабайның капка тишегеннән карап торганын сизенгән Сәет:
— Әхмәдиша абзый, этне җибәр бәйдән. Снайпер мылтыгын алып чык!
Ринат ялт итеп сикереп торды.
— Юк, юк, кирәкми. Акчагыз да, үзегез дә кирәкми. Чәнчелеп китегез бөтен мафиягез белән! — дип торып йөгерде.
Артык аны Төньяк калавылында күрмәделәр.

## 21

Шәһәрнең иң мөхтәрәм кешеләре, аеруча сәүдә, алыш-биреш тирәсендә эшләүче олылар Мансурны соңгы юлга зурлап озаттылар. Чит илдә ясалган зиннәтле, ялтыравык, үзебезнең «Волга», сигезле, тугызлы машиналар төркеме урамнарда гадәти хәрәкәтне туктатты. Кочак-кочак кыйммәтле чәчәкләр сибелде. Веникларның исәбен-хисабын алып бетерерлек кенә түгел иде. Үзенә шундый мәхәббәтне күрә алса, ресторан директоры нечкәләр шатланыр иде! Юк шул. Үлгән кеше ни сизгәнне без белмәгән төсле, мәрхүм дә исәннәрнең ни кыланганыннан хәбәрдар була алмый.
Берничә кеше чыгыш ясаганнан соң, Сәет сүз сорап алды. Мансурның якын аркадашы, күмүне үз өстенә алган Вильсур Садыков ирексездән Сакмановка сәер караш ташлап алды. Мәет янында бәхәсләшү, сүз көрәштерү кабул ителмәгән. Ярамый. Бу — кешелек буыннан-буынга тапшыра килгән, катгый үтәлә торган кануннарның берсе. Атлантиданы җир йота, соңгы мамонтның сөяге генә кала, Грек, Рим, Чыңгызхан, Аксак Тимер, төрек империяләре җимерелә, таркала, шөһрәтләре риваятьләрнең зәңгәрсу канатында гына саклана, халыклар кырыла, милли телләр юкка чыга, үлеләргә ихтирам дигән язылмаган канун исә көчен саклый, хәрәкәттә кала.
Сәетнең өстендә япон миллионерлары кия торган зәңгәрсу-кара кәчтүм. Гыйнвар кары төсле ап-ак күлмәк. Яшел кыяр төшерелгән тар ефәк

галстук. Үз бәясен белеп, тулы тынлык урнашканны көтеп алды. Матурлык өчен кигән алтын беләзекле кара күзлеген кулына төшерде.

— Кадерле Мансур Маулетович! Барчабызга кыен бүген синең белән аерылышу. Бу коточкыч җинаятькә ышанасы килми. Һәркемгә тормыш бер генә бирелә, аны тартып алырга берәүнең дә хакы юк. Явызлык бездән көчлерәк. Миһербансызлык үзенә корбанга күк йөзендә якты йолдыз булып янган безнең дустыбызны сайлады. Җиһанда Мансур атлы йолдыз сүнде. Аның якты, кешелекле, моңлы эзе безнең йөрәкләрдә мәңге сакланыр. Бу кайгылы минутларда бик күп сөйләп булыр иде. Тик безнең тирән хасрәтне чагылдырырлык сүзләр әлегә табылмаган.

Хуш, Мансур дус! Урының оҗмахта булсын!

Кесәсеннән ап-ак кулъяулыгын алып, күзләрен сөртеп, читкә китте.

Бу көнне табигать Сәеткә сынау арты сынауны җибәрә генә торды. Кабергә вакытлы таш һәм койма утыртканда арада Мансурның анасы килде аның кырына. Ак яулыктан, авызының бер читен генә бушатып:

— Беләсеңме әле, Сәет, улымны үтерделәр бит... Менә күмдек. Кайтмастыр инде.

— Беләм, апа,— дип, тиз генә читкә китте Сакманов... Калтырану китереп бәргән кулларын ашыгып кесәсенә тыкты.

Ярый әле апа аңларлык хәлдә түгел иде аның халәтен. Читкәрәк китеп тә өлгермәде, Сәетнең җиңенә икенче берәү орынды.

— Исәнлектәме, Сәет Яруллович!

Күзе белән күргәнче үк, тән күзәнәкләре белән тойган иде полковникны Сәет.

— О, иптәш полковник! Хәерле көн!

— Бик үк хәерле түгел шул, иптәш Сакманов. Алдан сезнең ярдәмчегез Фердинандны үтерделәр. Хәзер менә Мансур Маулетовичны алдылар.

— Бер үк кешеләр эше дип саныйсызмы?

Мондый сорауны бирергә тиеш түгел иде Сакманов. Аның да күңеле кояшлы көндәге язгы боз шикелле йомшарган. Сизми дә калды.

— Иманым камил, ике үлем арасында тыгыз элемтә бар. Берсе икенчесенең нәтиҗәсе дисәк тә, ялгыш булмас.

— Фердинандны үтермәгән булсалар, Мансур да яшәвен дәвам итәр иде димәкче буласызмы?

— Мин алай украслый алмыйм. Әле тикшерәсе, ачыклыйсы, өйрәнәсе бар. Сезгә бу нәрсәләр мәгълүм.

— Кинаяләр, төрттерүләр белән сөйләшмик әле, иптәш полковник, шундый хәсрәтле көнне булса да...

— Мин үтерүчене барыбер табачакмын, Сәет Яруллович! Ышануымча, сезнең бу эшкә катнашыгыз бар. Табут янында матур сөйләдегез, тик ихласлык җитмәде. Гаепле кеше икәнегезне мин тавышыгыздан сизендем.

— Хөрмәтле полковник иптәш, мин бик күп, бик күп нәрсәләрне сизенеп яшим. Тик аларны папкага теркәп булмый. Хөкем эше ачып та булмый хәтта.

— Мәсәлән?

— Күптән түгел Татарстан кооператорлар оешмасының Киндеридәге складлы янды. Анда 40 телевизор, 80 суыткыч, 10 чит ил гарнитуры һәм тагын әллә нәрсәләрне ут ялап алды, дип яздылар. Сез дә анда булдыгыз. Яндыга саналып, протоколга кертелгән әйберләрнең берсе дә складта булмавы сезгә мәгълүм.

Сәет аңлы рәвештә полковникны Мансур үлеме тирәсеннән читкәрәк алып китте. Ментлардан котылу юлы бер генә: үзең бәйләнү, үзең һөҗүмгә күчү.

— Юкны сөйләмәгез!

— Соң анда «янган» ун суыткычның алтысын бик арзанга үзем сатып алдым. Тик каян алганны әйтмәскә куштылар.

— Димәк, син үзең сообщник?

Сәет ялтыравык ботинкасының үткен очы белән, ташып торган җегәрен кая куярга белми бимазаланган шук малай кебек, кечкенә чуер ташны читкә тибеп очырды да, кәттә күзлегән киеп алып:

— Шул ук янгыннан берәр телевизор, келәм сезнең өйне бизәмиме икән?

— Сез нәрсә сөйлисез? Мин, мин...

— Сообщникларны, бәлки, ерак җәһәннәмнән эзләргә түгелдер, диюем генә.

Полковник, чыгырыннан чыгарга җитешеп, хәленнән килсә, янында атлаган чибәр һәм үзен ифрат иркен, бәйсез, хәтта явызларча өстен тоткан тәкәбберне хәзер үк кулга алып, аерым камерага ташлыйсы килеп тә, шуны эшли алмавына гарьләнеп баруын яшерә алмый.

— Мин үтерүчене табачакмын! Анда сезнең катнашыгыз булуында минем шигем юк,— дип төкерекләрен чәчә-чәчә чын күңелдән ярсыды полковник.

— Сау булыгыз, иптәш Насыров,— диде Сәет, юри кыланып, башын, билен бөгеп. Бер мизгелгә күзләре очрашты. Аларда бер-берсенә мөнәсәбәт ачык чагылган иде.

Фердинандны күмүдә дә катнашкан иде Җәүдәт Габдуллович. Каберлеккә ментны мәрхүмгә уңай мөнәсәбәте алып килмәгәнне сизенде Сәет. Буып ташланган сарыкның итен эзләп бүренең кабат киләсен белә ул. Кайгылы шөгыльдә катнашучылар арасында үтерүчеләрне күзли. Анда да үзе килгән иде Сәет катына.

— Кайгыңны уртаклашам.

— Рәхмәт.

— Сезгә бик турылыклы адәм иде.

— Әшәке кешене үтермиләр. Андыйлар дөньяны сасытып, картаеп, бавыр авыруы белән интегеп үләләр. Фердинанд бәхетле. Саубуллашырга ярты Казан килгән.

Җәүдәт аны бүлдермичә тыңлады. Кайгысы кара болыттай булса да, Сәетнең югалып, йомшап, таралып калырга хакы юк иде. Иптәш полковникның ачыклыйсы килгән мөштере дә бар икән. Сөйләшү көтмәгәнрәк юнәлеш алды.

— Сәет Яруллович, сезнең кыйблагыз бармы?

— Кыйбла барчабыз өчен уртак инде ул. Шул якка карап намаз укыйсы... картайгач.

— Кыйблагыз нинди? Җавап бирегез, мөмкин булса.

— Төсен сорыйсызмы? Тормыш кыйблам сезне борчыймы?

— Соңгысы кызыксындыра мине.

Башын күтәрмичә генә, сәерсенеп, полковник ягына күз салды. Йөзе җитди иде тегенең.

— Кыйблам — йөгәнсез җил. Җилнең төсе юк.

— Җаны бар,— диде Җәүдәт.

— Җилнең җанын эзли-эзли яшь гомерләр үтте инде, иптәш полковник.

— Кешеләрне саклыйсы иде, Сәет Яруллович! Сезнең белән бәйләнмәсә, Фердинандка яшисе дә яшисе әле бу фани дөньяда. Фәннәр кандидаты. Бу корбан — сезнең намуста.

— Ә бәлки, сезнекедәдер, иптәш полковник? Тәртипне мин сакларга тиешме? Мин милициядә эшләгән кеше, беләсез. Җинаятьчене тотып алып килгәч, кем минем кулга сукты? Ахыр чиктә, мине хәзерге шөгыльгә үзегез үк этәрдегез түгелме? Әлбәттә, конкрет сезне күздә тотмыйм.

Сөйләшү ике як өчен дә авыр, төртмәле, түбәнсетүле дулкында чайкалды.

Бүген дә шул ук рухта бара «аңлашу». Үзен күпме генә егетләрчә, бәйсез тотарга тырышса да, Сәетнең кальбендә тырнаклы мәче утыра. Шөреп, этне таптатып, юеш комда аркан эзе калдырган.

Полковник та шуңа киная ясый икән.

— Күрше апа күреп калган милиционерны, машинаны. Яшел иске «Жигули»ны эзләү дәвам итә. Табарбыз без аларны!

— Хозыр Ильяс юлдашыгыз булсын!

Сакмановның саруын кичәдән калган аш түгел, ә үзен туктаусыз күзәтү астында тоткан күрәлмаучан, тынгысыз, явыз күзләр кайната иде. Бу карашның көчле басымын табут алдында нотык тотканда да, полковник белән сөйләшеп барганда тоеп торды Сәет. Бу гадәти кызыксыну, ваемсыз өйрәнү генә түгел иде. Кемдер, әйтерсең лә, аны мылтык мушкасында тота, бармагы — чакмада. Як-якка борылгач, кесәсеннән кулъяулыгын алган, авыз кырыен, күзен сөрткән булып, үз тарафына яман дулкыннар җибәргән кешене эзләде Сәет. Хәрби тәҗрибә, табигый зирәклек, күзенең үткенлеге һәм һәрдаим этлеккә әзер тору ярдәм итте. Тапты ул аны. Читкәрәк китеп, бер каберлекнең тимер рәшәткәсенә тотынган да, Сәетне кармалый. Олыгайган, чәчләре сирәгәйгән, мәгәр үзен танырлык. Сигез ел элек тар-мар ителгән тәп-ләп оешмасының элеккеге җитәкчесе Андрей Северцев, оста сунарчыдай, күзли икән аны. Ара шактый булса да, сизде, күрде Сәет: нәфрәт тулы күзләре җансыз пыяла төсендә иде. Тәненә гүя ток йөгерде. Аның сигез урынына биш ел утырып төрмәдән кайтуы, янәдән Римма исемле уртак танышларында яши башлавы турында хәбәрне җиткергәннәр иде аңа. Мәрхүм Фердинанд та аның хакында тулы белешмә биреп калдырган иде. Димәк, Казан каласында аның тагын бер җан дошманы артты.

Тәп-ләп паханы белән тәүге очрашуы истәлекле һәм дәвамлы булды. Милициядә совет хакимиятенә якты киләчәк бәрабәренә армый-талмый хезмәт иткән дәверендә булды әлеге сәер хәл-әхвәл. Ул Северцовны сөяркәсен тукмап ятканда кулга төшергән иде. Район милиция бүлекчәсеннән хәбәр бирелде: «Синең участокта, Жданов урамында, фәлән йорт, фәлән фатирда бер ир хатынынмы, сөяркәсенме, фахишәсенме тукмый, шунда бар, тикшер, тиздән оператив группа да килеп җитәр».

Бик тиз тапты йортны. Мәче исе аңкып торган пычрак баскычтан өченче катка ташлады гәүдәсен Сәет. Ишек яртылаш ачык. Эчтән шыңшыган, ыңгырашкан, гырлаган сәер тавышлар килә. Бүлмәгә атылып кергән участковый шундый күренешкә тап булды: ут-кызыл җирән чәчле, таза бәдәнле ир күлмәкләре ертылган, изүләре ачык, тулы аяклары ялангач хатынның күкрәгенә тезен куйган да, битен чәбәкли, башын төя:

— Әйт, кая яшердең сөяркәңне? Кем ул? Үтерәм хәзер, сука!

Сәет сыбызгысын эшкә кушты. Яратып башкарган эшеннән аерылып, ир чакырылмаган кунакка явыз караш ташлап: «Ярдәмгә мент чакырдыңмы?» — дип, корбанын ташлап, участковый өстенә сикерде. Тәҗрибәле йодрык Сәетнең битенә сыланды. Хәмер эчеп, хатын белән булышып, явыз ир көчен беркадәр югалткан иде. Яңагы соңыннан кара янып чыкса да, сугуы әллә кем булмады.

Сәет җавапны тиз генә бирә алмады. Олы гәүдәле булса да, ир җиңел сөякле, заманча сугышу алымнарыннан шактый хәбәрдар булып чыкты. Олы бүлмә буйлап, Сәет тирәсендә орчык кебек бөтерелеп йөри башлады. Шул арада эләктереп тә ала. Максаты — дошманын үз артыннан йөртеп арыту, сулыш алу ритмыннан чыгару.

Сәет ачуына, гарьләнүенә түзә алмыйча, үзе бәргәндә, артык кабаланып, хаталар ясады. Ирнең сул йодрыгы янә Сәетнең битенә эләкте. Тәмам ачуы чыгып, милиционер аягын эшкә җикте һәм гәүдәсе белән әйләнгән уңайга тегенең корсагына типте.

Иләмсез тавыш чыгарып ыңгырашып куйса да, албасты аягында калды һәм кискен чүгәләп, башы белән Сәетнең эченә бәрмәкче булды, әмма тизлек җитмәде, өлгерә алмады, ияккә юнәлгән көчле йодрык борынына эләкте, шарлап кан китте. Кан исе нәфрәтенә өстәмә көч бирде. Ирнең кызгылт-соры күзләрендә үтергеч күралмаучан җәһәннәм уты кабынды.

Күрше бүлмәгә йөгереп кереп китте. Аннан пычак белән чыкты. Сәет артка чүкте. Бәхете бар икән, шул мәлдә оперативниклар бәреп керде. Кулына эләккән наган түбәсе салкын коралны зыңгылдап идәнгә төшәргә мәҗбүр итте. Ир бар ачуын, үчен Сәеткә юнәлтте.

— Мин синең арка сөягеңне сындырам барыбер, чоланыңны яндырам,— дип иләмсез, ямьсез сүгенде. Караклар жаргоны, тәп-ләпчеләрнең сүз байлыгы белән таныш түгел иде ул мәлдә Сәет. Күбесен аңламады.— Эзләп табармын сине барыбер, бәдбәхет мент,— дип кычкырырга өлгерде Северцев кулларына ябышкан милиционерлардан ычкынырга маташып.

Сәетнең күңелендә аның ләгънәте белән каргышы бергә буталган сүзләре түгел, күзләре калды. Асфальттагы бәләкәй чокырлар кебек тирәндә утырган бәбәкләре, утлы күмердәй көйрәүле карашы онытырлык кына түгел иде. Менә алар хәзер дә Сәетне капшыйлар, тишәләр, тентиләр, элеккечә үк куралмыйлар.

Ул көнне Сәетне хатын белән сөйләшергә, беркетмә төзергә калдырдылар. Хуҗабикә шул арада өстенә чәчәкле йомшак халат киеп, урыннарын рәтләп өлгергән иде. Төз аяклары, оятсызланып, халаттан чыгып-чыгып куя. Кара тамгалар, кыйнау эзләре битенең матурлыгын, халат якасы — күкрәгенең килешле, теләсә кайсы ир-атны җәлеп итеп, өмсендереп торырлык күркәмлеген яшерә алмый.

Сәетнең тәне авырта, бите сызлый, күңелендә ачу һәм үпкә. «Менә шундый тотнаксыз, әхлаксыз хатыннар өчен ирләр сугыша, пәһлеваннар үлә. Ә минем ни гаебем бар? Ни өчен мин тукмак ашадым? Хуш, теге дәҗҗал утыра, аны онытмаслык итеп дөмбәсләрләр, бу кагыйдәнең үтәлмичә калганы юк. Срок алыр. Шулай да ул хатынның рәхәтен күргән, иреннәренең балын суырган, тулы балтырлы аякларының дәртен тойган. Аңа бик үк үкенечле түгелдер?

Гаепне хатын-кызда эзлә, ялгышмассың, дигән борынгылар. «Монысын да күрше камерага тыгарга унбиш тәүлеккә. Морзе әлифбасы белән серләшеп ятсыннар шунда. Җитте аңа Казан пычрагын җыярга. Квартира алса, милициядә бер көн дә калмаска кирәк».

Сәет, папкасын ачып, тез башына куеп, беркетмә тутырырга керешә.

— Исем-фамилиягез, туган елыгыз, эшләгән урыныгыз...

— Ташлагыз әле, иптәш милиционер, сезнең яңагыгыз сызламыймы, иренегез авыртмыймы? Көзгегә карыйк әле. Хәзер одеколонлы мамык белән эшкәртәм.

Кулыннан алып, коридордагы олы көзге янына алып килде Сәетне.

— Карагыз әле, сезнең уң як каралган, минеке дә. Сезнең күз төбегезгә дә кара дага төшкән, минекендә дә шул. Сезнең борын да балык башына охшаган, минеке дә бәрәңге түгел...

Көлсу чырайлы, зур сыек зәңгәрсу күзле, сөяр өчен яратылган мул тәнле хатынга күтәрелеп карады да көлеп җибәрде Сәет. «Ни чуртыма соң әле мин шундый чибәр хатынга бәйләнеп ятам»,— дип, Римманы үз ягына борды. Тегесе, шуны гына көткәндәй, сусыл иреннәрен Сәет ихтыярына тапшырды.

Җене сөймәгән кәгазь урынына башка беркетмәгә өстенлек бирде егет ул чакта.

Северцев, көнчелегеннән тилереп, Риммадан булмаган сөяркәсен таптырып, үзенә-үзе баз казыган булып чыкты. Аны фатирлар басу, кибетләр талау, машиналар урлау буенча күптәннән эзлиләр икән. Акыллы гына караклар бер дә юктан яналар, пүчтәктән килеп кабалар. Шул шөгыльләрне оештыручы тәп-ләп җитәкчесе буларак, ул сигез елга каты режимлы төрмәгә эләкте.

Жданов-Эсперанто урамы Сәетнең күңеленә хуш килде. Хәтта күчеп тә куйды. Римма үзенең коткаручысын якын итте, тәрбияләде. Бишенче сыйныфта укучы кызы Марина милиционер абыйсының күчтәнәчләренә тиз ияләште.

Римма белән ул ике елдан артык кайгы-хәсрәтсез яшәп калды. Урамда очраган ертык итәкләр артыннан йөгерәсе булмады. Очраклы юлыккан ханым белән матур итеп яшәп китүен дус-ишләре аңламадылар. Нәрсәсе белән бәйләп куя алды икән үзенә гадәти бер хатын, дип аптыраучылар, аны яшьрәк, алар фикеренчә, матуррак хатыннар белән таныштырырга омтылучылары да табылды. Табышмакның җавабын Сәет үзе генә белә.

Римма белән җиңел һәм тыныч. Юк-барга бәйләнми, акча, әйбер сорап йөдәтми, бүләк алып кайтса да, «кирәкми, нигә миңа мондый кыйммәтле күлмәк, алмыйм» дип, инде аны өстенә киеп, көзге каршында биештергәндә дә, баш тарткан булып, ирнең күңелен, рухын күтәреп, зәвыгына астыртын мәдхия юллап, кыланыпмы-кылана.

Хатынның иркәккә рәхмәте кичке затлы аш, йомшак урын, назлы кочак, иркәләүләр, пышылдаулар, ыңгырашу-инрәүләр булып кайта. Төннәрен аз йоклаганда да, иртән ял итеп, үзендә Салсал батырларны җиңәрлек көч сизеп уяна иде. Сәеткә аның күзгә бәрелеп тормаган ягымлылыгы, иркәли белүе, көр күңеле, җанының кош йөрәгедәй лепелдәве, ахыр чиктә, табигать бүләге — мул күкрәге, тулы аяклары ошый иде. Хатынның гадилеге, тормышка, үлемгә аек карашы, теге дөньяда нәрсә буласын да үзенчә аңлатуы, изгелек белән гөнаһка үз бәясе — Сәеткә иң кыен вакытларында, аякка басканда, таяныч булды. Артык гади һәм гадәти фәлсәфәгә таянып яши Римма. «Тормыштан мөмкин булганны алып калырга, күңелле итеп яшәргә кирәк. Башкача ник ипи әрәм итәргә? Йокыны картайгач туйдырырбыз. Һич югында — кабердә. Ул ягы — ходай кулында», — ди торган иде ул.

Бөтие сөймәгән темасы бер генә. Ул — тәп-ләп җитәкчесе белән мөнәсәбәт. Сәет шул хакта сүз каттымы, кайнар теле салкын тимергә ябышкандай була. Бизгәк тоткандай калтырана башлый. Ир затының, серле сандыкны ачасы килеп, кытыгы кузгала.

Иркәләп, тәмле ризык белән затлы шәраб капкалап утырганда да кысып карады Сәет чибәркәен.

— Северцев мине оятсыз рәвештә кулга төшерде... Башкача хутым калмаган иде. Сорама, барыбер артыгын әйтә алмыйм.

— Менә хәзер ул төрмәдән кайтып төшсә?

Сәетне нәрсә борчыганны аңлап алды ханым.

— Сине яратам, Сәет. Бик тә... Ул кайтса, аны кабул итми булдыра алмаячакмын.

— Кыйнап үтерсә дәме?

— Тукмап үтерсә дә. Син дә сак бул, Сәет.

— Ни өчен?

Шактый икеләнеп, ахрысы, күңелендә кайнаган хисләр өермәсен бастырып, ачылырга, туарылырга булды. Ярата иде ул Сәетне.

— Миңа аның бер хаты килде.

— Соң, мине ул хат борчырга тиеш дип уйлыйсыңмы?

— Кызма әле син, Сәет. «Мин иректә калган егетләргә, аларның яшь дусларына сине яклаган милиционерның эзенә төшегез дә, үчне алыгыз, дигән фәрман төшердем. Эшеннән куганнар икән аны. Мастерской төзегән. Шуны пыран-зыран китерттем. Безнең очрашасылар алда әле. Мин соңгы сүземне әйтмәдем», — дигән. — Ул, Сәет, бернәрсә алдында да тукталып калмый торган коточкыч кеше. Әгәр мин аны кабул итмәсәм, ул кызымны, нәселемне, сине юкка чыгарачак. Бу халәтем — минем язмышым, тәкъдирем, йолдызнамәм...

Бу сәер аңлашудан соң, мөнәсәбәтләренең бер кырые калҗыды, аннан кителеп төште. Риясызлыгы, гаҗизлеге өчен Римманы гомере буена хөрмәт итеп, ярдәм кулын сузып яшәсә дә, үзен кешегә санамаган, көпә-көндез буып үтерә язган Андрей Северцевка илаһи, мифик, үлемгә әзер мөнәсәбәтне, күпме тырышса да, ахыргача аңлый алмады. Курку хисеме, теге дөнья мәхәббәтеме, үтә чыккан женси бозыклыкмы?

Иң олы серләрне хатын-кызга якынлык аша гына белеп була, диләр. Хак сүз икән. Римма аша үзенең җан дошманын белде, мебель цехын тар-мар итүнең сәбәбен ачыклады.

Милициядә чын күңелдән, тырышып, ышанып эшләгәне өчен күпме түләргә була?

Югарыдагы сөйләшүдән соң да, Сәет әле Риммада яшәп калды. Һәр ләззәт өчен адәм баласына бер түлисе була. Аерылышулары башка сәбәп аркасында, шактый сәер килеп чыкты. Вакыты житкән, сәгате суккан булгандыр, күрәсең.

Гадәти бер кышкы кичне эштән кайтып кергәндә, бөтен мөлкәте сыйган ике олы чемоданын ишекнең тышкы ягында тапты Сәет. Шалтыратып, тавыш күтәреп маташмады. Күтәренде дә, шыпын-шыпын аска кетәкләде.

Урамда йөгерүдән, каушаудан, каударланудан тыны кысылган Римма куып житте:

— Гафу ит, Сәеткәем, Маринаның әтисе кайтты. Кыз үзен бик ярата. «Әти белән яшисем килә»,— ди. Янәшә атлый-атлый, өстәп куйды: — Теләсәң, очрашып яшәрбез.

Сәет, чемоданнарын җиргә куеп, ялварып, өметләнеп торган хатын ягына акаеп карады да:

— Кирәкми. Әллә... синдә генә дип беләсеңме!

Соңыннан үкенде. Никахлы ирен, кызының атасын кайтарган өчен Римманы битәрләргә аның сукыр тиенлек хакы да юк иде. Хатын-кыз кирәк вакытта файдаландыңмы? Рәхәтен күрдеңме? Рәхмәт әйтә бел, Адәм белән Хава нәселе.

Римманың ире белән бәлеше пешмәде. Кискән икмәк кире ябышмый. Бала өчен генә яратмаган кешең белән гомер итеп булмый икән.

Сәет тә, бер суга ике тапкыр кереп булмый, дигән ышанычта яши торган кешеләрнең берсе иде. Риммага кире кайтмаса да, аңа кешелекле, самими җылы мөнәсәбәтен саклады һәм кызы нарасыйның, дөресе, яһүд һәм татар каннары аралашуы җимешенең, бандитлар кулына төшүен җаны-тәне, бөтен барлыгы белән теләми иде.

Тәп-ләп хуҗасы кырында сылу каен җиләге басып тора. Аны танығач, Сәетнең йөрәге жу итеп китте. Кыз — Римманың унберенче класста укучы бердәнбер баласы Марина иде.

Ни арада үсеп тә җиткән. Үтәкүренмәле күзләр, кабарынкы бөркү иреннәр, күкрәкнең ачык өлешләреннән, аяклардан сизелеп тора — нәкъ Лолита тәне... Йомшак песи баласыдай... Северцевны да гаепләп булмый. Нинди ир-ат мондый ләззәтле ризыктан үз ихтыяры белән баш тартсын, ди. Тәнендә җаны булса. Әхлак мәсьәләләренә килгәндә, аларын бит язган кеше үзе дә үтәми булыр. Кәгазь түзә. Ул — җансыз.

Сәетнең алар ягына караганын сизеп, күреп, Северцев кулын кызның көянтә биленә салды, үзенә тартты. Тегесе карышмады. Бандитка инде төсе уңган Римма кирәк түгел иде.

Полковник белән салкынча гына саубуллашып чыгып, берничә урам узгач, Замирга машинасын туктатырга кушып, автоматтан Римманың эшенә шалтыратты.

— Римма, исәнме! Бу — Сәет әле.

Бухгалтер ханым бик шатланды.

— Сәет, ни хәлләрең бар? Бер дә күренмисең, сагынып беттем.

— Марина өйдәме?

Чыбыкның теге башында сорауны үзләре теләгән юнәлештә аңладылар.

— Өйдә юк. Мин дүрттә булам. Кил, яме? Яраткан кыстыбыеңны пешереп куярмын.

Сәет хатынның ваемсыз, әмма чын йөрәктән яратып лыкылдавын игътибар ноктасена үткәрмичә, үз яссылыгын каерды:

— Марина кая дип сорыйм?

— Син нәрсә, Сәет? Марина да, Марина... Иптәш кызлары белән өченче көн Мәскәүгә китте. Бер атнага. Кичен сугыласыңмы?

— Марина беркая да китмәгән! Ул — Казанда. Бүген күрдем. Хуш!

Артык берни әйтмичә, трубканы куйды. Маринаны кызганды Сәет. Әүз кызы кайларда йөри, кем кулларына барып керде икән? Июльдә аңа унсигез тула.

Күз алдында тормаган йөрәкне артык тырнамый икән шул. Үз баланны онытып, кешенекен кайгыртып йөрисең. Үзеңнекене үзәктә, кешенекене кештәктә булырга тиеш тә бит. Нишлисең... Дөнья бу.

## 22

«Игелек»нең генераль директоры, Шөрепне Мәскәүдә качып ята, дип фараз кылып, нык ялгышты. Ул анда бер атна да тормады. Танышлары табып, аны Чаллы, Алабуга якларына алып кайттылар. Янә милиционер формасына киендерделәр, кулына чит ил пистолетын тоттырдылар, кемгә атарга икәнен күрсәттеләр. Эшне башкарганнан соң, кулына акча куеп, Казанда ташлап калдырдылар.

Теләсә кайсы җан иясенең үз оясы була. Ул анда яраларын ялый, ял итә. Кеше калебе, кан тамырлары, тән җепселләре табигый халәтенә кайтканнан соң гына хәрәкәткә күчә ала. Шөреп тә шыпырт кына бер бүлмәле фатирына кайтып төште (ул аны үзенә сатып алган иде инде), хатынына гына хәбәр итеп, яшертен рәвештә бикләнеп ятты. Дөньяда ул беркемгә кирәк түгел. Кыен мизгелләрдә хатыннан да якын кеше юк икән, дигән иманга килде Шөреп.

Бүген ул куркынып уянды. Чебеннәр пычратып бетергән көзге каршына басып, үзен өйрәнде. Тар маңгай, эчкә баткан сары алмалы күзләр, җилкәгә үк сыланып утырган имән муен. Көзгедәге адәмне ошатмады. Соңгы вакытта күп эчкәнлеге күренеп тора. Үтүк кирәк, дип ямьсез елмайды. Бүген яхшылап кырынырга икән. Иртәгә элеккеге тәп-ләп албастылары белән очрашасы. Алда бик зур эш тора, диделәр. Регина белсә, тау кәҗәседәй үрле-кырлы сикерер иде. Шул манзараны күз алдына китерде.

Шул арада Регина уянып, җәһәт кенә ире янына килеп басты.

— Иртәгә бурычны алырга барам.

— Нәрсә, берәрсе акча алып торган идеме? — дип сорады Регина, күңеле нидер сизенеп. Яхшыны да, яманны да хатын-кыз, киптергеч кәгазь төсле, бик тиз үзенә ала.

— Юк ла! Сүз акча турында бармый.

— Ә нәрсә тагын?

— Регина, мин куркам. Син мине бик кыю, тәвәккәл, елгыр кеше дип уйлыйсыңдыр. Мин — куркак кеше. Куяннар нәселеннән. Йолдызнамә буенча да шулай.

Үзе көлгәндәй итте. Тешләрен күрсәтеп, иреннәрне еру гына килеп чыкты.

— Сине коткардык. Хәзер безгә ярдәм итәргә вакыт, — диделәр.

— Шулай мәңге бер-берегезне сакалдан тартып йөрерсезме? Тагын кемнедер алырга кирәкме?

— Бер депутатны җәһәннәмгә озаттык. Кем икәнен дә тәгаен белмим. Депутат булганы өчен түгелдер, дип уйлыйм. Кемнеңдер бугазына сөяк булып кадалган, юлына аркылы төшкән бугай.

— Сәнгат кадерлем, тыңла тиле хатыныңны. Ахыр чиктә, бердәнбер якын кешеңне. Ташла син бу шөгылеңне. Кеше үтерүдән башка һөнәр юкмы? Теләсәң, киттек башка җиргә күчеп. Себергә, Уралга, Камчаткага...

«Милиция полковнигы кызы булып та берни аңламый, — дип уйлап алды Шөреп. — Алардан беркая да качып котылып булмый. Тәсбих төй-

мәләре төсле инде без, бер җепкә тезелгән. Берәү оештыра, куша, минем кебек мәхлүкләре пычрак эшен башкара. Аерма шунда гына: эләксәк — миңа унбиш, аларга бишәр ел Лаеш шулпасы».

— Алар мине эзләп табачак. Сатачак. Соңгысы дип әйттем инде.

— Синең, Сәнгат, гаиләң бар. Шул хакта уйладыңмы?

— Нәкъ менә шуның өчен ризалаштым да. Үзем генә булсам, баш тарткан, качып яткан булыр идем. Үчне синнән алачаклар.

Шөреп чөйдән курткасын алды, култык астына кыстырды, көрт басып киткән, кырда ялгыз утырган агач төсле, бүлмә уртасында катып калган Регина янына килде, үзеннән озынрак хатынының җилкәсенә башын куйды, көрсенде дә тиз-тиз атлап чыгып китте. Ул көнне урамны, йортны өйрәнделәр, җәһәннәмгә олагырга тиешле кешене хәтерләделәр.

Икенче көнне дә Шөреп үзенә урын таба алмыйча бүлмәсе буйлап арлы-бирле йөренде. Регинасы бүген килмәде. Әүвәл ни өчен саруы кайнаганны, йөрәге янганны аңлый алмый интекте. Күңелен игәүләп торган галәмәтнең Зөлфия икәнен танырга теләмәде. Анын мул күкрәкле Регинасы Зөлфиядән киммени? Һич юк! Ә шулай да ул Зөлфияне ярата бугай. Җанында яра булып кала, аның өчен генә яши бит Сәнгат. Аракысы бетте. Йөзенә ят елмаю иңде. Ул Зөлфиянең билендә, туры аркасында, төз аякларының дәвамы — артка чыгып торган кабартмаларында, Венера калкулыгында Сәетнең кулларын күз алдына китереп, бөтенләй чыгырыннан чыкты. Ачуы, яман шеш төсле, кабарды, утлы казандагы көнбагыш маедай котырынып-котырынып кайнады. Хәзер Пахан-Сәет Зөлфияне кочагында эретеп ята булыр. Бөтен тәне буенча салкын судан чыккан этнекедәй эре калтырану узды.

Аның Зөлфия турында уйларга, хыялланырга хакы юклыгын да аңлый. Теге вакытта Регина дөресен әйтте. Зөлфия аның кебек сасы авыз өчен ярагылган мал түгел. Шулай да ир кеше үзенә, нәфесенә, китереп кыскан теләгенә хуҗа була алмый. Адәм баласы шулай яну-көюләр, хәсрәт-сызланулар өчен туа, күрәсең! Ниятен гамәлгә ашырмас булгач, ник тудыра аны дөньяга ходай тәгалә? Бәхетсезләрне, ятимнәрне, явызларны гел таптырмасын иде ул хатын-кыздан! Ни өчен мондый гаделсезлек, тигезсезлек яши? Шул ук Сәеткә-Паханга барысын да — байлыгын да, чибәр хатынын да алдына чыгарып куйган. Шөреп аңардан кай ягы белән ким? Бус тәбәнәгрәк. Шул гына.

Җирдә бирмәгән мәрхәмәтне тәңребез теге дөньяда кайтармакчы буламы? Юк, Шөреп разый түгел. Аңа барысы да фани яшәештә, бүген кирәк!

Бугазына килеп бөялгән хисләр өермәсенә, җанына үрләгән бушлыкка түзә алмыйча, Шөреп урамга чыкты. Аяклары кая атлаганга башы җавап бирмәде, томанлы күзләре ишек такталарына, кирпеч биналарга сугылган исемнәрне укыды.

Тамагы кытыклавына һәм эчке чакыруга буйсынып, ул «кафе-ресторан» дип язылган бинаның эченә үтте. Халык күп түгел. Аккордеон, гитара һәм кларнеттан торган оркестр тавышны җитәрлек чыгара.

Көндезге уникеләрдән эчә башлаган Шөреп, бер чәркә җибәрүгә, исереп китте. Ул атнаның көнен исенә төшерергә газапланды. Бүген җомгамы, әллә ял көнеме? Юктыр, бүген сишәмбе көндер, якшәмбедә ресторан халык белән шыгрым тулы булыр иде.

Ул тирә-юненә күз салды. Янында фюрерныкы төсле борын тишеген генә каплаган, тырпайган мыеклы, утыз яшьләрдәге бер ир ниндидер соры сыекча эчеп утыра. Каядыр күргәне бар шикелле, исенә төшерә алмый Шөреп.

— Нинди көй уйный оркестр?

Тыгыз тиреле, очлы битле ир сискәнеп куйды:

— Нәрсә дисез?

— Оркестр нинди көй башкара, дип сорыйм.

— Әй, барыбер түгелмени?

— Барыбер булса, ат урынына койрыкны кешегә тагарлар иде.

Уңышлы шаяртуыннан канәгать калып, Шөреп эре, сары тешләрен күрсәтеп рәхәтләнеп көлде. Күршесе аңа ошамый иде. Дүрт кырлы ияге ямьсез булып алга чыгып тора. Җитмәсә әле борын астына шәмәхә мыек ябыштырып куйган. Үзенә бөтенләй килешмәгәнне белми микәнни. Шөреп алдындагы аракысын эчеп куйды. Өлеш тарелкасында яткан салатка орынмады да.

— Сезнең тарафларга мыекның килешмәгәнен беләсезме икән? Кырып атыгыз! — дип, Шөреп әмер теленә күчте.

Күршесе җавап бирмәде. Залны күзәтүендә булды. Шөрепнең бөтен гәүдәсенә каршындагы ирне күралмау, явызлык, дошманлык чыкты.

— Кеше хатынына карап, селәгәй агызып утыру килешми.

Шөреп тагын рәхәтләнеп кычкырып көлеп җибәрде. Чираттагы чәркәсен эчкәндә күзен күршесенең мыегыннан алмады. Кая күргәне бар аның бу иякне? Берне сыласаң, бераз тураер иде.

Ерактан, мыек тарафыннан акрын гына тавыш килде:

— Тыныч кына утырыгыз. Артыгын кыланасыз. Төрмә ишекләре сагынып елый булыр үзеңне.

— Чит хатынга озак карап утыру килешми!

Шөрепнең кыланышларына шактый түзгән күршесенең, ниһаять, сабыр сабы ычкынды. Ияк астына китереп сылаганны Шөреп сизми дә калды. Урындыгы белән барып төште. Башына утын пуләне белән китереп бәргәндәй хис итте үзен. Шулай да торды һәм үзен рәнҗеткән кеше өстенә китте. Әмма якын-тирәдә берәү дә юк иде. Очлы иякле, мыеклы ир юкка чыккан. Әллә берәр җен пәрие генә булдымы?

Юк, әнә килә. Үзе генә түгел. Берничә фуражка иярткән. Шөрепне култыклап алдылар.

— Җибәрегез. Минем эчеп бетермәгән аракым калды. Кем башка бәрде? Алыгыз бу мыеклыны, мине калдырыгыз...

Явызлык үче күзенә кан булып төшсә дә, Шөреп көчсез иде. КГБ майоры Насих Санчиевнең ыргаклы мускулына каршы тора алган кеше юк иде әле татар җирендә.

Алып барган төштә Сәнгат-Шөрепне бик тиз таныдылар. Сөекле этен югалткан әбинең, депутатның исән калган йөртүчесенең сөйләүләре буенча ясалган рәсемдә нәкъ ул чекрәеп утыра. Төрмә аны, чыннан да, көтеп, күптәннән сулкылдап-сулкылдап елый икән инде.

## 23

«Сәгать бергә әбәдкә өйгә кайт», — дигән иде Зөлфиясе. Сакмановның вакытны уздыра алмый утырган көне иде. Кремль курантлары уникене сукканда, япон аппараты, трубканы күтәрәсе, дигән хәбәр җиткерде.

Подполковник Салих Гаяров шалтырата икән. Аның үзен тәкъдим итү, сөйләшү рәвешен беркем белән бутап булмый.

— Мин әле бу. Срочно күрешәсе бар.

— Төньяк калавылында очрашыйкмы?

— Ярамый. Ленин урамындагы радиотоварлар кибете каршында, сәгать бердә... Машинада гына сөйләшеп алырбыз.

— Хоп. Вакытында шунда булырмын.

Милиция әһеле сөенечле хәбәр әйтү өчен чакырмас очрашуга. Салих белән аерылмас дуслар булып киттеләр дисәң, кирәкмәгән мактану булыр: бер-берсенә кирәк иде алар.

Гаяров тормыш ләззәтләрен, дөнья бизәкләрен ярата, вак-төяк күңелсезлекләр өчен картаймый торган, «калын тиреле» замана кешесе иде. Хаким оешмада эшләү чорында йөзе тупаслана, холкының кырыслыгына ишарә итеп, ияге алга чыга. Чынында ул шундый ук кеше. Үзе теләгәнчә

яшәү өчен, аңа Сакманов, Ваһапов, Башорин, Бабурин кебек кешеләр, дөресрәге, аларны үз янында тоту кирәк иде.

— Салих элеккеге танышы белән, «латыш укчыларына» тәмле-томлы ризыклар ясау өчен зарури коры сөт озатып ятканда очрашты. Сәет зур сумма тәкъдим итте. Гаяров, акчаның каян килгәнен сорап тормады, алды. Ни өчен бирелгәнен белгәч, шул җитмәгәнмени.

— Кәгазьләреңне күчереп яз. Үзеңнең имзаң, исемең калмасын! Саграк эш ит, ышыктарак калырга тырыш. Җаваплылыкны күбрәк шәүләләреңә йөклә! Нишләп әле барыгыз да, идрит-кудрит, Казанга ябыштыгыз? Шул ук сөтне Алексеевскида, Яңа Чишмәдә эшләп чыгаралар. Авылны талавы ансатрак.

Шул көннән алып, милиция подполковнигы «Игелек»нең рәсми булмаган яклаучысы, «крышасы», хәтта шымчысы, киңәшчесе булып китте. Дөрес, үзенә тиешле өлешне арттыра барырга да онытмады.

Салих белән артык якынаерга тимәде Сәет. Тарихчылар нәрсә диләр әле: кытайлар белән дус яшә, тик аерым-аерым тормыш ит; кытайлы белән тулы аңлашу, якынлашу, аралашу өчен үзеңә шул халык вәкиле булып туу шарт.

Салихның кара-кучкыл, озынча йөзе ифрат борчулы иде. Кыска җиңле күлмәкне аксыл чалбарга кыстырган. Алты потлы гәүдәсен арткы утыргычка урнаштыргач, фәрман бирде:

— Аккош күле ягына киттек.

Сәет каршы килмәде. Машинасында, гадәттәгечә, затлы коньягы, капкаларга ризыгы бар. Салихның болай гына ычкындырмасын белә. Холкы шундый: юк-бар хәбәренә серлелек биреп, анысын да бер-ике шешәне бушатмыйча әйтми интектерер. Тик бу юлы башкачарак тотты үзен өлкән әфисәр.

Машинаны тыныч кына урынга куеп, Замирны һава суларга чыгарып җибәргәч, Салих бөтен шартын китереп күрсәнеп куйды:

— Бик үк күңелле булмаган хәбәрләр алып килдем үзеңә, Сәет Ярулловиv.

Үткен пәке өстеннән йөрергә күнеккән Пахан коелып төшмәде. Кырмызы тавыш белән генә сорап куйды:

— Тагын нәрсә җимерелгән? Бастилияне алганмы әллә минем башкисәрләр? Президент исәндер бит?

— Җимерелгән шул, егетем.

Салих аңардан биш-алты яшькә олырак иде. Шуны гел ассызыклап яшәде.

— Җәүдәт Габдуллович сиңа каршы эш башларга рөхсәт алырга бер-ике атна элек, министр урынбасарында булды.

— Каян беләсең?

— Приемга язылгач, үзе минем белән киңәште. «Туйдырды бу мафиянең башбаштаклыгы. Нәрсәдер кылырга кирәк. Кешеләрнең күзенә карарга оят. Рөхсәт ала алсам, үзем барам Сакмановны җәтмәгә эләктерергә. Кулыма килеп керсә, телен ачтыра белер идем. Миндә аңа каршы документлар җитәрлек. Районда КамАЗлар белән бер каптырган идем инде. Бу юлы ычкына алмас»,— дип ярып салды.

— Нәрсә эчәсең?

— Илле грамм әрмән коньягы сал. Эшкә сугыласым бар әле. Җәүдәтнең гадәте начар. Борынын авызга ук китереп тыга. Үбешергә җыена диярсең.

— Добро ала алганмы?

— Юктыр, замминистрдан бик кәефсез чыкты. Сөмсере коелган, сугышчан рухы шактый шиңгән иде. Үзе керде минем бүлмәгә. Бик озак тәрәзәгә, Черек күлгә карап басып торды да: «Мансурны үтерүне оештыручы Сакманов кына. Шул киллерны тотсам, пенсиягә китәм»,— дип шактый озак сөйләнеп торды.

— Ни өчен Мансурның үлемен шулай күңеленә якын алган әле?

— Ул хәтлесен үзем дә аңламадым. Мал бүлешүдән чыккан гадәти үтерү. Көн саен булып тора,— диде Салих, җилкәсен сикертеп.

— Миңа зиратта да бәйләнеп маташты. Кулы кыска. Министр урынбасары алдан күрүчән, гадел кеше, башбаштаклыкка юл куймас. Тагын нинди яңалыгың белән чәчне үрә торгыза аласың?

— Шәреп бездә утыра.

Үзен кулда тотарга, бернәрсәгә дә гаҗәпләнмәскә өйрәнгән Сәет урынында сискәнеп куйды. Астан ток җибәрделәр диярсең.

— Шаяртма, Салих. Шөреп Мәскәүдә яши. Әгәр аны Мансур белән бәйләргә уйласагыз, ялгышасыз. Ул күп элек киткән иде башкалага. Билетларын тикшерә аласыз!

— Ничек уйлыйсың, яраткан Шурупчигың кесәсендәге кәгазьләре, билетлары, чурты-мурты буенча Мәскәүдә саналып та, Татарстанда кеше үтереп йөри алмыймы?

Салих, җәенке кашларын уйнатып, маңгай җыерчыкларын биетеп алды. Кискен итеп әйтте:

— Буш гоманны калдырыйк! Мин малай-шалай түгел. Шөрепне аерым камерада саклыйлар. Янына кердем. Бик нык изгәннәр үзен. Карарга куркыныч.

Сәеткә тәэсирне көчәйтү нияте белән, җентекләп, тәфсилләп тәкрарлап бирүне кирәк тапты.

— Битен куе каннан торган боламык иткәннәр. Күз бәбәкләре яңгыр гөмбәсе төсле шешенгән. Шартлаган иреннәннән аккан кан елгачыгы йон үскән иягенә, ертык күлмәгенә агып төшкән.

«Нишләп шулай җирәнгеч ваклыкларга туктала? Мине өркетеп алу өченме, бәясен күбрәк кую максаты беләнме? Киленем, сиңа әйтәм, кызым, син тыңла, дигән сүзе түгелме ментның?»

— Күрдем мин Шөребеңне,— дип, һәр сүзгә чүкеч белән сандалга суккандай басым ясап дәвам итте.— «Тагын шулай кыйнасалар, мин түзә алмам. Аларга нәрсә кирәк, ничек кирәк, барысын да әйтәм, теләсә нинди кәгазьгә кул куям, тырнак асларына энә генә кадамасыннар, аркада тәмәке төпчеге генә сүндермәсеннәр»,— дип кычкыра. Бу сүзләрне ул сиңа тапшыру өчен әйткәндер, дип уйлыйм. Сал әле тагын илле грамм.

Уйланырлык нәрсәләр бар иде Гаяров сүзләрендә. Димәк ки, Шөреп-Сәнгат аны тыңламыйча, әйткәнне үтәмичә, бу якка кайтып, тагын нәрсәдер кылган. Милиция кулына эләккән. Ялгыз камерада аның авызын ачтырулары табигый. Сорауны Ежов белән Берия кебек җәлладлар алганда, телсезләр дә телгә килә, диләр.

Шөреп күп белә. Сүздән чыккан, тәртип бозган өчен җир йөзеннән югалырга тиеш. Тик ничек, ни рәвешле? Анысы шулай ук милиция эше. Сәет башын ватып утыра торган мәсьәлә түгел.

Авыр тынлык пәрдәсен «Игелек» ширкәтенең җитәкчесе күтәрде.

— Шөрепне алырга кирәк!

Салих үтә гаҗәпләнгән булып, янә куе кашларын уйнатып, кул кабыргасы белән алгы утыргычның аркасына шап-шоп сугып алды.

— Ничек? Ни формада күз алдыңа китерәсең инде бу гамәлне?

— Үтәлү рәвеше синең хыял очышыңа бәйле. Мин үземнән өлеш кертә алам,— дип, машинаның бардачогын ачып, озын, ефәк бау алып, подполковникка тоттырды.

— Әйтик, кемдер бу нәфис җепне аның оясына ташлый, ялгыш төшереп калдыра.

— Кемсәдер аның очын тартып торырга тиеш, абзыкай.

Сәет, җиденче тоемы белән, сумманы билгеләү вакыты сукканны сизде.

— Ике бакса җитәрме?

— Усал шаяртасың. Ике мең долларга яллап кара үтерүчене.

— Гади киллерне күндереп булыр иде дә,— диде Сәет киная белән.

Аның төрттеруен кабул итмичә, Гаяров булачак операциянең авырлыгын бәян итә башлады.

— Ул — гади кеше генә түгел. Шуруп — саморез. Тиле көчкә ия. Аны-сы сиңа мәгълүм. Ягъни бирәү генә аны җиңә алмый. Мин кимендә ике кеше ялларга тиеш булам. Аларның өлеше... Аны бик нык саклыйлар. Шуны да истә тотып, бишне сал.

— Риза. Яртысы бүген, калганы — соңыннан.

Сәет үзенең болай гына котылмасын белеп, сүз өчен генә әйтте.

— Барысы да хәзер кирәк. Юкса, мә бавыңны!

Салихның тавышы кырыс иде.

Сәет кулын сузды. Тегесе кискен хәрәкәт белән учына сугып кына алды да, әйтергәме икән, юкмы икән дигәндәй уйланып торды, кискен тавыш белән ярып салды:

— Син юкка Шөреп белән бәйләнгәнсең. Башканы ялларга иде. Ул тагын бер пычрак эштә катнашкан булып чыкты. Матбугатта укыдыңмы икән, бу арада гына Алабуга-Чаллы арасында бер бизнесменны, Кафиятуллинныммы, Гатиятуллинныммы атып үтерделәр. Бу эшне Шөреп башкарган. Милиционер киемендә булган. Ничә әйттем мин сиңа, котыл ул балбестан, дип. Үзсүзләнден.

Әмәт тавына ай төшеп утырса да, исе китмәс Сәет өчен бу яңалык шактый вәсвәсәле иде.

— Анысын кем күргән дә, кем әйткән?

— Машина йөртүче исән. Аның төсен, битен, буен чамалап кала. Шоферларда тышкы дөньяга хәтер ифрат көчле. Эре тешләрен дә хәтерләп калган, диләр.

Сәет Тәварихы халәтенең мөшкел генә түгел, үтә хөрти икәнен тәгаен күзалласа да, шаяртырга көч тапты.

— Соң хәзер ул тешләр юк дисең ич инде. Теге дөньяга алтыннан куйдырып озатырбыз.

Милиция әһеле юморны урынсыз тапты бугай. Кабул итмәде.

— Шөреп милициягә килеп капкач, шофер сөйләве буенча ясалган рәсем күзенә чалына кизүдә торучы лейтенантның. Йөртүчене чакыралар Алабугадан. Шөреп менә шулай капкынга килеп эләгә. Эте тапталган әби дә таный үзен.

— Нәрсә белән килеп капты соң ул сезнең кулга? Валлаһи, дим, Мәскәүдә булырга тиеш иде бу көннәрдә Шөреп, — диде чарасыз калган Сәет.

— Ул хәтлесен әйтә алмыйм, Сәет Яруллович. Чапай әйтмешли, не копенгаген.

Бу очрашу авыр тәэсир калдырды Сәетнең күңелендә. Шөрепне дә кызганды. Аны туктаусыз авыр үкенү хисе әзәрлекләде. Янында Зөлфиясе булып, ул аның җанына җылылык бөркеп тормаса, Сәеткә күп тапкырлар кыенрак булыр иде.

Тышкы дөньяның фаҗигале хәлләреннән хәбәрдар булмаган Зөлфия, матур тезләрен итәк астына алып, диванга менеп кунаклый да, Сәеткә вәгазь сөйләргә, әхлак дәресләре бирергә керешә. Ир уртасы да эчкерсез, гади, самими уенга кереп китеп, онытыла, ял итә.

— Мәхәббәт, Сәетҗан, мин сиңа әйтим, җитди нәрсә.

— Кит аннан! Кем әйткән бу акыллы һәм тиле фикерне?

— Мин, — ди Зөлфия җитди итеп һәм шул ук дулкында дәвам иттерә: — Читтән караганда, канаты мәхәббәт утында көймәгән күбәләккә ярату шашып торган бәхет, сөенеч, йолдызлар арасында йөзү кебек кенә күренсә, кем өчендер сөю — йөрәк ярасы, бәгырьләрне көйдерә торган зәһәр ут.

— Бик каты, коры утын кебек, дөрләп янамы инде ул? — дип сүз кыстырырга тырышса да, Сәетнең шаяртуын мәслихәт күрмичә, ханым үз фәлсәфәсен үстерүне дәвам иттерә.

— Мәхәббәт сирәк кешегә тәти торган кичереш ул, Сәетҗан! Адәм балалары бергә яши, күнегә, балалар үстерә, мәхәббәтнең нәрсә икәнен белмичә, зәңгәр күк гөмбәзен ташлап та китә.

— Мин үткән ел автомобиль авариясендә үлеп калган булсам, мәхәббәтнең нәрсә икәнен аңышмыйча, оҗмахка ычкынган булыр идеммени?

— Мәхәббәт сафлыгын, ләззәтен татыган кеше — бәхетле. Марксизм-ленининизм тәгълиматында бәхет төшенчәсенә аңлатмалар биреп маташалар. Ул, имеш, халыкка хезмәт итү, якты киләчәк, коммунизм идеаллары өчен яшәү. Чүртым,— дип Зөлфия матур кулы белән һаваны кисеп төшерде.— Дөньяда берәүне өзелеп яратсаң, яраттыра белсәң, аңа һәрдаим кирәк булсаң, син бәхетле.

— Мәхәббәттә иң мөһиме нәрсә? — дип комагайланып сорау бирә «Игелек» генераль директоры.

— Һәрхәлдә, сез табынган байлык түгел,— дип кырт кисә Зөлфия.

«Минем матурым тырма телле була белә икән,— дип сөендереп ала күңеленә Сәет.— Үзен рәнҗетергә бирмәс».

— Ә нәрсә? Миңа бу сер мәгълүм түгел.

— Рухи якынлык.

Шаярта-шаярта, кызый җитдирәк темага кереп китә.

— Минем өчен байлыктан, малдан, затлы машинадан өстен нәрсә юк, дип саныйсыңмы, балакаем? — ди Сәет.

— Кара машинаңа, яхшы фатирыңа, алтын-көмешеңә кызыгып кияүгә чыкты дип уйлый күрмә! Әлбәттә, алары да... кирәктер. Хәерчелек мәртәбә саналган заманалар үтеп бара төсле, шөкер.

— Мал-мөлкатемә исең-акылың китмәгәч, нәрсәм белән синең тутый күңелеңне яулап алдым соң? Яратуың хакмы?

Зөлфия, иренмичә, диваннан төште:

— Әйтимме дөресен?

— Алдашмасаң, теләсә нинди затлы бүләк алып бирергә риза.

— Вәгъдәңдә тордың! Кысылган пружина кебек гәүдәң, егетләрчә тотуың җәлеп итте. Кара чәчләреңә бәс кунган, затлы тоз кебек матур ялтырый ак чәчләрең. Алары да килешеп, ышандыру көчен арттырып тора. Күзләрең белән сүзләреңне яраттым. Аннан инде барысы бергә буталды. Хис дигән нәрсә йөрәкне китереп кысты.

— Шуннан,— ди Сәет,— үзенә бәяне ошатып, мөкиббән китеп, дәвамын көтеп. Хатын-кыз ярты сүздән туктый белер, барыбер соңгы тиенен чыгарып салмас.

— Шул буталудан карабодай боткасы peшrе. Кулларыңны юып, табынга рәхим ит, Сәетҗан әфәндем.

— Тагын бер соравым, киңәшем бар,— ди хуҗа.

— Рәхим ит! — Зөлфия үз бәясен белгән укытучы кыяфәтенә керә.— Урысның иң зыялы язучыларыннан берсе, минем яраткан шагыйрем Иван Бунин, мәхәббәт өлкән яшьтәге кешеләрдә, җиргә якын затларда, димәк, крәстияннарда гына була, дигәнрәк фикер әйткән. Мин сүзләрен яттан, эзмә-эз әйтә алмыйм. Әмма фикерен дөрес китерүемне өстемә алам.

Зөлфия алдан Бунин белән бәхәскә керергә, аны язучы буларак кылануда, хәтта кәперәюдә, ахыр, туган иленә кайтмыйча, читтә үлемен табуда гаепләргә җыенса да, соңыннан шаяртып котылырга булды:

— Ул, гомумән, абстракт, коллектив мәхәббәтне күз алдында тоткандыр?

— Коллектив мәхәббәт теге видеофильмнарда күрсәтелгәнеме инде ул?

Зөлфия «янаралның» яшьләргә төрттерүен колагына да элмичә, дәвам итте:

— Нигездә, Бунин хаклы. Саф мәхәббәт өлкән яшьтәге ирләр белән яшь хатыннар арасында гына була ала ул, дигән фикерен кызыл җепкә таккан бит язучы. Безнең мисал шуны раслый.

Сәет бирешми. Янә бер авторитетның фикерен тартып чыгара:

— Педагогларның кумиры, бөек гуманист Жан Жак Руссо бабан әйткән сүзләр миңа якынрак.

Зөлфия керфекләрен уйнатып алды.

— Нәрсә дигән инде анысы?

— Хатын-кызның тәне табигать тарафыннан ирләргә ләззәт бирү өчен яратылган.

Бу юлы бәхәсләшеп тормады ханым.

Сөйләнүеннән арып, Зөлфия ире янына диванга утырды, иркәләнеп, бөтен тәне белән елышты. Шунда ук торып китеп, өстәл әзерли башлады.

## 24

Бер кичне аларга көтелмәгән кунак — милиция подполковнигы килеп керде. Күрәсең, алдан килешенгән булгандыр. Сәетнең кальгасына теләсә кем, теләсә кайчан үтеп керә алмый.

Салих өйдә сизгер иренле, килешле борынлы, күтәренке яңаклы, чибәр йөзле һәм кырт иткән гәүдәле ханымны күргәч, югалып калды. Йөрәге леп-леп итеп тибә башлады. Булса да була икән һәр яктан килгән гүзәл алиһәләр!

— Салих дус, бу кызның исеме Зөлфия,— диде Сәет. Алсу төс йөгергән битенә күз салды да өстәп куйды:

— Хатыным минем.

— Сезнең хатыныгыз?— дип гаҗәпләнеп сораганын Салих сизми дә калды. Аңына килеп: — Мин хәбәрдар түгел идем. Котлыйм!

«Акчага сатып алган, валютный кыздыр әле, артык гүзәл»,— дип уйлап куюын, табигый ки, беркемгә дә сиздермәде.

— Чын күңелдән котлыйм,— дип кызның назлы, йомшак кулын учына алды. Борынын назлы хушбуй исе кытыклады.

— Мин сине гомерлек буйдак булып калырсың, дип уйлаган идем.

— Нәкъ менә шул кызны эзләдем, аның үсеп, өлгереп җиткәнен көттем,— диде үзенә бер нәзакатьлек белән, кулын Зөлфиянең эчкә тартылып кереп торган биленә салып.— Көтә белүемне аллаһы тәгаләбез тиешенчә бәяләде һәм миңа егерменче гасырның икенче яртысында татар халкы тудыра, тәрбияли алган иң илаһи затын бүләк итте.

Сәет хәләл җефетен кунак белән таныштырырга тиеш иде.

— Зөлфия, Салих абыең булыр. Милиция һөнәре мөмкинлек биргән микъдарда кешелекле, игелекле, ярдәмчел кеше. Бу сүзләрне әлеге халыкка карата кулланып булса, аларны бары тик бер кешегә нисбәтән генә әйтеп була. Ул бүген бездә кунакта,— диде ак, тигез тешләрен елтыратып.

Чибәркәе янында теленә салыну үзенә дә охшый, ә Гаяровның мактаганны ятратканын тәгаен белә:

— Арттырасың,— дигән булса да, аңа рәхәт иде.

Ни өчен килгәне исенә төшеп, йөзенә, гәүдәсенә кырыслык җилүен типтерде подполковник:

— Сәет Яруллович, мин ашыгам. Чәйләп, гәпләшеп утырырга бүтән вакытта керермен.

— Акыллым, син теге бүлмәдә сабакларыңны караштырып утыр. Студентка әле ул минем. Бергәләп дәрес әзерлибез. Абыең белән сөйләшеп аласы бар.

Гаяров Зөлфияне күзләре белән капшап озатты. «Шәп кызны кулга төшергән мафиозник,— дип көнләшеп куйды.— Акча хәл итә бу дөньяда һәр нәрсәне, кесәңдә кыштырдап торса, хатыны да сылана, хуҗалар да аяк астында бутала. Ә шулай да, бүген Сакманов аның кулында».

Салих үз дәрәҗәсенә, олылыгына горур сокланып, урта тәрәзә янына барып басты. Ифрат отышлы һәм илләм матур поза алды. Сәет, аңа

карап, тәрәзәдән иңгән яктылык фонында иптәшнең борчулы, уйчан һәм хәтта кайгылы икәнлегенә ышанырга тиеш иде.

— Хәлләр, кәефләр ничек?

— Кәефләр турында башка урында сөйләшербез,— дип, Салих шома өстәл янына килеп утырды. Ялтыравык, шома такта өстендә куллары әллә ничә төсле күренә. Шәмәхә, ал, фирүзә, зәңгәр төсләр уйный.

— Артыннан саф җилләр искәнне сизенәсеңдер, Сәет Яруллович! Үтәдән-үтәли җил яхшы нәрсә түгел. Үпкәгә бәрүе мөмкин.

— Нәрсә дигән сүз бу? Төрттерүнең нигезен аңламыйм.

— Мансурны алуны кем оештырганны мин белми дисеңме? Беләм!

— Белсәң, ник ычкындырдың?!

— Юк, Салих дәдәңнән ычкынуы җиңел түгел.

— Кая соң алайса үтерүче?

Сәет үзенең җиңелчә дулкынланганын, тавышының калтыранып алуың тойды. Мент сизенмәсен! Дус булса да, ул халык алдында туарылырга ярамый. Тормыш кырысланган саен, алар явызлана бара.

— Шөреп гади исполнитель,— диде Салих һәр сүзгә аерым мәгънәви басым төшереп.— Һәм әле ул гына да түгел!

Салих, күкрәген алга чыгарып, эре генә бүлмә буйлап йөреп алды, Сәетнең күңелен кытыклап, нерв күзәнәкләрен сынап, юри сузды.

— Шотландские виски салыйммы, боз белән?

— Юк, син әүвәл премияңне өстәлгә сал!

— Әллә, әллә... хәл кылындымы? Ничегрәк булды?

Сәет, артык сорау биргәнен аңлап, аскы иренен тешләде. Булгалый аның белән. Ашыга торган гадәте бар. Каударланып кызыксынганын, җавапны интегеп көткәнен Салихка сиздерергә ярамый. Кирәк түгел.

— Заманында сезнең мебель цехында балта остасы булып эшләгән Сәнгат Кашипов бүген төнлә, үзәк төрмәдә үз-үзенә кул салган. Җепкә асылынып үлгән,— диде, суд карарын укыгандай, тантаналы тавыш белән.

Сәет әсәренеп китте. Чыраенда кан әсәре калмады. Олы куллары соң чиккә җиткән алкашныкы төсле калтыранып алды. Көчкә сүзен әйтә алды:

— Урыны оҗмахта булсын, диләрме әле. Ни әйтсәң дә, егет кызганыч. Насыров беләме?

— Иртән эшкә бер вакытта, җидегә килдек. Дежур егет доложить итте,— диде Салих тыныч кына.

Шундук үзен туктатып, чөйне икенче яктан кага башлады.

— Син, чыннан да, бәхетле кеше икәнсең, Сәет. Хатыныңның яшь, чибәр, аңлавымча, акыллы булуын күздә тотмыйм.

— Кашиповны кызганам,— диде Сәет бу юнәлешне кабул итмичә. Кешеләрчә җәллим мин аны. Шулай яшьли китеп бару... Кызгану хисе андыйларга карата, үлемнәреннән соң гына әйтелә шул.

— Котырынып барган поезд астына үзең төртеп кертмәдеңме? Соңарган тәүбәң кемгә кирәк!

— Аның язмышы тумас борын хәл ителгән иде. Мин аның гади кесә карагы тормышына яңалык керттем, ул ниндидер файдалы эшләр башкарды. Совет төрмәсенә башын яшьли тыгып, анда биш ел утырган адәм кеше була алмый. Шукшинның «Калина красная» фильмын хәтерлисеңдер. Төп герой күпме генә үзенчә яшәргә тырышса да, аңа ирек бирмиләр, әйтерсең лә аның гаиләкорып, сөеп, сөешеп, сөелеп яшәргә, табигать матурлыгы белән хозурланырга хакы юк.

— «Шөреп файдалы эшләр башкарды», дисең инде. Салих өстенлеген яшермичә, турыдан төрттерде:

— Ул «алган» абзыйлар, белүемчә, берсе дә кеше өчен яшәмәде. Тик үз мәнфәгатьләрен кайгырттылар.

— Ә син үзең?

Гаяров соңыннан бу сорауны биргәненә үкенде. Әйткән сүз — аткан ук, диләр шул. Кире кайтарып булмый. Бер мизгелгә мие чуалып, бу сөйләшүдә янә үзенең өстенлеген күрсәтәсе килеп китте. Шул гына.

Сәет йолдыз атылган тизлек белән урынынннан сикереп торды да, өсте берсеннән-берсе матур кәгазьләр белән бизәүле бутылкалар тезелгән шкафның аскы тартмасын ачып, күн папка тартып чыгарды.

— Менә кара, туксан өч, туксан дүртенче елларда гына яңа төзелә торган мәчеткә биш миллион, реконструкциягә өч миллион, балалар йортына, картлар йортына фәлән сум акчалар күчерелгән. Украинадан, Белорусьтан, Балтика буйларыннан күпме арзанлы мебель ташыдым. Сөйли китсәң... Ә сиңа нәрсә! Шүрәле бабаң төсле кытыкны китереп утырасың шунда маттиити.

Эченнән һавасы чыккан шар төсле тынып калды Сәет. Күңеле бушады. Чирканчык алты. Тынычлык килмәде.

— Бәхетле кеше икәнсең...— дигән булды Салих, фикерен элеккеге юлына кайтарып.

Сәет эндәшмәде. Аңа барыбер иде. Ул Шөрепне үтерде. Ул — кеше жанын алучы газазил. Барыбер берсенең — Мансурныңмы, Шөрепненме каргышы төшәчәк. Әмма мент әйткән хәбәр аны янә фани дөньяга кайтарды.

— Шөреп Җәүдәтнең кияве булган икән,— диде Салих.

— Син нәрсә сөйлисең? Тузга язмаганны.

— Ике ай элек кенә өйләнешкәннәр. Сәнгат Кашипов белән Регина. Соңгысы — Җәүдәтнең бердәнбер кызы. Дөрес, полковник фатихасын бирмәгән. Кыз егет фатирына күчеп киткән. Хикмәт андамыни! Нәтиҗә шул ук. МВДның бүлек мөдире кияве, ахыргача аңлашылып җитмәгән сәбәпләр аркасында, төрмә камерасында асылынып үлгән, дип язачак пресса. Журналистлар өчен нинди кызыклы хәбәр. Сенсация.

— Миңа бүлек мөдире булып бер-ике ел эшләп алырга туры килмәгәе дим!

— Җәүдәт пенсиягә китәм, дип куркытып алган иде дә. Хәзер тынычланды бугай.

— Бердәнбер кияве камерада асылынып үлгәннән соң, аны эштә калдырырлар дип уйлыйсыңмы? Син бездәге тәртипләрне оныта башлагансың. Ул яктан органнарда бик строго.

Кияү балакайның рестораңда сугышып әләгүе — бер. Депутатны үтерүдә гаепләнүе — ике. Иң мөһиме өченчесе.

— Анысы тагын нәрсә?

Мансурны үтертүгә Салих тупас киная ясар, дип көткән иде Сәет. Мантыйк ягы шактый көчле булып чыкты подполковникның.

— Кияүне полковник кабул итми, яратмый, ишеген ачып, бусагасыннан үткәрми. Димәк, аны кызына тиң яр түгел дип саный.

— Хуш. Шуннан ни чыга?

— Форсат чыкканда, бу бандиттан котылырга теләве табигый, аңлашыла. Теләсә кайсы ата, ходай тәгалә үзе биргән бу мөмкинлекне кулдан ычкындырмас иде. Милиционер бигрәк тә.

— Син, Кашиповны юк итүне полковник үзе оештырган, дип әйтмәкче буласыңмы?

Хәтта Сәет тә бу көтелмәгән борылышка әзер түгел иде.

— Мин түгел, йолдызлар шулай, ди. Һәрхәлдә, бауны камерага ул ташлаган булуны инкяр итүе кыен. Бер версия булып каралачак. Җәүдәт дус бу упкынны икегә бүлеп тә сикереп чыга алмаячак. Әйдә, вискиеңны кой да, киттем. Китер әҗереңне...

— Соң мин исәп-хисапны Җәүдәт белән өзәргә тиеш түгелме? Шөрепне ул алгач.

— Әйдә, бөгештермә! Ихтыярың чүмәлә, «б» урынына «с» хәрефен куя аласың. Менә шулай. Тәртип!

— Сал тагын аз гына сасы нәрсәнне дә, йөгердем. Вакыйгаларның кызыгы алда әле.

Подполковник хаклы булып чыкты.

## 25

Зөлфия үзе өчен яңа тормыш башланганны, Сәет аны күпме генә яратса да, барысын да әйтеп бетермәсен, хезмәт, алыш-биреш хикмәтләрен, үзгә оешмалар, кешеләр белән мөнәсәбәтен ачып салмасын аңлый башлады. Ир-атның үз эше, үз сере булырга тиеш, күрәсең. Ә безнең — үзебезнеке...

Соңыннан Сәете аңа подполковникның өйләнү тарихын сөйләп, көлдереп, эчләрен катырды. Чыннан да, Гаяровның гаиләле булуы үзе бер тарих. Чапаев турындагы мәзәкләрең бер якта торсын.

Ишле гаиләдә туа Салих. Бер атаның алты ир малае арасында ул берүзе милиция һөнәрен сайлый. Әллә холкы хыялый-романтик булдымы, дус-ишләре йогынты ясадымы, башка берәр тирәнрәк сәбәп этәрдеме бу юлга, хәзер әйтүе кыен. Шул хәтлесе хак: урта мәктәпне тәмамлау турында таныклыгын ала да, гаризасын Алабуга милиция мәктәбенә күтәреп бара. Анда элегү өчен армиядә хезмәт итү мәҗбүри шарт була ул елларда. Солдатка да барып кайта. Оҗмахка юлны үз куллары белән ача.

Аны эшкә Семипалат шәһәренә җибәрәләр. Яратып хезмәт итә, капитан дәрәҗәсенә күтәрелә. Югары белем алу хыялын да ташламый. Татарстанга кайтып, җирле педагогия институтына урыс теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән торып укырга керә.

Дөрес, кагыйдәләр ятлап үзен бик ватмый. Укытучылар, җитәкчелек белән танышып өлгерә. Шул арада җөмһүриятнең җаваплы һәм саваплы урыннарына үрмәләгән абыйлары да кирәк чакта терсәкне куеп, җилкәне биреп торалар. Ерактагы кояш яхшырак җылыта. Якын күреп каршы алалар, кунак итәләр, зурлап озаталар.

Хатын-кызга беркайчан да битараф булмаган Салих мул күкрәкле, түгәрәк битле, таза бәдәнле, җайлы холыклы хохоллар нәселе үстергән хатын белән таныша. Дөресе, милиция әһелләре арасында бинһая ханым буйдакны үзе шәйләп ала, «Ко мне, Мухтар!» диюгә, шуны гына көткән Салих авызын йөгәнгә тыга. Ун яшьлек малае да татарин дядясын уңай кабул итә.

— Ясаган ата түгел, тәрбияләп кеше иткән чын ата,— ди Любушкасы.

Ханым егеттән канәгать, ул үзенә яклаучы, төннәрен юатучы тапты. Саран түгел. Акчаны кесәсенә тамыза тора.

Артык сораулар бирмәскә, туйдырмыйча иркәли белүгә, үзенне кол дәрәҗәсенә төшермичә, эченне мәчеләр тырнаса да, ир-атка охшарлык кәефтә булуга, теләнеп алмаска, әмма үзеңә тиешне, мөмкинлекне ычкындырмаска ханымны тормыш өйрәткән иде инде.

— Чанаңа утырдым, Салих. Начар шумаска тиеш синең чанаң. Тик синең, бәбкә чыгарган каз кебек, дежуркада утыруың ошамый миңа,— диде хуҗабикә бер көнне.

Аның киңәше, хәтта ярдәме белән кибетче, сатучы-алучы, ришвәтче халык белән эшләү бүлегенә күчкәч, капитанның тормышы нурланып китте. Адәм баласына күп кирәкме? Юк, өч аршын җир генә җитми икән аңа!

Күчтәнәч алуның тәмен сизә башлады. Җылы кочагында эреп яткан-да, киңәшне хатын бирде.

— Бер-береңә бүләкләр бирү — кешеләрне үзара якынайта, явызлыкны киметә. Тик чама хисеңне югалтма! Күпне кочаклаган, аз учлар.

Салих нәрсәдер алуны, кулга салуны ришвәт дип санамаска өйрәнә. Акчалата каеру — гөнаһ, законны бозу. Ә менә затлы шәраб, фин колбасасы, алтынга манчылган кашык-пычак, муены әйләнмәле самавыр, Канада курткасы, Австриядә тегелгән йон кәстүм ише әйберләр — уенчык күчтәнәчләр, чын күңеллелек, дуслык һәм ихтирам билгесе генә. Җилкәсендә — халык ышанычы тамгасы — биш канатлы йолдыз утырган кеше бу хәлне табигый, эшенең, хезмәтенең дәвамы дип саный. Мәче исен сизгән тычкан кебек, бу төр кешеләр яныннан тайса, ул үзен бик җайсыз сизәр, үпкәләр, рәнҗер иде.

Салих үзен бәхет күгендә тоя башлады. «Салихчик, нәрсә кирәк? Ничек ятыйм? Нәрсә пешерим? Син ни әйтсәң, шулай булыр»,— дип иркәләп, назлап кына тора җәмәгате. Татар хатыннарына ялагайлык, ир теләген алдан тоеп тору җитешми шул, дигән күзәтүен күңеленә беркетеп куйды Салих. Кыскасы, исерек, бәйләнчек, дуамал беренче иреннән көчкә котылган хатын тагылчыгына ярарга тырыша. Мондый да булган, таза, малташыр ирләр урамда ятмый. Аунап ятарга мөмкин, андыйлар да җитәрлек. Ул мәхлукълардан он суы да, тоз суы да юк шул.

Суыткычындагы аракының төбенә төшеп, «мине башка кеше белән бутагансыз, мин — просто алкоголик», дип диванына чишенмичә гөрселдәп егылып, гырлап йоклап китүдән уза алмаучылар дөньяда артканнан-арта бара. Аның Салихы бөтенләй башка...

Көйле тормышның гомере кыска булды. Алдан хәбәр итмичә генә, узып барышлый дигән булып, Салихның олы абыйсы килеп төшә. Милиция бүлегендә тапмагач, адресын сорап ала да өйләренә килә. Любаша Салихның ир туганын җиренә җиткереп каршы алырга тырышса да, җылылык килеп чыкмый. Энесенең үзеннән өлкән, балалы һәм үзгә милләт кешесе белән яшәвен хупламый. Салихка: «Кендек каның Казанда тамган»,— дигән бер сәер җөмлә әйтә дә, ниндидер карарга килеп, тиз генә кайтып китә.

Гаяровлар нәселенең ул чорда булдыра алмаган эше, чишә алмаган мәсьәләсе юк иде. Абыйларының берсе иң олы хуҗаның үзенә бик якын бер кешесе иде. Көтелмәгән сәфәрнең нәтиҗәсе тиз күренде: капитан Гаяровны Казанга күчерергә дигән боерык Мәскәүдән үк килеп төште.

Салих Люба белән аерылышуны бик авыр кичерде. Җанына ут капты, йөрәгенә кан сауды, күзләренә яшь килеп тыгылды. «Урнашкач, килеп алырмын, син минем иң олы мәхәббәтем»,— дип сайрарга керешкән иде дә, дөньяның ачысын-төчесен күбрәк күргән, ир-атның холкын яхшы белгән ханым сүз-хис өермәсен кырт кисте:

— Юкны сөйләмә! Ике ел рәхәтеңне күрдем. Миңа шул җиткән. Берәр лейтенантик килеп чыгар әле,— диде дә, тулы беләкле ак кулларын муенына куеп суырып үпте дә:

— Ярый, бар,— диде. Бөтен озатуы шул булды.

Абыйлары Салих кайткан төшкә бер бүлмәле фатир әзерләп куйганнар. Шәһәр өчен иң мөһиме — торыр урының булу. Фатирың булса, дус-ишкә, йоклап чыгарга теләүчеләргә кытлык булмас.

Инде утыз өченче яше белән киткән капитан Гаяров элеккедән дә рәхәтрәк, бәйсезрәк тормышка чыкты. «Крышасы» — абыйлары җилиңгыр тидертмиләр. Бүләк-күчтәнәчләре дә, акмаса да, тама тора.

Әти-әнисе авылдан килеп, абыйлары, апа-сеңелләре җыелышып, «Вакытың чыгып бара, өйләнергә кирәк»,— дип кысып карыйлар.

— Өлгерермен әле, качмас. Яшьлек ике килми. Граф Толстой утыз тугызда өйләнгән, «иртә башлы-күзле булдым, хатын картайды», дип зарланып яшәгән. Миңа дигән кәләш үсеп җитмәгән әле,— дип, котылу ягын чамалый. Рәхәт хәяты белән җиңел генә хушлашасы килми иде ир-затының.

Мәгәр Салих фаразы белән хаталанды. Аңа дигән кыз үсеп җитеп, химия-технология институтын тәмамлап, бер заводта инженер булып эшләп йөри икән инде.

Казанда һәм Чаллыда эшләүче ике олы җитәкче абыйсы кызны Салихның өенә алып килделәр. «Берәрсенең сөяркәседер»,— дигән уйны күңеленә беркетеп, кыз ягына күтәрелеп тә карамады өй хуҗасы.

— Бу кызның исеме Венера. Синең булачак тормыш иптәшең,— диде олы абыйсы, бусаганы атлап үтүгә.

Икенчесе өстәлгә ашамлыклар куя, шампан шәрабы ача башлады.

— Безнең яхшы танышларның кызы. Югары белемле.

— Ничек була инде ул? Без бөтенләй таныш түгел,— дип, Салих кыз ягына күз салырга булды.

Уртача буйлы, ясаткан сары чәчле, күзлекле кызга бер караудa гашыйк була алмады капитан Гаяров. Әмма бу оста куелган тозактан котылу әмәлен дә күрмәде. Абыйларының талканы коры иде.

— Бәлки, әле Венера риза түгелдер,— дип саламга ябышып карады үз теләгеннән башка кияү егете булып киткән Салих.

Кыз вак-вак атлап түргә үтте, өстәл янындагы урындыкка кунаклады, күзлеген төзәтеп алды.

— Соң миннән ризалыкны алдылар инде. Башкода булып абыйларың ике кат килде. Сез мине театрда күреп, бик охшаткан, диделәр.

Бүлмәдә давыл алдыннан була торган тынлык урнашты. Салихның Казанда бер тапкыр театрда булганы, кызны өнендә түгел, төшендә дә күргәне юк иде. Теленә шайтан төкергән икенче абыйсы яшенне яшьнәтеп җибәрде.

— Мин кулымдагы шампан суында ике яшь кешенең туачак бәхетен, өй тулы балаларын күрәм. Ә инде алдан күрешү-танышу мәсьәләсенә килгәндә, кирәкмәгән шөгыль ул. Безнең әби-бабайлар бер-берсен бөтенләй күрмичә өйләнешкәннәр, типтереп яшәгәннәр. Никахны бозу очраклары бик сирәк булган. Аннан килеп, көпчәк түгәрәк булмаса әйләнми. Абыйларыңның сүзеннән чыкмаслык баш кына бардыр синдә дип уйлыйбыз.

Янә кыз телгә килде:

— Ул риза булмаса, мин китәм. Бүрәнәләрем бүлгән. Ябышып чыгарга җыенмыйм.

Шулвакыт ишектән тәэминатчы абыйсы килеп керде. Бусы, гадәтенчә, кызмача иде. Салих алдында торган бәллүр чәркәне кулына алды да, калын тавыш белән:

— Горько, горько, ачы! — дип кычкырды.

Венера күзлеген салып, йөзен Салих ягына борды. Диңгез суы төсендәге күзләре зур һәм матур, чынында гәүдәсе күзләренә сыйган иде. Кызның нәфис куллары җәмгысы сигез данә йолдыз өстенә ятты. Мөмкинлек булганда, бер хатын-кызны да үпми калдырмаган Салих авызын кызның коймактай кабарып торган иреннәренә батырды. Затлы шәраб эчкәндәй башы әйләнеп китте. Венераның күз төбендәге сөрмәсе җебеп битенә акты. Яшьләр айныганда, абыйлары урамда көлешә-көлешә машиналарына төялеп яталар иде инде.

Венера тиз арада Салихны кулга алды, бер-бер артлы ике бала китерде. Тышкы тынычлыгы астында дәртле һәм акыллы, зирәк юнәлеш биргүгә сәләтле хатын яшеренгән булып чыкты. Любасын искә төшергәләсә дә, Гаяров бүгенге тормышыннан канәгать иде. Яратуы үртәлүдән килде. Абыйларының кулы Татарстан атлы тулпарның билендә чакта бер-бер артлы ике йолдыз алды — подполковник дәрәҗәсенә күтәрелде.

## 26

Затлы эчемлекләрне Мансурның якты истәлегенә Казанның атаклы пешекчеләре табадан төшергән нигъмәтләр белән бастырыклап куйгач, көн тәртибенә бурычны түләү мәсьәләсе кабыргасы белән килеп басты.

Бу эш белән шөгыльләнгән милиция майоры үтерүчене эзләп баш ватмады, чит сөяккә исе китмәгән тук маэмай кебек, сүз өчен генә иснәнде. Мансурның болай да томаналанган, һушын җуйган әнисеннән, «мафа башлыгына» караганда көпчәк астына эләккән әнчеген күбрәк җәлләгән карчыктан сорау алган булды да, беркетмәгә куллар куйдырып, «Бу пычрак эшкә безне бутамагыз, үзегез аңышыгыз»,— дип, офыктан рәшә төсле югалды.

Чынында, ятимә анасыннан башка берәү дә икенче атнасын кара җир астында яткан Мансур өчен артык янтыгаймады. Үлгән үгездән ите, ватылган арбадан утыны калды. Хикмәт башкада иде. Кабилның кулыннан тотмасаң, үчне алмасаң, шул ук үлчәмдәге кургаш башкаларның маңгаен чәрдәкләргә дә күп сорамас. Гаеплене чамалыйлар. Сакманов кулы уйнаганы, аның Фердинанд өчен сарутын чыгарган булып, исәннәргә бармак янавын чамалыйлар.

Абруйлар җыенын, гадәттә, Мансур белән Вильсур икәү алып барсалар, бу юлы дилбегә бер кеше кулына күчте.

— Йәгез, җәмәгать, нинди карарга киләбез?— диде ул, янгынга эләккән песинеке төсле тырпаеп торган мыекларын сыпырып.

Терсәктәшенең вафатын сүздә, чырайда авыр кабул итсә дә, йөрәгенә кыенлык китермәде Вильсур. Соңгы вакытта Мансур артыгын азына башлаган иде. Үз башына булган. Аны «аударып» дөрес эшләгәннәр.

Вильсур буй-сын тарафыннан мәрхүмнән кайтышрак булса да, үзен эре, тәкәббер тота, янында утыручыларга биредә кемнең хуҗа икәнен, беренче имзаның аныкы булуын сиздереп утыра. Аркасын уклау йоткандай туры катырып тотуы, бөтен рәвеше белән «тәмгыгызны тыегыз, кәнәфине берәү белән дә бүләргә җыенмыйм» дип шыр, ярып тора иде. Соргылт кырыс чырай, үҗәт карашлы, куе керфекле кара күзләр... Иң кирәк җирендә бөркет томшыгыдай юка борыны киңәеп ала, иреннәре турсаеп, кысылып, сүзне чалгы белән печән чапкандай чыжлатып, юри кистереп чыгара. Йомры ак алтыннан эшләнгән балдак кигән кыска бармаклы сул кулын алга сузып йөзем алганда да үзенең кемлеген сиздерергә тырыша Вильсур. Үз-үзенә ышанычы астан бәреп тора.

Мәҗлес хуҗасының соравы һавада асылынып калмады. Гаепле стрелочник табылды. Мансурны саклау— заманында Казанны дерелдәтеп торган, хәзер инде тешләре коелган арыслан хәленә төшә барган Северцевка тапшырылган иде.

— Җавапны ул тотарга тиеш. Дустыбызны саклый алмады,— диде тәвәккәл сары башлы, киптерелгән мүк төсендәге иренле беренче куштаны.

— Үчне кайтарсын, үтерүченең баш сөяген алсын,— дип өстәргә ашыкты күзләренең чепилегеннән оялып , кара күзлек кигән икенче куштаны.

— Мансур Мәүлетычка атучыны коры агачка асып куйсын. Түләүчесен тапсын,— дип кәлимәсен кыстырды җирән кашлы, чәчсез башлы, асылда хөкүмәт базасы мөдире.

— Кем дип уйлыйсыз соң?— дип сүз катарга җөрьәт итте тәп-ләпне оештыручы.

— Нәкъ син мүшкәдә торган адәм,— диделәр абруйлар бердәм рәвештә.

— Соң аны ничек алырга? Үзен атып үтерергәме?

Вильсур, ачы юа капкандай, чыраен ватты, көзге чебенне кугандай, кулын изәде.

— Заманчарак фикерлә, абзыкай. Үлем ул — кеше өчен дөнья мәшәкатьләреннән котылу. Бүләк! Шуңа чаклы адәм баласы хатасын танысын, ялгыш юлда йөргәнен аңласын! Тәүбәгә килсен. Дөньяда бит әле әхлак, әдәп дигән нәрсәләр бар. Шулар турында төшендерергә кирәк сәнәктән көрәк булган мент койрыгына.

Иренеп кенә үрелеп алып, янә бер йөзем ташлады бүселгән иреннәргә. Балдагын тәрәзә аша үрелгән кояш нурына чумдырып, уйнатып алды. Тыныш билгеләрен урынына куйгач кына, сүзен дәвам итте:

— Бусы — бер. Икенчедән, диимме, ул хәзер бик саклана. Үзе генә йөрми. Тазалыгы да сиңа мәгълүм. Аның йодрык тәмен оныттыңмы әллә, туганкаем? Теге, мусор чагында... Үзеңне яхшы дөмбәсләгән, төрмәгә дә илтеп тыккан, диләр. Сөяркәң дә аның күкрәгенә ауган диләр. Дөрес булса...

Вильсур тамак төбе белән кеткелдәп куйды. Балдаклы кулы белән авызын каплагандай итте.

Тимер тәнле Северцевның иң авырткан, ничәмә еллар буенча кан саркып яткан ярасына орынды Вильсур. Тәп-ләпченең төрмә тозы ашаган аксыл чәч калдыклары үрә торгандай булды, ясалма тешләре шыгырдап, калын иреннәре дерелдәп китте. Эчтән кайный башлады.

Садист канәгать. Северцевның кытыгы котырганы күренеп тора. Сүзләренә түбәнсетүле төсмер бирергә тырышып, киңәшен дәвам итә. Колакларга токмач элә. Барчасы йөзем капкалап, игътибар белән тыңлый. Акча аның кулында, кая барасың.

— Аннан килеп, ни өчен әле без сине өч профессор оклады түләп асрыйбыз. Сөннәткә утырту — синең проблема. Безнең бурыч башка... Кылган эшеңнең нәтиҗәсен раслау. Раслау... яисә үзеңне Мансур Мәүлетовичның суынып өлгермәгән куенына озату,— дип, Вильсур сүзен бик кырку тәмамлады. Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла дию булды бугай.

— Бик дөрес сөйли Вильсур Мәгъсүмович,— дип мөһер сугарга ашыкты сары башлы ялагае.

— Нәкъ шулай,— дип шаулашты башкалары.

Вильсур мәҗлестәшләренең бердәм хуплавыннан, җеп очын ялгап китүләреннән канәгать калып, мул артын урындыкка ышкып алып, нәтиҗә ясады:

— Хәзер таралышабыз. Һай-һай, вакыт тиз бара. Мин сәгать өчтә Кабминда булырга тиеш. Бер атна вакыт бирәбез, Андрей Сидоровичка. Нәкъ шул сәгатьтә урмандагы йортыбызда очрашабыз. Место встречи изменить нельзя...

Бүлмәдә утыручыларны елгыр күзләренең нәзек энәләре белән чәнчеп алды да, бөтен тотышына салкын бәйсезлек, күрәлмаулык мәгънәсе биреп, Вильсур бүлмәдән чыгып китте. Баш өсте дип озатырга торып баскан сыек зәңгәрсу күзле, көлсу чырайлы адәмгә кулын бирмәде, әйләнеп үтте.

Мондый илтифатсызлыкның асылында Мансурны саклый алмаган өчен үпкә, рәнҗү кебек хисләр ятмады. Тәп-ләпченең зур һәм ямьсез куллары һәрвакыт юеш һәм салкын иде. Аның белән кул алышканнан соң, Вильсур берничә көн учында сөт суытырга салган бака тоткандай йөри. Кулын сабын белән юып, кытыршы чалбарына ышкып карый, бәйләнчек тойгыдан котыла алмый.

Северцев кул бирмәүне үзенчә юрады. Күз алдына куркыныч сызык килде. Кискен, үткен, коры хәрәкәт таләп ителә аңардан. Кыскасы, уйламаганнан отыры көчле нәтиҗә туды.

Тәп-ләп хуҗасының төсендә, килбәте үзгәргән иреннәрендә явыз елмаю бии. Римма аңа Сакмановның бик чибәр, яшь хатынга өйләнүе, бәхет кочагында изрәве турында хәбәр җиткергән иде. «Хатынын урларга. Аны җим итеп, Сакмановтан Мансурны үтерүдә катнашуын танытырга. Үзен тотып алып килеп, күз алдында чибәркәен чиратка куеп көчләргә. Соңыннан икесен дә тиражга чыгарырга».

Шул манзараны күз алдына китергәч, кашларын сикертә- сикертә, уйларының рәхәтенә оеп, изрәп киткәндәй булды. Җилкәсеннән йөкне алгандай, тәне, сеңерләре җиңеләйде. Зөлфияне табуга Римманың якын

ахирәте Наилә-Нонса булышты. Акчаны да күп сауды, әмма сүзендә торды Сәетнең «ышанычлы» хисапчысы. Тик бу хакта Сәет белән Зөлфия генә хәбәрдар булмадылар.

## 27

Гәүдәсен мамыктай җиңел сизеп, институттан сикерә-атлап чыкты Зөлфия. Иптәш кызлары артта калды. Аларга ни: гайбәт, ләтчә капчыкларына, өйләренә кайтып, ирләренә аш әзерлиселәре, өй җыештырасылары юк. Дөньяда шактый яшәгән булса да, ризыкка талымсыз аның Сәете. Нәрсә генә пешерсә дә, мактый-мактый ашый. Ир хатынының күңел көрлеге, үзен бәхетле сизүе өч нәрсәгә бәйле дип юкка гына әйтмәгәннәр икән. Берсе — өйгә гел яңалык кертеп тору: диварны, сервантны ук булмаса да, өстәлне, кәнәфине, урындыкларны урыннан-урынга күчерү, алыштыру, аралаштыру, бутау. Икенчесе — чәчнең юылган булуы. Чибәрлек күрке керле, пычрак чакта хатын-кызның кәефсихәтләре бер тиенгә чыкмас, йөзе-теше сызлаган кешене искә төшереп торыр. Өченчесе — өстәлгә куйган нигъмәтен якын кешеләренең яратып, матур сүзләр тезә-тезә ашавы.

Зөлфиянең кәефе язгы һава төсле күтәренке. Кичә Сәетенә күңеле болгануы, укшуы хакында ычкындырган иде. Ир уртасы кешенең балаларча кылануын, яшь кәҗә бәтиедәй сикеренүен күрсәң, исең, акылың китәр. Сабыйлыгы чыкмаган.

— Ур-ра... Безнең нәсел калачак... Болай булгач, яшибез. Бабай да, бавырын тотып, оныгын күрергә килеп җитәр,— дип, ак кешенең баш сөяген кулына төшергән папуаслар кебек, баскан урынында әйләнде, зык килде.

Мондый ук югары дәрәҗәдә кабул итүне көтмәгән яшь ханым оялыбрак китеп, көянтәдәй керфекләрен паркет идәнгә чәнечте.

— Алдан укуны бетерергә дигәнием.

— Уку качмас. Быел булмаса, киләсе елга өстеңнән төшерерсең. Ә мирасчыбыз үсә торыр.

Зөлфия: «Сиңа кем кирәк, ир баламы, әллә кыз булса да ярыймы?» — дип сорамый түзә алмады.

Иренең җавабы әзер булып чыкты. Аны сыртка салуы кыен иде.

— Уңган хатын ул китерер, изге хатын кыз китерер, дигәннәр борынгылар. Сине тикшереп карыйбыз инде. Кайсы графага керерсең икән.

Хыялларына бирелеп, троллейбус тукталышына юл алганда, аның исемен атадылар. Ир-ат тавышы иде.

— Зөлфия! Сез Зөлфия буласызмы?

Аңа эндәшкән тавыш ханымга таныш түгел иде.

— Әйе, мин булам. Сезгә ни кирәк?

— Бер дә борчылмагыз, Зөлфия. Минем исемем Заһит, Сәетнең дусты мин.

Зөлфия тавыш хуҗасына күтәрелеп карады. Аңа, буе озын булмаса да, ыспай гәүдәле, яше утызлар тирәсендәге ир дәшкән булып чыкты. Пөхтә, дөресе, көяз итеп киенгән. Затлы соры кәстүм астындагы төсле күлмәкне тәвә кошы коерыгы кебек чуар галстук белән ныгытып куйган. Бу адәми затны Зөлфиянең күргәне юк иде.

— Зинһар, курка, шикләнә күрмәгез, Зөлфия. Туегызда була алмадым, чит илдә командировкада идем. Хәзер менә күрештек. Сәет Ярулловичөегезгә кереп калды. Зөлфиянең дөресе сәгать икедә бетә, син аны тиз генә алып кайт әле дип, мине җибәрде. «Чәй куя торам», диде. Сүзен елмаю тәгәлләде.

Француз туфлиенең очлы табанында зың итеп әйләнеп, борылып китеп кенә барасы иде дә, хатын-кызлык табигате җиңде. Сорамыйча булдыра алмады:

— Ничек мине таныдыгыз?

— Сәет Яруллович карточкагызны күрсәтте. Мондый чибәр ханым бөтен институтына бирәү булса, ул сездер,— дип төчеләнеп сөйләнеп китте купшы ир.— Утырыгыз, машинага!

— Юк, рәхмәт.

— Ашыкмагыз. Машинада ирегезнең уң кулы — бухгалтеры Наилә Матыгуллина утыра.

Хатынның киреләнүен, ышанып бетмәвен күреп, күрәсең, ир уен тузын ташларга булды.

Зөлфия җиңел машинада ничә кеше барын пыялалар аша күрә алмады. Тукталып калды.

— Юк, юк, кирәкми. Минем әле кибетләргә керәсе бар,— дип кискен рәвештә читкә ала башлады. Шунда машинадан хатын-кыз чыкты.

— Зөлфия, кил монда, курыкма! — дигән таныш аваз аны борылырга мәҗбүр итте.

Машина янында Сәетнең баш бухгалтеры Наилә-Нонса басып тора иде. Ат өстендә йөрергә әзерләнгән жокей диярсең. Тар, кара вак вельвет чалбарын биек, коңгырт итальян итекләренә кыстырган. Кыска җинле, аркылыга кызыл, яшел, ак буйлар төшерелгән йон күлмәгән чалбар эченә тыккан. Алтын алкалары, шул ук асыл тимердән чүкелгән тешләре хуҗабикәнең көлүле изге ниятен хуплап, ялтырап, өмсендереп торалар. Ханым чакыруын янә кабатлады.

Тәрәзәләре төсле пыялалы, ап-ак «Жигули»ның арткы ишеге ачылды.

Зөлфиянең күңеле тартмады. Сәетнең: «Чит-ят машинага утырма, Замир килеп алмаганда, халык транспорты белән йөре. На самый худой конец, такси ялла»,— дип кат-кат кисәткәнен хәтерли.

Әлбәттә, ул карточка күрсәткән иргә ышанып утырмас иде, зыялы кеше күренсә дә. Бухгалтер ханымны исә яхшы белә. «Сәет абый, үзем килә алмыйм дип, мине җибәрде»,— ди бит әнә.

Кешегә ышанучан, беркатлы изге җан шикләнсә дә, тышыннан сиздермәде. Ничек инде иренең беренче ярдәмчесе, хатын-кызга ышанмыйсың! Дөресе, уйланып, баш тартып, киреләнеп торырга арасы да булмады. Күз ачып йомганчы, мультфильмнардагы шикелле булды бу хәлләр. Машина аз гына чигенде. Үзен Заһит дип тәкъдим иткәне арткы ишекне ачты, ханымны култыгыннан алып утыртты, үзе үк ишекне япты. Алга кунаклады.

Арткы утыргычта таза бәдәнле, аксыл сирәк чәчле, спорт киемендә бер ир-зат та бар икән. Машина урыныннан кискен кузгалып киткән арада, ул Зөлфия җилкәсе аша йөнтәс кулын сузып, ишекне йозакка салды.

Хисапчы ханым салонда юк иде, урамда да күренмәде. Җир астына убылып төште диярсең.

— Бухгалтер апа кая? Нишләп аны утыртмадыгыз? — дип сорады Зөлфия, үзенең капкынга эләгүен аңлый башлап.

— Ул икенче машина белән кайта. Биредә урын аз,— дип җавап бирде Заһит дигәннәре.

Сөт төсендәге «Жигули» өйләре ягына алмыйча, бөтенләй үзгә юлга чыгып, шәһәрне артта калдыра башлагач кына, ахыр пошынып, шомланып, тавышлана башлады Зөлфия.

— Кая алып барасыз мине? Кире якка киттек! Сез кемнәр?

— Дөрес барабыз! — диде алда утырганы.

Тавышында корыч кырыслыгы . Баягы ялагайлыкның, төчелекнең, ярарга тырышуның эзе дә юк.

Чигәсе сулкылдап тибә, йөрәге тартыша башласа да, үзен эттән алып эткә салып эрләсә дә, тавыш күтәрергә ашыкмады. Берәр җиргә кереп чыгабыздыр, дип үзен юатырга, тынычландырырга тырышты зифа ханым. Ялкындай бәрхет күлмәктән ул бигрәк тә гүзәл һәм сылу күренә иде. Шунда ул күзен күтәреп алга карады, карашы пыялага төште. Колга

буйлы йөртүченең оятсыз, ач, комсыз күзләре кармалый иде Зөлфияне. Коточкыч куркыныч кешеләр кулына төшкәнен аңларлык кына тормыш тәҗрибәсе бар иде Исхак абзый кызының...

«Жигули» шәһәр кырыена чыгып, ят урманнан бара башлагач, Зөлфия үзенең әшәке интригага килеп капканын аңлады. Ишекне ачарга ымсынып карады.

— Чыгарыгыз мине! Кая алып барасыз? Сез кемнәр?

— Ишекне ватасың!

Йөнтәс куллар Зөлфияне кочаклап алды. Кызның битенә сасы ис бәрелде.

— Җибәрегез!

— Хәзер Сәетчигың янына килеп җитәбез. Әнә теге ике катлы агач йортта көтә ул сине,— диде алда утырганы, борылып, пычак белән сарымай кискәндәй, Зөлфияне карашы белән үтәли тишеп.

— Үзегезне киеренке тотмагыз,— диде йомшаграк әйтергә тырышып.— Без инде хатын-кызга болай гына ташлана торган яшьтә түгел. Бездән генә тормый,— дип сүзен киная белән тәмамлады.

Зөлфия, яшь булса да, аңлады: ул — Сәетнең дошманнары кулында. Үч алачаклар. Нонса-Наиләнең иренә каршы эш алып баруы, әллә ничек кенә рәшә төсле юкка чыгуы миен бораулады. Ничек инде шулай була ала? Бергә дөнья куалар, катлаулы эшләр алып баралар, үткен пәке өстеннән бергә атлыйлар... Сатлык җан булып чыга түгелме соң Сәетнең «финанс министры»? Зөлфия иренә бу хакта сөйләмәс дип ышана микәнни? Ничек инде ул шундый мәкер, явызлык, фетнә турында әйтми калсын, ди? Ә бәлки... Йөрәге авыр итеп чәнчеп куйды. Баласы тибеп куйгандай тоелды аңа.

Шул арада машина, сырлы тимер капка аша үтеп, ике катлы соры йорт янына килеп туктады. Эт өргән тавыш керде колагына. Заһит ишекне ачты. Кулын сузган булды. Ахмак һәм мәнсез беркатлылыгы өчен үзенә ачулы Зөлфия кулын бирмәде, машинадан чыгу теләге барлыгын сиздермәде. Капланып җылыйсылары килде. Бүре көтүе уртасында калган сарык бәтиедәй хис итте ул үзен.

— Сез кемнәр? Нәрсә кирәк сезгә миннән?

— Курыкма, без синең дусларың,— дип әшәке итеп көлде сирәк җирән чәчлесе.

— Киләчәгең иреңнең үзен ничек тотуына, безнең шартларга күнүенә бәйле,— диде Заһит дигәне.

Йөнтәс куллы горилла өстәп куйды:

— Девка — смак, озак көтеп, түзеп тора алмабыз, дип уйлыйм.

— Без Сәетеңнең сине ни дәрәҗәдә яратуын гына тикшерергә булдык. Аңа бик кирәк, кадерле булсаң, без кушканнарны үтәр. Ризалашмаса, бигайбә,— диде үзен Заһит дип таныштырганы, әле һаман да зыялы кыланып.

— Шартларыгыз нидән гыйбарәт?

— Анысы инде хатын-кыз эше түгел. Хәзер сездән үзегезне тәртипле, инсафлы гына тотып, күрсәтелгән бүлмәдә тыныч кына утыру сорала. Таләп ителә,— диде шул ук Заһит.

Зөлфия нәфис, кечкенә куллары белән алгы утыргычка ябышты. Әлегәчә бер сүз дәшми утырган озын буйлы йөртүче кинәт кенә ханымның беләгеннән каты итеп тотты:

— Чыгыгыз! Миңа машинаны урынына куясы бар. Хәзер карышу бесполезно. Алданрак уйларга кирәк иде.

Бигәнаһ ханымны өйгә алып керделәр, сары агач идәнле өй аша уздырып, кара клеенка белән тышланган икенче ишекне ачып, дүрт почмаклы ялтыравык өстәлдән һәм агач караваттан башка нәрсәсе булмаган бүлмәгә керттеләр. Тышкы келәне биккә салган тавыш ишетелде.

Зөлфия югалган фаҗигале көнне Сәет үзе дә эштән соңарып, гүя нидер сизенгәндәй, элекке-салынкы халдә кайтты. Җитмәсә, көне дә уңышсыз булды, гамәли ниятләренең очына чыга алмады.

Үз ачкычы белән ишекләрне үтеп, фатирына керде. Төшенке караңгылык, өметсез тынлык каршы алды «Игелек» хуҗасын. Ут кабызды. Хатыны өйдә булмаганны самавырның салкынлыгыннан, аш кәстрүленең бушлыгыннан аңлады. «Бәлки, берәр очрашуга киткәндер»,— дип фараз кылудан уза алмады.

Билгесез, авыр тойгы биләде күңелен. Йөрәге чигәсенә күчеп, зың-зың итеп тибә башлады. «Әгәр ул дошман капкынына эләккән булса?» Бу тынгысыз, ямьсез, иләмсез уеннан ул, әрсез кигәвенне куган төсле, котылырга тырышып караса да, кара сакаллы фикер, иреккә ыргылган мәхбүс төсле, зиһенен тишә, игәүли, бораулый... Бер шешә коньяк эчеп бетерә язса да, иртәнге якта гына йокыга сеңде. Киң, йомшак ятак һаман да буш һәм салкын иде.

Икенче көнне эчендә ач, явыз бүре уласа да, чит-ятларга сиздермәскә тырышты. Йөзенә чирү елмаю чыгарып, «янарал» вазыйфалары белән шөгыльләнде.

Хатыны төшке ашка кайтмагач, Мисхәт белән Замирны институтка, тулай торакка җибәрде. Буш хәбәр белән әйләнделәр. Дәрескә дә килмәгән, старосталары Әлфия дә берни белми. Үпкә кытыклары килеп, иптәш кызлары янында куна калгандыр, дигән хыялы каз куыгы кеби шартлады.

Әнисе-мазар чирләп, әтисенең хастасы тотып, ашыгыч хәбәр алып, авылына кайтып киткәндер, дип юрарга мөмкинлек калды әле. Әгәренки, теге, беренче ир кисәге Мөнипме, Мөнирме, Мөзипме очрап, чардаклэнеп бетмәгән хисе, чуар йөрәгенең ерак бер почмагында кымырҗып яткан мәхәббәте уянып, аның янына китсә дигән, күңеленә бик үк хуш килмәгән гөманга өлеш чыгарып алды. Чәчәген беренче өзгән ир-атның дәгъвасына хатын-кыз каршы килә алмый, диләр, хак булса. Холык тирбәлеше табигать бизәкләре өчен табигый. Безгә тансык һәр нәрсәсен үзе белән йөртә ич хатын-кыз. Өендә чираты узган киемнәре генә кала.

Зөлфиянең күңелендә икебезне чагыштырып карау теләге туып, янәшәлек абзаң файдасына булмаса, нишләрсең. «М» хәрефе белән башланган исемле ир синнән яшьрәк. Өй антеннасы кебек тырпаеп торган мыегы бар. Хатын-кыз мыеклы ирләргә күбрәк ышана. Аларны көчлерәк саный. Еш кына ялгыша да...

Мунча сагызы төсле ябешкәк уйларын куарга тырышты Сәет. Зөлфия андый бала түгел. «Кискән икмәк кире ябышмый»,— дип үзе кырт өзгән иде.

Тешләрен уалып коелганчы шыгырдатып булса да, түзәр, кичерер иде әле Сәет. Үзе дә фәрештә түгел, бума ютәле кебек бәйләнчек булды хатын-кызга мөнәсәбәттә. Һәрхәлдә, Отелло төсле кыланмас иде. Исән генә була күрсен йөрәк парәсе.

Баласын төшереп йөри күрмәсен тагын шайтан кыз, дигән ямьсез мәел дә үтте башыннан. Беренчене табиблар табарга кушалар, дип искәрткән иде, хәер. Татар акылы төштән соң... Алдан эшли, шуннан соң киңәш-табыш итә башлый.

Йөрәге өтелсә дә, Сәет ышанычын югалтмады. Бу фани дөньяда хис вә өмет, иман вә вөҗдан яшәтә адәм баласын. Дөньяны әче фетнә, давыл, бәла-каза басканда да өмет кеше өчен бердәнбер яктылык нуры булып кала. Ышаныч аны баррикадаларга күтәрә, сабырлыкка күндерә, явызлык кылмаска өйрәтә.

Ходай баласын мал-мөлкәтеннән мәхрүм итәргә, туып-үскән җиреннән сөрергә, ач-ялангач калдырырга, үзгә этлекләр эшләргә мөмкин. Мәгәр аның өмет чаткысын берәү дә сүндерә алмый. Адәм баласын теләк котырта, оят тыя.

Сәет Зөлфиянең югалуын ифрат авыр кичерде. Берничә көн эчендә тартылып, ябыгып калды. Эчке уйларга бирелүдән чыраенда җыерчыклар артты. Бер ел элек кенә: «Бер яшь ханым, җилбәзәк студентка өчен шулай янып-көеп, мәҗнүнләнеп йөрерсең»,— дисәләр, йөзләренә карап,

kahkahәләп көлер генә иде. Унжиде яшьлек үсмерләр тәсле тилереп гашыйк булып йөрүләре ике ятып бер төшенә дә кермәгән иде ләбаса. Элек, парлы булганда да, җаны ялгыз яшәгән икән. Зөлфия аның йөрәгенә туры юл тапты.

Морадына ирешкән иде Сәет. Һәр яктан килгән, үзен яраткан, кешегә санаган хатынга тап булган иде. Ходай тәгалә аны җир бүләге, гади дә, җиде йозаклы сандыктай серле дә Зөлфиядән аермасын иде дә бит. Менә ничек килеп чыкты. Барысы да язмышның чәнечкеле кулында.

Сәетнең җаны Зөлфия белән киткән икән. Бу чаклы шашынып ратуның, юксынуның шыр тилелек, чеп-чи ахмаклык икәнен акылы таныса да, үзе белән берни кыла, үзенә хуҗа була алмады. Язмышлар бер-берсенә охшамаса да, кабатлана икән шул, дигән фикергә килде Сәет, мәхәббәт ялкынында күбәләктәй көйрәп янган Көнчыгыш әдәбияты каһарманнарын исенә төшереп.

Зөлфияне эзләвендә, явыз мәчедән куркып, керер тишеген югалткан тычкан кебек үрсәләнде Сәет. Кайда хәрәкәт — шунда бәрәкәт икәнне белә иде ул. Милициягә хәбәр итте, хастаханәләрне барлады, йөртүчесен мәет йортына җибәреп кайтарды. Тирән суга төшкән балта кебек юкка чыкты Зөлфия.

Утны-суны кичкән, совет хакимияте бирә алган барча үҗәтлекне, хөсетлекне, имансызлыкны миенә, тән тукымасына дыңгычлап тутырган Сәет Сакманов өметсез чарасызлыктан аллага ышана башлады. Имтомны, табынуны хорафат, наданлык, томаналык галәмәте дип санаган, бусагадан кире каккан, элеккеге сәяси, тәрбияче сугышчан атеист һәм милиция хезмәткәре эре-эре акчаларны хәерче карчыкларның, чегән балаларының янган күмердәй кара кулларына салганда: «Йә, ходаем, синең кодрәтең чиксез, Зөлфиямне исән-имин килеш кайтарып бирче, зинһар өчен», — дип тәкрарлый, «тәүбә», «алла» сүзләрен тәһлилли торган булып китте. Булдыра алса, елый-елый намаз укырга да разый иде Казан мафиясенең умыртка баганаларыннан берсе. Тик ходай аның ниязын, үтенечен кабул итмәде.

Бәла-каза, хәсрәт булганда кемсәгә дә күңел таянычы кирәк була икән. Эчке ныклыкны акчаның муллыгы, байлыкның ташып торуы гына тәэмин итә алмый шул.

«Зөлфиям сау-сәламәт кайтса, гел изге юлда йөреп, ярлы-ябагага ярдәм итеп, явызлыкка каршы көрәшер идем. Йа, аллаһы тәгаләм, ялварып сорыйм, ярлыка минем гөнаһларымны, гафу ит, сәдакамны кабул кыл», — дип сөйләнә-сөйләнә Зөлфиясез узган өченче көненә чыкты.

Бала вакыттан зиһенендә сеңеп калган шул сүзләрне кабатлый торгач, аңа ничектер җиңел булып китте, җанына нур иңде, тәне тынычлык тапкандай итте.

Төньяк калавылында яшәүче мулла янына барып, «Тәүби иллаһ» аятен кат-кат укытты. Шуңа күңеле, җаны белән ышанасы килде.

Әйе, сүнеп барган өметенә тоз сибеп булса да, сүндермәскә тырышты. Читтән ярдәм белән дәррәү күтәрелгән ут тиз сүнүчән була икән шул.

Оҗмах кошы, таң нуры — Зөлфиясен дошманның исән-имин калдыруына ышанычы утлы шәм кебек эри барды. Артык интектермәсеннәр, пычрак алымнар белән рәнҗетмәсеннәр иде. Кадерлесенә кагылган читят дошман куллар күз алдына килеп, җаны үртәлде, сөмсере коелды.

Ничек кенә авыр кичермәсен бу югалтуын, Сәет сынмады, сытылмады. Хәтәр сынау көннәрендә, авыр мизгелләрдә табигать һәрдаим гаҗизләнгән баласына гаҗил ярдәмгә ашыга икән. Сәетне дә ташламады табигать-ана. Ялтыравыклы күзләре тоныкланып, ятим этнекенә охшап калса да, ул үзенең хәлен артык мөшкел дип санамады. Туктаусыз тикшерү, сүтү, ачыклау, үз-үзен битәрләү урынына, изасызлыктан бавырына кан сауса да, ул Зөлфияне эзләүне дәвам иттерде. Бер тишекне, йомран кебек, күпме генә бораулап ятсаң да, җирнең төбенә төшеп җитә

алмаячаксың. Күп тапкырлар оттырып та, сугышчан рухын сынмаган, могҗизага ышанган, үзеннән көчлерәк көндәшен үртәп, ирештереп, һаман-һаман яңа бәйгегә чакырган шахматчы кебек, Сәет Зөлфиясен табасына ышанды. Иптәш кызларын үзе күреп сөйләште, чапкынчыларны туган авылларына җибәрде. Салих Гаяров ярдәмендә тагын бер кат милиция бүлекләрен, хастаханәләрне тикшереп чыкты.

Ниһаять, «тышкы» дөньядан Зөлфия турында шыттырылган хәбәр килде. Билгесез хатын-кыз аны телефоннан, үз өендә эзләп тапты.

— Сез Сәет Сакманов буласызмы?

— Әйе. Тыңлыйм сезне.

Тонык тавыш. Үзгәртелгән. Таныщлык түгел. Таныш чалымнар да бар кебек. «Юеш чүпрәк аша сөйли»,— дип күңеленә беркетеп алды Сәет.

— Безнең тәкъдим бар.

— Сез кем буласыз инде? Минем хакта барысын да беләсез бугай.

— Дошманың, дустың хакында һәммәсен дә белү хәер.

— Кем икәнлеген әйтергә курыккан кешеләр белән сөйләшүне үзем өчен түбәнлек саныйм. Хатын-кыз булса да...,— дип, Сәет трубканы ташлады.

Янәдән шалтыратачакларын һәм бу юлы вакытны заяга уздырмыйча, үгезне мөгезеннән алачакларын белә. Сыналган алым. Телефонга туйганчы калтыранырга ирек биргәч, тыңлагычны күтәрде.

— Сакманов, тыңла, игътибар белән. Син җиңелдең! Зөлфияң бездә...

Шул ук төссез, иссез, тәмсез тавыш. Ханымның кулында хәлиткеч көч юклыгын, аның арадашчы гына икәнен белсә дә, Сәет чарасыздан, саламга ябышты:

— Бәягезне атагыз! Мин риза.

— Үзең белән алыштырырга ризамы?

— Минем шаярып торырга вакытым юк. Трубканы куям.

Хатын җир астыннан килгән ләмле тавыш белән әшәке итеп көлде.

— Кыланма артыгын, мусор. Хәзер телефонны мин генә ташлый алам. Башка хутың юк.

— Шартыгызны әйтегез? Теләсә-нинди сумманы түләргә тырышырмын. Кешечә кылансагыз!

Сәет артык киерелеп сөйләшә алмый. Койрыгы бозда.

— Безгә акчаң, байлыгың кирәкми. Үзебез алырбыз анысын. Яраткан, яшь хатыныңны акчага әйләндерергә риза булыр идеңме әллә? Җир корты! Оятсыз фараон.

— Зөлфияне телефонга чакырыгыз! Аның тавышын ишетим.

Тагын да явызрак көлү ишетелде:

— Хәйләкәр син, мент калдыгы! Хатының ирләр белән типтереп яткан җирдә телефон юк. Ул барыбер лаякыл исерек. Сөйләшә алырлык хәлдә түгел.

Хатын кемнеңдер кушуы, боерыгы буенча Сакмановны үрти, мыскыл итә, кешелеген кызыл балчыкка ташлап, кысыр кәҗә тоягы белән изә. Заманында Булат Окуджава «бер акыллыга бер тиле», дип җырлый торган иде. Ә Сәеткә, татарың киңәш биргәнчә, үзен «түзәргә кирәк, балам» дип тынычландырырга гына кала.

— Мансур Маулетовичны үтергән кешегә алыштырырга әзер без. Тотып китерә алмасаң, исемен ата. Үзебез эзләп табарбыз.

— Ниткән тупас шаярту бу? Сез мине башка кеше белән бутыйсыз түгелме? Мансурның үлемендә минем бернинди катнашым юк.

Дөньяда иң якын, иң газиз кешесе язмышы хәл ителгәнгә, Сәет сөйләшүне тупас өзәргә җөрьәт итми; трубканы колагына магнит белән ябыштырганнар диярсең. Марля аша иңгән тонык вә бозык тавышны тыңлый. Җавап бирә, вакытны суза.

Әңгәмәнең төбендә икесе дә тәгаен аңлаган кинә ята. Ялланган атучының сукыр тиенемә дә хаҗәте юк. Сәетнең катнашуын, бу эшне оештыруын ачыклау гына ләзим аларга. Мансурны Сакманов юкка

чыгарган дигән фикри гөманнары булса да, кулларында какшамас дәлилләре юк. Шуңар да Сәетне сыныйлар, тикшерәләр. Башкорт әйтмешли, катмарлы уен бара. Шөрепне таләп итәләр. Әлбәттә, аның кирәге юк имансызларга. Мәхлук кул астында, янында тышауда утырса да, Сәет аны дәгъвачыларга тотып бирә алмас иде. Аны тәмләп җәзалап үтерерләр, гәүдәләр өстеннән узган танклар төсле, алга китәрләр, Сакмановка килеп җитәрләр, бугазына пычак тыгарлар. Салих Гаяровның раславына ышансаң (акча каеру өчен генә уйлап чыгармаган булса), Шөреп үз-үзенә кул салган. Оста корылган мәкер капкыны гына бу. Сырны карга авызыннан төшерү уе ята үзәктә...

Ханым белән сөйләшү мәгънәсез дулкында өзелде. Ул дөньядан бүтәнчә хәбәр килмәде.

Бу талымсыз әңгәмә Сәеткә авыр тәэсир итте. Җанын вак йомычкаларга телгәләде. Шикләнү, борчылу, чарасызлыктан гасабилану аны соң чиккә җиткерергә мөмкин иде. Еш утырган урман агачларыдай берсен-берсе кысрыклап килгән соры уйлары аның миен изә, сөякләрен сындыра башлагандай тоелды. Симферопольдә, чире тоткандагы төсле, йөртларның астын өскә китерәсе генә калды. Болай бетәшсәм, ычкынуым бар, кем беләндер аралашырга, хәсрәт дәрьясын бүлешергә кирәк, дигән карарга килде. Аягы белән түшәмгә асылынган килеш калырга ярамый аңа. Кая юл тотарга? Кемнән бәйләтергә йөрәк ярасын.

Үзе өчен ачыш ясады: таныш-белешләре, мәҗлестәшләре күп булса да, юшкынны эретердәй якын аркадашлары санаулы гына икән. Теләсә кемгә бара алмый, горурлыгы тота. Ялгызлыкта, алтын читлектә үлгән байлар язмышы...

Шәхси «табышына» үзе үк гаҗәпкә калып, сул як аскы иренен төшереп, кинаяле елмаеп куйды. Әлеге дә баягы Әхмәдиша абзыйларга юл алды. Өстәлгә нигъмәтләрен, «чуаш» малаен чыгарып куйгач, ир күрке — кыска сакалын олы учына алып, хөсетсез кайгылы күзләрен Сәеткә текәп, карт сорап куйды:

— Хатының дим... Зөлфиябез табылмадымы?

Каны саркып торган ярага тоз сипкәндәй булды картның сөале. Колагында хатынның бозык тавышы зыңлый. Зарарлы шеш төсле каядыр эчтә утырып калган. Телефоннан сөйләшүне берәүгә дә әйтмәскә булды Сәет. Бәлки, берәр коткы, шантаж гынадыр әле. Аптырау төсле агарынып, ялганларга булды «Игелек» хуҗасы, «әлегә юк», диде.

— Берәр төрле уең бармы?

— Миңа үпкәләп, берәр иптәш кызының авылына кайтып киткәндер әле шунда. Бала-чагалыгы чыгып бетмәгән.

Сорауга җаваптан бигрәк, аның үзе өчен алдавыч, юаныч эзләве иде. Әгәр чыннан да Зөлфиясе, теге явыз хатын әйткәнчә, мәхбүслектә интексә? Йөрәге гомердә булмаганны, чәнчешеп-тартышып куйды. Хәтерен җуйган кеше итеп сизде үзен. Зөлфиядән башка аның өчен дөнья юк иде. Үткәне, сандугачлы бакчалар — барысы да онытылды, гаип булды. Җир шарының уртасында ай йөзле, ап-ак чырайлы, зур күгелҗемяшел күзле Зөлфия генә калды. Иркәсен коткарса, аны башкача сөяр, колагына җылы сулышын өрә-өрә, гел матур сүзләрдән тәсбих төймәләре тезәр иде.

Соң, шуннан, хатынын эзлисе урынга, ул монда балавыз сыгып, үзен кулак калдыгыннан җәлләтеп утыра. Хәрәкәттә — бәрәкәт, ди татарын. Икенче яктан, әтисе әйтмешли, бухты-барахты өй күтәреп булмый. Кая барып сугылсын ул? Милициягә мәгълүм! Өендә, телефонда Мисхәтне калдырды.

Әхмәдиша агайны эчтән корт кимергәне, нәрсәдер әйтәсе килеп кымырҗаганы сизелә. Нидер борчый үзен. Әйтергәме, әллә телне тупсада калдырыргамы, дип уйланып утыра. Таякның ике башлы икәнен онытмый ул. Сәеткә ихтирамы, табигать баласы — Зөлфиягә яхшы карашы җиңдеме, әллә әләклисе кешегә мөнәсәбәте өстенлек алдымы, хәзер

кистереп әйтүе кыен, ул кадәресе мөһим дә түгел, Әхмәдиша карт серле янчыкны чишәргә булды.

— Миңа Арбакайтың бер дә ошамый, Сәет. Теге чакта әйткәнием.

Сәет яше тышка бәреп чыгарга әзер күзләре белән елмайгандай итте. Ясалма килеп чыкты.

— Кызык кеше син, абзыкай. Мин бит сиңа аның белән йокларга тәкъдим итмим. Ошамаса... Йә, нәрсә булган? Кай җиреңә кимегән шуннан? Миңа да ошамаган кешеләр во! — дип, кул кабыргасы белән муенына сызды.

Карт, элеккеге фирка җыелышларында сүз сорагандай, уң кулын — балалар көрәген өскә күтәрде.

— Ашыктырма, энем. Гафу кыл. Ашыгу — кеше хатыны белән аның өендә булганда, ГУЛАГта борча тотканда гына ярый, ди торганыек без яшь чакта, уйлап бетерим, может, ялгышамдыр...

Сәет иңнәрен җиңелчә генә сикертеп куйды. Янәсе, теләмәсәң, үзеңә кара, көчләштән түгел. Елан итен үзең сорап алдың.

Карт күптәннән уйланып, күңелен бимазалап йөргән фикерен бер тын белән ярып салды:

— Синең хатынны урлаганнар, дип уйлыйм. Ул хәтлесен үзең дә сизенәсеңдер. Әйтергә кыюлыгың, йөрәгең җитми. Бу эшне оештыруда бухгалтерыңның катнашы бар дип чутлыйм. Зөбаниларның төп ярдәмчесе булуы да бик мөмкин аның.

Сакманов очына ит эләктергән чәнечкесен өстәлгә ташлады. Тупасрак чыкты.

— Ничек? Ни рәвешле? Юкны сөйләмә!

Әхмәдиша бу юлы кадими шәкерт беләге юанлыгындагы күрсәткеч бармагын өскә күтәрде.

— Сез мине салпы колаклы диванага саныйсыз инде. Беләсең килсә, ул сиңа күптәннән яшертен хисләр яндырып йөри, бахыр.

Шуны әйтте дә карт, тукталып, төртелеп калды. Тормыш Сәетне күп нәрсәгә, аерым алганда, түземлелеккә, көтә белергә өйрәтте. Картның әлифне әйткәч, таякны да чыгарасына ышанып, йөрәгә чәнчеп куйса да, көтәргә булды. Пауза озаккарак сузылгач чыраена ваемсызлык, искитмәүлек тамгасы чыгарып, «соң, шуннан?» дигән булды.

— Хатыныңны урлауда ул катнашкан булырга тиеш. Этнең баласы эчендә өрә, — диде карт, сүзләрен кызыл балчыктай яргаланып беткән иреннәреннән капшап, тикшереп, авырлык белән чыгарып.

— Фаразыңны ни белән раслый аласың?

— Көнчелек кешене бүрәнәгә сикертә, утка кертә. Син, аңа карамыйча, Зөлфияне апкайттың. Чыраеңа бәхет фәрештәсе шәүләсе төшкәнне күреп, ябыкты, саргайда бухгалтерың. Озын чәч акылны кыскарта. Аның көрәш юлына, үч алу юлына басуы ихтимал.

Сәет тынсыз калды. Карт төлкенең сүзләрендә уй дәрьясына ташларлык хикмәт бар. Хисапчысының үзенә сәер-сәер карап куюларын, кайнар учын кулында озаграк тотуларын гади ярарга тырышу, адәм баласы башыннан йөри торган гади ялагайлык дип кенә карый иде. Чикләвек төше тирәндәрәк икән. Күкрәге белән сырпаланып алган очрак та исенә төште. Анысына да дикъкать бирмәгән иде.

Әхмәдиша абзый белән, нигездә, килешүен чыраендагы үзгәреш аша сиздерде.

Зөлфияне машинага утыртып алып китүләре көн кебек ачык. Артыннан чыккан иптәш кызлары аны капылт югалталар. Троллейбус, автобус тукталышында да күзләренә чалынмый. Чит машинага утырмаска тиеш иде. Үзе дә куркытылган поши баласы кебек бик сак иде. Аңлашылмый. Һәркемнең эчендә үз сәгатен көтеп утырган кара фикер янә телен кыймылдатты. «Ә үзеңә, бөтенләй белмәгән, күрмәгән, исен иснәмәгән ирнең машинасына кереп утырды ич. Ашыга, имеш, дөньяда соңгы поезд булмагандыр».

Аек акылның кабихка җавабы әзер иде: «Анысы язмыш инде, андый очрашу-ышанулар гомергә бер генә була».

Томана кара фикер ачыкламышны йөрәгенә уткәрмәде, үҗәтләнүен дәвам итте: «Әгәренки, бу юлы да шундый ук берәгәйле очрашу-табышу булса, тиз гашыйк булучан хатының янә берәрсенә, синнән дә крутойрак-ка ияреп китсә...» Сәет, мондый ырылдашуга җавап биреп торуны үзе өчен түбәнлек санап, кара фикернең лепкәсен йөз грамм аракы белән бастырыклап куйды.

Картның хисапчысы турындагы «крамол», вәсвәсәле сүзләре ачуын чыгарып, зиһенен кара кайрак белән игәүләп, эчендә тугыз баллы давыл котырынып, ике фикер арасында кискен орыш барса да, йөзенең бер мускулы да селкенмәде. Әхмәдиша абзыйның хаклыгына мөһер сугарга ашыкмаса да, тәҗрибәле, күзәтүчән кешенең сүзләрендә дөреслек ор-лыгының тамыр тибеп ятуы бәхәссез иде. Картлар сүзе буш булмас. Яхшы киңәшне өлкәннән сора. Наилә-Нонсаның үз-үзен тотышын, аңа мөнәсәбәтен чит кеше күзенә чалынмый торган ваклыклары аша исенә, хәтеренә төшергәч, шуларга сәер тавышлы кешенең телефоннан ирештерелгән дошмани тәкъдимнәрен өстәгәч, ул әкренләп карт ягына авыша барды.

Зөлфияне машинага утыртып алып киткәннәр. Биредә хатын-кызның катнашы булырга тиеш. Ә ни өчен әле Наилә-Нонса? Ул бит аңа күп нәрсәне ышанып яшәде. Сәетнең терәге комнан үргән бау булып чык-тымы? Күңелле булыр иде, болай ук күңелсез булмаса.

«Абзый, туктале син, тормозга бас, баш миеңдәге сыекчаңны эшләтеп ал. Нонса-Наилә сиңа эшкә ничек килеп эләкте? Аны кем тәкъдим итте? Һәр нәрсәнең җае бар, ботканың да мае бар. Аны бит... Элеккеге ярың Римма үтенече буенча кабул иттең. Җанашың мактый-мактый сылады. «Бергә эшлибез, телен йозакта тота белә торган партизан хатын. Минем шикелле, үзе генә бер бала үстерә, ире алкаш булып чыкты»,— дип кодалаганы исеңә төштеме?

Ә Римма — тәп-ләп хуҗасы Андрей Северцевның турылыклы мөридәсе булып чыкты. Димәк ки, Наилә Матыгуллина теге хайвани зат белән таныш булып чыга түгелме соң? Мин агач таякка атланган пәри хәлендә калам түгелме? Ике хатынны янәшә куеп, бер үк ясcылыкта яткан төшенчәләрне чәкештереп карарга башым җитмәгәч, миңа тагын Зөлфиядәй асыл кошны саклап калу. Терсәк бик якын булса да, тешләп булмый шул. Үзе егылган еламас, дип тынычландырырга гына кала үзеңне».

Сәет хисапчының эшкә килеп урнашуын, кешеләр белән аралашу юлларын, килеш-килбәтен күңеленнән уздырды.

Беренче мәлне хатын сәер гадәтләре белән шаккатырды. Эшкә алынып берничә атна үтүгә, татар милләтеннән булуына зарлана башлады. Исеммени инде ул Наилә? Тамыры «на» — ал, бери, аннан инде теләсәң ничек «илә». Фамилиясе дә «матыга» сүзеннән алынган икән. Бакча матыклаучы кешенең оныгы — нәбирәсе була инде ул. Башка шөгыльгә ярамагач. Кыскасы, мондый ямьсез, йөрәккә ятышсыз исем-фамилияләр үзен хөрмәт иткән бер халыкта да була алмый. Ата-анасы кушкан билгеләмәләрдән туйганчы көлгәч, мәсхәрәләгәч, Джульетта, Барди, Регина, Нонса, Лаура, Дульсина кебек, аның уенча, матур, аһәңле яңгырашлы исемнәрне мактый башлады. Арбакайте концертларына тавышы өчен түгел, ә фамилиясенә кызыгып йөриләр, дип авыз суын корытып сөйләгәннәре исенә төште Сәетнең.

Шул көннән алып Нонса-Наилә Арбакайте булып китте хисапчы ханым. Матыгуллина дигән үзбилгеләмәсе имзалы кәгазьләрдә генә калды.

Дөрес, ханым дебет-кредит, керем-чыгымнарны яхшы алып барды. Эш ягыннан бәйләнергә урын калдырмады. Банктагы танышлары аша да тикшереп карады. Тота алмады. Ә хәзер ни әйтергә дә белми. Хикмәт картның коткыга якын шикләнүендә, хәвефләнүендә генә түгел. Үз шәхси

күзәтүләре, эш узгачрак ясаган нәтиҗәләре шуңа алып килә. Телефоннан шалтыраткан ханымның үзгәртелгән тавышында да таныш чалымнар бар кебек. Юк ла, галлюцинация башланмасын тагын!

Әхмәдиша исә Сәетнең хикмәтле уйга талган, акшарланган йөзенә карап алды да, хуҗасының борчуларына яңа агым кертүне, камырга чүпрә өстәүне кирәк тапты:

— Аның бит тәненә ябештерелгән алтын-мәрҗәннәре генә дә ике-өч бүлмәле фатир сатып алырга җитәрлек.

— Күбесе бездә эшли башлаганчы тагылган иде,— дигән булды Сәет, хисапчыны яклаган булды.

Чынында бу хакта үзенең дә уйлаштырганы бар иде. Акча янындагы акыллы кешегә хуҗасын алдау ике бармакны тозлы суда чылату гамәлендә дә тормый. Үзенә кирәгенчә батыргандыр кулын. Кышкы ачы бураннарда, урманда КамАЗлар саклап, таможняны алдау юлларын, милицияне майлау ысулларын эзләп, чәчен агартмый ич исәп-хисап халкы.

Тылсымчы карт сөякне ташлады да тынып калды. Оялып кызарынгандай итте, төрәнне башка эзгә төшерү хаҗәтен сизенеп, кәмперенә чәен яңартырга кушты да, югалып калган хуҗасына олылар киңәшен биреп карарга булды.

— Акылыңа кил, Сәетҗан. Бер матур көнне, тамырына үткен балта белән чапкан агачтай егылып төшүең бар. Беребез дә тимердән ясалмаган. Памятниклар түгел. Хәер, аларын да кран белән генә күтәреп алалар да чүплеккә илтеп ташлыйлар.

— Дөрес әйтәсең, абзый, мин дә сөяк белән иттән һәм болганчык каннан торам,— дип, иреннәрен бөкрәйтеп кенә елмайды.— Мине ышандырдың. Чыгарып ташлыйм Зөлфияне баштан. Наиләгә ябышам.

— Энем, алай дип әйтүем түгел. Ачуланма. Болай бөтерелергә ярамый, диюем.

Сәет сабыйларча көрсенеп куйды.

— Киңәш бирүе җиңел. Бөкреңдә капчык ташу түгел. Беребезнең йөрәген икенчебез аңлый алмыйбыз. Туң кәбестәләр без.

Аңына килде. «Картның ни гаебе бар. Ул чын күңелдән кайгырта. Тормыштан арыдым бугай. Гамәлгә ашмаган хыяллардан, бәллүр пыяла төсле чәлпәрәмә килгән ният-өметләрдән, хыянәттән, ялгышулардан, татлы һәм ачы эчемлекләрдән, хатын-кыздан... Тәкъдирдә язылганнарның барысы да булды кебек. Үтәлмәгән вәгъдәләре, әйтелмәгән васыятьләре калмадымы икән?»

Дусларын, элеккеге хатыннарын искә төшереп карады. Барысы да томан эчендә, һәммәсен Зөлфиянең көләч елмаюы, ак тигез тешләре, бит очындагы тычкан күзе хәтле генә чокырчыклары каплый. Серле экрандагы төсле.

Бухгалтерын эзләтергә җибәрде Замирны. Гаҗәбе, ул берни булмагандай, «Игелек»нең конторасындагы тар бүлмәсендә алтын тешләрен елтыратып утыра иде.

## 29

Мәхбүс Зөлфиянең беренче тәүлеге авыр тынлыкта узды. Ике тапкыр тышка чыгардылар. Пешкән ит, сыр, су кебек ризыклар кертте машина йөртүчеләре. Зөлфия аларга кагылмады. Аның ишек кагуына, ялвару, кычкыруларына игътибар итүче булмады. Сәетнең үзен эзләп табасына ышанычын югалтмады кыз. Шул иманыннан үзенә көч алды, таяныч тапты.

Икенче кичне Заһит белән йөнтәс куллы адәм Зөлфия янында пәйда булдылар. Артта шоферлары елмаеп басып тора.

— Ирең сине яратмый икән. Безнең шартларга күнми. Без яхшылык белән араны өзмәкче булган идек. Теләмәде... Үзенә үпкәләр...

Кергән кешеләргә җавап кирәк түгел иде. Алар дәррәү Зөлфиягә ташландылар, башын кысып, авызын ачып, бер стакан аракы койдылар. Ханым буш ашказанына эчемлекнең яндырып-көйдереп төшеп урнашуын тойды. Аңын югалтты. Шуннан инде аңа зиһененә килергә бирмәделәр. Тәне, гәүдәсе авыртуга, ватылуга сискәнеп, уянып киткәндә, янә авызына сыекча койдылар, энә белән нәрсәнедер беләгенә кертteләр...

Өченче тәүлек тәмамланып килгәндә, артык көчле микъдарда бирелгән агулы матдәгә, өч ирнең бер-бер артлы көчләвенә түзә алмыйча, Зөлфия дөнья кайгы-хәсрәтеннән, үзен мәсхәрә итүләрдән котылды. Төнбоек чәчәге күзләрен йомды. Дөньялыкта берәүгә дә начарлык кылмаган таң кызы, яралгыда калган баласы белән җир куенына керергә тиеш иде.

Югалып торуына дүрт тәүлек узгач, Зөлфия өенә «кайтты». Гәүдәсен Әхмәдиша картның кече капкасы янына, коймага терәп, утыртып киттеләр. Йорт тирәсеннән чит тавык узганда да иләмсез тавыш күтәрергә яраткан Туман ым салмаган, сизми калган. Өйрәтелгән, нәселле этнең тавыш чыгармавын Зөлфиянең үзен тануы яисә аны китергән кешеләр арасында маэмайның «белешләре» булу белән генә аңлатып була. Әмма акыллы этнең үзен тотышын аңлавы кыен иде.

Ниндидер чүпрәк-чапракка төренгән, сәер төстә утырган-яткан Зөлфияне кибеткә ипигә барырга чыккан Хәерниса апа күреп, танып ала. Әле берни аңламыйча, эндәшеп, өйгә чакырып карый. Нидер сизенә, сырлы, кытыршы битенә кан йөгерә, иреннәре калтырана. Кычкырырга итә, тавышы чыкмый, артка чигенә, иренә эндәшә.

Карт аркасын коймага сөяп, җирдә утырган ханым янына килә, чүгәләп: «Кызым, синме бу, нәрсә булды, нишләп монда утырасың, өйгә керериең»,— дип сөйләнә-сөйләнә, кәкерәеп каткан бармаклары белән җилкәсенә кагыла. Чүпрәкләре аша салкынлык, җансызлык бәреләә. Куллын утка тыккандай тартып ала, телефонга йөгерә. Гел чылтырау көтеп утырган Сәет трубканы шундук күтәрә.

— Кем, Сәет... Зөлфия...

— Нәрсә? Кайда Зөлфия?

— Өйдә. Юк. Урамда. Утырып тора. Ятып тора...

— Исәнме?.. Үзе кайттымы?

Телефонда тынлык.

— Йә, әйт, абзый, исәнме?

— Исәнме дип... Килгәч күрерсең.

Өй янында гына торган «кадиллагына» утырып, бик тиз килеп җитте Сәет. Машинасын сүндереп тә тормыйча, авыр гәүдәсен урамда басып торган Әхмәдиша карт янына ташлады.

Зөлфиясен таныды. Йорт баганасыннан төшкән яктылык гәүдәгә сыек утын сибәли. Сәет сөеклесе янына чүгәләде. Кулларын учына алды, каралган, күзләре ябык битенә, шәмәхә иреннәренә тынын өрде. Җан әсәре сизелмәде.

Дөнья караңгыланып китте. Күзләренә тозлы юеш төште. Сарык бәтиен күтәргән шикелле, Зөлфияне кулларына алды. Фәрештәдәй җиңел иде вөҗүде. Өйгә алып керде, кая куярга белмичә, олы бүлмә буйлап күтәреп йөрде. Хәерниса апа ым белән ишеккә күрсәтте, аны ачып, өстенә җәймә ябылган киң ятакка күрсәтте.

Сәет бер нәрсәне аңлады: Зөлфия үле иде. Тәҗрибәле кеше буларак, ул ашыгыч ярдәм, милиция чакыртты, беркетмәләр тутыртты.

Аның өчен барысы да томан эчендә. Берни аңламый, төшенми.

Зөлфиянең бөтен тәне кара янган, тешләү, җәрәхәт, кыйнау эзләре белән капланган. Каен җиләгедәй назлы тәнне изгәннәр, таптаганнар, явызлык тамгалары калдырганнар. Хатын — көчләү һәм агулы сыекчалар нәтиҗәсендә үлгән, дигән карарга килде тикшерүчеләр. Барыбер кат-кат һәм җентекләп өйрәнгән булдылар. Әмма Хәерниса апа, Әхмәдиша карт һәм Сәеттән допрос алудан ары китмәделәр.

Тормыш театр түгел шул. Иренә ияреп йөреп, төрмәләрне, Себерләрне узган Хәерниса апаның да бу вәхшилекне күреп, йөрәге кысылды, тәне чымырдады.

Барысына да билгесез курку, пошыну рухы керде. Максатсыз әрлебирле йөренә башладылар. Аһ-ваһ килеп, күршеләр кереп тулды.

Хәсрәтнең иң авырын бөеренә алган Сәет хәлне ничек тә үз кулында тотарга, юнәлеш бирергә тиеш иде.

Явыз көч аның йөрәк парәсен — бигөнаһ Зөлфиясен алды. Тәңре тәүбәсен кабул итмәде.

Сәет үз күңелендә билгесез усал көчнең, үчнең ачу булып әчтән күтәрелүен тойды.

Очраклы рәвештә көзгегә карады. Яңакта ялтыравык чәчләр, борын янәшәсенә яткан кара шәүлә, эчкә баткан яңак, маңгайдагы, муендагы сырлар — барысы да аңа ят, бөтенләй башка кешенеке төсле иде.

Коръәндә болай диелгән: «Һәм тиешле булган үлем газабы килде». Ни өчен ул үлем башка берәүне түгел, ә аның сөеклесен алды? Сәетнең үзенә килсен иде... Армиядә, милициядә хезмәт иткәндә, мөстәкыйль эшен алып барганда, Сәет үзен күп нәрсәгә, курку хисен бастырыклауга, ничаклы гына авыр булса да хакыйкатьне әйтергә, кырмавык фикерләрдән арына белергә, хисләре белән идарә итәргә һәм дошманын дөрес бәяләргә өйрәнде.

Зөлфия өчен ул бары үзен битәрләде. Яраткан хатынына базны үзе казыды, упкынга үзе сикертте. Күндәм генә, баш иеп, берни булмагандай, тук тормыш белән, табигать ямендә, ризык тәменә сокланып кына яшисе иде дә бит, Сәет булдыра алмады. Нәфесе җиңде. Ни пычагыма кирәк иде аңа Мансур белән булышырга? Фердинандны да үҗәтлеккә ул өйрәтте, астыртын өстереп торды. Ыржыктай егетләр җир куенында череп ята. Ачу алдан, акыл арттан йөри шул.

Бу фани дөньяда һәр тайчыну өчен түлисе буласын белә иде ич ул. Гафу итмәсләрен, кичермәсләрен, соңарган тәүбәсен ходаның кабул итмәсен чамаласа да, тыелган чикне үтте. Тасманы үзе өзде.

Аллабыз күп санлы галәмнәренең берсенә атланып, гөнаһ, зина, җинаять кылганнан соң гына мине искә төшерәсез, ярлыкамны сорыйсыз, тәртәгез диварга килеп төртелгәч кенә мине сагынасыз, дип әрләп, көлеп утыра булыр. «Оҗмахтан алма урлап тотылган балага мин биргән иң зур сынау да шул: сират күперенә, тәүбәгә җиткермәү иде бит, адәми затлар»,— ди торгандыр әле.

Иртәгә күмәсе дигән көн елак килде. Сәетнең кара хәсрәтен уртаклашкандай, болытлар туктаусыз диярсез тозсыз күз яше түгә. Кан әсәре калмаган битен учларына салып, хуҗа, мәрткә киткән кешедәй, Зөлфиянең юылган, ап-ак киемгә төрелгән гәүдәсе янында утыра. Бичараны, интектереп, тагын өстәмә тикшерүгә алып барган булдылар. Эченә кертелгән агуның килеш-килбәтен, сыйфатын, күләмен, составын тикшергәндәй иттеләр. Энә белән бик көчле наркотик кертелгәнлеге ачыкланды. Аракы да эченә үтергеч күләмдә коелган.

Вәхшилек эзләрен ачудан, фашлаудан Сәеткә җиңел түгел. Йөрәге эссесе беткән мунча кебек йончу, тынчу хәлендә. Һава җитми, ә миен болан мөгезе кебек тармаклы сораулар интектерә. «Ни өчен Зөлфия, кемгә тиде аның зыяны? Нинди начарлык кылды ул? Явызлыктан башканы белмәгән кемсәләр яши, ә аның сөеклесе инде беркайчан да, берәүгә дә яхшылык эшли алмас!»

Каршы якта, шундый ук кечкенә, гади утыргычта кызның әнисе — кайгы дәрьясына чумган Рәмзия ханым ачы яшьләрен тыя алмыйча утыра. Әтисе үзенә тугрылыклы калган, күмәргә кайтмаган. «Мин шулай бетәсен белгән идем»,— дип, кайгысын яшел агу белән юарга пожаркага кереп киткән. Сагышын һәркем үзе белгәнчә чыгара, үзе кабул кылганча юана. Иптәш кызлары кереп-чыгып йөри. Әлфия дустының гәүдәсе яныннан китми. «Ни өчен үзен генә институттан чыгарып җибәрдем,

троллейбуска гел үзем утыртып озата идем».— дип җанын битәрли. Чәчләрен үрле-кырлы сикертеп куярга онытмаган Тачанка-Наташа да шунда. Регина күренми. Үз хәсрәте баштан ашкан, күрәсең.

Сәетнең ярдәмчесе — Хәлил тәкә кебек меркелдәп, гөл сөйләнеп, эчне пошырып йөри. Кумү мәшәкатьләре аның өстендә. Үзен күрсәтеп калырга мөмкинлек бар.

Сораулар, борчулар җәтмәсендәге башын кая куярга белми утырганда, Сакмановны телефонга дәштеләр. Ясалма кеше хәрәкәтләре белән торып китте. Робот диярсең.

Калтыранып, дерелдәп чыккан көчле тавыш бәрелде колагына трубкадан:

— Браток, кайгың турында ишеттем. Ваһапов бу. Уртаклашам.

— Аңладым. Рәхмәт,— диде Сәет чырайсыз, әлек язылып куелгандай тавыш белән. Гәүдәсендә тоташ гөжләү. Хисләре — ак белән кара төсләрдән генә укмашкан кан төере. Тыштан «крутой» күренсә дә, шәхси кичерешләренә хуҗа була алмый икән.

«Монысына тагын нәрсә кирәк, ул гына җитмәгән иде»,— дип уйлап алды. Аның берәү белән дә аралашасы, күрешәсе килми. Көне буена, кара янып, Зөлфия гәүдәсе янында, агач урындыкта утырудан үзгә теләге юк.

Тынлыкны янә «кит» тавышы бүлде:

— Күмү кайчан?

— Иртәгә.

— Мәһәрен түләргә исәбең бармы? Гафу иттеңме әллә?

Сәетнең гарипләнгән зиһененә фикер үтеп керә алмый. Буага килеп бәрелгән агымсу төсле, «нинди мәһер, ниткән гафу итү, нәрсә сөйли кит? Кайгыны уртаклаштың, булды, җитте, отвали, ради бога, башкасы синең хәсрәтең түгел».

Калтыравык тавыш трубканы яргалавын дәвам итә.

— Көт мине, хәзер килеп җитәм,— диде Ваһапов, хуҗаларча.

Әйтте-бетте. Ярты сәгатьтән ул әнә яһүдме, алманмы икәнен үзе дә белми торган җирән сакчысы белән килеп тә төште. Олы бүлмә кешеләр белән шыплап тулгандай булды. Лилипутлар илендәге Гулливер диярсең үзен.

Очлаеп калган битен учларына урнаштырып утырган Сәет кырына килеп, җиңеннән чеметеп алып, аягына бастырды, үзе артыннан барырга кушты. Бакчага алып чыкты. Сүзне, ышанычлы дусты кебек, үгезне мөгезеннән алып башлады:

— Телефоннан барысын да әйтеп булмады. Казан халкы татарча белмәсә дә, үзенә кирәккәндә чамалый. Хатының өчен үч аласы булсаң, бүген эшләргә кирәк.

— Мин сезне аңламыйм, Нургали абый!

— Хатыныңны үтергән кешеләр белән исәп-хисапны өзү турында сүз алып барам, браток. Уян! Йоклый торган вакыт түгел! Йөрәгеңне йон басканмы әллә?

Сәетнең миендәге боз эрегәндәй булды. «Үч алырга, Зөлфия өчен үч алырга»,— дигән фикер күңеленә әрсез колмактай үрләде.

— Соң, иртәгә күмү. Шуннан соң инде.

Ваһапов Сәетнең терсәген каты итеп кысты:

— Бүген башкарырга кирәк бу эшне. Төнге уникe белән бер арасында, браток. Таң йокысы тәмле була. Иртәгә аларны табып булмаска мөмкин. Таралышырлар. Ә бүген алар бәйрәм итәләрдер әле, дип уйлыйм. Кеше каны җирдә ятмаска тиеш.

Сакманов китнең хаклы икәнен аңлый башлады. Әҗәтне бүген кайтарырга. Зөлфия үзе өчен түләгәнне белеп чумсын җир куенына. Изге, нарасый җаны рәнҗеп китмәсен.

— Кемнәр кулы икәнен чамалыйсың булыр?

— Мансур өчен үч алулары дип уйлыйм.

— Ул хакта сүз бармый, браток. Син нәрсә? — диде кит, пырдымсызлана башлап.

Сәеткә сүз кыстырырга да бирмичә, күкерт кебек кабынып, һәр нәрсәне үзе аңлатты.

— Тыныч яшисең киләме? Үч алу турында катык болгатып тормыйм.

Соравына үзе үк җавап тотты:

— Килә булыр. Шикләнмим. Синең бүген: «Минем яшисем килми, хатыным белән бергә күмегез»,— дип ычкындыруың да мөмкин. Үлгән белән үлеп булмый, браток. Тынычлык урнашсын өчен бурычны түләү, этлеккә явызлык белән җавап бирү кирәк. Хәзер ул банданы юлдан алып ташламасак, алардан мәрхәмәт көтмә! Тормыш бетте сиңа! Тәвәккәллик! Мәслихәт белән атылган таш үз урынына төшәр.

Акрын сөйләргә тырышса да, Нургалиның бу нияте барып чыкмый, пышылдап, яшерен сөйләшергә көйләнмәгән тавышы.

Сәеткә илләм оят булып китте. Ярдәм турында ул сорыйсы, үтенәсе, ялварасы урынга, кит аны үгетләп маташа.

— Тәп-ләп хуҗасы Северцевны беләсезме? Аның катнашы булуында шигем юк,— диде Сәет.

— Беләм генә түгел. Үземнең дә расчет ясыйсым бар аның шайка ләйкәсе белән. Төрмәдән кайтуга, миңа зур этлек кылырга өлгерде. Котырган эт үз койрыгын үзе чәйнәр, ди. Синең хатын өчен генә, бәлки, болай кыбырсып йөрмәс тә идем. Анысы да зур хулиганлык инде. Бер гаепсезгә баланы харап итәргә.

Гадәти бер шөгыль турында сүз алып барамыни? Һич дулкынланмый.

Кит белән уртак дошманнары бар икән. Анысы начар түгел. Сәет фикерен өздереп әйтергә тиешлеген аңлады. Маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Кульяулыгын алырга дип учын чалбар кесәсенә тыккан иде, җирән сакчы ялт итеп янына килеп басты, кесәсен тыштан капшап алды.

— Мин риза,— диде рәхмәтле Сәет, маңгай тирен сөртә-сөртә.— Аларны каян табасың, ничек аласың?

— Алары синең кайгы түгел. Ныклап әзерләнү хәзер синең бурычың. Ат аунаган җирдә төк калыр. Табарбыз. «Ял йортларын» беләм мин аларның. Элегрәк булганым барые. Артык кешең булмасын. Йөртүчең житкән, дип уйлыйм... Тәк, өч канистра бензин, чыбыркыңны әзерлә. Глушитель белән ике көпшәлеңне ал диюем. Нәкъ төнге унбергә көтегез мине. Хәзергә, браток.

Калтыравык тавышын көлүгә җайлады.

— Нәрсәдән көләсең? — дип сорый алды Сәет. Шундый хәтәр карар кабул иткәндә, дымлы теш күрсәтү аңа гайре табигый тоелды.

— Күңелле эшкә барабыз. Кан үчен алудан да изге нәрсә юк төрки халыкларда. Көлүне, браток, табиблар дару, авыр вакытта иң олы таяныч, диләр.

Бераз уйлап торгандай итте дә, өстәп куйды:

— Сакманов хатынын саклый алмаган, ачык авыз икән, дип бөтен дөнья кара күмергә әйләнергә тиеш түгелдер, шәт? Тормыш дәвам итә. Зөлфиянең рухын шатландырырбыз бүген, алла кушкан булса.

Ваһаповтай кешегә ни әйтсә дә, ничек кыланса да килешә. Туган-тумача да, кода да түгел, ярдәм кулын сузды. Заманында мылтык бүләк иткән, имеш... Аңа андый һәдиян малмы...

Сәет кит турында шактый имеш-мимешне ишеткән иде. Катлаулы, үпкәчел, үз-үзенә бикләнгән, читләрне дөньясына бик кертми торган кеше булса да, аны күп укый, будда фәлсәфәсен өйрәнә, тарих турында сөйләшергә ярата, диләр. Хатын-кыз белән буталып алуда олуг гөнаһ күрмәсә дә, илләм, яшерергә тырыша, диләр. Мәгәр андый кешенең мәхәббәт романы бөреләнеп, уҗымга керергә өлгергәнче үк, гайбәте таралып өлгерә, сасы хәбәр беренче нәүбәттә хатыны колагына ирештерелә. Тайгак юлга басканыңны көтеп торучы саламторханнары табыла һәр чорда.

Кем аркасында рәхәттә яшәгәнен аңлаган, рәхмәтле хәләл җефете мондый сөйләкләрне йөрәгенә үткәрми, һәрхәлдә, әхлак сагында торучыларның дәртен сүндереп, «тилереп туйгач, кайтыр әле», артык әрсез тырышларына «юкка борчыласыз, ул бит инде күптәннән ата чыпчык итен киптереп ашый», дип кенә ычкындыра, имеш.

Ни генә сөйләмәсеннәр, Ваһапов — көчле, яклаучан, сәрвәр һәм уйлы шәхес булып чыкты. Орыш өчен җаваплы баһадир кебек, кит соңгы күрсәтмәләрен бирүне дәвам итә:

— Сез УАЗик машинасы белән барырсыз. Мин чит ил җилбәзәгендә булырмын.

Сәетнең «ни өчен» кебек буш сөален алдан искәртеп, мәсьәләне япты:

— Көпчәк эзләре төрле булсын! Акыллы сыщикларның башы катсын. Эзгә төшсәләр димен.

Төнюлында шәм кабыну «Игелек» хуҗасын терелтеп, айнытып җибәрде. Замирга төгәл, анык эшләр кушкач, күптәннән ачмаган сейфыннан теге вакытта китка бүләк иткәннең игезәген — «тигр» кушаматлы мылтыгын алды. Иркәләп сөртте, җыйды. Патрон кертеп, төзәп карады. Автомат-карабин сугышка әзер иде. Күзләре явыз ялтырый. Маңгае күтәртмәле күпердәй алга чыккан. Битенә кара болыт төшкән. Явыз елмая. Үз-үзен тотышына, әйтерсең лә, Җабраил фәрештә чалымнары күчкән. Иреннәре янындагы тирәнәеп киткән сызыкларда ихтыяр көче, нәфрәт уты.

Сәет Сакманов Зөлфиясе өчен үч алу, сугыш юлына чыкты. Килешүнең була алмаячагы ачык иде.

Нургали бер сәгатькә иртәрәк килде. Сакмановны, өстендә торып, кырындырды, юындырды, затлы кәчтүмен киярга мәҗбүр итте. Туйга әзерлимени.

— Җаныбыз да, тәнебез дә чиста булырга тиеш,— диде.

Янында җирән яугиренең булмавы гәҗәпләндерде. Кит хатын-кыз кавеме белән аңлашып, ятатышып торганда да, бу бәндәсе ишек төбендә көтә, диләр бөкре теллеләр.

— Ул иртәрәк китте. Этләрен «тукландыру» белән шөгыльләнә,— диде Ваһапов, Сәетнең күзләрендә кәкре билле сорау галәмәте күреп.

Сакманов кай тарафларга юл алганнарын да артык белештерми. Аның бөтен тотышында битараф ваемсызлык. Машиналарны сүндереп, урман мәйданчыгында калдырдылар. Ике йөз метр чамасы җәяүләп бардылар. Кулларында канистрлар, мылтык исә күн футляр эчендә. Сырлы тимер капкалы биек койма янына килеп җиттеләр. Шылдырап торган нарат бүрәнәләрдән салынган ике катлы йорт масаеп тора. Тирә-юньдә сирәк урманлык. Еракта елгага охшаган түбәнлек күренә.

Нургалинең җирән яугире пәйда булды. Хуҗаларча кыланып, кечкенә капканы ачты.

Ваһапов Сәетнең колагына иелеп: «Ул инде монда үз кеше. Этне хәл кылган. Безгә ут уйнатып юанасы гына калды»,— дип пышылдады. Акрын сөйләргә өйрәнмәгән тавышы гырылдап чыга.

Сәет аның ниятен аңлады: йортны эчендәге кешеләре белән бергә ут хөкеменә тапшыру. «Анда бөтенләй башка, гаепсез кешеләр булса?» Бу уйны: «Зөлфиянең ни гаебе бар иде. Аны бит шул йортта мәсхәрәләгәннәр. Бу өйнең яшәргә хакы юк. Урынында көл өеме генә калырга тиеш»,— дигән катгый карар белән кысрыклап чыгарды уен.

Сәетнең күңелендәге каршылыкны аңлагандай, Нургали өстәп куйды:

— Агачның башын киссәң, төбе калыр. Янгын урынында көл калыр, арыш чәчәрләр,— дип гүләде.

Аңа ни сөйләсә дә, ни кыланса да килешә. Ул — хуҗа.

Егетләр аскы бүрәнәләргә як-яклап бензин сиптеләр. Җирән сакчы еракрак китеп, ягулык төшкән эзгә янган шырпы ташлады. Ут, өйрәтелгән эт төсле, юлны тиз тапты.

Яңгырга артык чыланмаган иркә бүрәнәләр, өсте капланган күтәрмәле агач баскыч, шуны гына көтеп торгандай, дәррәү кабынып, ярыша-ярыша чылтырап яна, күңелле чаткыларын өскә ташлый башладылар. Ялкын утыннан туймас, диләр. Хак икән. Койма капкасын эчтән бикләп, җирән сакчы тышка сикерде. Бераз читкәрәк китеп, аерыла алмыйча карап тордылар. Тәмуг уты күзнең явын ала, үзеннән җибәрми. Сыер телләре инде икенче катка үрли башлагач, «өй тавыклары» уянды. Иләмсез тавыш, кычкыру, ыңгырашу, каһәрләү ишетелде. Хатын-кыз чинавы үзәкне өзде.

Эчтәгеләрнең тәрәзәләргә, ишекләргә барып бәргәләнгәне, җан өшеткеч ачы тавышлары көчәя. Хуҗа, караклардан саклану чараларын алдан күреп, һәр тәрәзәгә тимер рәшәткәләр ясаткан. Бәреп чыгарлык түгел. Танк тимере белән тышланган тышкы ишекне Нургали егетләре эчтән ачып булмау хәстәрен кайгыртып өлгергәннәр иде.

Эчтә калганнарның берсе ялкыны артык котырмаган икенче катның тәрәзә рамасын бәреп төшерде, лом белән рәшәткәне каера башлады. Әзерлекле булуы, көче сизелеп тора. Утка игътибар итмичә, каера, бәрә, сындыра. Үлем куркынычы тиле көч өсти адәми затка. Менә ул кеше сыярлык, чыгарлык тишек ясады.

Сәет күрү, танудан бигрәк, теге вакытта зираттагы шикелле, тән күзәнәкләре, җаны белән таныды ул кешене. Югалып калды. Бу гәүдәнең явызлыктан, әшәкелектән торганын белсә дә, тәп-ләп җитәкчесен кызганып куйды. Җилкәсендә Ваһапов кулын тойды.

— Бас төймәңә! Шунда катып калсын!

Сәетнең икеләнүен тоепмы, карарын куәтләпме, өстәде:

— Хатыныңның каны аңарда. Бәр!

Шунда Сәет тавыш бетергеч куелган авыр мылтыгының җиңеләеп китүен тойды. Көпшә астында Замирның кулын күрде. Тиешле югарылыкка күтәргән икән мылтыкны. Куллары Иблис идарәсенә күчте. Ашыкмыйча гына гәүдәне мүшкәгә алды. Тәрәзә төбенә менгән кеше каршында басып торгандай якынайды. Ул аның өстенә кигән ак майкасын, шәрә ботларын, сирәк аксыл чәчләрен, тирәнгә утыртылган чокыр күзләренә хәтле шәйләде. Тәп-ләп хуҗасы Северцевны таныды Сәет. Күз алдына тешләп, чеметеп, кыйналып, кара яндырылып бетерелгән Зөлфия килде.

Бар көчен сикерүгә туплаган гәүдә тишеккә ташланыйм дигән мизгелдә Сәет тәтегә йомшак кына басты. Северцев, алга атларгамы, артка чигенергәме, дигәндәй чайкалып куйды. Артка егылып төште. Күрәсең, аңа табындагы дуслары «ярдәм» дә иткәннәрдер, аның урынын икенчесе алды. Соң иде. Түшәм аска ишелеп төште. Тавышлар тынды.

Сәет кинәттән тынычланды. Шунда гына төнге салкынлыкны тойды.

Туар көнне даулап таң сызыла. Һаваның яхшыга үзгәрергә исәбе. «Иртә торган икеләтә бәхетле, ул иртәнге кояшны күрә»,— дигән сөенечле фикер үтте Сәетнең башыннан. Тормышның бер бүлегенә нокта куелды. Тик Северцев һәм аның дуслары белән бергә хисапчысы Наилә-Нонсаның янып үлүен, тәп-ләп хуҗасын тәрәзә төбеннән аска сөйрәп алучы кешенең уртак хатыннары Римма икәнен генә белми иде әлегә. Берничә көннән ул бу хакта хәбәрне ишетәчәк. Кемнәрнедер кызганачак... Мәгәр үкенмәячәк.

Кеше күмүдән соң таралырга рөхсәт иткәндәй, дымык тавыш белән Ваһапов соңгы әмерен төшерде:

— Безнең эш тәмам. Киттек машиналарга. Урманны чыкканчы эзмәэз барабыз, аннары диңгездәге кораблар төсле... Төрле якка. Гали үз юлында, Вәли — үзенекендә...

*1994—1995.*

# ШИГЪРИЯТ



## Әхсән Баян

### Дога

И син, Тәкъдир, кодрәтләрең киңдер.
Бир син безгә, бир хәерле гомер.
Оялмаслык булсын үзебез өчен.
Оялмаслык булсын илебез өчен.
Бир абруйлы гомер.

Бөкереләрне турайт, төзне ныгыт,
Телсезгә — тел, нансызга бир ризык.
Катыйльләрнең телен, кулын корыт.
Дәрәҗәдән төшсен имансызлык.
Нансызга бир ризык.

Кем дан җыйган садәләрне алдап,
Кем мал җыйган мәзлүмнарны талап,
Андыйларны бөлдер, дөнья көлдер.
Кичермәсен алар рәхәт гомер,
Мәзлумнарны талап.

Фәкыйрьне дә яратырлык хис бир,
Эшсезгә — эш, көчсезләргә көч бир.
Кече илне җимереп горурланган
Олугъ илне хур кыла күр, Тәкъдир.
Көчсезләргә көч бир.

Тәрәзәмә иелеп, көннәр саен
Сөенечле моң сирпесен каен.
Кошлар анда чыгарсыннар бала,
Шатлыкларын ил җанына салыйм.
Моң сирпесен каен.

Иртә саен кылган догам шулдыр:
Бәндәләргә ихлас иман күндер.
Һава белән суга сафлык иңдер.
Илгә, җиргә тәүфыйк, иминлек бир,
Ихлас иман күндер.

Ихлас иман...

*1995*

* * *

Күңел аша күпме көйләр узган,
Барысы, барысы бергә кушылган.
Их, гомерем, яңгырап уздың инде,
Тыңлап туелмаган моң сыман.

Чиксез сыман моңнар, чыңлап озак,
Югалдылар, тынып калдылар.
Тасмаларда, кәгазьләрдә калса,
Бәлки алар кабат яңгырар.

Тасмалардан, кәгазьләрдән дә тик
Бер заманны җуелыр көн килер.
Ә син? Ә син? Халкың хәтеренә
Язылмассыңмыни? И гомер!

*1995*

* * *

Оста гына, шома гына
Яшәлмәде бу юлы.
Икенче кабат, күрерсез,
Акылым булыр тулы.

Абзагыз дөреслек эзләп
Маташмас — тиле булмас.
Төзәтер барча хатасын...
Икенче кабат тугач.

*1995*

* * *

Киләчәк кояшы якты,
Сүнгән ай моңы татлы.
Ә бүген, килде дигәндә,
Китте дә барды шатлык.

«Кулыңнан тиз ычкындырма,
Саклый бел мизгелләрне!» —
Дип киңәш бирү җиңел дә,
Ничек тотыйм җилләрне?

Ничек тотыйм кулларымда
Кояш һәм Ай нурларын?
Ничек туктатыйм чишмәне,
Диңгезнең дулкыннарын?

Мизгелләрне сораулардан,
Кайгыдан аералмадым.
Чын яшәү бүген икәнне
Артык та соң аңладым.

*1995*

* * *

Байлык-муллыкта йөзсәң дә,
Син, әфәнде, чат фәкыйрь.
Ышанмасаң, илгә кара,
Илең сиңа хак әйтер.

Иле бәхетсез чагында
Ир бәхетле буламы?
Айкалды ил, айкалды җан,
Айкалды да тулганды.

Син иректә ирме, туган,
Ил әгәр булса зиндан?
Үз хәлеңне белим дисәң,
Халкың хакында уйлан.

*1995*

* * *

Әй, туган җир, безнең белән бергә
Картайдыңмы? Ник карашың уйчан?
Әбиләрнең бит-куллары сыман,
Куырылган йөзең моң-сагыштан.

Чишмәләрең, күз яшьләре төсле,
Әле дә саф, ләкин тоям ачы.
Чишмәле тау яшел бүреген салган,
Күрше бабай сыман такыр башлы.

Яшьлек теләкләрем, ярсуларым
Белән бергә, йөзгән елгам кипкән.
Яшел кыйгта булып җанда калган
Тугайларым төсен җуйган күптән.

Күрәм, ишетәм: уйлы җаннар сыман
Чайкала кыр, аның күрке — ашлык.
Икмәксез җыр, шөкер, күп җырладык...
Җырсыз икмәк? Әллә шулмы тансык?

Дала булып калган әрәмәләр.
Шәрә таулар. Кош, балыксыз сулар.
Коргаксыган җанның рәвешләре,
Әй, туган җир, шулар ук бит, шулар!

*1987 (95)*

## Борынгылар сүзе

Дусларын белгән кеше,
Дошманнарын белмәсә,
Тырышса да, уңышка
Бик тә сирәк өлгәшә.

Дошманнарын белсә дә,
Дусларын ул белмәсә,
Ирешалмый уңышка,
Тырышса да бик, гәрчә...

Дошманнарын белә кем? —
Дусларын белә гәрчә,
Ирешалмый уңышка...
Әгәр үзен белмәсә.

*1994*

## Күккә карыйм

Күккә карыйм, анда аккош юлы
Төн карасын гүя юк итә.
Якты хәбәр көткән күңелемне
Җем-җем иткән серләр җилкетә.

Ерак томан, кара кучкыллыклар,
Әйтегезче, зинһар, сез шуны:
Сездә булса җаннар, алар Яктылыкмы,
Әллә Караңгылык рухымы?

Адашып калган Җир баласы, мин еш
Сорыйм сездән шулай кычкырып.
Ә җавапсыз тынлык шундый суык —
Йолдызларны тота очкылык.

Тын рухларга үзем бирәм җавап:
Җирдә яши сезнең ишеләр.
Кара җаннар Җирдә шартлый, күкри,
Күктә гәрчә телсез, өнсезләр.

Тик барыбер чыгып Кояш таңда
Әйтер дисез кайсы көч сүзен?
Мин ул сүзне беләм, гәрчә таштан чыккан
Очкыннарның бары берсемен.

*1993*

## Тиргәмә

Һәр нәрсәнең чамасын бел, бәндә,
Артыкка син аны җибәрмә.
Яхшылык та, артса, шик кузгата,
Чиген аның күрә бел, бәндә.

Мактау — зарур, тик артыкка китсә,
Хәйләнең ул — бары бер төре.
Күпкә китсә, яшерен мактау була
Усал тәнкыйть, каһәр төшкере.

Яманнарны, ялганнарны күбрәк
Очратырга туры килгәндә,
Дөньяның бар, хак икәнен бел дә,
Бөтенләй үк бетереп тиргәмә.

*1994*

* * *

Татлы шәрап ачы серкә була,
Ачык шешәләрдә торса озак.
Артык торса озак, ачы серкә,
Нәфрәт сымак, була агулырак.

Гомер буе булган хыял, сөю
Инде, гүя, беткән, юкка чыккан.
Ачы серкә гомер азагында
Үт суына әйләнер дип куркам.

*1994*

* * *

Төштә һаман торыр урын эзлим,
Чит җирләрдә — шыксыз, җил, томан.
Кунак йорты йә фатирда торам,
Хакын түләү, никтер, онтылган.

Күпме түләргә дип, эзлим хуҗа,
Ара өзми ничек юл чыгыйм.
Эзли торгач, ачкыч югалтам да,
Ача алмыйм бүлмәм ишеген.

Ә бүлмәгә керсәм, юк чемодан,
Киенергә кием калмаган.
Кайтыр өчен билет юкка чыккан,
Аны тизрәк юнәт яңадан.

Самолетка йә поездга таба
Чаба-чаба, калдың, соңардың.
Ә тукталгач, күрдең, күрдең кинәт —
Туфлиләрнең җуйдың сыңарын.

Туфли җую — ярсыз калу диләр...
Рас килмәгез, яман төшләрем!
Бер ялгызым — сөйгән ярсыз, өйсез,
Туган җирсез, мин соң нишләрмен!

Ахирәттә догасызлар шулай
Дога эзләп йөрер дигәннәр.
Әнкәм миңа бәхиллеген бирде
Һәм өнемдә исән сөйгән яр...

Кайсына соң, ничек ышанырга —
Әллә өнгә, әллә төшкәме?
Урыным әллә башка галәмдәме,
Мин адашып Җиргә төшкәнме?

Дөрес сүзме әллә гавам сүзе —
Безгә Җир тик кунак йортымы?
Төштә һаман торыр урын эзлим,
Төшләрдә дә җанга юк тынгы.

*1995*

* * *

Югары мәктәп бетереп
Каладан кайткан егет
Надан әңкәсенә бер мәл
Ятсынып баккан кебек,

Әй, авылым, кошлар белән
Кайткач ерак җир гизеп,
Мин дә сиңа, танымыйча,
Карап тордым читсенеп.

Кичер, кичер, туган җирем,
Мин тәүфыйксыз балаңны.
Сагынуларым дөнья гамен
Озак җиңә алмады.

Инде беләм, синнән ерак
Китеп булмый һичничек.
Күпме биек очса да кош
Җан бирә җиргә төшеп.

Кайттым җаным, тәнем белән
Сиңа һәм үткәнемә.
Сабыйдай сагынып әнкәмне,
Капланам күкрәгенә.

*1988*



# Рәдиф Гаташ

## ҖАННЫҢ БЕР СӘФӘРЕ...

* * *

Заманнарның, син — әйт, нинди заманы?
Ялкыннарың җанны безнең ялмады:
Явыз карчык йә ялмавыз аузымы
Йотты барсын — илдә «изге калмады»?...

Заман дигәнем, син — кемнәр заманы?
Мәхәббәткә, сафлыкка көн калмады...
Тагын — алтын, байлык итә патшалык,
Акыл, вөҗданны — дәрәҗә алдады.

Заман, син соң — шагыйрь яшәр заманмы?
Фәрман — килә, ул — түрәләр ялганы...
Халкын сөйгән, сатылмаган җанга — көч...
Тагын илдә — имансызлар базары.

Заман, чынлап та син — «ахырзаман»мы?
Шулай дию бездән генә калганмы?
Яшәү — күптәнге, дөнья — шул, үзгәрмәс:
Анда язмыш кемгә ниләр язмады?

...Кем генә каһәрләмәде Дөньяны?
Ә кем йөгәнләде Аны — Заманны?!.

### Синең сәфәр

Кыз хыялы! Сәер уйлар, серле йөк...
Иделдән диңгез ягына килдең ник?—

Кайсы кәрванның нык, чыдам дөясе
Илтте иңендә бай җаның дөньясын?

Атаклы чал Хәзәрдә бит чылатып,
Еладыңмы аннан — комына ятып?

Җир маеннан чыраг кабызган шәһәр
Яшьлегеңә булдымы калым-мәһәр?

Уен идеме, туеңмы — ул кичләр?
Гомереңне яктырткан айлы хисләр...

Азак сагынгансың, бәлки: кәрваннар
Алырга сине — илеңнән барганнар.

Ни белән баеган яшь җаның тик?—
Таумы анда? Кәрванчыга авыр бик...

— Кайта, дисең, төрки шигырь гөлләре,
Гел чәчәктә, мәңге тере үзләре.

Шул гөлләрнең исе тансык Иделгә:
Мең-мең еллар яшәсеннәр илемдә!

...Сәяхәт... йә сәясәтме? Риваять —
Җаныңның бер сәфәреннән хикәят.

Хыялың бит гел — Ай тулган чакларда
Шунда дәшә,— сүнмәгән учакларга.

* * *

Ни китәрде Әфганда синең һушны?!—
Һират гөле йә биек Һиндукушмы?

Йә Әзәрдә, төрки яр «арбагач», аһ,
Арагызга кердеме ут-Карабах?

...Һәм Азия — Термез, Карши капкасын,
Таулар белән хушлашып, бер япкач син,

Күпме ерак китсә дә дисең, алар
Озата килә... Гел күренә шул таулар.

...Күңел язында таулар күп булганга,
Сәяхәткә дәштем — Идел, Чулманга.

Тик, моңыңнан гүя туфан ташты да
Мин дә тау (!) салдым аягың астына:

Карадык икәү кыядан — дөньяга...
(Тукталган, килеп, хыяллар — Уфага!)

Биеклекләр — мөгаен, язмышыңда,
Иркен сулый тауларда җаның шуңа...

Онытма: елады монда Гаташың,
Агыйделнең кочып изге ак ташын...

* * *

Ир күңеле таш, йомшармаса,
ул «таш»тан су-яшь чыкмас!—
Тик хәмер йомшарта аны —
сәрхүш күңле яшь тотмас...

Әмма хәмер түктергән яшь
нидән тәмсез, болганчык?!
...Таштан агып чыккан чишмә
якты сулы, саф, ачык...

Зурайгач, болгата ямьсез
уймы күңел чишмәсен?—
Сабый чакта хыяллар саф,
пакь шуңамы күз яшең?

Исерек уй, хыялдан үзең
еракта йөрт, йа рабби!
...Юкса, гөлләр касәсеннән
ни эчтек без — шәрабмы?

Коштай, гүя дәва иттек
яшь йөрәккә таң чыгын.
Касә-касә гөл яшен ич
эчтек ул чак — талчыгып...

Балачакка кайттыкмы соң?—
күңел — саф, пакь чишмәле:
Яшьләрендә хәмер түгел,
кыңгырау чәчәк тәме!

* * *

*Әмирхан ага Еникигә*

Бала итте бүген — шаштырды шатлык:
Аксакал белән түбәтәй алмаштык.

— Сез-яшьләргә килешә, ди, укалы.
Ә миңа — бизәксез, гади булганы...

Чын алтын көз Уфада — туй дәвамы:
Сиксән биш яшь — морза әдип бәйрәме!

Гасырлардан мирас акыл — сүзендә;
Татарның язмышы — моң, гаме күзендә.

«Әйтелмәгән васыять»ләрен әйттеме,
Тарих төпкеленә уйны дәштеме,

Илле яшьлек йөрәкне кыстым учка:
Очар кебек, әверелеп хәтер-кошка.

— «Сөт калыр, ватан китәр» шул... Кызганыч!
Исән ләкин рухта өмет-ышаныч...

Инде кыйбла җуймыйча барырсызмы?
Шул «изге сөт, кан»ның сез — варисымы?

...Мин дә хәзер чал чәчле ир бугай да,
Олы гамьнән читтәмен күк шулай да...

Гаҗәпмени — уй ташып, калсам шашып?—
Аксакал белән түбәтәй алмашып...

* * *

Әүвәл пәйда булып илдә вәкиле,
Озакламый аннан ислам да килде.
Моңа мең ел! Күңелләрдә — бер Илаһ!
Язмышыңны синең язган ул инде.

Дин тойгысын алганмын каумем аша,
Ә нигә мәҗүси уйлар бу башта?—
Сине уйлап, багам, юллар салам мин,
Уем — тарих, Болгарларга тоташа.

Эзлим Ибне Фазлан узган юлларны,
Изге байракны ил кабул кылганны...
Яшел төсе күзләреңнең шуннандыр,
Күзаллыйм мин ялкын чәчле син-ярны!

Күрәм: яңа дин өчен, вәкилләргә
Бүләк Кыз син, китәсе — ят илләргә.—
Шул кол ярның мин — гашыйк үз корбаны,
Акыл җуеп, кермәдемме телләргә?!

...Югалтканмын сине мең еллар элек,
Юлга чыксам, бүген каян эзләргә?!

* * *

Ниндидер төпсез коеда калганмы
Яшьлек ядкарең — бәһасез балдагың?
Төштең, эзләп, нинди уй чоңгылына,
Алып чыгыйм сине, кереп анда мин?

Табылырмы җуйган балдагың кабат?
Йөзеңә көләч яз нуры кайтырмы?
Яшерен сереңә — күңелеңә тимичә,
Яратырга телимен син матурны.

Оныттырыйм — дәва булыйм яраңа,
Гашыйк җыры биеккә дәшсен сине.
Әйт, ничегрәк коткарыйм уй-упкыннан,
Кайтарыйм синең шат, гамьсез хисеңне?

Ниндидер тирән коеда калган күк
Әллә күңелең синең, әллә балдагың,—
Табармынмы? Бүген мин ул упкында
Аздан гына үзем торып калмадым:

Яшьлегем яктысын күрдем анда мин!

* * *

Сагынсам оҗмах бакчасын, кәүсәрен,—
Алдым шуннан мин-Адәм җан җәүһәрен.

Уйда — аң, канны уяткан фирдәвес,—
Ничә мең ел!— юатыгыз, тиргәгез,

Һаман җирдән күкләргә ашса күңел,
Дәшә, бәлки, аннан назлы әнкә тел?!

Йә хәтерне тарта изге сөт хакы?
Яратылган туфрагым — ни? Күк заты...

Бу ямьле җир, мең гамьле Җир, моң иле
Тарих башы санап, яд итсә мине,

Җирме — ватан? Җавап тапмыйм мин-Адәм,
Тәнгә туфрак монда... Ә рух — Галәмнән...

Ник онытыйм мин фирдәвес кәүсәрен,—
Калдыргач шунда мәңгелек җәүһәрем!

## «Моңлы бер мөнәҗәт»

* * *

Ахырына җитсә безнең бу хикәят,
Ул — бер гүзәл кыйссадан мисал, шаять?
Тик, мәңгелек түгел ник — Җирдә һични?
Җавап бирерме Мәңгелек — ниһаять?

* * *

Шулкадәр, дим, чаң сук — җаныңны кыйна:
Әллә Сөю — дөнья күләм вакыйга?!
...Шуңа инанганга язам бу җырны,
Һәм ышанганга: калыр, дип, бакыйга!

* * *

Узып бара Дуңгыз атлы бу ел да...
Быел каләм ник сүлпән йөри кулда?
Беттеме көч? Юк, син ардың, дип куркам,—
Хис кәрваны тик фәрман көтә — юлда...

* * *

Сине минем күк яраткан — булырмы?
Күкләргә ашкан, җан аткан — булырмы?

... Кайчан да бер үзең сөйсәң шулай — бел:
Кәгазьгә дә чишмә яшерен уеңны...

* * *

Масрадан чакырган — инде Басрамы?
Борынгы Гыйракмы тарта, башкамы?
...Галәм хәйрандыр күңелеңә: күптән ул
Кыйтгаларга — Җиргә сыймый башлады!

* * *

Моңлыларга читен заман (ни әйтим!),
Моңсызларга, бәлки, таман (ни әйтим?).
Өйдә, урам, илләрдә — Җирдә җәнҗал,
Син дә усалландың тәмам (ни әйтим?!).

* * *

Уйлыйм: җанга ихлас ярмы син, юкмы?—
Гамь «утын» яктың — көчәйттең утны...
Шул хәлемә тик сөенгән Кыз! Сиңа
Үзем бирдем бугай мондый хокукны?

* * *

Эндәшә кем шулай? Әллә соң Тәкъдир?
Бик олылап әйтә:— Әй-йа, кем, тәкъсир!
Һич үкенмә сөеп узган гомереңә:
Ул — Киләчәк бер аклар «җинаять»тер...

* * *

Ымсындырдың, яндырдың — чын сер булдың!
Тоташ бер китап яздырды — күр, кулың!
Гөл-ярларны оныттырдың — яныңа
Биеккә, Күккә чакырдың... Ник кудың?!

* * *

«Аллаһе әкбәр ел ярым!» дип, ахрысы,
Кабатлар җан: анда Бабич яктысы...
Сиңа баглы китапта да чагылсын
«Китабеннас»ның саф алтын-ак төсе...

* * *

Гарәпчәне өйрәнүең ярады:
Урлады җаныңны «Багдад карагы»...
Югалмассың чит илләрдә, тел белгәч,
Мин тынычлык җуйдым, аның каравы...

* * *

Бу — сиңа күңел телендә эндәшем:
Гашыйк җаннар аңлар шивәм-сөйләшем —
Холкыма хас сәердер күп сүзләрем,
Тик әнкәм телендә — моңлы күз яшем!

* * *

Кайчак уйлыйм: яшь кенә гомереңдә син
Күпме моң-гамь күргәнсең — кичергәнсең...
Минем яшьтә нинди булачак җаның?
...Буш касәдән, мөгаен, исермәссең...

* * *

Ут иткән, күр, яфракларны көз тыны,
Алтын диме һаман шигъри сүз шуны?
Ник матурлык, балкыш — үләр алдыннан?
Картлар гыйшкы, дип атыйкмы без моны?

* * *

Илледән соң да сөюем хак, — димме?
Чәчләрдә дә, шөкер, аз бит ак, — димме?
Әллә сөеп, әллә көлеп, янымда
Тукталган яшьлеккә карап, аһ! — димме?!

* * *

Аерылышу! Беләм, авыр буласы...
Әмма — тиеш, шундый тормыш йоласы...
Киткән чакта, алдыңа тезләнеп, Яр,
Озын итеп нинди дога кыласы?!

* * *

Көз чишендергән табигатьтәй халәт.
Күңелсез — калам күк синсез, мәхәббәт!
...Хисе ташып, былтыр көз чәчәк аткан
Алмагач та үлде... Ни бу, әй, Хәят?!

* * *

Иске җәрәхәтең генә канаттың,
Яшьлеккә якынайма, җан, кабат син...
...Тик, Бөек хис — Илһам яры! — үлмәсме
Гүзәллеккә, куркып, читтән карап син?!

* * *

Яр кашында тиңсез яшь, шәп егеткә
Бармы ихтыяҗ — сүз, вәгазь, үгеткә?! —
Калдырганнар ярга ялвару фәнен
Чал гашыйкка, — әйе, безнең кебеккә!

* * *

Телем әйләнми «сөй мине!» диярга:
Тиеш син яшьне, тиңеңне сөяргә. —
Бәхет — аның кулындадыр... Ә миңа
Кала — моңлы бер мөнәҗәт көйләргә!

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



## Рөстәм Вәлиев

# ФИНИНСПЕКТОР ҺӘМ БАБАЙ

хикәя

Танышы белән дә, белеше булмаган кеше белән дә самими елмаеп күрешә ул, йомшак сүзе белән сәламен бирә. Шушы елмаюда, мин сезгә көчемнән килгәнчә ярдәмгә әзер, дигән күңел байлыгы сизелә. Шушы ук риясызлыкта, сез дә мине иш-интәшлектә рәнҗетмәскә тиешсез, дигән каттый кисәтүе дә чагыла.

Ара-тирә очрашулардан Рөстәм Вәлиев (ул Чиләбедә яши) күңелгә әнә шундый булып керде.

Дус-иш жыелып әңгәмә корганда, сүзгә алдан кыбырсып катышмый ул. Моңысы тыйнаклык билгесе дәдер — эш сөючегә һәм дәрәҗәсен белүчегә хас сыйфат та бит әле бу. Әмма каударланмауның тагын бер хикмәте бар, минемчә. Әңгәмәдәшләр ишәеп, әдәби бәхәснең кызуы житкән чакта да һич тә йөзсезләнмичә уртага чыгарга үзенең көче житәчәген белә Рөстәм. Мондый ышанычка тормыш тәжрибәң бай, белемең төпле булганда, кешелеклегең аермачык беленеп торганда гына ирешергә мөмкин. Һәм — боларга өстәп — уйлану, уйлана белү тудыра андый ышанычны. Ә язучы Рөстәм Вәлиев гамәлен уйламыйча кылмый. Үзе һәм ижаты турында менә ничек яза ул:

«...яза башлагач, мин, тормыш чынлыгына хилафлык кылып, әдәбиятка охшаган нәрсәкәйләр тасвирларга тырыштым. Бары тик ярсулы соклану елгасы гына хакыйкатькә илтер, дип уйладым, бистә хорафатларының һәм искелекләренең, андагы минем көнкүрешем каршылыкларының тын култыкларын күрмәдем. Армия хезмәте, Магнитогорск металлургия комбинатында эшләү, Төмән тундрасында йөрүләр, мөгаллимнәрем сабаклары миңа гайрәтле ирләр учының йомшак сөюе, яманнан кисәтүнең һәм игелек теләүнең йомшак тавышы булды. Мин яңа тормышка — әлегәчә үзем начар белгән тормышка ияләнә башладым кебек.

Минем әсәрләрем геройлары, тормышның заманы узган гадәт-рәвешләрен, тәртипләрен кире кагуның фетнәче хисен кичереп, бүтән тормышны үз итәләр. Бу исә «тормыш итү хакында уйланучы егет» өчен файдалы. Әмма кире кагу һәм кабул итү арасындагы бушлык куркыныч. Монда һичнәрсә алыштыра алмаслык югалтулар булуы ихтимал...»

Рөстәм Вәлиев күп санлы повестьлар һәм хикәяләр язды, аның Тукай турындагы романын татар укучысы жылы кабул итте.

Рөстәм эшне зурдан башларга ярата. Сүзне дә. Зурдан башланган эшнең нәтижәсе дә бәләкәй була алмый, әлбәттә. Үзе турында сөйләвен дә ул олы кешедән — бабасыннан башлый.

«Минем бабаем оныкларына йомшак, хәтта иркә мөнәсәбәттә булды. Кайчакта, үзенең хатасын аңлап алгандай, кырыс булырга тырыша иде, шул кырыслыгын аклау өчен, безнең өйдәгеләрне эти кысан йөгәндә тотты, дияр иде...»

**Шушы киң күңелле, игелекле бабай образы тулы сурәтләнгән хикәя укучылар игътибарына тәкъдим ителә. Мин аны Рөстәм Вәлиевнең 1975 елда Новосибирскида чыккан «Тын шәһәр җәе» («Лето тихого города») исемле китабыннан тәрҗемә иттем.**

**Мәгъсум ХУҖИН.**

1

— Шунда ят әле,— диде әби.— Тегүче үлчәвеңне алыр да чалбар тегәр сиңа. Әхмәт абыеңныкы кебек итеп.

Мин ишек төбендәге келәм кисәгенә аякларымны сөрттем һәм идәнгә җәелгән одеял өстендәге җәймәгә горур кереп бастым. Җәймә крахмалланган иде, ак һәм бик тә чиста иде.

Мин сузылып яттым. Әби баш очыма чүгәләде. Аның сулышы миңа тиде, йөзе янымда башлары түшәмгә тияр-тимәс басып торучы тегүченең һәм бабайның чырайларыннан мәрхәмәтлерәк иде. Бабай атлап барган кебек, юлында истә-оста югында миңа тап булган да, оныгымны үземә алыйм әле, башкалар кибеттән сатып алалар, ә мин оныгымны юлдан таптым, дип уйлый сыман. Һәм ул табышын алырга теләгән кебек иелде, соры күлмәкле тегүченең җәенке гәүдәсе исә бабайның күләгәсе булып иярде. Алар аякларымны һәм кулларымны кинәт тотып алдылар да идәнгә чытырдатып кыстылар. Шул чакта гына мин башта ук абайларга тиеш булган нәрсәкәйне күреп алдым — бабайның йөзендә алдашу сизелә, ә тегүченең йөзен гадәти һәм мыскыллы эшлеклелек томалаган икән ләбаса.

Мин алданган һәм кимсетелгән кешеләрчә усал һәм үчле тавыш белән кычкырдым. Әби нәрсәдәндер куркып:

— Менә Әхмәт абыең...— диде.— Исерек...

Һәм ишектән чыннан да Әхмәт абый килеп керде. Һәм минем усаллыктан һәм үчлектән чыдап булмастай авыртуны белдерүгә күчкән тавышым, исерек Әхмәт абыйдан курыккач, басылды. Ә әби, тегүче соңыннан күз ачып йомган арада чамасыз авырткан түшемә якын ук иелгәч, минем битемне итәге белән каплады...

Кулларым яннарыма салынып төште, мин мескен һәм таланган кыяфәттә идем. Басынкы тавышым сулкылдауга, хурлыклы ыңгырашуга әйләнгән иде.

— Менә сиңа бау,— диде әби һәм кулым янына бау куйды.— Тегүче сиңа колын алып киләчәк.

— Әйе, әйе,— дип мине ышандырырга тырышып кабатлады бабай, ә үзе «тегүче»не ишеккә таба туктаусыз, әмма хөрмәтен сиздереп этүен белде.

Сөннәткә утыртканнан соң ике көн үткәч тә, олы бүлмәдә йөренгәндә, иелеп карагач, киң күлмәгемнең тиздән ашкан итәгендә марганцовканың күгәрек таплары күренә иде әле...

Боз киткән чак. Дәү-дәү бозлар рәткә тезелеп агалар да аннары котырынып әүмәкләшергә тотыналар. Тәрәзә янында эч пошып утырам, ямансулаудан теге бауны бөтергәлим.

— Ә-әнә,— дип еракка-еракка, күк белән су бергә кушылган төшкә күрсәтте әби,— әнә шуннан, боз өстенә басып, колын йөзеп киләчәк...

Бабай ат сатып алган. Атын тәрәзә турысындагы рәшәткә баганасына бәйләде дә, өйгә кереп, күр әнә, дигәндәй, миңа ымлады һәм үзе атка текәлеп карап торды. Аның йөзендә шатлык та, кайгы да сизелми иде.

Атны ишегалдына кемдер китергәндәй һәм нинди ният белән китерүе әлегә билгесез кебек карый иде ул.

...Әби миңа соңыннан бабай турында, инде аның вафатыннан соң, күп тапкырлар сөйләде. Һәм бу хикәятләр минем үз хатирәләремне кирәгенчә ачыклый иде. Бабайны кызгануы хикәятләрендә еллар узу һәм мәрхүм турында кайгыру белән күпертелми иде.

Аны, дип сөйләде әби, малай килеш Кечкенә Шәһәргә алып килгәннәр һәм бүрек тегүчегә өйрәнчек итеп биргәннәр. Өч ел чамасыннан ул, картузлар һәм бүрекләр тегәргә остарып җиткәч, үзбашка эш җайлау нияте белән, карт тегүчедән киткән. Ләкин үзе генә берни майтара алмагач, кире кайткан.

Шулай да нэп елларында бабай эшен үзбашка оештырып җибәргән һәм, сөйләүләренә караганда, аны ярыйсы ук алып барган. Тик бу хәл озак дәвам итмәгән. Шуннан соңгы елларда аны туктаусыз әзәрлекләгәннәр — яңа заманга син ят зат, үтә үк куркыныч булмасаң да, хосусый милекчелек карашларың белән зыянлы бәндә син, янәсе.

Мондый кысу-кискенлекләр, билгеле инде, бабайны алҗыткан, әмма ул кызының һәм киявенең каршы төшүеннән ныграк газапланган. Тормыш хәлләре аның холкына көчле йогынты ясаган — әйтик, үз вакытында ул, Кечкенә Шәһәрнең чеп-чи наданнарыннан аермалы буларак, кызын мәктәпкә укырга илткән. Һәм кызын, теләгенә каршы килмичә, комсомол егеткә кияүгә биргән, хәтта киявен үз йортына керткән. Ә бүрекләр тегүен барыбер дәвам иткән, бу хурлыклы эшне туктату турында киявенең үгет-нәсихәтләрен тыңламаган, оялтуларына игътибар итмәгән, тегүчелекнең аларның — яшь укытучыларның — яман атын чыгару ихтималы турындагы үтенечләренә колак салмаган. Шулай да кызы белән кияве аны бүрек тегүен вакытлыча ташлап торырга мәҗбүр иткәннәр. Әмма вакытлыча гына, чөнки эч пошу һәм ваем аның кулына тагын инә-кайчы тоттырган, һәм ул, кызы белән киявенең шелтәләү-әрләүләренә исе дә китмичә, һөнәренә тагын да хирысланыбрак керешкән.

Әни үлгәч, бабай, тегүне ташлыйм, дип, әтигә ант иткән икән. Озак кына вакытка һөнәрен ташлап та торган — әтинең безне алып китеп баруыннан курыккан.

Шушы чакта бабай акылдан шаша язган, өйдә хәлләр бик тә киеренкеләнгән. Бүрекләр теккәндә, аның тормышының мәгънәсе булган, ул йорт хуҗасы өстенә төшкән башка шөгыль-мәшәкатьләрне дә онытмаган. Ә текмәгәндә, һәр нәрсәгә битараф булып, җаны кыелып, өйдә һәм ишегалдында тик йөри биргән.

...Әтинең, эштән кайткач мине елап шешенгән, марганцовкага һәм канга баткан хәлдә күреп, яман да ачуы купты. Ул, шул ук мәлдә бабай йортын бөтенләйгә ташлап китәргә ниятләп, әйберләрне җыештыра башлады. Кайбер нәрсәләрне төйнәгәч, минем янга килеп утырды. Бабай ишек янына барып басты. Тонык тавыш белән:

— Мин бүрекләр тегүне ташлыйм...— диде ул.— Ант итеп әйтәм...

— Монысын эшләмичә,— әти миңа таба ишарәләде,— бүрекләренне тексәң, яхшырак булган булыр иде...

Ул үтә талчыккан кыяфәттә иде.

Башыма, кайчан китәрбез икән, дигән тынгысыз уй керде. Әмма әти селкенмичә дә утыра бирде, аның ачуы беткән бугай, шулай да кырыс карарга килүе йөзендә сизелмәде, кызганыч та, көлке дә кебек иде аның йөзе.

— Мин ант итеп әйтәм,— дип кабатлады бабай.

Ул алпан-тилпән дә килгән кебек, ләкин бу әлләни сизелми, гәүдәсе ишек яңагына табарак авышып тора, бераздан, ниһаять, ишек яңагына бөтен гәүдәсе белән сөялде.

— Бабай бүрек текмәячәк,— дип куркып кына әйтеп куйдым мин.

Әти миңа җавап бирмәде. Ул бабайның антын кабул кылырга ашыкмый һәм аның бу йорттан бик китәсе дә килми иде бугай.

Ә бабай куркып калган иде. Кызы һәм оныклары туган йортта оныкларының балалары да туарга тиеш дип уйлый идедер ул. Хезмәте һәм осталыгы өчен бүләк кебек булган бу йорт, кияве һәм оныклары ташлап китсә, бөтен җылылыгын-мәгънәсен югалтачак булып тоелгандыр аңа. Һәм ул кулына инәне бүтән тотмаска әтигә ант итте...

Аның ат тотуга беркайчан да исе китмәгән, диләр. Менә ул, үзенең бәйсезлеген күрсәтү өчен, ат сатып алды. Әйе, ул җиңелде, әмма бөтенләй үк бирешә алмый иде ул.

...Бабай миңа:

— Күр әле син аны,— диде, үзе тәрәзә турысында коймага бәйләнгән атка карый, бу җан иясе башка кешенекедер, дигән кебегрәк гаҗәпсенеп карый.

Ә мин атның безнеке икәнен беләм һәм бабайга:

— Җик әле син аны,— дидем.

Ул нык, әмма җиңел гәүдәсе белән борылды да өйдән чыкты. Мине җылы итеп киендерделәр, җитәкләп алып чыктылар да чанага утырттылар. Капка ачык иде инде.

Кая барабыз без? Мин, ат яратудан рәхәт каушап калган биш яшьлек малай, кая барырга мөмкин ди? Тормыш мәгънәсе белән тулган нинди сәфәргә чыга алыйм икән мин? Хәер, миңа каядыр барырга, ерак-еракзагы аклыкка илтүче ак юлның сәфәргә чакырып торуын аңлап, каядыр барырга гына кирәк иде, юл йөрү рәхәтен тоярга һәм сәфәрнең максатын һәм мәгънәсен хыялымда гына тудырырга кирәк иде. Миңа әле хәзер дә далага бабай белән максатсыз сәфәрләребездә без охшаш булганбыз кебек тоела. Хыялларыбыз да охшаш булгандыр — ул да, мин дә тормышка ашмастай хикмәтне бер төсле итеп күргәнбездер. Тик аерма шунда гынадыр — минем хыялым мине шатландырса, бабайның хыялы аны хәсрәткә чумдыргандыр.

Ул миннән башка — ялгызы гына да чыгып китә иде. Беркөнне иртән уянгач, аның өйдә юклыгын күреп, мин:

— Ә бабай кая китте? — дип сорадым.

— Ярминкәгә,— диде әби.

Мин аның тавышындагы мыскыллау һәм кызгану төсмерен тоя алмадым. Ярминкә дигәне миңа яшелгә һәм зәңгәргә буялган, җиле кылганны туктаусыз тибрәлдерүче гап-гади дала булып күренде.

Ул бүләкләр алып кайта иде. Зур гына күн сумкадан өстәлгә ипи, бер кап чәй, шакмаклы шикәр чыгарып сала да аларны әбигә таба этәрә, миңа прәннекләр, чыбыкка ябышып кунган әтәч бирә иде. Мин тәмтомлы булуымнан гына түгел, ә ниндидер мәҗбүри бер йола үтәлүенә катнашым булуына да куана идем. Соң, күчтәнәч алып кайту йоласы минсез бөтен булмас иде бит!

Мин бер хикмәтне соңыннан гына аңладым... Бабай, ат сатып алгач, башта аның белән нишләргә икәнен белмәгән, ә аннары әмәлен тапкан. Уен уйнаган икән ул — янәсе эш эшли дә ярминкәдән бүләкләр алып кайта...

## 2

Хәзер мин Әхмәт абыйныкы кебек озын чалбар кия башладым. Ләкин Әхмәт абыйның чалбары киң түгел, ә галифе иде.

Бераздан соң Әхмәт абыйны атлы гаскәриләр белән фронтка җибәрделәр, тиздән әти дә китте, һәм бабай атны сатты.

Бабай аны соңгы тапкыр ашыкмыйча гына, иркәләп җикте — шушы соңгы җигүе рәхәтен озаккарак сузарга теләде кебек ул. (Ә читтәрәк, сакалын һавага чөеп, чегән басып тора иде. Аның сакалы мине мыскыллый сыман — әйтерсең, ул безнең атны үбәргә җыенган да бахбаебызны кара каты сакалы белән кытыклаячак иде.) Ат миңа ягымлы итеп карады...

Аннары мин жигүле ат артыннан, йомшак тузанны туздырып, ераккача йөгереп бардым. Урамдагы кешеләрнең: «Карагыз әле, Бүрекче оныгы!» һәм: «Бабасы атын сатты микәнни?» кебек сүзләрен йөгерүем уңаенда колакларым җыя барды. Шәһәр читендә мин артка калдым. Юлдан таш алдым да аны, атка тидерүдән бик тә куркып, чегәнгә тидерергә тырышып аттым.

Өйне атсыз калу кайгысы басып алгандыр, караңгы тынлыктыр анда, дип борчылып кайттым. Алай ук түгел икән. Бабай идәндә җәелеп утыра, каршысына калыплар, чүкечләр, тукмаклар тезгән, шулар арасында төрле зурлыктагы инәләр кадаган күпчек тә бар.

— Бүрекләр текмәкче буласың мәллә? — дип сорады әби.

Бабай аңа ачу белән, хәтта нәфрәтләнгәндәй карады.

— Кияүнең киткәндә нәрсә дигәнен ишеттеңме син, кортка?! Малайларны карый күрегез, диде ул. Шулай дидеме?

Шушы хәлдән соң, бабай горур, мәһабәт кыяфәттә йөри башлады.

Әнә ул ике тәгәрмәче дә алпан-тилпән килеп, мәсхәрәләп шыгырдаучы җинел арба яныннан исе дә китмичә атлый. «Мыеклар» чыгарган бау-дилбегәне тәбәнәк сыерның — Маньканың арт саны өстендә еш селти. Элек, сугыш башланганчы, Маньканы ике тәгәрмәчле җинел арбага җиккәннәр, һәм ул әйбәт йөргән икән.

Бабай бау-дилбегәсен селти, ә каршыга очраган кешеләр көлә. Кәрлә сыерның мөгезләре өскә караткан өтерләр кебек тоеладыр, мөгаен. Ә бабай сыер янәшәсеннән һичнәрсәгә исе китмичә атлавын белә, көлкe һәм төртке сүзләр аның горурлыгын чеметә алмыйча сүрәнәяләр.

Ул, бәлки, мыскыллы көлүләрне ишетмәгәндер һәм ачык авызларның үзләрен дә күрмәгәндер. Уйлары аның өйдә, кадерле бүлмәдә — элек энем белән минем йокы бүлмәсендә, хәзер үзенең кярханәсендә булгандыр. Сарык тиресенең әче исенә һәм куе тәмәке төтененә тулган шушы һөнәрханәсендә керосин лампасының сыек яктысында йончыткыч һәм басылып утыруны таләп иткән хезмәтеннән рәхәтлек таба ул.

Менә бабай постауны алдына җәя, аны йомшак кына кага-сыпыра — бу минутларда ул мине яки энемне сөя кебек. Ләкин сөюе мин йокылы-йокысыз яисә сырхап киткән чактагы кебек түгел. Постауга катырак сугарга да, аны ныграк сыпырырга да ярый бит.

Һәм бабай постау өстенә сыдырылудан очланган, матур уенчыкка охшаган акбурын кулына ала. Гәүдәсен арткарак ташлый да постауга ниндидер билгеләр сала. Кара постауга туры-төгәл сызыклар төшкәч, зур авыр кайчысын тотып, постауны кисә башлый. Бүлмәдә тынлык, бары тик кайчының постауны салмак кисү тавышы әкрен генә ишетелгәләп куя. Бабай постауны түбән үк бөкерәеп, тигез-тын челтерәгәндәй тавышка колагы белән ешынып ук кисә... Аннары ул машинасы янына утыра да кискән постауларын тегә. Машина чер-чер итә, ә бабай шул череллдәү астына постауны аз-азлап шудыра, аягы белән, гармунга ияреп һаман саен кызыбрак биегән кебек итеп, педальгә баса.

Машина тынып кала. Ә бабайның аягы, ул аны инде педальдән алса да, акрын-салмак биегәндәгечә селкенәләр. Аның йөзе, куллары һәм күзләре инде эштән читләшкән сыман. Әмма бу читләшү-аерылышу бөтенләйгә түгел. Бабайның яраткан эшенә тиздән тагын утырачагы сизелеп-күренеп тора. Әби аңа ризык алып килә, аны бабай янындагы артсыз урындыкка куя, бабай ашыкмыйча гына ашый, ризыгын сеңдереп бара кебек, ләкин ул күп ашамый — бер тәлинкә шулпа да бер касә балсыз каты чәй, акрын ашаса да, әбәтен тиз бетерә... Аннары бабай кулына инә ала. Ул эшкә ургылып торган өлгер инәне кулыннан ычкындырып җибәрә дә нәкъ кирәк төшеннән тотып өлгерә. Инәнең ялтыравы шундыен да җәһәт һәм җете — аның туктаусыз җемелдәве һаман саен тизрәк нәфисләнә бара. Шуңа күрәдер сарай ярыгыннан кергән кояш нурыдай эреп югалыр кебек ул. Инәгә карап торганда, тавыш ишетмисең. Ә башыңны читкә боруга ук инәнең постауга һәм тирегә тиеп кыштырдавын ап-аермачык ишетәсең.

Иртән ул кипкән бүрекләрне, мичтән алып, калыптан салдыра. Бу чакта бабай бик тә тыныч, ләкин кичәгечә ашыкмый һәм дәрте ташып тормый. Дөрес, ул кичә, ашыгып, кайдадыр кимчелек җибәргән булуы ихтималын белә, шуңа күрә үзенең хатасын үтә дә җентекләп эзли. Инәләр кебек очлы һәм еш төшле тимер тарак белән акрын гына тарый, аннары чәчтарашныкы кебек җиңел ялтыравык кайчы белән йоннарны тигезләп кырка. Шуннан соң бүрекләрне ян сәкегә куя да аларга оныкларына карагандай итеп текәлеп тора. Аның карашы ягымлы да, горур да, шелтәле дә, пошынулы да сыман.

Мин энем белән, әбинең тыюына колак салмыйча (ул безнең элекке бүлмәдәге агулы исләрдән бетерешүебездән курка иде, ә, бәлки, ул безнең, бабай һөнәре белән артык мавыгып, Ходай күрсәтмәсен — үзебезнең дә бүрекчеләр булып китүебездән курыккандыр), кичләрен бабай янында утыра идек. Әби бу чакта зур мичкә яга, анда бабай калыпларга кидерткән бүрекләр әйбәтләп кибәргә тиеш. Бу электәге бер бәйрәмгә — утыннар күмергә әйләнгәч, әбинең зур табада көлчә пешерүенә тартым иде. Хәер, хәзер көлчә исе килми килүен, әмма бабай белән әби өчен шундый бәйрәм мәгънәсе саклангандыр, күрәсең — алар үз эшләре белән шундыен да мавыкканнар, дөньяда алар өчен бүтән бернәрсә дә юк кебек иде.

Мич гөрләп яна, бабай, тукмак белән суккалап-каккалап, калыпларга бүрекләрен кидертә.

— Йәле! — дип кычкырыбрак әйтеп куя ул, тавышыннан күңеле хушлыгы бөркелеп тора. — Йә, ничек?!

Энем белән мине үз яныннан кумый иде бабай, безнең аның тирәсендә утыруыбыз ошый да иде аңа. Без бабайга комачаулаганбыздыр да, әмма ул безгә беркайчан да, тегесен алмагыз, монысына кагылмагыз, димәде. Ул оныкларына үзенеке кебек язмыш туры килмәвен тели иде.

— Менә минем инженерларым үсә! — дип кабатлаштыра иде ул.

Шулай да безнең аның һөнәре белән кызыксынуыбыз бабайның күңеленә ята иде.

— Бүрекче малае, диген, ә! — дип яңгыратып әйткәли иде ул.

Мине, дөрестән дә, бүрекче малае, дип йөртәләр иде. Югыйсә, минем әтием мәктәп директоры, әнием укытучы лабаса. Ләкин миңа, директор малае, яки, укытучы малае, димәделәр, бүрекче малае булдым мин. (Хәер, безнең күршебез — әти белән бильярд уйнавына горурланучы Әхмәт абый, директор малае, дия иде. Бабай үзен, останы түгел, ә директорны өстен куюга хәтере калуын белгертмәскә тырыша иде.) Хәтта бервакыт мәктәпкә баргач, ишек төбендә керергә кыймыйча торганда, өлкәнрәк сыйныфтагы бер укучы:

— Бүрекче малае бит бу! — дип кычкырды һәм әтине чакырырга йөгерде.

...Менә шулай — бабай тагын бүрекләр тегә башлады. Тик бу эш аңа хәзер кадерле һөнәре бердәнбер белән шөгыльләнү генә түгел, ул инде акча эшли иде — бурычын үти иде бабай. Әти аңардан: «Малайларны сакла», — дип үтенде, ә ул әтигә вәгъдә бирде бит. Һәм аны бернинди көч тә һөнәрен ташларга мәҗбүр итә алмас иде, чөнки бабайның үз һөнәре белән шөгыльләнүе сугыштагылар алдында олы бурычын үтәүдә бердәнбер мөмкинлеге булгандыр.

## 3

Сугыштан Әхмәт абый кайтты, сул кулы юк, йөзе ябык, картайган. Чүпрәк-чапраклар белән тулы тартмалар төялгән арбада йөри башлады ул. Кер кыстыргычлар, тараклар, кармаклар, сыбызгылар, гомумән, бала-чаганы һәм хатын-кызны кызыктыра торган бүтән әйберләр дә була аның арбасында.

Әхмәт абый иске-москы җыючы булып эшләргә күнекмәгән, дип уйламыйм мин. Арбага утырып: «Чүпрәкләр, сөякләр җыям!» — дип кычкырып, урам буйлап йөрергә һәркем булдыра ала. Ләкин Әхмәт абый алай да эшләми иде. Ике-өч йортны узгач, атын туктата да, тын гына утыра бирә, ә карашы өметсез. Хатын-кызлар балаларга чүпрәк-чапракны бәйләп-төйнәп бирәләр, шуңа алмашка Әхмәт абыйдан кармак-сыбызгы гына түгел, ә тараклар да алырга кушалар иде. Соңрак Әхмәт абый дилбегәне тотмый ук башлады, ат үзе кирәк төштә туктарга гадәтләнде.

Беркөнне Әхмәт абыйның аты безнең капка төбендә туктады. Малайлар һәм кызлар, сөяк-чүпрәкләр күтәреп, йөгерешеп килергә нигәдер ашыкмадылар. Салкын җил кистереп исә иде. Әхмәт абый бөрешеп утыра. Бабай аның янына чыкты.

— Әхмәт, мин сиңа бүрек тегеп бирермен,— диде ул.

Әхмәт абый көлемсерәде һәм:

— Әле сугышка чаклы тегеп биргән бүрегең дә өр-яңа диярлек,— дип җавап кайтарды.

— Син ялгышасың, Әхмәт, сугышка чаклы мин сиңа бүрек текмәдем.

— Ничек инде — текмәдең? — дип каршы төште Әхмәт абый.— Өйдә сандыкта тәмәке сипкән өр-яңа диярлек бүрегем бар бит минем.

— Син ялгышасың, Әхмәт,— дип кабатлады бабай.— Сугышка чаклы мин сиңа да, башка берәүгә дә бүрек текмәдем, чөнки киявем моңа каршы иде. (Бәлки, ул сугышка чаклы бүрекләр текмәвенә үзе дә чынлап торып ышангандыр?) Ә хәзер тегәм, чөнки кияү, фронтка киткәндә, оныкларым турында кайгыртырга кушты. Аңладыңмы инде хәзер, Әхмәт?

— Ярар, текмәгәнсең икән — текмәгәнсең,— дип битараф кына җавап кайтарды Әхмәт абый.— Бүрекнең шулай да кирәге юк миңа. Акча туплыйм да киез итекләр сатып алам әле. Сазлыкта ятып салкын тидергән аякларымны җылыда тоту хәерлерәк.

Бабай беркайчан да берәүгә дә бүрек алырга тәкъдим итми иде. Хәтта базарда болай эшләмәде. Югыйсә анда: «Бүрек сатам! Бүрек алыгыз!» — дип кычкырып, кешеләрнең игътибарын тиз җәлеп итеп була бит. Ә менә Әхмәт абый белән капка төбендәге сөйләшүдән соң, бабай итек басучы Семенга бүрек алырга тәкъдим итте.

— Мин сиңа, Семен, бүрекне шундый да итеп тегәрмен,— диде бабай,— син аның башыңда барлыгын да сизмәссең!

— Юк ла, миңа кыргыз бүреге кирәкми.

— Мин сиңа, Семен, колакчын бүрек тәкъдим итмим бит, малахай түгел, дим. Мин сиңа атап теккән бүрек җыйнак булыр, кышын башыңны җылыда тотар, җәен кояштан каплар.

— Миңа җыйнак-пөхтә, җөен җөйгә китереп теккән бүрек кенә кирәк. Каракүл бүрек.

Бабай уйга калды. Аннары:

— Каракүлдән тегәрмен,— диде.

— Миңа күн тышлы бүрек кирәк,— дип таләбен тәфсилләде Семен.— Син постау тышлы бүрек тегәсең, миңа андые кирәкми.

Бабай тагын уйга төште, бу юлы инде озак ук уйланды. Аннары:

— Күн тышлысын тегәрмен,— диде.— Тик син, Семен, постау тышлы бүрекне зерә яманлыйсың. Хикмәт бит бүрекнең җылы һәм башта җайлы утыруында, ул кимендә өч кышка җитсен. Бер пар әйбәт киез итеккә мин сиңа бер әйбәт бүрек тегәрмен, Семен,— дип үтенгәндәй әйтте бабай.

— Киез итек бүректән кыйммәтрәк хәзер.

— Шулай да булсын. Ә мин сиңа, Семен, каракүлдән күн тышлы бүрек тегәрмен.

Семенның сүзләре бабайның хәтерен калдырды. Аның болай да бүрекләрне, каракүлдән күн тышлы итеп текмичә, сарык тиресеннән постау тышлы һәм колакчынлы гына итеп тегүе кәефен китәргәли иде. Хәзер каракүл һәм күн юнәтүе авыр, алар шәһәргә кыек юллардан гына

китерелә. Ә бабай безне дә, үзен дә куркыныч астына куярга — төгәлрәк әйткәндә, безне иркен тормышта үстерергә әтигә биргән вәгъдәсен үтәү мөмкинлегенә аркылы киртә салынуын теләми иде.

Беркөнне ул миңа базарда бүрек тоттырды. Мин шуны күтәреп йөрергә һәм, әлбәттә инде, алучы булса, сатып җибәрергә тиеш идем. Бабай үзе, гадәттә, базарның тәбәнәк коймасы буендагы япма астында утыра, бүрекләр салынган чемоданын сирәк ачып куя иде. Усал телле кешеләр, бүрекче саран да соң инде, товарын маклер-арадашчыларга бирми, ә кечкенә оныгын сәүдә итәргә изяләндерә, дип төрттереп сөйләнгәләделәр дә ул көнне. Моның болай түгеллеген мин сезгә ихластан ышандырып әйтәм. Бабай, хәзер аңлавымча, минем күзләремдә өлгереп җитүче сәләт чаткысы күргәндер — сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр шәһәрчегендә үсәм ләбаса мин! Хәер, шәһәрчек бу сыйфатын җуя бара, ләкин базар көендә, ыгы-зыгысында бабайның тәвәккәллекнең, чаялыкның җәлеп итүчән, йогучан хыялый рухы, җай килеп бәхет елмаячагын сиземләү саклана иде әле. Димәк, бабай минем дулкынлануымны сизеп алгандыр, дип уйлыйм мин хәзер. Үз һөнәре малай кешене кызыктыру, мавыктыру ихтималы аның күңеленә яткандыр. Әмма, кабатлап әйтәм, ул минем киләчәгемнең үз язмышына охшавын теләми иде.

Мин базарның чуар кысынкылыгына куанып һәм горурланып барып кердем. Бүрекне фокусчыдай оста гына югары чөйдем дә:

— Кемгә бүрек кирәк! Менә ул — иң шәп бүрек! — дип кычкырдым.

Бүрекнең бераүне дә кызыктырмавы минем хәтеремне һич тә кырмады. Якшәмбе базарының шау-шулы ешкынлыгына керергә миңа беркем дә комачауламый, тирә-юнен җентекләп күзәтеп, эчпошыргыч кызыксыз сәүдәсе белән күңелемә тиюче юк — шулары куаныч.

Рәхәтләнеп, онытылып йөрим базарда! Әмма мине кинәт озын буйлы, чандыр гәүдәле бер абый кычкырып туктатты, башта йомшак кына, аннары кысып ук кулымнан тотты.

— Бүрек алыгыз! — дип кабаланып әйттем мин.

Ул мине үзе күреп туктатканчы, аны күрмәвем һәм бүрек тәкъдим итмәвем өчен уңайсызланып куйдым.

Абый кеше миңа озак кына текәлеп карап торды, аннары шулай ук уңайсызланган кебек кенә итеп:

— Башымда бүрек булмагач та, син минем бүрегем юктыр дисеңме әллә? — диде.

— Әйе ди инде! Кем инде җәй көне бүрек кисен! — дип гаҗәпләндем мин. — Ә бүрекне хәзердән сатып алырга кирәк, чөнки кыш көне туры китермәвегез бар.

Ул тагын миңа озак кына текәлеп карап торды, аннары бер сүз дә әйтмичә һәм артына борылып та карамыйча китеп барды.

Мин килгәндә, бабай бүрекләрен фанер чемоданына тутыра иде. Ашыга иде ул, хәвефләнүе сизелә иде аның.

— Фининспектор сиңа нәрсә әйтте? — дип сорады ул.

«Фининспектор» сүзен беренче ишетүем һәм фининспекторның үзен беренче күрүем шушы булды. Ләкин соңыннан бабайның озакка сузылган сәер мөнәсәбәтләре фининспекторның монысы белән түгел иде.

## 4

Фининспекторның икенчесен мин беренче тапкыр базарда түгел, өебездә күрдем (бабай да тегесен соңыннан базарда очратмавын әйтте).

Мин энем белән тоткан ташбашларны кызу плитә өстенә тезә идем. Без аларны башта җепкә асып кояшта, аннары плитәдә киптерә идек. Кипкән балыкны бик тә ашыйсы килгән чак иде минем. Һәм менә плитәгә ташбашлар тезгәндә, ишектән ул килеп керде.

— Исәнмесез,— дидем дә аңа текәлеп катып калдым мин.

Ул ялтыравык төймәле китель кигән, ә башында биек фуражка иде.

Ул бабайны фамилиясен әйтеп сорады. Мин өйдә үзем генә булуымны әйттем.

— Ни кылуың әле синең? — дип кызыксынды ул.— Әһә, мичне шуның өчен яктыгызмыни?

— Әйе. Балык киптерү өчен, җылы булсын өчен, аннары...

Ул кычкырып көлеп җибәрде, хәтта күзләреннән яшь атылып чыкты. Кесәсеннән кулъяулыгын алды, һәм миңа ислемай исе китереп бәрде.

— Тышта чүлдәгедәй эссе,— дип көлә бирде ул.— Ә ташбашларны плитәдә киптермиләр.

— Әйе, ие...— дип мәми авызландым мин. (Мичне бүрекләр киптерү өчен яккан идек без.)

— Ә бабаң кайда?

— Әйе, ие... Су коенырга китте бугай бабай...

— Су коеныргa? — дип күңеле булып сорады ул.

Күнитекләрен шыгырдатып, түргәрәк узды һәм терәксез урындыкка, аны өстәл янына күчермичә генә, утырды, янында әйләнеп йөреп, үзенә сокланып карарга җайлы булсын өчен шулай эшләде кебек. Ашыкмый иде бугай ул.

Бабай кергәч, ул атылып диярлек урыныннан торды, үкчәләрен бер-берсенә бәреп куйды, усал-кырыс кыяфәттә бабайга текәлеп катты.

— Исәнмесез,— дип горур гына сәламләде бабай.— Рәхим итегез,— дип кунаклар өчен дигән зур бүлмә ишегенә күрсәтте.

— Монда да ярый,— дип сабыр гына җавап кайтарды ул.— Мин эш белән. Шәһәр финанс бүлеге хезмәткәре мин.

Бабай иңбашын сикертеп куйды, тәкәббер кыяфәттә сүзсез калды — үзеннән яшьрәк кешенең, өйгә кергәч, мондагы тәртипләрне санга сукмавын ошатмады, һәм шуңа күрә бу чакырылмаган кунакны илтифатсыз гына тыңларга җыена иде. Бабай хәтта мине дә куып чыгармады. Бераздан әби белән энем керде, бабай аларга да чыгып торырга боермады. Ә фининспектор безнең монда булуыбызны хуплый кебек иде. Ул бабайга таба борылды һәм, нечкә тавышын чатнатып:

— Сез тыелган кәсеп белән егерме сигезенче елдан бирле шөгыльләнәсез,— диде.— Сезнең хәтта патент алырга да хакыгыз юк. Әгәр моннан ары бер генә тапкыр законны бозсагыз да, эшнең шунда ук тикшерү органнарына биреләчәге турында мин сезне кисәтеп куям. Аңлашылдымы?

— Аңлашылды,— дип җавап кайтарды бабай.

Һәм фининспектор күнитекләрен шыгырдата-шыгырдата чыгып китте...

Бабай ишекле-түрле йөренергә тотынды, аның чүәкләре, идәнгә йомшак кына тиеп, кайгылы тавыш чыгарып кыштырдый иде. Ә фининспектор күнитекләренең шыгырдавы башта өйалдыннан, аннары ишегалдыннан, аннары урамдагы такта юлдан ап-аермачык ишетелеп торды.

— Ул миннән, нигә мичкә яктыгыз, дип сорады,— дидем мин.

Бабай миңа борылып та карамады. Минем аңа кечтек кенә булса да ярдәм итәсем килә иде һәм мин:

— Мичне балык киптерү һәм җылы булсын өчен яктык, дидем,— дип өстәдем.

Бабай чүәкләрен акрын кыштырдатып йөргән белде. Бераздан бу хәсрәтле кыштырдау кискенләшеп җәһәтләнде. Бабай чүәкләрен салды да, катгый карарга килгәндәй, читекләрен киде.

— Карале! — дип кычкырыбрак әйтте ул әбигә.— Мич суынганчы...

Һәм, сүзен бетермичә, күрше бүлмәдән калыптагы бүрекләрне алып чыкты, аларны мич эченә тезде. Аның йөзе кайгылы һәм кырыс иде, үзен йолып калачак, аклаячак гамәл кыла кебек иде ул.

Бабайны алдагы якшәмбедә үк базарда эләктерделәр. Әби, бу турыда ишетүгә үк, яңа киемнәрен киде һәм, әтинең дипломын алып, милициягә китте. Аңа дипломны күрсәтергә кирәк булмаган бугай, әтине шәһәрдә яхшы хәтерлиләр, ә тикшерүче, бәлки, әтинең укучысы ук булгандыр. Өстәвенә сарык тиресеннән теккән постау тышлы бүрекләр милицияне артык кызыксындырмаган. Соңыннан тикшерүче бабайдан:

— Йә, бабай, бүрекләрне тагын тегәрсеңме? — дип сораган. Бабай җавап кайтармаган. Шуннан соң тикшерүче: — Текмәячәксең икән — ярар соң... — дигән дә бабайны кайтарып җибәргән.

Бабай моннан соң да бүрекләр текте тегүен, әмма милиция аңа әлегә кагылмады.

Ә берничә көннән соң, фининспектор безгә тагын килде.

— Күптән сездә булганым юк, — дип үз иткәндәй әйтте ул. — Комачау ясамадыммы?

Бабай бу сорауга җавап бирмәде һәм кунакны, тыйнак кына итеп, зур бүлмәгә чакырды. Фининспектор карышмады, хәтта ишек төбендә күнитекләрен салмакчы да иде, бабай аны тыйды, һәм алар зур бүлмәгә керделәр.

— Чәй, — диде бабай, һәм әби җәһәтләнеп самавырга ут салды.

Мин фининспекторга дүрт күз белән дигәндәй карадым, һәм мине бер капма-каршылык уйга салып интектерде. Бөтенләе белән диярлек хәрби киемле, кителе тәненә сыланып һәм күнитекләре балкып торган бу ыспай абый игътибарны үзенә туктаусыз җәлеп итә иде. Шул ук вакытта минем аны, килеп керү белән үк безнең өйдә курку һәм тәшвиш тудыруы өчен, җенем сөймәскә тиеш иде.

Ул җитез-оста хәрәкәтчән, шулай да бу кыяфәте аңа беренче килүендәгедән авыррак бирелә иде. Әнә ул, кунаклар өчен түрдәге урынга узганда, өстәл-урындыкларга бәрелә, келәм ябылган сандыкка ләх итеп утыра, сандык хәтта сыкрап шыгырдый; әнә ул чәйле касәгә ике кулы белән тотына, ә касә аның кулларыннан шуып чыга яза. Ул элеккеге пөхтәлек-төгәллекне теләми, аның гадирәк, мөлаемрак буласы килә кебек.

— Без танышмадык та бит әле, — дип каушап елмайды ул. — Мин Анатолий исемле. Ә мин сезгә, Бабай, диярмен. Каршы килмәссез бит?

— Алай да мөмкин. Теләгәнегезчә булсын, — диде бабай.

Алар чәйне озаклап эчтеләр. Анатолий, йөзен җыергаласа да, бабайдан калышмады, куе-каты чәй эчәргә ияләнмәгән иде бугай ул.

— Мин сезнең киявегез турында мактау сүзләрен күп ишеттем. Ул мәктәп директоры булган, име? Аны, баксаң, бөтен шәһәр белә икән. — Анатолий тынып торды. — Сезне дә шәһәрдә әйбәт беләләр.

— Кечкенә шәһәрдә һәркем күз алдында, шуңа күрә беләләр, — дип тыйнак кына җавап кайтарды бабай.

— Сез дә күпләрне беләсез булыр... Сугышка чаклы фининспектор булган Николаевны хәтерлисезме?

Бабай иңбашын чак кына сикертеп куйды.

— Менә аның хкмәтләрен сөйләп тә күрсәтәләр соң! Бистә урамнарын урап йөри икән бу. Саф һава сулый янәсе. Тәрәзәләрдәге бер үк төрле бизәкләргә күзе төшә моның. Әһә, димәк, бистәдә кемдер пәрдәләр белән кәсеп итә!..

— Хәйләкәр бәндә иде, — диде бабай. — Син, әйдә, чәеңне эч әле.

Ләкин Анатолий чәй турында уйламый да иде инде, ул:

— Николаев гадел һәм намуслы кеше иде, — дип бик бирелеп дәвам итте. — Кешеләрне хаксызга кыерсытмады. Әйтик, һөнәрчегә бүрек тегеп сату хокукы бирелмәгән. Әгәр бу эш иптәшлек нигезендә башкарылса, ягъни, бүрек заказчы материалыннан тегелсә, монысын закон тыймый... Ә менә шәл бәйләү иптәшләрчә очракта да тыела.

Бабай әңгәмәнең ничек баруына игътибарсыз иде, әмма ул кинәт кенә:

— Нигә? — дип сорады.

— Ярамый,— дип кызганулы сыманрак җавап кайтарды Анатолий.
— Нигә? — дип кабатлап сорады бабай.
Анатолий тагын:
— Ярамый,— дип җавап кайтарды һәм тирән итеп сулады.— Закон шундый. Ә сез шәһәрдә күпме атсатар булганын хәтерлисезме? — дип җанланып китте ул.— Кем әйтмешли, хет буа буарга мөмкин иде үзләре белән.
— Әйе,— дип сүлпән тавыш бирде бабай.— Соңыннан аларны әртильгә җыйдылар.
— Артеле нинди әле! Ул ит комбинатын, сабын заводын, әзерләүләр конторасын йөк атлары белән тәэмин итте. Шуны исегездә тотыгыз, атсатарлар закон нигезендә хезмәт хакы алдылар. Ә артельне төзүне кем башлап җибәрде? Николаев!
— Әртил хәзер юк инде,— диде бабай.
— Ә «Бәйләнеш» итек басу фабрикасы? Итек басучы һөнәрчеләр моннан егерме ел элек, Николаев ярдәмендә, «Бәйләнеш» артеле булып оештылар. Кайчан да булса фабрикага аны нигезләүче фининспектор Николаев исеме биреләчәк — күрерсез дә торырсыз менә!
Бабай кинәт кенә:
— Син яшь әле,— диде.
— Яшь, дип, дүртенче дистәгә авышты инде,— дип кызарынды Анатолий.— Тәҗрибәне тиз генә туплап булмый, анысы бар...— Ул тагын да кызара төште. Әгәр шулай каушамаса:— Ә сез, Бабай, бүрек тегүегезне ташларга җыенмыйсызмы? — дигән кótелмәгән соравын һичшиксез бирмәс иде, һәм Анатолий шушы соравыннан соң тагын да ныграк каушап калды.
Бабай аңа мыскыллап карады, җавап кайтарып тормады.

## 5

Бабай шәһәрдә озак яшәсә дә, кешеләрнең аңа мөнәсәбәте нинди булуын мин тәгаен генә әйтә алмыйм. Шулай да мине «бүрекче малае» дип атап йөрткәндә, аңа көлеп яки түбәнсетеп карауларын сизмәдем. Әмма хикәядә тасвирланган вакыйгалар вакытында Елга аръягында яшәүчеләр бабайга начаррак мөнәсәбәттә була башладылар. Мондый хәлне яшелчә бакчасы китереп чыгарды. Хикмәт менә нәрсәдә иде — елга буенда куе куаклык каплаган каты җир бар иде, безнең урам кешеләре, шуны бергәләп төпләп, яшелчә бакчалары ясамакчы булдылар. Безгә дә бу эштә катнашырга әйттеләр, тик бабай каршы төште. Безнең гаиләдән бакча карарлык кем бар соң әле? Бабаймы? Әгәр ул бакчачылык белән шөгыльләнсә, бүрек тегә алмас иде, димәк, безгә ризык юнәтү җае бетәр иде. Ә әбигә безне карау да чиктән ашкан. Боларны күршеләр дә аңлый иде аңлавын, бәлки, шуңа күрәдер, алар бабайны сүз белән гаепләмәделәр, аңа бүтән гамәл дә кылмадылар. Шулай да төрле сүзләр йөргәндер, күрәсең, малайлар энем белән миннән:
— Алар яшелчәне базардан сатып алачаклар! — дип көләләр иде.
— Сатып алса — ни булган? — дип чәпчи идем мин.— Бабай яшелчәне базардан хәзер дә сатып ала. Моның ни начарлыгы бар?
— Ха-ха! Уха-ха! — дип тагын да кычкырыбрак көләләр иде малайлар.— Базардан яшелчә сатып алулары гына җитмәгән, моның ни начарлыгы-хурлыгы бар, diләр бит әле! Ха-ха! Уха-ха! Көлеп үләрсең!..
Әтиебезнең һәлак булуы турында хәбәр килгәч, малайлар безнең базардан яшелчә сатып алуыбызны гаепләп көлүдән туктадылар. Авыр кайгылы хәбәр килгәч, күршеләребез безгә җыелдылар һәм әби янында озаклап утырдылар.

Бабайның бүрек һәм итекләр турында сөйләшүен хәтерлисезме? Ул башта Әхмәт абый белән, аннары итекче Семен белән сөйләшкән иде.

һәм менә бабайга Семен исе аңкып торган өр-яңа итекләр китерде, ә бабай аңа бик әйбәт бүрек бирде. Күн тышлы, колакчыннары каракулдән! Бабай беркайчан да мондый бүрек текмәгәндер, тексә дә, тегe-тегe заманнарда гына теккәндер. Әмма ул Әхмәт абыйга итекләрне бирергә озак вакытлар кыймыйча йөрде — Әхмәт абый бик тә горур кеше бит, аннары яшелчә бакчасы мәсьәләсендә Әхмәт абый күршеләр яклы иде.

Ниһаять, бабай Әхмәт абыйны өйгә чакырды.

— Син минем кияүне әйбәт белә идеңме, Әхмәт?

— Әйбәтме, дип... Мин бүтән берәү белән дә бильярд уйнамадым,— диде Әхмәт абый.— Аның да төрле...

— Киявемнең һөнәрем белән шөгыльләнергә рөхсәт итмәвен беләсеңме? — дип бүлдерде аны бабай.

— Беләм.

— Әхмәт, син ничек уйлыйсың, әгәр аңа яңа итек бассалар, итекләр аңа йә зур, йә кечкенә булсалар, ул аларны сатарга базарга чыгар идеме?

— Чыгар ди бик! — дип балаларча кызды Әхмәт абый.

— Бәлки, итекләрне сатарга миңа кушар иде ул?

— Синең киявең мондый эш белән сине базарга беркайчан да җибәрмәячәк иде.

— Димәк, мин, аңа атап басылган итекләрне базарга алып чыгып, аның истәлегенә тап төшерә аламмы? Нигә дәшмисең, Әхмәт? Нигә җавап бирмисең? Әллә мин ялган сатаммы? Юк-бар сөйләп, ботка пешермәкче буламмы?

— Син хак сүз сөйлисең, Ибрай абый,— диде Әхмәт абый.— Әмма мин синнән бер нәрсә турында сорамакчымын...

— Сора,— диде бабай һәм сагаеп кына Әхмәт абыйга якынайды.

— Нигә син хәзер алны-артны белмичә бүрек тегәсең? Бәлки, киявең тыеп тормагангадыр?

Бабайның йөзе кинәт суырылып китте, күзләре ялтырады, ул кызып, ярсып диярлек сөйли башлады.

— Бүрек тегү — минем бурычым, Әхмәт! Мин шул бурычны үтим! Минем киявемнең балалары ач та, ялангач та түгелме? Түгел! — Ул тынып торды.— Их-х, Әхмәт, син минем нинди бүрекләр тегә алырымны белмисең шул!

— Һәркем үз бурычын үти,— диде Әхмәт абый.— Ятимнәрсез дә, тол хатыннарсыз йортлар бик, бик аздыр хәзер...

— Аңламыйсың син мине...

Әхмәт абый урыныннан торды, эндәшмәде, чыгып та китмәде. Бераздан гына:

— Итекләрең кайда? — дип сорады.

Бабай урыныннан очып кына кузгалды, Әхмәт абыйга газетага төрелгән итекләрне алып килеп тә бирде.

— Сугыш бетәр. Тормыш җайланыр,— диде Әхмәт абый.— Оныкларың үсәр. Алар сиңа рәхмәт әйтерләр. Әмма бер нәрсә начар булыр — алар сине кызганырлар.— Әхмәт абый сүзсез торды.— Итекләр әйбәт икән. Рәхмәт.

Фининспектор болытлы, җепшек көнне кичке уңайда килде. Аның күнитекләренә пычрак мул ябышкан, шинеле чыланган иде, шуны салганда, ул тамак кыргалады.

Бабай белән фининспектор тагын чәй эчтеләр. Фининспектор урындыкка салынган йомшак мендәрдә утыруыннан канәгать иде, чәй эчеп, тәмәке тартып рәхәтләнүен яшерmәде ул.

— Иртәдән бирле сәгать төзәтүче тирәсендә матавыкланып йөрдем,— дип башлады ул, йөзен сөртеп алды, арыганлыгы хәрәкәтеннән сизелә иде.— Аның будкасы сез утыра торган төштән ерак түгеллеген беләсездер. Әйе... Сәгатьче белән шул хәтле изаланырга туры килер, дип

уйламаган идем. Ләкин шунысы әйбәт булды — мин аның көнгә ничә сәгать төзәтүен белә алдым кебек.

— Сәгать төзәтүче ашыкмаска да мөмкин,— дип кыстырды бабай.

— Шулай дисезме? — Фининспектор хәтта талпынып куйды. Аннары күңеле төшеп, хәтта кайгылы кыяфәттә: — Менә монысын искәрмәгәнмен,— дип елмайгандай итте. Озак кына сүзсез торды.— Ә безнең хуҗа бер инспектор хатынга шелтә бирде,— дип очын очка ялгамыйча әйтеп салды ул.— Алтарьга кереп торган шул хатын. Атакайның бу хәлгә ачуы купкан да протест белдергән.

— Нишләмәк кирәк,— диде бабай,— эшли белмәгәч, шелтә аласың.

— Эшли белә ул,— дип нигәдер тирән сулады Анатолий.— Эшен белә. Соңгы арада гына милиция кешеләре белән бер тегүченең өендә тентү үткәрделәр. Әллә ни тапмаганнар. Төрле бизәкле чүпрәк-чапрак тутырылган бер капчык күргәннәр. Нәрсәгә кирәктер, дип уйлыйсыз инде калдык-постыкны?

— Кем белгән...

— Менә без дә белмәгән-аңламаган идек шул. Әле шушы көннәрдә генә органнар күлмәкләр сатучы бер карчыкны каптырдылар. Бактың исә, чүпрәк-чапраклары күлмәкләреннән калган икән моның.

— Хәйләкәр икән инспектор хатыныгыз,— дип бәяләде бабай.

— Эшли белә ул! — диде Анатолий һәм тагын тирән итеп сулады.

Фининспектор җылынды, йөзендә арыганлык билгеләре бетте. Кинәт кенә ул:

— Сез, Бабай, тегесеннән соң базарга өч тапкыр чыктыгыз,— диде.

Бабай эндәшмәде. Әйдә, әйдә, сайрый бир, дигәндәй, исе китмичә утыра бирде.

— Сез базарда дүшәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе көннәрдә булдыгыз. Ә элек базарга шимбәдә һәм якшәмбедә чыга идегез, әйеме? — Анатолийга дәрт керде, аның күзләре җемелди башлады.— Сез, Бабай, итекче Семен Харламовка бүрек теккәнсез... Бүлдермәгез мине!..

Ул сөйләвеннән туктады, күзләре җемелдәсә дә, дулкынлануын инде тыеп кала алуы сизелә иде. Һәм фининспектор тыныч, ягымлы тавыш белән сөйләүгә күчте дә:

— Ярар, әйбәт утырдык. Сыең өчен рәхмәт, Бабай,— дип тәмамлады.

Фининспектор китүгә үк без, тагын кайчан килер икән, дип уйлана башладык.

Бу килүендә ул бик тә җайлы вакытны сайлаган иде — бабайның бүрек теккән чагына туры килергә кирәк булган аңа. Моны без соңыннан аның үзен тотышыннан аңладык. Бер уйласаң, аның бабайны бүрек теккән чагында күрергә тырышуы мәгънәсез дә кебек. Бабайның һөнәрчелек белән шөгыльләнүенә аның дәлилләре җитәрлек бит. Ул, хәйләмазар кормыйча гына, базарда милиционерны чакырып китереп, бабайның чемоданын ачтыра ала иде. Ләкин аңа профессиональ хәйлә кора белүен күрсәтергә, үзенең төшеп калганнардан түгеллеген, теге хәйләкәр инспектор хатыннан начар эшләмәвен, ә, бәлки, Николаевка тиңлеген сездерергә кирәк булгандыр.

Соң иде инде. Бабай үз эшендә, әби белән мин аның янында утырабыз. Кинәт тәрәзәдән сәер тавышлар ишетелде. Кемдер капканы нәрсә беләндер кыра кебек, койма тактасын каералар да сыман. Тавышлар көчәйде, эт өрә башлады, дөпелдәтеп бастылар бугай, нәрсәдер гөрселдәде.

— Ишегалдына кемдер керде,— диде бабай.

Эт котырынып өрде дә, тамагына сөяк кадалгандай, кинәт тынды. Һәм шул чакта ук ишегалдында ачы тавыш яңгырады. Әби, ишекне төбенәчә ачык калдырып, тышка атылды, һәм шуннан соңгы хәлләрне мин анык ук күреп тордым. Менә ул болайга таба борылды, аның йөзен курку баскан иде. Аннары ишектән төшкән якты шакмакта Анатолий

күренде, шинеле чабуын сөйри иде ул, ә чабуга ычкындырмаслык итеп эт ябышкан иде. Әби итәге белән селтәнеп алар әйләнәсендә йөри, этне куа. Әмма бик тырышмый бугай ул (бабай мәсьәләнең асылын аңлап алса, бүрек әйберләрен һәм эш коралларын еракка ак яшерергә өлгерер иде). Ниһаять, әби этне куып җибәрде, Анатолий ачык ишеккә йөгерде, өйалдында мине бәреп ега язды. Мин, куркуыннан шулай тиз йөгерәдер, дип уйладым. Ләкин аның атылып басып керүенең чын сәбәбен бабай янында җинүче кыяфәтендә торуын күргәч аңладым.

— Менә шулай! — дип нәтиҗә ясагандай әйтте ул. Тәрәксез тәбәнәк урындыкка утырды, кычкырып көлеп җибәрде, тавышы каһкаһале түгел иде, ихластан шатланып көлә иде.— Сез, әлбәттә, мине болай соң килер дип көтмәгәнсездер?

— Көтмәдек,— дип турысын әйтте бабай һәм тегә торган бүреген читкә куйды.

— Бәлки, аның бик соң килүе дә ихтимал, диген уй башыгызга кереп тә чыкмагандыр?

— Юк,— диде бабай һәм күзлеген салды, аның карашы таркау иде, ул, каушап калып, эндәшмичә утырды.

Анатолий папирос кабызды, күгелҗем төтен бабайның башын, җилкәләрен каплый барды. Фининспектор тартуын, башын чайкап көлүен белде.

— Күптән түгел генә кызыклы хәл булды әле... Полковникның элекке тарлавында Кирпичев диген берәү яши икән. Мал-туар алып сату белән шөгыльләнә икән бу. Безнең бер иптәш шуның янына китте. Тарлауны әйләнеп чыга иптәшебез — шикләнерлек бернәрсә дә күренми. Хуҗа белән әңгәмә корып җибәрә. «Нигә сез, Кирпичев, — ди,— моннан бер ай элек танагызны саттыгыз? Ашатырына бетте ме?» «Хәтерләмим бит»,— ди тегесе. «Ә бәлки, хәтерләрсез?» Шул чакта мич артыннан Кирпичевның балалары йөгерешеп чыга да: «Әти, әти, яшь үгезләрне бер абыйга сатканыңны оныттыңмыни?!» — дип гөрләшергә тотыналар. Шәпме, ә?! — дип көлеп җибәрде Анатолий.— Шәп!

Гаҗәп хәл — бабай төнге кунакның рәхәтләнеп көлүенә ачуланмады, үзе дә кушылып көлде.

— Мин дә сезне оста эләктердем бит, ә?! Сез, шулай уйламаганда каптырыр, дип башыгызга да китермәгәнсездер, ә?

Ул тагын көлеп җибәрде һәм, ни гаҗәп, бабай да аңа кушылып көлде. Хөрмәт йөзеннән яки мыскыллап көлеп кенә куйса, бер хәл иде, алай түгел бит — Анатолий гадәти генә көлә, ә бабай туктаусыз кеткелдәп утыра, шул кеткелдәвеннән салынкы җилкәләре дерелди хәтта.

Төннең яртысы күптән узды. Фининспектор китәргә уйламый да бугай. Бүлмә буйлап йөренә, тарта, сөйләшми. Бабай да сөйләшмичә утыра, аның башы һәм салынкы җилкәләре өсте дә Анатолий папиросыннан чыккан куе төтен бөтерелә.

Фининспектор урындыктан торды. Бабай, башын күтәреп, аңа карады.

— Нәрсә? — дип талчыккан кыяфәттә сорады ул.— Нәрсә, Анатолий?

Фининспектор алга талпынып куйды, аннары бабай янына барды да аның каршысына чүгәләде.

— Минем өйдә чып-чын тәмугъ,— диде ул.— Бабай... берәү дә минем кебек яшәмидер...— диде дә башын чайкады, тагын папиросын кабызды.

Ул хәсрәтле яшерен нәрсә турында әйтергә теләгәндер, һәм бүтән чакта бабай аны аңлар да иде, ләкин бу мәлдә аның күңеле Анатолийның хәленә керүгә, кайгысын уртаклашуга каршы иде.

Икеме, өчме көннән соң, Анатолий култык астына төргәк кыстырып килде. Аның кәефе тантаналы төстә күтәренке иде, бабайга бүләк китергән, дип тә уйларлык иде.

— Бер эш бар,— диде ул.— Фуражка тегәргә кирәк.

— Фининспекторгамы? Фуражкамы? — дип гаҗәпләнде бабай.— Мин тегәргә тиешме?
— Берне генә тегәргә кирәк. Кем әйтмешли, иптәшләрчә. Җаваплы эштәге кешегә.
— Ярар,— дип мәҗбүр булуын таныды бабай.
Анатолий төргәкне сүтте, өстәлгә соргылт-яшел төстәге материалны куйды, күкрәк кесәсеннән җеп чыгарды.
— Менә, үлчәвен үзем алдым.
Ул килешсез итеп көлде, ләкин мондый көлүеннән тиз тыелды, йөзен җитдилек, хәтта кырыслык басты.
Бабай метр үлчәвен турайтты, аңа җепне сузып салды да:
— Башы зур икән! — дип шаккатты.— Күр әле, алтмыш ике сантиметр!
— Аңыштык! — дип тагын көлде Анатолий.
Шундый зур фуражкага заказ китерүеннән канәгать булуы сизелеп тора иде.
— Төшендем,— дип кеткелдәде бабай.
— Алтмыш ике сантиметр, дисезме?
— Алтмыш ике,— дип тагын кеткелдәде бабай.
— Баш зур, ә акылы?
— Әйе, әйе, акыллы,— дип баш кагып кеткелдәде бабай.
Анатолий, бабай фуражка теккәндә, алдан сиздермичә, берничә тапкыр килеп китте. Бабай иптәшләрчә, ягъни бушка тексә дә, ярамаган эш эшләмәсә дә, диюем, мондый килеп китүләр аны туйдырып бетерде. Тәгаенләп әйткәндә, аның тынычлап эшләвенә ышанычын җуйдырды, ахыр чиктә, бәйсез останың горурлыгына сукты бу килеп китүләр.
Әмма Анатолийга да нидер булды. Бабайны эзәрлекләүнең кызыгын тапмый башлады кебек ул. Фининспектор элеккедән ешрак килгәләде, кайчакта салмыш була, гаиләсендә тәртип бетүеннән зарлана иде. Ул элекке җитди, төпченүчән фининспектор түгел иде инде, әмма бабай моны сизми иде бугай, безнең алдагы бурычын үтәү — безне карап үстерү өчен бүрекләр тегүен дәвам итсә дә, өметсезлеккә тарыган иде инде. Берчакны Анатолий бурычка оялып кына акча сорагач та, аның кыерсытылган хәлдә икәнлеген сизмәде — үзе дә кимсетелгән бит инде — һәм аңа акча бирде. Анатолий бурычын икенче көнне кайтарды, гаиләсе тормышының җәһәннәм упкынына әверелә баруыннан тагын зарланды һәм, бик мескен хәлгә калып, бабайдан тагын акча сорады. Бабай Анатолийга әле генә китергән акчаны өстәлдән алды да — акчаны җыеп куярга да өлгермәгән иде ул — фининспекторга бирде. Соңыннан, Анатолий оялып кына кабат килгәч, бабай аңа тагын акча бирде, кеткелдәп аяк астына чиртте — хәлеңне аңлыйм, янәсе...

## 6

Аларның шундый мөнәсәбәтләре озак дәвам итте. Бабай бу елларда бүрекләр тегеп сатуын ташламады, аны беркем тыймады да, эзәрлекләмәде дә.
Миңа унҗиде яшь тулды, кирпеч заводында эшлим — аз булса да акча табам, ә энем мәктәптә укый. Бабай белән әби бик картайдылар, бабай аеруча какшады, ул ничектер тиз үк — бер елда — бетеренде, бөкересе чыкты, начар күрә һәм көч-хәлгә йөри башлады, ахыр, урынга егылды. Ул күз алдында сула барды, йә әби, йә энем белән мин, көннәр буена янәшәннан китмичә, аның һәр теләген үтәргә тырыштык.
— Бабай, нәрсә дә булса кирәкмиме? — дигәч, ул, сары-юка күз кабакларын авырдан күтәреп:
— Анатолий килмәдеме? — дип сорый иде.
— Юк,— дия идек без һәм үзебезне гаепле саный идек.

Әби йөдәп бетте, Анатолийны эт итеп сүгә иде — әйтерсең, Анатолий — безнең туганыбыз, ул үлем түшәгендә ятучы кеше алдында изге бурычын онытканн инде, әй. Ул миңа әгәр Анатолийны урамда очратсам, бабайның хәлен белергә кичекмәстән килергә әйтергә кушты. Әгәр инде очратмасам, эшләгән җиренә кереп, бабай бик каты авырый, хәлен белегез, диярга тиеш идем. Мин урамнар буйлап кешеләрне карап йөри башладым, әмма, үч иткәндәй, фининспектор Анатолий очрамады. Ә эшләгән җиренә барасым килми иде — бабай аны күтеп ятуы белән үк аның алдында түбәнсенә кебек иде миңа.

Ниһаять, мин аны очраттым. Мин кинодан чыкканда, ул үзе мине кычкырып тукттаты. Дәште дә, кешеләрне аралый-аралый, минем күздән югалуымнан курыккан кебек, миңа ташланды.

— Карале,— дип ашыгып кына сүз башлады да мине кулымнан тотты ул.— Бабайның хәлен белергә һич кенә дә җыенып җитә алмыйм бит. Әмма барам, барыбер барам! — Ул, тукталып торгач:— Мин теге эштән киттем бит, анда эшләмим,— диде.

Ул оялган сыман иде, шулай да бүтән эшкә күчүен миңа әйтүенә шатлана кебек иде.

Без, шәһәр бакчасына кереп, эскәмиягә утырдык.

— Күрче,— дип гаҗәпләнеп миңа текәлде ул,— син үсеп киткәнсең ич, егеткәй! Эшлисеңме?

— Әйе. Кирпеч заводында.

— Кирпеч заводында? Нигә нәкъ менә анда? — Мин тиз генә җавап кайтармагач, ул:— Кеше ни өчен нәкъ менә монда эшләвенең, ә бүтән җирдә түгеллеге сәбәбен ап-ачык белергә тиеш,— дип өстәде.

— Кайда эшлисең инде... Кирпеч заводында булмаса, сабын заводы да әзерләүләр конторы гына кала — бездә башка эшләр урын да юк бит.

— Анысы да дөрес,— дип килеште ул.— Ярар соң. Ә үзең кайда эшләргә теләр идең? Кем буласың килә, кайда укымакчысың?.. Гомумән, тормышта ни кылмакчы буласың?..

— Ну инде...— Мин тотлыгып калдым, аның кызыксынуының мәгънәсе аңлашылмый иде миңа.— Ну, эшләрмен инде... Энем укый, әби картайды, бабайның хәле...

Ул, тирән итеп сулады да, миңа карамыйча гына:

— Хәле бик начармы? Врачлар ни диләр? — дип сорады.

— Начар. Врачлар алай димиләр инде. Сырхауханәгә кереп ятырга кирәк, диләр. Бабай теләми.

Анатолий озак кына сүзсез торды, йотлыгып тәмәке тартты — нигә моңа чаклы бабайның хәлен белмәве сәбәбен аңлатырга, акланырга теләгән кебек иде.

— Карале, бабаң белән минем мөнәсәбәтләр әйбәт булды, дип уйлыйсыңмы син?

Мин елмайдым. Аның белән бу хакта сөйләшәсем килми иде.

— Әгәр мөнәсәбәтләрегез начар булса, ул сезне көтмәс иде.

— Әйе, әйе, шулай. Ләкин ул хакта әйтүем түгел, мин һичшиксез, керермен, мин бүтән турыда сүз йөртәм әле... Мин сиңа... Ну, ярар, минем урында булган кеше сиңа киңәш бирә алыр идеме?

Мин аның минем җавабымны эчке бер киеренкелек белән көтүен сиздем.

— Бирә алыр иде,— дидем мин. Дөрес, бу сүзләрем, син, әйдә, киңәш-табышларыңны сип кенә, дигән кебегрәк яңгырады.— Ә нинди киңәш бирмәкчесез?

— Беләсеңме... Картая башлаудыр, бәлки...— Ул көлеп алды.— Бәлки, чыннан да, шушы кадәр гомер иткәч, кайбер нәтиҗәләргә киләсеңдер. Беләсеңме, кеше булган кешегә, хәзергә кирпеч заводы ярап тора, аннары күз күрер, дип фикерләү килешми.

— Ну, ярар алайса, әйтим, радиотехника буенча инженер буласым килә минем.

— Синең максатың булырга тиеш, син тырышырга-тырмашырга, әмма шул максатыңа ирешергә тиеш. Максатың булуы мәҗбүри. Ләкин... дәрт, тугрылык максаттан да әһәмиятлерәк... Төрле юк-барга кызыгырга ярамый. Әйтик, бабаңдагы кебек дәрт булуы кирәк!

— Бабайдагы кебек?

— Әйе.

— Әмма бабайның ул дәрте аңа әллә ни шатлык китермәде.

— Их-х, хикмәт анда түгел... Ә син беләсеңме, мин кем булырга теләгән идем? Археолог! Фронтта кем булган, дисең инде мине?

— Сез фронтта булдыгызмыни?

— Булдым! — дип горурланды ул.— Фронтта мин шофер идем. Кайткач, фининспектор булып киттем. Хәзер инде үткән заманда — фининспектор идем. Тартасыңмы?

— Тартмыйм. Ә сез начар фининспектор түгел идегез кебек,— дип көлеп һәм ачынып әйттем мин.

— Начар буласым килмәде! — дип кызды ул.— Үзем теләгәнчә... Ну, син инде моны аңлыйсың.— Ул көлеп җибәрде.— Николаев кебек булырга теләдем. Шундый фининспектор булган, диләр.

Ул тагын озак кына сүзсез торды.

— Мин хатын белән аерылыштым бит,— диде ул. Йөзендә моңсулык сизелде, ләкин аерылышуына үкенми кебек иде.— Аерылыштык, йортны саттык та акчасын бүлештек. Кызыкмы? Хатын китте.— Ул кинәт кенә торып басты, мине җилкәмнән кысып тотып бастырды. Аннары ашыгып, кайнарланып сөйли башлады.— Мин дә китәм! Без йортны саттык, акчасын бүлештек. Хәзер минем акчам бар һәм мин бабаңа бурычымны түли алам. Һичшиксез, керәм мин сезгә. Һәм бурычымны, һичшиксез, түлим!

Анатолий белән очрашуым турында мин бабайга берничә көн әйтмичә тордым. Әмма Анатолий һаман күренмәде, бабайның хәле гел начарланды. Беркөнне ул фининспектор турында сорагач, аны күрүемне һәм аның безгә керергә ышандыруын әйттем. Бабайның бу хәбәрне тыныч кабул итүе мине гаҗәпләндерде. Анатолийның килүен ихластан тели иде бит ул!

— Бабай, синең аны бик тә күрәсең киләме?

— Килсен иде шул,— дип акрын гына, тыныч кына әйтте бабай.— Дуслар идек бит. Ул фининспектор түгел икән инде. Шулай... Күрәсем килә иде үзен, карыйсым килә иде үзенә.

Мин очрашуыбыз турында сөйләргә теләми идем, ләкин бабай тыныч та, битараф та иде — килсә, килер, карыйсым гына килгән иде үзенә, ди бит, шуңа күрә кайбер нәрсәләрне әйтергә булдым.

— Аны, хатыны белән аерылышкан, диләр. Алар йортларын сатканнар, акчасын бүлешкәннәр. Анатолий үз өлешеннән сиңа акча бирмәкче була. Бурычым бар, ди.

— Бик тә кызганыч,— дип әйтеп куйды бабай,— кызганыч...— Ул өзек-өзек һәм көчәнеп сөйли иде.— Һай бу каһәр суккан авыруны... Бик тә карыйсым килә иде үзенә...

## 7

Бабай исән чагында, аның фининспектор Анатолий белән мөнәсәбәтләрен шәһәрдә белү-белмәүләре хакында кызыксынмаган идем. Бабай вафат булгач, бу мөнәсәбәтләрдән хәбәрдар булуларын аңладым.

Җеназага картлар күп килде. Алар җылы киенгәннәр, кайберләре шәл дә ураганнар иде. Безнең өй янына җыелып, бабайның гәүдәсен алып чыгуны сүзсез һәм тыныч кына (миңа хәтта алар үз җеназаларында катнашалар кебек тоелды) көттеләр. Менә бабайны, гөмбәзгә охшаган

яшел өсле, сыгылмалы носилкага салып, ишегалдыннан алып чыктылар. Озатучылар күп иде, алар, иелә төшеп, табут артыннан бардылар. Тыкрык башларында карап-озатып торучылар тагын да күбрәк иде. Ирләр бабай тегеп биргән бүрекләрдән иде.

Тыйнаклык һәм кырыс әдәп сизелә иде җеназада. Һәм кинәт кенә кешеләрсез култыктан фининспектор Анатолий күренде, безгә таба килә башлады. Ул яланбаш иде, чәчләре тузгыган иде. Һәм кешеләр каушап куйдылар, ләкин бу уңайсызлануны җанлану бик тиз алыштырды. Картлар гына ачулары чыгып пышылдаштылар. Гаҗәп, әй, мин Анатолийны күрүемә шатландым һәм аңа кулымны болгадым. Аннары җеназа тыйнак һәм кырыс әдәпле хәленә кайтты, бу кешенең бүрекчегә чит-ят булмавын әйткәч, картлар да мыгырдаудан туктадылар. Анатолий үзен басынкы һәм кайгылы тотты, җеназадагылар тиздән аның турында оныттылар.

Ул юл буена бер сүз дә әйтмәде, зиратның упкынга охшаган буш һәм йөрәк яргыч ачык капкасы күренгәч кенә, миннән:

— Миңа зиратка керергә ярыймы? — дип сорады.

— Ярый. Тик бүрегегезне киегез һәм картлардан читтәрәк торыгыз.

— Ярар, — дип кабаланып башын какты һәм бүреген батырып киде.

Бабайны җирләгәч, без зираттан чыктык. Мин Анатолийны тапмакчы булдым, ләкин ул күренмәде. Йөгереп юлга чыктым, шәһәр ягына текәлеп карадым. Ак юлда берәү дә юк иде. Мин кирегә йөгердем. Зират караучы капканы яба иде инде.

— Анда кеше калмадымы? — дип дулкынланып сорадым.

Зират караучы сүзсез генә елмайды. Шушы мәлдә мин ни өчен нәкъ менә Анатолийны күрергә теләвемнең сәбәбен аңладым — бабайга барча кешеләрдән дә якын бәйләнештә иде бит ул.

...Син кайчан да булса гаҗәеп хискә бирелерсең әле. Моны син, бәлки, бөтен мал-мөлкәтең — күлмәк-ыштаның, дәреслекләрең, яраткан китабың һәм кәгазьгә төрелгән эремчек шәңгәләре салынган мескен фанер чемоданыңны вагон утыргычы астына куйганда тоярсың. Бәлки, шәһәрчегең белән хушлашырга чыгарсың да, аны бөтенләе белән күреп бетерә алмасаң да, станция янындагы йорт-биналары, агач бакчасы һәм уйсулыкка шуып диярлек төшкән автобус сине шундый халәттә калдырыр. Бәлки, озак вакыт читтә йөргәннән соң, вокзалдан шәһәрчегеңә җәяүләп керерсең — калкулык түбәсенә җиткәч, сиңа елгачык күренер, елгачык аръягыннан иртәнге балкышта шат тәрәзәле йортлар сиңа елмаер, алар арасында синең нигезең-йортың да бар, тик ул синеке дә, синеке түгел дә кебек, әмма туганнарың яшәүче йортны барыбер дә танырсың син һәм күңелеңдә гаҗәеп талпынучан хисләр уяныр. Син хәзер инде вакытны ашыктырмавыңны сизәрсең. Чөнки син хәзер инде, көннәрне куркынып санамасаң да, тормыш ташкынының ургылучанлыгын аңлыйсың, һәм көнне, һәм елны бәһали беләсең. Син күңелне үзенә тартып торучы, шул ук вакытта, ят булып тоелган шәһәрчек урамнарыннан шатланып атлыйсың. Монда барлык нәрсә дә үзгәрешсез, һәм шул күңелгә сагыш сала... Барасың, барасың, һәм кинәт...

Ачык төсле буяулар белән фырт-көяз язылган белдерү күргәч, туктальп калдым. Болай итеп провинция буяучылары гына яза ала, һәм гадәттә аларны рәссамнәр дип атыйлар. Каймалаган тактага «М. Г. шәһәренең көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинатының әйберләр биреп тору кибете» дип язылган иде. Ә кибет бусагасында Әхмәт абый басып тора иде. Иртәнең сабыйлыгына картайган күзләрен кыскалый, аның агарган чәчләре үз итеп йомшак кына җемелди. Ул мине менә ничә еллар инде ике кулы авырлыгын ялгызы күтәрүче тугрылыклы кулы белән кысып кочаклады.

— Синме бу?! — дип мине этәребрәк кычкырып әйтте Әхмәт абый.— Күрче, директор малае нинди булган!

— Чү! — дидем мин.— Бүрекче малае!

— Ярар, шулай булсын,— дип килеште ул һәм сүзсез торды.— Очраштык бит...

— Очрашуыбыз әйбәт булды.

— Әйбәт, әлбәттә,— дип килеште ул.— Ә син әле бик кызыклы очрашуың буласын беләсеңме? — Ул миңа сагаеп карады.— Бүген, менә хәзер-хәзер, кибеткә кем килергә тиеш? — Ул тагын сүзсез торды һәм:— Фининспектор Анатолий! — дип өстәде.— Нәкъ менә бүген килергә тиеш. Әйдә, минем бүлмәгә кереп көтик,— дип тәкъдим итте Әхмәт абый.— Ул туры минем янга керәчәк. Беләсеңме, без кайчакта истәлекләрне яңартабыз...

— Анда кермик. Мин аны монда көтәм.

Әхмәт абый кибеткә кереп китте, мин кибет тирәсендә әрле-бирле йөрендем. Бераздан мин ерактан, тузанлы урам томанында һәм яктысында көр череләдәү ишеттем һәм, юл читенә басып, сагаеп тыңлый башладым. Тимерләр балкышына, тузан һәм төтен болытларына төренеп, моторлы велосипедка атланган фининспектор Анатолий туп-туры миңа төбәп килә иде. Ул, миңа бәрелмәс өчен, рулен җәһәт борып өлгерде, кибет кырында ук туктап, моторын сүндерде.

— Күрешмәгәнгә ничә җәйләр, ничә кышлар узган, әй! Әкәмәт...

Бу сүзләрен ул уңайсызланып та, шатланып та, озак вакытлар очрашмаган булсак та, миңа төбәлеп карамыйча әйтте. Ул үз эченә бикләнгән кебек иде. Аны, юанаеп киткән, дип булмый, ул чын мәгънәсендә таза, сәламәт иде. Күзләре аның яшендәгеләргә хас булмаганча җем-җем итеп елкылдый иде.

— Студентмы? — диде ул.— Вакыт уза... Өйләнмәденме? Юкмы? Ә мин...— дип үзен нәрсә өчендер шелтәләгәндәй итте ул.— Ә мин... Син беләсеңме, кызым туды бит минем! Беләсеңме, өйләндем бит мин!.. Кибетләрдә бишекле арбалар юк, ә менә прокат кибетендә андый арба дүртәү... Әхмәт Галиевичтан сорап торырга булдым... Чиләбегә шундый арба алырга барачакмын әле, хәзергә китеп булмый, эш муеннан. Мин хәзер автовокзал начальнигы бит... Яңа автобуслар алабыз...

— Сезнең өчен бик шатмын,— дидем мин.— Хатыныгызга сәлам күндерегез.

— Рәхмәт,— дип кулымны каты итеп кысты һәм җибәрмичә торды ул.— Рәхмәт! — дип тагын да ихласрак итеп кабатлады, кулымны ычкындырмады, тагын да катырак итеп кыса бирде.

— Мә! — диде ул кинәт, минем кулны ычкындырды, һәм аның талчыккан йөзенә бәхет йомшарып җәелде.— Мә! — диде ул һәм моторлы велосипедына таба атлады. Велосипедны җайлы гына житәкләде дә, риясыз олыланып, минем янга алып килде.— Мә, утырып әйләнеп кил!

Утырып киткәч, башыма сәер фикер килде — ул борчылсын, велосипедымны нишләтте икән, дип газаплансын өчен, мин еракка-еракка китәргә теләдем, әмма көлемсерәдем дә, кире борылдым. Хушлашканда, мин аңа тагын:

— Сезнең өчен бик шатмын,— дидем.— Хатыныгызга сәлам күндерегез.

— Ничек? — дип моторлы велосипедка күрсәтте ул.

— Җен көчләре бар моның моторында! — дидем мин.

Һәм ул минем кулымны тагын каты итеп кысты, мин дә калышмадым, икебез дә икебезнең риясызлыгыннан канәгать идек. Аннары миңа ямансу-моңсу булып китте. Без бабайның үле гәүдәсе янында торабыз кебек тоелды. Һәм ул электәге бөтен йомшаклыгы яки кырыслыгы өчен гафу үтенергә тырыша, ә мин, гәрчә моңа хакым булмаса да, аның гаебен йолдым кебек иде.

⁂

# ШИГЪРИЯТ



## Нәҗибә Сафина

## МӘҢГЕЛЕК СЕР

### Җанын чөя...

Мин җиргә — түбән төшкәнмен,
Ә гавам карый күккә...
Шундый да тирән төшкәнмен
Һәм терәлгәнмен төпкә.

Ә кеше кошка кызыга,—
Очканга, канатлыга.
Мин исә ияргә алмыйм
Җәяүлегә, атлыга...

Мин төшкән тирәнлек, беләм —
Халык йөзгән тирәнлек.
Җанны да батырыйм мәллә
Хакыйкатькә керәм дип?..

Ә халык дигәнең гали:
Җанын җибәрми төпкә,
Үзе батса бата, әмма
Ул — җанын чөя күккә!

* * *

Дөнья бер мантыйксыз, фәлсәфәсез
Әйләнгән чакта
Хәер сорап тора икән
Фәйләсүф — чатта.

...Дөнья — җыр ишетми — туптан
Атылган чакта

Сүгенергә мәҗбүр, имеш,
Сандугач хәтта!..

## Әле син белмисең...

Гаҗиз калдым:
Бүләк итеп,
Китергәнсең ылыс.
Йөрәгемә кадалды ул
Булып үткен кылыч.

Ни уйладың?
Аңлый алмыйм:
Һәм шул көннән бирле
Аяк өсте табут кидем,—
Салкын гүр күк җире...

Ә монсы төш:
Табут, ылыс.
Табутта кем дисең?
...Мәхәббәтне җирләп булганлыкны
Әле син белмисең...

## Булмый...

Күз яшьләрем ачы-ачы,
Тама алар тамчы-тамчы.
Тамчы-тамчы, тамчы-тамчы:
Безнең арабызга ташчы
Өя бара таштан дивар...

Сүтмәк булып, берсен кубар!
Бармакларың көчсез — пешәр,
Кулларың өзелеп төшәр...

Тамчы-тамчы яшем булып
Минем җанымката бара —
Тирәнәя бара яра,
Ераклаша бара ара.

Синнән миңа, миннән сиңа
Карап торсаң, ара юк күк —
Канап торган яра юк күк.

Ачы тауны үтеп булмый,
Җан ташларын сүтеп булмый.
Дәрья ташып, тау күчсә дә,
Үз-үзеңнән китеп булмый.

## Үз-үземә генә...

Үз-үземә генә ачуланам:
Дулкын кебек «кайта-китәле» мин.
Килеп бәреләм дә ярларыма,
Кабат дәрьяларга китәмен мин.

Үз-үземә генә ачуланам:
Табигатьнең нәни баласы мин.
Үзем генә ярган ярларымда
Елга җыры булып агасы, дим.

Үз-үземә генә ачуланам:
Үз җанымны тыеп, кыеп кара...
Үз-үземнән киткән мизгелемнән
Җанымдагы һәрбер кыен яра.

## Үзгәртеп кору...

Хәзер инде
Кызыл гына түгел әләмнәр.
Кызыл гына түгел адәмнәр...
Тик салават күпере һаман бертөрле —
«Үзгәртеп кормаганнар» ул күперне...

* * *

Сабыр төбе сары алтын булса,
Төпсез күңел аны күрмәячәк:
Алтын эзләүчеләр беркайчан да
Төпсез күңелләргә кермәячәк.

* * *

Язмышыма яр кирәк,
Күңел ярыма — терәк;
Сискәндем, һушсыз калдым:
«Ул — мин», — ди ямьсез өрәк...

Хәзер ярлар кирәкми:
Өрәк ярды йөрәкне.
Һәм...
Мин ике йөрәкле...

* * *

Уттан алып суга салма җанымны —
Әверелермен ташка.
Таш язмышы шундый: бәрсә берсе
Бер гаепсез башка?..

* * *

Елга ташы — мунча ташы,
Йөзек ташы — асыл таш.
Мунча ташының эченнән
Энже чыкты — ярылгач...

* * *

Төпкә батса да,
Тау башында ташлар.
Таулга менсә дә,
Җиргә ава башлар.

* * *

Яратасыңмы — ярат.
Дөньяга гайбәт тарат.
Китәр юлыма инде
Җигеп куелган пар ат.

Ул пар атта син кучер —
Минем хакта соңгы җыр.

* * *

Учак яна — җылыналар.
Якынрак җыелалар.
Аннан таптап сүндерәләр.
Утны шуңа күндерәләр.
Ә мин — кеше, учак түгел.—
Сынса сына, сүнми күңел.

* * *

Җир бар, җыр бар, чор бар.
Син бар, мин бар — сер бар.
Җирне, җырны чорга бәйләп,
Мәңгелек сер гел әйләнә
Утлы Кояшны тирәләп...

* * *

Ташларны җыяр чак җиткән.
Таулар җыяр чак бармы?
Сулы ярны кушып булмый —
Җыеп булмый тауларны.

* * *

Хыялга ияреп киттем —
Зәңгәр томан ул.

Зәңгәр томан коча — авам,
Юк шул тотар кул...

* * *

Мәхәббәткә ышандырып,
Мине шундый яраттылар:
Ярларымнан ашкач ташкын —
Бар дөньяга тараттылар.

Ә мәхәббәт шундый «кызык»:
Яратсаң — бар, таратсаң — юк...

* * *

Исерекләр илне баскан,
Галимнәр үз илен ачкан.
Җансыз калганга гәүдәләр,
Фәрештәләр илдән качкан.

* * *

Шаша, таша елгалар,—
Тотып торалар ярлар:
Берсе — текә, берсе — сөзәк...
Берсе — акыл, берсе — йөрәк.

* * *

Аквариум балыгына
Әйләнә күрмә, халык!
Савытың ватмый гына,
Җаныңны якмый гына
Табылмый җирдә хаклык...

* * *

Иртәгә дә кабызырга
Томалыйлар күмерне...
Кабызалырмы Киләчәк
Бүген сүнгән гомерне?



# Басыйр Рафиков

## Соң түгел

*Милләтемә*

Әле тупаслык
Җанга үтмәгән.
Милли кайнарлык
Тәмам бетмәгән.
Әле туган тел
Йөрәкне назлый.
Кызлар, апалар
Әдәплек саклый.
Яхшы уй белән
Әйтелә нәзер...

Асылга кайту
Юлын тап хәзер!

* * *

Аклар, кызыллар —
Бар да аналар улы.
Аклар, кызыллар —
Аерган язмыш юлы.
Аклар, кызыллар —
Берсенә берсе яный.
Аклар, кызыллар —
Бүген барсы да фани...

Ә Ил ярасы —
Һаман каный да каный...

## Өн һәм төш

Кан саркытып, гасыр узып бара,
Туплар шартлый, мылтык атыла.
Хакимдарлык өчен, тәхет өчен
Мәсләк-идеаллар сатыла.

Җан тетрәтеп килә яңа көннәр,
Үткәннәре — чүпкә ташлана.
Өндә генә түгел, төшләрдә дә —
Җәрәхәтле авыр манзара...

## Көзге элегия

Сәер битарафлык тирә-юньдә,
Черем итә чуар җир өсте.
Әремнәр дә монда бездәге күк,
Сагышлы һәм әрнеткеч исле.

Арган инде яфрак бураннары.
Киткән кошлар эзе югалды...
Чияләнеп беткән уйлар кебек,
Офык сызыклары томанлы.

Басып торам — килер көннәр өнен
Сихерләнгән күңлем сагалый...
Туган илдән искән табиб җилләр
Чал чәчемнән сыйпый — дәвалый.



# ПУБЛИЦИСТИКА



Рафаэль Сибат

# ТЕКӘ КҮТӘРЕЛЕШ

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

## Астан өскә карап...

Коммунизм тавына күтәрелеп киләбез, дип дөньяга чаң сукканда гына кинәт, чылбырыннан ычкынган кое чиләге кебек, төпкә убылып төштек. Бәрелү, су чәчрәү, караңгыда калу хәлләре сыманрак бу...

Әйе, авыр заманда яшибез. Үрә баскан инфляция, законнарны урап йөри торган коррупция, үзенең хөкемгә тартылмаячаклыгына нык ышанган җинаятьчелек. Ерткыч хайваннарны да хәйран калдырырлык явызлык галәмәтләре...

«Тукта, без кешеләрме соң?!» — дигән уйга китерерлек Чечня вакыйгалары.

Берәүләрнең искитмәле баеп, икенчеләрнең үз тамагын да туйдыра алмаслык хәерчеләнүе...

Депрессия, өметсезлек, кәефсез тормыш. Без аста. Өскә күтәрелеп карасаң, нидидер ачыклык күренә дә кебек. Адәм балалары иң караңгы тормышта да яктылыкка, нурга омтылалар.

Текә төшү күпләрдә мескен гаҗизләнү тудырды, вакыт-вакыт югарыда утырган башлыкларга гына түгел, ата улына, ана кызына ышанмый башлады. Кешеләрдәге оптимизм рухы, киләчәккә булган өмет уты сүнеп бара. Һәрхәлдә, ул хәзер янмый, ә бозлы яңгыр суккан учак кебек пыскый гына...

Әмма!..

Дөньяда әнә шул «ӘММА» да бар әле!!

Әмма караңгылык үзенең кара пәрдәсе белән һәр урынны нур кермәстәй итеп томалады дип гомание да һич дөрескә туры килмәс, чөнки шушы борчулы-мәшәкатьле заманда да үз тавына күтәрелеп баручылар бар. Хәйранмы?!

Хикмәт нидә?

Алар бары «яңа тормышка» алданрак җайлаша төштеләр, аның өермәле дулкын-упкыннарында курыкмыйча йөзәргә өйрәнделәр.

Шундый хуҗалыкларның берсе — Кукмара районындагы «Яңа тормыш» арендачылар берлеге. Исеме җисеменә туры килгән әлеге берләшмә урыс Чарлысы, Татар Толлысы, Плаксиха авылларын үз эченә ала. Өч авылда барлыгы 276 хуҗалык. Бер-берсеннән артык еракта урнашмаган әлеге салалар яшел урманга терәлеп үк утыра. Толлыдан ике чакрымда Көмеш Нократ ага. Басу-кырлары алай бик тигез дә түгел, чокыр-чакырлы, ләкин уңышны күп бирә. Дөресрәге, монда күп уңыш ала беләләр. Бу хуҗалык белән Татарстанның атказанган агрономы, «Почет билгесе» ордены кавалеры, Россиянең һәм Татарстан Республикасының мәгариф отличнигы, өч бала атасы Рәфыйк Габдерәүф улы Рәүфов җитәкчелек итә.

Журнал варианты.

## Ике рәсем арасындагы гомер

**1995** елның эссе табадай җәе...

Толлыда Рәүфовлар йорты.

Татар хатыннарына гына хас якты һәм мөлаем йөзле йорт хуҗабикәсе Бәрия ханым безне елмаеп каршы ала, чәйгә чакыра.

Заманча эшләнгән вә бизәлгән, яхшы-яңа мебель урнаштырылган йортта миңа иң нык тәэсир иткән нәрсә стенадагы рәсем булды. Бер үк кешенең яшь һәм бүгенге бабай вакыты. «Бабай чоры» рәссам Эрот Зариповның хыялы аша төсмерләнеп иҗат ителгән. Чөнки әлеге кешенең — Рәфыйкның әтисе Габдерәүф Заһидуллинның — яшь чагы гына булган. Ул шул яшьлек чорында мәңгегә туктап калган...

1941 елның җәе...

Ошбу елның 5 январенда туган нәни Рәфыйкка ярты гына яшь...

Июньнең 22 сендә коточкыч хәбәр ишетелә:

— Немец сугыш башлаган!..

Аның әтисе — авыл Советы секретаре булып эшләүче Габдерәүф Гали улы Заһидуллин афәтнең беренче көннәрендә үк Ватан сугышына китә һәм ике елдан соң, 1943 елның май аенда, чит җирләрдә ятып кала. Яңа туган улын юньләп күрми дә башын сала. Шушы нарасыеннан бер тапкыр да «әттә» сүзен ишетми. Изге, кадерле, рәхәт сүзне. Ул сугышка киткәндә малайның әле теле ачылмаган була.

Мин икенче портретка текәләм...

Нигәдер ул ныграк тарта. Анда нииндидер сер-сихер бар димме...

Әгәр сугыш булмаса, әгәр Габдерәүф Заһидуллин сугыш кырларында ятып калмаса, менә нинди татарча мөлаем, түбәтәйле мәчет карты булыр иде. Ул менә шушындый карт булыр иде, ди рәссам. Җитәкче урында эшләүче улына, бәлки, үз киңәшләрен дә бирер иде. Җомга саен Толлыда салынган яңа мәчеткә намазга йөрер иде. Аннан кайткач, карчыгы Мәгъсүмә белән чүкердәшеп, олы кешеләргә хас булганча һәрнәрсәне искә алып, авыл хәбәрләрен хәтергә китереп чәй эчәр иде...

Эчәр иде...

Ул юк инде. Аны сугыш аждаһасы йоткан.

— Кырык бердә сугышка киткән әти менә шушындый яшь, таза кеше булган,— ди Рәфыйк уйчан гына.— Исән булса, хәзер менә мондый карт булыр иде. Бу арага 54 ел вакыт кергән. Минем әтисез яшәгән елларым бу...

Илле дүрт ел...

54 ел — Рәфыйк Рәүфовның 1941 дән 1995 елга кадәр үтелгән гомер озынлыгы, яшәгән еллары.

Ике рәсем арасындагы гомер бу...

## Кырык беренче ел балалары

**1945** елның ямьле җәе...

Рәфыйк инде 5 яшьлек бала.

Әнә сугыштан кайткан Толлы ирләре гимнастеркаларындагы орден-медальләрен елкылдатып, чыңлатып, Берлинны алганнан соң туган кәеф белән күкрәкләрен киереп урамда йөриләр. Ике фронтовик очраса, тәмәке кабызалар, сугыш хәлләрен искә алалар, йә берәрсенә кереп, чәркәгә салып, аракы эчәләр. Аларга эчәргә дә ярый. Алар — Җиңүчеләр!

Менә бер бала әтисенә дәшә:

— Әти! Әтием дим, әни ашарга чакыра...

Рәфыйкның күзләренә мөлдерәп яшьләр килә. Аларда атасыз үскән ятимнәр сагышы. Аның әле бер генә тапкыр да:

— Әти! Әтием!! — дип әйткәне юк. Чөнки әтисе юк. Ул бар иде, хәзер менә юк та юк. Нигәдер кайтмый. Нигә икән?

Малай аптырагач әнисенә дәшә:

— Әнием, безнең әти кайчан кайта инде?! Минем дә иптәшләрем кебек аңа әти дип әйтәсем килә бит...

— Кайтыр, улым, кайтыр... Тагы бераз гына көтик әле,— ди әнисе. Ә үзе күз яшьләрен күрсәтмәскә тырыша, читкә борылып аларны яулык очы белән сөртеп ала.

Әнә шулай улын әтисенең исәнлегенә ышандыра торгач, үзендә дә өмет уяна:
— Бәлки, чыннан да, кайтыр...
Кайтсын иде: улына ата, аңа ир кирәк ич. Би-и-ик кирәк!
Рәфыйк та бераз тынычлана:
— Әтисе кайтачак! Әнисе шулай дип тора ич. Ә әниләр балаларына ялган сөйләмиләр. Алар үз балаларын алдарга тиеш түгелләр...
Күтәп-күтәп тә әтисе күренмәгәч, ул әлеге сорауны тагын әнисенә бирәчәк. Бирмәс иде, ятимлек сиздерә үзен. Ул күзләре аша карап тора. Ул кигән өс-башта, ашаган ризыкта да нык сизелә. И ятимлек...
Үзләреннән биш чакрымдагы Түбән Шөн мәктәбендә укыганда да күрә ул үзе кебек ятимнәрне. Толлыда да алар шактый иде.
Бөек Җиңүгә 50 ел тулу алдыннан туган авылында галим Фоат Галимуллин, җырчы Миңгол Галиев белән очрашкач та, әлеге яшьтәшләренә ул эчтән генә:
— Без — кырык беренче ел балалары...— дип дәшәчәк. Нәкъ Мөхәммәт Мәһдиевчә.
Аларның да әтиләре яуда калган. Башкача ничек дәшсен — өчесе дә кырык беренче елгылар ич. Авыр килде аларга бу дөньяда, сабыйлык чорына сагышлы-кайгылы үрмәгәл чорналган иде.
Әтисезләр бит алар. Ә әтисез кеше тәтисез кеше генә түгел, ятим вә ким кеше. Ләкин шунысы да бар, андыйлар яшьтән үк тормышка берегеп үсә, үз максатларына үҗәтләнеп ирешә. Болар инде кемнеңдер таяныр таза җилкәсен, ярдәмгә дип сузган «йонлач кулын» эзләп маташмыйлар, ә юлны үзләренә үзләре яралар. Нинди генә авырлыклар килмәсен һәм иң зур каршылыкларга очрасалар да — һаман алга баралар, тауга үрмәлиләр.



**Рәсемдә:** Рәфыйк Рәуфов *(уртада)* үзенең якын дуслары — әдип Мәгъсум ага Насыйбуллин *(уңда)*, Татарстанның халык артисты, җырчы Миңгол Галиев һәм әдәбият галиме, язучы Фоат Галимуллин белән.

## Туган йортта уянулар

И Туган Йорт!
Иң изге почмак. Һәр бәндәнең Тән-Җан-Рухы мәңгегә оялаган гомерлек мәчет син.
Сиңа кайтып керүләр...
Балаларың Әлфия, Лилия, Марсельнең шат йөзен күрүләр.
Әниеңнең олы ашы, Бәриянең җылы карашы. И гомер — искән җил! Миңа да 54 бит. Әнигә әнә 89 яшь инде. Бәрия хәзер аны карый. Ипиен дә кулына тоттырып ашата.

Ә элек?.. Дүрт яшьлек Рәфыйк йокысыннан уяна:
— Әни! Әнием!!
— Әү, улым...
— Ашарга бир!
— Бераз гына көт. Аз гына соңыннан...
Адәм баласы шундый: ул көненә юк дигәндә өч тапкыр ашарга тиеш. Бармы-юкмы дип ашказаны сорап тормый, вакыты җиттеме:
— Давай, давай! — дип тарткалый.
Син ул «аш капчыгы»н тутырырга тиешсең. Келәттәге капчыгында, ларында бер генә кисәк сохари булмаса да.
Әй, ул көннәрне. Дүрт яшьтәге тамак бик үк истә калмаган, ә менә җәяүләп 5 чакрымдагы Түбән Шөн мәктәбенә укырга йөргәндәге тамак гел истә. Зур Тамак иде ул, Олы Тамак. Зурлыгы шуннан — һәрвакыт ач иде. Эчне кисеп үзен туктаусыз искә төшереп торды.
Кышкы юл...
Кысылган корсаклы тәнне суык өтә. Өстә юка чалбар, тишек фуфайка. Мәктәпкә көн саен йөреп укулар. Салкын көннәрдә ничек туңмаган, катып үлмәгән. Рәфыйк моңа хәзер үзе дә аптырый. Белем эстәүләр әнә шулай гел дә ачлык-ялангачлык белән бер арба-чанада барды... Кайчак йокыдан торасы килми. Уянасы килми...

...«Яна тормыш» арендачылар берлеге рәисе, 54 яшьлек Рәфыйк Габдерәүф улы Рәүфов йокысыннан уянды:
— Сәгать ничә микән?
Хәер, карап та торасы юк. Иртәнге биш булырга тиеш. Егерме ел колхоз председателе булып эшләү дәверендә аның организмы — баш мие һәм йөрәге — үзе үк җанлы сәгатькә әйләнде. Кичтән сәгать ничәдә генә ятмасын — иртәрәкме, йә бик соңмы — күңел сәгате биш тулуга әтәч булып кычкыра:
— Кикрикүк! Сәгать биш, тор, Рәфыйк!! Эшкә барасың бар...
Ике дистә ел инде туган йортта шундый уянулар.
...Төннәрен укып ятарга ярата ул. «Казан утлары», «Идел» һәм башка журналларны, Ә. Еники, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, Н. Фәттах, М. Юныс, Р. Мөхәммәдиев, М. Галиев һәм башка язучыларны.
Бүген төнлә Мөхәммәт Мәһдиевнең сугыш чоры яшүсмерләре турындагы юмористик повестен укып ятты. Кычкырып көлә-көлә. Шул мәлдә хатыны Бәрия уянып китте:
— Юләрләндеңме әллә, Рәфыйк? Төнге бердә кычкырып көлеп ятмасаң...
— Мәле! — дип китапны суза ул Бәриясенә.— Менә бу төшен генә укып кара. Билләһи, син дә кычкырып көләрсең. Кызык ич! Әйбәт яза!!!
Ә иртәгә ул нәкъ биштә уяначак. Дүрт кенә сәгать йокы туйдырган булса да. Янгырмы яисә кармы, буранмы, әллә давылмы — ул үз постында. Анда аны кешеләр көтә.
Иртүк гадәте буенча машина-трактор паркын, фермаларны карап чыгар.
Их!
Бүгенге машина-тракторларны әтисенә, бабалары Заһидулла, Гали, Мөхәммәдиләргә күрсәтергә иде. Никме? Чөнки утызынчы еллар башында, Түбән Шөнгә кайткан беренче тракторны күрү өчен! — алар авылы белән кубарылган кешеләр ич. Ләкин...
Фани Дөньяларда яшәүче инсаннарга көн дә иртәнге уянулар булса да, мәңгелек йортта уянулар юк шул инде...

## Толлы тракторга шаккаткан!

Әле Түбән Шөн мәктәбендә укыган чакта ук Толлыдан йөреп укучы балаларны түбәншөнлеләр горур гына күкрәк киереп:
— Толлы тракторга шаккаткан! — дип үчеклиләр иде.
30 нчы еллар башы...
Күрше авылда яшәүче абыйлы-энеле Бәдыгетдин һәм Шаһабетдин Шәрәфетдиновлар Түбән Шөнгә беренче трактор алып кайталар. Шушы тракторның кырда эшләвен күргән Толлы кешесе, янгын чыккандай, авылына йөгерә:
— Иптәшләр! Авылдашлар, Шөннәр трактор алып кайтканнар. Пәри күк эшли менә. Берүзе ун атка тора!

Шаккатмалы хәл була бу. Барлык Толлы кешеләре кубарылып трактор күрергә чаба. Шундый кызу төшәләр ки,— артларыннан шайтан туе узгандай, албасты үзе күтәргәндәй, кара тузан болыты пәйда була. Хәтта Шөн ягы кешеләре:

— Нәрсә, сугыш чыкканмы әллә? Яисә берәр җирдә әкәмәт зур янгынмы?— дип куркуга төшәләр.

Шөкер, юк икән!

Толлы халкы трактор күрергә төшкән. Менә шунда түбәншөнлеләрнең бер җор теллесе әре генә әйтеп куя да инде:

— Толлы тракторга шаккаткан! Күргәннәре юктыр...

Шулай итеп, «Толлы тракторга шаккаткан» боларга бер гыйбарә тамга булып тагылып кала. Бу әйтемнең бүгенге көнгә кадәр югалганы юк. Ул — халык телендә.

Хәер, алай дисәң, Толлы бүген дә тракторга «шакката». Әнә җитәкчеләре Рәфыйк Рәүфов үзе дә тракторга «шаккатты» ич! Ул колхоз рәисе булып эшли башлаганда бер җиңел, алты йөк машинасы һәм унике трактор була. Күбесе ярым-йорты, ватык, тузган. Саны да шаккатмалы түгел. Менә шул вакыттан ул техниканы арттыра башлый: яңа машина, трактор, комбайннар сатып ала «Яңа тормыш». Бүгенге көндә монда 13 комбайн; 31 автомашина, тәгәрмәчле һәм чылбырлы утыз җиде трактор бар. 276 хуҗалыгы булган өч авыл өчен аз сан түгел бу. Барлыгы 81 данә бит. Өч йортка бер машина-трактор туры килә дигән сүз. Шул чама. Бабайларның бу төшенә дә кермәгән. Бер тракторга шаккаткан кешеләр ич алар.

## 16 йортка кунган кызыл әтәч

**1991** елның эссе җәе иде...

Авыл халкы бары да эштә. Өйдә карт-карчыклар, ә урамда бала-чагалар. Менә берзаман эссе авыл урамнарын өшетеп яман шомлы хәбәр узды:

— По-жа-ар! Түбән оч яна!!

Моны урамда уйнаучы балалар кычкырды булса кирәк. Көне дә җилле иде, янгын ничек һәм кемнән башлангандыр, күрми дә калдылар, халык җыелып сүндерергә өлгергәнче, кызыл әтәч 16 йортка очып кунды. Ике-өч сәгатьтән алардан кара күмер генә торып калды.

Йортлар янган күп кенә кешеләрнең өстендәге күлмәкләреннән башка берниләре дә калмады. Хатын-кызлар елаштылар, ирләр йөзенә кара иңде. Бала-чагалар моңсуланды.

Бу коточкыч күренеш, кара күмергә әйләнгән йорт, каралты-кура урыннарын күрү җитәкчеләре Рәфыйк Рәүфовка да нык тәэсир итте. Алар колхозында семинар уздырырга гына йөриләр иде бит. Менә сиңа, мә! Авылда кара күмерле кара кайгы.

Рәис башта ни әйтергә дә белмәде. Ул болай да һәрнәрсәне ныклап күңеленә алучан, кеше кайгысына керүчән кеше бит. Ләкин шушы иң авыр вакытта да авылдашлары алдында халык көткән кирәкле, өметне сүндерми, ышаныч тудыра торган сүзләрне әйтергә аның теле җитте:

— Бик яман хәл бу. Сездән бернәрсә генә сорыйм: зинһар, кара кайгыга бирелмәгез. Кышка кадәр барыгыз да өйле, каралты-куралы булыр. Мин моны сезнең җитәкчегез буларак әйтәм. Әйтәм генә түгел — вәгъдә бирәм!

Вәгъдә — иман, ди.

Халык Рәфыйкка ышана иде. Аны горурланып:

— Безнең Рәфыйк! — дип кенә атый иде.

Бу юлы да аңа ышанды һәм моның белән ялгышмады — көзгә барысы да йортлы, каралты-куралы булдылар.

Әлбәттә, Кукмара районы, Казан каласы да булышты. Югарырак утыручы җитәкчеләр дә читтә калмадылар.

Шунысын да өстик: бу янгын Толлы, Чарлы янгынчылар командасына да ачы сабак булды. Хәзер алар янгынга каршы тәртипләрне нык саклау өстенә, ифрат активлык һәм житезлек күрсәтеп башка урында, чит авылларда башланган янгынны сүндерү өчен дә иң беренчеләрдән булып килеп җитәләр. Әнә Шөн якларындагы ничәмә-ничә янгынны сүндерүдә катнаштылар. Инженер Мулланур Мөхәммәтов җитәкчелек иткән янгынчылар Марсель Кавиев, Рафаэль Ибраһи-

мов, Виктор Харжавин, «хуҗа»ның каты кулын, ныклы күзәтүен тоеп яшиләр. Чөнки бу мәсьәләдә башкача мөмкин түгел. «Кызыл әтәч» тәртипсезлекне сөйми ул.

## Көзге Сабантуй

Җәй башында янгын утлы теле белән 16 йортны ялап чыккач, тиешле вакытында Сабантуй уздырмадылар. Уналты гаилә кайгыда калып, туганнарында-якыннарында яшәп ятканда, ничек бәйрәм итеп, мәҗлесләп, күңел ачып йөрергә, ди. Менә, Алла бирсә...

...Әйе, җәйге Сабантуйлар бар, хәтта кичке һәм кышкы Сабантуйлар да була. Ә менә «Яңа тормыш» арендачылар берлеге рәисе шушы изге, саф, ак, бөек бәйрәмнең ике мең еллык тарихында беренче тапкыр көзге Сабантуй ясады. Ясарлыгы да бар иде шул: өйләре янып беткән 16 гаилә әр-яңа коттедж-йортларга кереп утырды. Авылның түбән очы элеккедән дә матурланды. Ә Сабантуйлар, гадәттә, түбән очта, инеш буенда уза.

Ямьле яшел чирәмлеккә каршы таулар ята. Гүя алар төньяк җилләрен каплау өчен аягүрә басканнар. Инеш буйлап китсәң, аның сулары сине гүзәл Нократ-Вяткага китерер. Күңелле урын бу!

Көзге Сабантуйга ул елны халык җыелды да соң инде! Ник дигәндә, елның иң-иң-иң соңгы Сабантуе ич. Сатучылар да ничәмә-ничә машиналарда килгәннәр. Бер читтә шашлык пешереп яталар, икенче урында көнбагыш саталар. Тәмтомның кайсын яратасың — сайла да ал. Пилмәнгә кадәр пешерделәр монда.

Гөрләде Сабантуй: халык көлде-сөенде, җырлады-биеде. Ир-егетләр бил алышты.

Һәркемнең йөзендә шатлыклы елмаю иде һәм аның иң кәттәсе Рәфыйк Рәуфов күзләрендә чагылды кебек.

Ә нигә шатланмаска ди?

Халыкка биргән вәгъдәсен үтәде бит: йортлы да булдылар, бәйрәмне дә уздырдылар. Үзләре генә түгел, моны читтән килгәннәр дә күрделәр. Кешеләргә килгән кара кайгыны күңелләреннән юып төшереп, ак-чиста Сабантуй уздыруны күрделәр. Ә адәм балаларын сөендерүдән дә олы шатлык Җир йөзендә юктыр!

Кайгыда ташлама кешене...

## Чарлы ярлы түгел...

Чарлы — рус авылы.

Зурлыгы ягыннан Толлыдан калышса да, аны «Яңа тормыш»ның үзәк усадьбасы иткәннәр. «Ни өчен? Чөнки 80 нче еллар башында Чарлы яшьләре Кукмара һәм бигрәк тә алардан ерак урнашмаган Вятские Поляны шәһәренә китә башлыйлар. Авылда карт-коры гына кала. Колхоз җитәкчелеге, бигрәк тә рәисләре Рәфыйк Рәуфов өчен зур проблема була бу:

— Ничек яшьләрнең читкә китүен туктатырга?? Чарлының ярлыланып һәм искереп баруына ничек чик куярга???

Уйлый торгач, проблеманы чишү юлын таба ул — бу авылны үзәк усадьба итәргә! Гадәттә, рус авылында кешеләр соңгы 15—20 елда шәһәргә күчеп беттеләр диярлек, ә менә «Яңа тормыш»та рус авылы Чарлы, киресенчә: үсеп-яшәреп китте.

— Татарларда японнарга хас үҗәтлек, эшчәнлек, тырышлык бар,— ди Рәуфов.— Әгәр Россия татарлардан гына торса, күптән череп баеп бетер иде инде. Безнең Толлы кешеләре элек-электән Чарлыны өстерәп-тартып барды. Бу авылга килеп эшлиләр иде. Ләкин мин рус халкын да «лапошник», «русская лень» сүзләре белән характерламас идем. Бик тырыш руслар да бар. Әнә Чарлыга караш үзгәргәч, эштә яңа тәртипләр, икенчерәк система керткәч, чарлылылар үзләре Толлыга эшкә киләләр. Комбайнчыларның күбесе Чарлыдан. Җир җимертеп эшлиләр, шуңа бай торалар...»

Чарлыда менә дигән унъеллык мәктәп, кибет, балалар бакчасы, ашханә төзелде, матур гына мәдәният йорты эшләнде. Руслар гына яшәми хәзер Чарлыда: мәктәп белән югары белемле Рәфәгать Гайнуллин җитәкчелек итә, мәдәният йортында Зөбәрә Мөхәммәтова директор. Әлеге биналарны салу өчен Рәфыйк Рәуфов бик тырышып йөргән, аңа юкка гына Россиянең һәм Татарстанның халык мәгарифе отличнигы исемен бирмәгәннәр.

Үз авылында түгел, күрше рус авылында үзәк усадьба ясау үзе үк батырлык, минемчә. Эш өчен яну бу. Эшче көчләрне читләштермәскә теләү. Татарның урыс авылын күтәрүе. Текә күтәрүе.

Гомумән, Чарлыны яңарту, баету, «бабайлар» авылыннан яшьләр һәм малайлар саласына әйләндерүдә рәиснең көче күп керде дип әйтәләр монда.

Ә халык хагын әйтә ул!

## Идарә йорты

Театр кием элгеченнән башлана, диләр. Ә авыл хуҗалыгы оешмалары эше — идарәдән. Дөресрәге, идарә йортыннан. Анда тәртип икән — башка җирдә дә тәртип.

Беренче күрүгә үк бу агач бина үзенең матурлыгы, гадилеге, җыйнаклыгы вә төзеклеге белән үзенә тартып тора. Алдында зур гына бакча. Анда тупыл, ак чыршы, юкә агачлары. Алмагачлар, карлыганнар да бар бирედә. Җиргә әнә тупырдап алмалар коелган. Бер читтәрәк түбәсе буялган кое, кечкенә беседка, бакча түрендә фонтаннар.

Матур монда, рәхәт монда!

Кошлар сайрый, бал кортлары гөжләп тора.

Минем үземә ошаганнардан тагы күрсәткечләр тактасы һәм Җиңүнең 50 еллыгына багышланган стендлар булды. Солдат һәйкәле янындагы мәрмәр ташлардан Богомолов, Кормильцев, Козлов, Котов, Колесников, Соловьев, Семагин, Староверов, Селезнев, Савиков, Пичугин, Харжавин, Шахмаев, Якунин һәм башка дистәләрчә фамилияләрне укыдым. Ватан сугышы корбаннары болар. Хәзер әнә аларның уллары-оныклары «Яңа тормыш»та әйбәт кенә эшләп көн күреп яталар.

Идарә йорты янындагы бакчада «Мактау тактасы» булу — үзе үк мактаулы күренеш. Хәзер тырыш хезмәт итүчеләрне бик үк мактап бетермиләр. Ә мондагы «такта»да алдынгыларның рәсемнәре урнаштырылган.

Менә алар: дуңгыз карауччы Сания Зарипова, дуңгыз балалатучылар Анна Григорьева һәм Фәнүзә Шәрәфетдинова, шофер Владимир Шахмаев, комбайнчы Валерий Котов, тракторчы Сергей Карлушин, шофер Данил Миннеханов, механизатор Флюр Миннеханов, Т-150 дә эшләүче Фердинанд Сәетгәрәев, бензин ташучы Вәгыйз Кавиев. Барлыгы 14 кеше.

Татар-керәшен егете рәссам Виктор Кириллов стендларны гел яңартып тора икән. «Иренми ул»,— диләр аның турында. Иреккән — иркә ялкауны Рәфыйк Рәүфов тотып та тормас иде.

Идарә йорты тирәсендә чисталык һәм тәртип. Тирә-як асфальтланган. Ишек төбендә үк чүп-чар савыты. Кәгазь кисәген, тәмәке төпчекләрен ташлар өчен.

Шулай шул: хуҗалыктагы чын тәртип идарә йортыннан ук башлана һәм ул башка эш биналарына да күчә. Авылларда-колхозларда шактый йөргән кеше буларак, үзем моңа нык инанган кеше. Ә тәҗрибә сирәк алдый. Үзе күргән — хакны күргән.

Тәртипнең идарә йортыннан башлануын рәис Рәүфов та тиз аңлаган, күрәсең.

## Баш экономист Мансур Хәсәнов

«Яңа тормыш»тагы соңгы 15—20, хәтта 30—40 елдагы җитештерү күрсәткечләре белән яхшылап танышу өчен берлек рәисе миңа баш экономист Мансур Хәсән улы Хәсәновны тәкъдим итте. Ул көнне Рәүфов Кукмарага җыелышка ашыга иде. Хакимият башлыгы Мөхәммәт Хәбибулла улы Гатиятуллин аларны «срочно» җыя икән.

— Менә минем соңгы егерме елда кочаклашып-талашып эшләгән дустым-дошманым шушы инде,— дип көлде Рәфыйк. Юмор хисе бар икән үзендә, дип уйлап куйдым.

— Булды инде төрле чаклар. Эш өчен бит, үзебез өчен түгел,— диде Хәсәнов, тыйнак кына елмаеп.

Алар икесе дә бер яшьләрдә, Түбән Шөн мәктәбендә дә бер чорларда укыганнар. 1958—59 уку елында мәктәпне тәмамлап чыкканнар.

Мансур Хәсәнов чандыр гәүдәле, ап-ак чәчле, сөйкемле кеше. Үз эшен белеп, кабаланмый гына алып бара. Һәр сүзендә-хәрәкәтендә үз-үзенә ышанганлык, тәҗрибәгә ия булу сизелә.

Калын кашлы Ильич, икенче «юлбашчы»быз кайчандыр:

— «Экономика должна быть экономной»,— дип үзенчә шәп кенә бер фикергыйбарә, тәгъбир-әйтем ычкындырган иде. Яисә экономика сүзен каламбурлап тел осталары язып биргәннәрме шунда. Хагын әйтик, бу сүзләрдән соңыннан көлебрәк йөрсәк тә, аларда дөреслек ятмый дияргә тел бармый. Экономияле булу — байлыкка туры юл. Әнә, немецларны яисә японнарны гына ал. Алар агач ботагын да, хәтта пычкы чүбен дә әрәм-шәрәм итми!

Бүгенге көнне теләсә кайсы житештерү берлегендә-оешмасында, завод-фабрикаларда экономистлар теге яисә бу нәрсә эшләп чыгаруның файда-табыш, зыян-чыгымын алдан ук чутлап куярга тиешләр. Ялганламыйча! Ялгыштың — банкротлык. Хаталандың — беттең, дигән сүз. Экономик яктан. Бар планнарың комнан ишкән бауга әйләнәчәк.

— Безнең «Яңа тормыш» соңгы ун ел эчендә текә сикереш ясады,— ди Мансур Хәсән улы.— Бигрәк тә соңгы 5-6 елда. Менә күршедәге Шөн яклары — Киров өлкәсендәге иң көчле хужалыкларның берсе булган XXII партсъезд исемендәге колхоз белән генә чагыштырып карыйк. Без бит — Кукмара районының Толлы, Бурсык, Ташлы Елга, Кәркәвеч авылы кешеләре — заманында Түбән Шөн мәктәбендә белем алдык һәм алардагы хәлне үз күзләребез белән күреп белә идек. Ни күрдекме? Без, Толлы кешеләре, Шөннекеләрдән бер ун елга артка калып бардык. Хәтта, әйтер идем, бер буынга диярлек. Бездә ярлы колхоз, аларда бай, председательләре Таһир Әхмәтович Галиәхмәтов 1970 елда ук Социалистик Хезмәт Герое исемен алган кеше. Аерма хәтта киемдә дә күренде: алар галош кигәндә — без чабата, без галош кигәндә — алар ботинка-туфлилы иде. Без жәяү йөрдек — алар велосипедта, без велосипедка утырганда — алар мотоциклда, безнекеләр мотоцикл ала башлаганда — алар «Москвич», «Жигули»да элдерәләр иде инде.

Хәтерлим: аларда ипи шәп пешә иде. Безнең хатыннар ипигә дип капчык күтәреп төшсәләр, болар бездән көләләр:

— Ә, Толлы хәерчеләре килгән! Сәхүәләр...

— Соң хәзер,—дим мин.— Киресенчә сөйлиләр ич бездә: кара-кара, бу Толлы ничек котайды, ә?! Без булып безне дә узды болар!!

— Юк,— дип сүземне тыйнак кына бүлә экономист Хәсәнов.— Хәзер без Шөннәр белән тигезләштек дип уйлыйм мин.

Бәлки шулайдыр да, кем белә...

Тик берәр нәрсә кирәк булса, йә акчага алырга, йә бартерга алмаштырырга дип безнең Шөн якларыннан монда киләләр. Һәрхәлдә, яңатормышлыларның нидер сорап безгә килгәннәре юк. Кирәген үзләре табалар. Үз районнарыннан яисә башка жирдән.

Байлар соранып-сорашып йөрергә яратмый шул.

## Игенчелектәге күтәрелеш

«Яңа тормыш» үзенең таулы-чокырлы басу-кырларында элек-электән бодай, арыш, арпа, солы, борчак, бәрәңге, кукуруз, чөгендер, карабодай, вика иккән.

Мансур Хәсәнов биргән таблицаларны карап утырганда, соңгы 10 елдагы уңыш алуда, чыннан да, текә күтәрелеш күрдем. Ә инде 30-40 ел элеккеге саннарга күз салсаң — аерма берничә мәртәбә тәшкил итә. Әйтик, 1958 елда арыш, арпа, бодай һәр гектардан 7-8 центнер, борчак 10 ц, бәрәңге 51 ц уңыш бирсә — узган елгы күрсәткечләр 4-5 мәртәбәгә артык: бөртеклеләр 35-40, ә бәрәңге 224 центнер жыеп алынган. Хәтта 80 нче еллар башында да бу саннар 10-15 тән артмый. Чөгендер 1958 елда 80 центнер алынса, 1994 елда 563 ц жыелган. Әле 5-10 еллар гына элек тә бу сан 200-300 дән югары түгел.

Инде быелгы корылыклы елда да уңыш алуда тотрыклылык сизелә. 1994 нең рекордлы күрсәткечләре һич тә кимемәгән, һәр гектардан 35 центнер бөртекләләр сугып алганнар. Ә бит күршедәге данлыклы Шөн якларында да бу күрсәткеч 23-25 тән артмый. Кырлар рәттән генә, ә уңыш аермасы — 10 центнер. Нидән бу?

— Сезнең як кырларын чүп басты,— дип аңлаткан иде миңа Рәуфов, УАЗик белән барганда.— Болай да Киров өлкәсе кырлары алабута, билчән, әремгә бик бай. Ә аларны урып-сугып бодай алып булмый. Мин үзебезнекен генә әйтмим, кара Татарстан басуларын, аларда чүп үләннәр юк, яисә чагыштырмача бик аз.

— Ә ашламалар кертү? Ансыз уңыш көтмә инде!

— Көч килгәнчә кертергә тырышабыз!

— Әле житәкчелекнең игътибары да бар бит сездә,— дим. Киров өлкәсендәге авыл-колхозларга карата Ельцин рухы сизелә. Ничек булдыра аласыз, шулай яшәгез, янәсе. Безне генә борчымагыз, безнең сездә эш юк...

— Килешәм. Президентыбыз да, авыл хуҗалыгы министры да йөзләре белән авылга борылган кешеләр. Бу — зур ышаныч тудыра, абзый!

Рәфыйк Рәуфовның, миннән биш яшькә зур булса да, «абзый» дип дәшүе күңелгә рәхәтлек өсти. Юк, картайтып, бабай иттереп әйтми ул «абзый»ны, ә якын итеп, хөрмәтләп, йөрәге белән дәшә!..

...Тагы кайтыйк әле «Яңа тормыш» басуларына! Кырларга чыгып китәм дисәң, машинасы да кул астында гына бит аның. Йөр, кара, күр!!! «Килдем-күрдем — сокланып йөрдем!» — дигән шикелле... Үзебезнең Шөн басулары белән чагыштырып карыйм. Безнең рәис Фоат Гарәфиев — Рәфыйкның сабакташы ич. Алар үзара ярышып яшиләр.

Без югары белемле агроном, «Яңа тормыш» арендачылар берлеге рәисе урынбасары Альфред Баһманов белән җиңел машинада басу-кырларны карап йөрибез.

— Менә бу кырдагы һәр гектардан 50 центнер ашлык суктырып алдык,— ди ул тыйнак кына. Гомумән, Толлы кешеләренең күбесе тыйнак, эчке культурага ия, үз тормышларында текә күтәрелеш ясасалар да, кешегә эре текәлеп, текәләнеп йөрмиләр.

Альфред әле утызның аръягына гына чыккан. Кара мыеклы, уртача төз гәүдәле, сөйкемле егет. Егет дигәч тә, аның балалары үсә инде: бер малай, бер кыз! Хатыны — Рәфыйк Рәуфовның олы кызы Әлфия, димәк, Альфредка хуҗалык рәисе «бабай» була. Ләкин монда ничә килеп тә, мин аның үз житәкчесенә «бабай» дип дәшкәнен ишетмәдем. Эш башка, аш башка дигәндәй, хезмәт урынында ул аңа «Хуҗа!» — дип дәшә, ә кунакта: «Бабай!» Ике сүз дә бик тәмле. Әйтә белеп һәм урынында, кирәкле вакытта әйткән кеше өчен.

— Дәүләткә сату планыгыз күпме? — дип сорыйм Альфредтан.

— Борчак — һәр гектар саен ике центнер, бодай — ун центнер. Бер тонна, димәк...

Күрәм: бу план үтәлер, ындыр табагында — тау-тау ашлык көшелләре ята.

Урылмаган-сугылмаган кырга кердек. Бу — бодай басуы. Яп-якты кыр. Алтын кояш нурлары астында саргаеп килгән башаклар күзгә кереп тора. Үзләре эре, тук. Кырда бер генә чүп үлән дә юк.

— Уракны август башына төгәллибез,— ди Баһманов.— Инде көзге чәчүгә жир әзерләп тә куйдык.

Арышны көз чәчү өчен жир әзерләнгән. Быел бу жиргә известь керткәннәр. «Туфракның әчелеге югары»,— ди Альфред.

Машина алга элдерә. Кукуруз басуына життек. Бу үсемлек тә хәйран гына үскән монда: үзләре озын, үзләре куе. Әле тагы үсәселәре бар. Яшел масса мул булачак малларга.

Кукуруз басуы Көмеш Нократ буенда да тирбәлә иде. Буйга кайтышрак булсалар да, мондагылары да ким-хур үсмәгән.

Вятка буйлап ком төягән баржа килә. Белмим, ни сәбәптәндер мин аңа алтын бодай гәрәбәләре төялгәндәй хис иттем.

Гүзәл елга ярына утырып ял иттек. Рәфыйк Рәуфов та бу урыннарда ял иткәләп китә икән. Йә урман буенда. Ярты гына сәгать. Хет ун гына минут. Бер кавымга дөнья мәшәкатьләреннән арынып тору өчен. Таугa менгәндә нәни генә булса да көч алу өчен. Яңа уйларны дөрес итеп туплар өчен.

Мин дә яраткан елгама күз салам. Аннан тәмәке кабызам, иркенәеп төтәтеп жибәрәм.

Чыннан да...

Матур яклар бу! Күңелгә рәхәт монда!!

## Дуслар җыелган җирдә

Сентябрь башы...

Искитмәле жылы көннәр. Бакчалардагы бәрәңгене казып чыгарып туфрак өстендә озаграк тотсаң — ул да пешә! Комга тыксаң, күкәй пешәрдәй кыздыра кояш. Эссе табага салып кыздырасы да түгел. Төш турысында 30-32 градус эсселек. Мондый жылы көзне әби-бабайлар да хәтерләми. Сәер сентябрь бу...

Без «Яңа тормыш»ка керә торган Плаксиха авылында. Ул кечкенә генә рус авылы. Элек, хәтерлим, Плаксиха урыслары Вяткадан балыкны шәп тоталар иде. Бу як урманнарда көзен чикләвек тә күп үсә. Капчыгы-капчыгы белән генә ташыган еллар да булды.

Без тагы гүзәл Нократ буенда. Аның ямь-яшел чирәмле ярында. Дуслар җыелган урында...

Без дигәнебез: Түбән Кама автотранспорт берләшмәсе начальнигы Хәлим Кави улы Мостафин, Кукмара катнаш азык заводы директоры Равил Гайфетдин улы Зиатдинов, Татарстанның атаклы фоторәссамы Мидхәт ага Шакирҗанов, публицист-язучы Шаһинур Мостафин һәм, ниһаять, әсәребез герое — Рәфыйк Рәүфов. Соңыннан безгә әлеге хуҗалыкның шефы — «Агропромбанкның» Кукмара бүлеге җитәкчесе Фәргат Нургата улы Сафин кушылды...



**Рәсемдә:** *(уңнан сулга):* Равил Зиатдинов, Рафаэль Сибат, Хәлим Мостафин, Рәфыйк Рәүфов, Шаһинур Мостафин.

Яшел чирәмгә зур гына ашъяулык җәелгән, аңа турап ипи, ит куелган. Табынны зурлап, йодрык-йодрык алмалар тәгәрәп ята. Шампан, сыра, баллысу шешәләре ятып тора. Хәл җыйган кебек...

Мәҗлестәшләр күтәренке рухта. Сөйләшәләр, көлешәләр. Ләкин...

Алданма, укучым! Юк, бу — син уйлаган вә үзенчә күз алдыңа китергән эчү мәҗлесе түгел. Бу — табигатьтә, Көмеш Нократ буенда көндезге эшләрдән соң бераз гына ял итеп алу. Рәис Рәүфов аракыны әнә авызына да алмый. Мидхәт ага кабып та карамый, теге ике зур «нәчәлник» та — Хәлим Мостафин белән Равил Зиатдинов — аңа мөкиббән китмиләр...

Утырабыз шулай сыра йотып, «Тархун» эчкәләп. Әлбәттә, тавык итен дә капкалыйбыз. Кичке ашка вакыт җиткән инде. Рәфыйк Рәүфов, әнә, ит консервасы да ача. Әйе, тамак ачкан! Шуңа карамастан авыз күбрәк сөйләшү белән мәшгуль. Кешеләре нинди бит әле аның: укымышлы, эрудицияле, интеллектуаль инсаннар. Һәр темага матур гәп алып бара алалар, һәр тема буенча иркен йөзгәннәре сизелә. Арага мәзәк кыстырып алырга да күп сорамыйлар. Бу өлкәдә Хәлим Мостафин белән Мидхәт ага Шакирҗанов бигрәк тә җор кешеләр икән.

Хәлим Мостафин — тумышы белән шушы яклар кешесе. Рәфыйк Рәүфов белән бер чорда Түбән Шөн мәктәбендә укып та йөргән. Алар — күптәнге дуслар.

Татарларга хас кара күзле, кара чәчле, матур кыяфәтле Хәлим үз тормышыннан бер хәлне сөйләп көлдерә:

— Барабыз шулай минем «оппель»дә асфальт буйлап. Юлыбыз асфальтсыз эре-эре генә яткан урынга терәлде. Нишлисең, алга барырга кирәк, тик менә ташлар машина астына тия. Кабинада апам, хатыным, тагы ике хатын-кыз. Әйдәгез, дим боларга, әгәр теләгән авылыгызга барып җитәсегез килсә, юлдан ташны чүпләгез, шунсыз алга бару юк. Чыктылар мескеннәрем дүртәүләп, и җыялар ташны, и җыялар! Мин дә булышам инде, кәнишне. Иртәгәсен Түбән

Камада сөйлиләр икән: Мостафинның «оппеле» үтә алмагач, фәлән колхоз председателе бер бригада хатын-кызлар куйдырып юлны чистарттырган, имеш...

Көлешәбез...

Билләһи, рәхәт менә шушындый кешеләр белән сөйләшеп утыру! Бер утыруың — бер гомер, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер...

Озынча буйлы, зәңгәр күзле, сөйкемле кеше Равил Зиатдинов сөйләп китә:

— Казагыстанга баргач, безнең Президент Шәймиевне татарларның күрәсе килгән. Җансакчылары моңа очрашуга бармаска кушканнар, озатып йөрүче Сарыбай Сабирович та программаны үзгәртәсе килмәгән. Ә теге татарлар бит Кытайның үзеннән Казагыстанга кайтып тирмә корганнар. Күңелен күргән Президент боларның, тәки тирмәгә кергән. Кергән генә түгел, утырып чәй дә эчкәннәр. Хәтта бер агайның тальянына кушылып: «Сандугач... Китмә, китмә, сандугач...» — дип җырлап та җибәргәннәр.

— Менә ничек була ул киң күңеллелек! — ди Рәфыйк Рәүфов. — Укыдым мин бу турыда. «Ватаным Татарстан» газетасында язучы Ринат Мөхәммәдиевнең «Абай иленә сәяхәт» дигән язмасы чыкты...

Сөйләшү дәвам итә, тема артыннан тема үзгәрә, мәсьәлә дингә күчә. Ифрат та сабыр, зыялы кыяфәтле, фәлсәфи фикерле, туры сүзле Мидхәт ага Шакирҗанов әйтә:

— Бутамагыз, иптәшләр, дин — әхлак кына түгел. Мораль — мораль инде ул. Дин бик тирән нәрсә. Ул халыкны рухи тәрбияләү яисә тәртипле, чиста, пакь тоту өчен генә кирәк диючеләр аны беркатлы гына аңлыйлар. Дин дөньяны аңлау өчен иң көчле тәгълимат! Бәлки ул, чыннан да, галәмне, дөньяны ныклап ачу өчен чын күпер булыр...

Сүз авылларга күчә...

«Яңа тормыш»та бәрәңгене алып та бетергәннәр инде. Шулай тиз!? Һәр гектар 300-320 центнер уңыш биргән. Күршеләрдә бу күрсәткеч: 150—160 центнер. Бәрәңге алуны тәмамлау шатлыгыннан Рәфыйк Рәүфов дуслары белән Вятка буенда ял итеп, сөйләшеп утырырга булган.

Хәлим Мостафин туган авылы Казакларның (Югары Өскебаш) тарихы турында сөйли:

— Безнең иске зиратта 1360 ел белән тамгаланган кабер ташы да булган бит. Үзем дә аны күрдем, белгән кешеләрдән язуын укыттым. Гаҗәп бит, ә?! Значит, авылга нигез салган кеше дип исәпләнгән Сөләйман казакка кадәрле дә анда кешеләр яшәгәннәр булып чыга.

— 1360 ел Болгар чорына карый. Казан ханлыгы бу вакытта оешмаган әле,— дим.

— Рәхмәт сиңа, Хәлим! — ди Мидхәт ага. — Син бит эшең буенча чып-чын технарь, металл йөрәкле кеше, 1200 (мең ике йөз!) машинага хуҗа адәм. Ә җаның белән шагыйрь икәнсең. Үз авылының тарихы белән кызыксынган кеше — саф милләт кешесе ул...

— Нәкъ безнең Рәүфович кебек! — ди Шаһинур.

— Әйе, без дә Толлы тарихын язарга булдык әле,— ди рәис Рәүфов тыйнак кына. — Мәмәширдәге журналист һәм тарихчы Нур Шәрифуллинны чакырдык. Инде үз авылы турында язган иде...

— Ул килер дә, берәр атна сорашып-сөйләшеп йөрер дә, аннан авыл тарихын язар. Ләкин бу чын тарих булмас! — дип каршы төшә Равил Зиатдинов.

— Сүзеңдә дөреслек бар, абзый,— ди Рәфыйк Рәүфов. — Ләкин һәр эшне башлап җибәрергә кирәк бит. Башы булса — ахыры булачак. Эх! Элеккеге муллаларның язмаларын саклап кала алмадык. Алар бит барысын да язып барганнар...

Сүз ничектер кабат дингә әйләнеп кайта. Ә мин эчемнән генә уйлыйм:

— Йә, Аллам! Шушындый матур кичтә шушындый яхшы бәндәләрең белән очраштырган өчен мең дога — мең рәхмәт сиңа!!!

Сентябрь башы — көз башы.

Нократ ярында, дуслар җыелган урында утыручыларның да гомер көзе башы. Алар төпле, акыллы, уйчан, тормышчан, яшәүчән, милләтчел инсаннар. Яраттым мин аларны!!

Түбән Шөнгә мине үз машинасында Рәфыйк Рәүфовнең улы Марсель озата. «Сез» дип әдәби тел беләнрәк сөйләшүче егет. Әтисе кебек таза гәүдәле, матур сөякле, тыйнак, сабыр егет.

Без экономистлар бүлмәсендә.

Мансур Хәсәнов сөйләп китә:

— Элек ничек иде? Безгә һәрнәрсәне диярлек көчләп тактылар. Батамы ул безнең хуҗалыкка, юкмы — аны уйлап тору юк. Көчләреннән килсә, дөя яисә фил асратырлар иде. Ә бу дөя бөлгенлеккә төшермиме — уйлап баш ватмадылар...

— Шәхси хуҗалыкта, мәсәлән, безнең якларда юләр дә дөя асрамас! — дип куям.

— Ә бит булды вакытлар, — ди Хәсәнов. — Безне көчләп песец ак төлке, куяннар асрарга мәҗбүр иттеләр. Бары файдасын гына күрмәдек. Ә зыяны кыя кадәр!

— Төлке шулпасы булган икән...

— Нәрсә-нәрсә?

— Алдаганнар сезне! Алдау-хәйләләүне, «төлке шулпасы эчү» дип атыйлар...

— Вәт-вәт, алдандык шул. Хет Толлы, Чарлы хатыннарына ак төлке туны да кидерә алмадык. Кая ул! Әйтәм ич, зыянның зыяннан башка ние бар?

— Аның каравы — хәзер ирек!

— Әйе, хәзер менә ирек, кайсы малны тотасын, кайсы терлекне асрыйсын үзебез чамалыйбыз. Ә чамалау табыш буенча. Табыш китерә икән — асра, юк икән — юк ит ул малны. Иткә чал!

...Терлекчелектәге хәлләр дә һич яманларлык түгел монда. Киресенчә, мактанырлык. Әнә Мансур Хәсәнов саннар китерә. Экономистлар теле — саннар инде ул, саннар һәм санау теле. Ләкин болар үле цифрлар гына түгел, ә тере саннар.

Экономистлар лирикага бирелеп маташмый. Хәсәнов саннарны, муенсага энҗе кидергәндәй, тезә генә. Һәрхәлдә, алдагы еллар белән чагыштырганда үсеш күзгә нык ташлана. Дөрес, 1994 елда терлекләр саны кими төшкән, ләкин арендачылар берлеге җитәкчеләре моны алга таба төзәтерлек хәл дип саныйлар.

«Яңа тормыш»та һәр сыердан елына 5000-5500 литр сөт савалар. Мөгезле эре терлектән артымны уртача 700-800, ә дуңгызлардан 500-600 граммга җиткергәннәр.

Терлекчелектә төп файда китерә торган тармак — дуңгызчылык.

— Татар авылларында дуңгыз асрау килешми. Дин буенча да хәрәм санала, — дим, сүз кыстырып.

— Беләм-беләм... Милләтчеләр җырын җырлыйсың, — ди моңа каршы Мансур Хәсәнов. — Кискен, ультрарадикаль милләтчеләр моны күтәреп чыкты. Аларның төп ялгышлары: икътисадны аңламауда яисә санга сукмауда. Коры сәясәт тамак туйдырмый. Гәҗит укыйбыз, радио тыңлыйбыз, телевизор карыйбыз: шуңа барын да, шөкер, ишетеп, күреп, белеп торабыз. Казаннан яисә Чаллыдан торып милләтне ничек яшәргә өйрәтү җиңел нәрсә ул. Ә менә авыл халкына, шул милләттәшләргә, ай саен хезмәт хакын ничек биреп барырга? Монда безне дуңгызчылык, кемнәрдер сүккән Дуңгыз Бабай коткара. Кемдер сүгә дип кенә ифрат файдалы тармакка балта чабып булмый...

Кызарак төшкән Хәсәновны туктатам:

— Соң сезнең дуңгыз фермалары да Чарлыда гына бугай. Толлыда сыерлар бит. Рәфыйк Габдерәүфович әйткәнчә: «Татарга — сыер, урыска — дуңгыз» түгелме? Һәркемгә — үз малы!

— Дөрес шул, — дип куя Хәсәнов тагы тыйнак кына. — Дуңгызчылык буенча рус авылы Чарлы специальләште, ә сөтчелек буенча — Татар Тулбасы. Дуңгызны мактавым аны яратудан түгел, ә файдалы, тиз үрчемле, күп итле хайван булуыннан. Шул дуңгыз безгә ай саен хезмәт хакы тоттыра. Ә менә күршеләрдә февраль аеннан бирле акча ала алмыйлар инде. Ай саен хезмәт хакы түләп бару — Татарстан авылларында да сирәк күренеш хәзер. Кем хәзер айныкын айга бирүе белән мактана ала? Без!!!

Юк, мин бу сүзләрдә мактану сизмәдем. Фактларны җәеп салу гына иде бу. Тагы... Күпмедер горурлык.

— Ә аена күпме түлисез соң? — дип сорыйм.

— Савымчылар уртача — 320 мең, бозау караучылар 290, дуңгыз симертүчеләр 280 мең хезмәт хакы алалар.

— Иң күп акчаны кемнәр эшли?

— Механизаторлар. Алар 500-550 мең алалар...

— Алардан да күп эшләүчеләр бармы?
— Бар, ник булмасын. Төзелештә эшләүчеләр 600-700 меңгә кадәр куалар.

## Төзелеш, көнкүреш һәм яшьләр

Кайсы авылда яшьләр калалар?
Әлбәттә, гөрләп төзелеш барган, мәдәният-көнкүреш биналары балкып кына тормыйча, аларда дөрләп эш барган урыннарда. Яшьләр гөрләү белән дөрләүне якын күрә, аларның җаны пыскуны кабул итми.

Чарлы турында әйткән идек инде. Толлыда да яшьләр авылдан читкә таю ягын карамый хәзер. «Яңа тормыш»тагы йортлар инде өч ел газ ягалар. Уңайлы һәм җайлы. Кышның иң суыгында да бер үк температура. Утын кисеп интегәсе түгел. Өй өче дә чиста-пөхтә тора.

Урта мәктәп, мәдәният йорты, клуб эшләү өстенә, ике авылда да «Акчәчәк» һәм «Каенкай» исемендәге балалар бакчалары бар. Көнкүреш комбинатлары, кибет, ашханәләр эшләп килә. Чарлыда читтән килгәннәр өчен кунакханә дә салынган. Авылларны асфальт юллар тоташтыра. Ул 30 километр озынлыкта. Монда үз асфальт заводын булдырганнар. Без урман полосасы юлы буйлап барганда, ул төтен чыгарып эшләп ята иде.

— Толлы урамнарын яхшылап асфальтлыйсы бар әле,— дигән иде рәис Рәүфов. Июльдә әйтте — августта эшләде. Толлыда асфальт хәзер.

Авылларга су кертелгән, һәркайсында өчәр бөя буылган. Буаларга карп балыгы җибәрелгән.

Соңгы елларда гына 35-40 яңа йорт салынган биредә. Бигрәк тә Толлы үзенең шәп итеп салынган йортлары белән аерылып тора. Татар йорты кайда да матур ул!

Монда житештерү биналарын салуны да артка куймыйлар. Ындыр табаклары яна, ремонт мастерскойлары, җылы гаражлар нык, иркен итеп эшләнгән.

Толлыда симертү малларын бәйләүсез тоту өчен өр-яңа ферма төзеп яталар. Баганалар һәм каркаслары тимердән.

Ә көнкүрешкә килсәк, халык үз тормышыннан зарланмый. Ел саен яңатормышлыларга люцерна, чөгендер, ашлык, печән бирелә. Шуңа бу якта малны күп тоталар. Икешәр сыер тотучылар шактый, сугымга да ике-өч мал асрыйлар. Сарык, һәр гаиләдә биштән унга кадәр, урыслар дуңгыз симертәләр. Кирәк кешегә дуңгыз балалары сатып бирелә. Тавык-чеби, каз-үрдәкне һәркем теләгәнчә тота. Ишегалды тутырып йөри алар!

Нигә китсен мондый авылдан яшьләр? Бар да бар бит! Кая китсен алар? Юкны эзләпме? Әнә рәис Рәфыйк Рәүфовның улы Марсель, Лубъян урман хуҗалыгын тәмамласа да, туган ягын, басу-кырларын ташлап урман эшенә китмәде, «Яңа тормыш»та шофер булып урнашты. Үз әтисе янында. Әнисе Бәрия, әбисе Мәгъсүмә белән гомер итә яшь егет. Монда калганына үкенми дә...

Башлыкның улы читтә җылы урын эзләп йөрмәве — башка яшьләр өчен дә үрнәк.

Ике авылда да яшьләр шактый монда. Читкә китми, авылда кала алар. Ә нигә калмаска ди?! Яшәргә була ич! Бу авыр заманда да барлык мөмкинлекләр бар диярлек. Чит җирләр дигәнендә дә бал-май белән каршы алып тормыйлар хәзер...

## Эшне кемнәр хәл итә?

— Ничек ирештегез бу уңышларга? — дип сорыйм Мансур Хәсәновтан.
— Барысын да кешеләр хәл итә! — ди ул.
— Кадрлар, димәк...
— Әйе, кадрлар. Коры кадрлар гына түгел: белемле, тәҗрибәле, үз эшен яратып башкаручы намуслы эшчеләр.
— Ә оешканлык, дәресрәге, оештыра белү?
— Хак сүзләр! Бездә бит оешканлык көчле, чөнки оештыра белү бар. Халыкны, бигрәк тә кадрларны оештыруда Рәфыйк Габдерәүфовичның роле бик зур. Эшне эленке-салынкы итеп тә оештырырга була. Безнекеләр эшен бик кыска вакытта тота беләләр. Уракны без күршеләрдән ике-өч атна алдан бетердек. Югалтуларга юл куелмады, бик тиз эшләсәләр дә...

— Җитәкчелек-идарәдә югары белемле кадрлар күпме сон?

— Аерым тармак башында торучыларның күбесе югары белемле. Санап китәм: зоотехник Әгъзәм Сәлимгәрәев, ветврач Азат Мөхәммәтдинов, агроном һәм рәис урынбасары Альфред Баһманов, агроном Айдар Габделхаков, малларга азык әзерләү буенча рәиснең урынбасары Нургали Шәрипов, төзүче-инженер Илсур Хәсәнов һәм башкалар. Бухгалтерия эшчеләрен алыйк. Барысы да махсус урта белемле, техникум тәмамлаган кешеләр: Мария Сергеева, Нурия Гаянова, Рауза Сәлимгәрәева, Диләрә Шаһабиева. Сөтчелек фермалары башлыклары Флүрә Рәхмәтуллина, Әминә Шәвәлиева һәм аларның хезмәттәшләре — менә дигән кадрлар бездә. Ә механизаторлар? Тракторчылар Фәрхетдин Мөхәммәтдинов, Мансур Хаҗиев, Рифат Гатин, Михаил Шахмаев, Николай Пасенков, комбайнчылар Виктор Карлушин, Леонид Староверов — мондый эшчәннәр белән әллә нинди зур уңышларга ирешеп була. Әле аларның барысы да диярлек бер үк вакытта тракторчы да, шофер да, комбайнчы да. Урак бетүгә, комбайнын куеп, тракторга яисә машинага утыра алар.

— Чарлыда һәм Толлыда техника төзеклеге өчен җавап бирүче Юрий Столяров белән Рифат Мәүләвиев та алтын куллы кешеләр,— дип дәвам итә М. Хәсәнов.— Алар кул астындагы эшчеләр дә менә дигән итеп эшлиләр. Барысын да санап бетерергә вакыт та җитмәс, тик шулай да безнең «Яңа тормыш»та бик тырыш савымчылар, терлекчеләр, мал симертүчеләр, механизаторлар, шоферлар, төзүчеләр бар дип әйтә алам. Әгәр алар эшкә салкын караса, өстен-өстен генә йөрсә, без санап киткән уңышларга ирешә алыр идекмени?

Бу соравына баш экономист үзе үк җавап бирә:

— Һич тә юк! Барысы да алар көче, алар хезмәте, аларның тырышлыгыннан туган уңышлар.

Шаклар катам! Әллә болар телепатлар инде. Рәис Рәуфов белән экономист Хәсәновны әйтәм. Рәфыйкның уйларын Мансур кабатлыймы, әллә Мансурныкы белән Рәфыйкныкы туры киләме? Никме?? Чөнки шушы ук сүзләрне, үз кадрларына булган хөрмәт һәм аларны санлау турында «хуҗа» миңа Түбән Шөннән Толлыга килгәндә сөйләп барды ич!

## Арендачылык — үзен аклаган ысул

— Әхәзер,— дим Мансур Хәсәновичка,— соңгы елларда уңышларга ирешүнең, текә сикереш ясауның төп сәбәпләренең тагы берсенә күчик әле. Кадрлар барын да хәл иткәнен аңлыйбыз инде. Бу турыда Күнитекле Тимер Юлбашчы да күптән әйткән. Ә яңа эш алымнары һәм яңача, заман кушканча эшне оештыруны кая куябыз? Ул да төп сәбәпләрнең берсе түгелме?

— Нәкъ өстенә бастыгыз? Без Кукмара районында гына түгел, хәтта Татарстанда, ә бәлки Россиядә беренчеләрдән булып аренда тәртибенә күчтек. 1988 елда ук. Күрәсең, илдә реформалар башланса да, әле кай якка китәргә белмәгән икеле-микеле чаклар. Шулвакыт Рәфыйк Габдерәүфовичның интуициясе үзенең сиземләү көчен ачык күрсәтте һәм без аренда ысулын сынап карарга булдык. Югарырак утыручы җитәкчелек тә моңа каршы төшмәде. Беләсезме, беренче нәтиҗәләр үк шаккатырлык булды: шул ук 1988 елны без ит һәм сөтне 100әр тоннага артык җитештердек. Алга таба тагы сынау еллары. Тора-бара һәр сыердан 3000-3500 килограмм гына сөт сауган «Яңа тормыш» савымчылары бу санны 5000-5500 гә җиткерделәр. Тагы да озын-озак сынап караулар уздырып тормадык, 1992 елны арендачылык ысулын юридик яктан теркәдек.

Папкасыннан алып, ул миңа бер кәгазь суза. «Яңа тормыш» арендачылар берлеген оештыру структуралары» дип аталучы документ бу. «15 февраль, 1992 ел» белән тамгаланган, Кукмара район Советы карары белән 244 нче номер астында шул ук 1992 елның 20 октябрендә расланган.

Берлектә 5 берләшмә бар, шушы берләшмәләр 32 аренда группаларына бүленә, аларда 3-5 тән алып 10-15 кә кадәр кеше тупланган.

Иң зур берләшмәләр, аренда группалары һәм аларның җитәкчеләре:

Толлыда «Вятка» — җитәкчесе Галимҗан Хәлимов.

Чарлыда «Лесная» — Юрий Петрович Харжавин.

Плаксихада «Переправа» — Павел Емельянович Березин.

«Терлекче» — Рәвия Мулланур кызы Хәбибуллина.

«Дуңгызчылык» берләшмәсе — Виктор Леонидович Харжавин.

«Механизатор» — Рафаэль Вәсил улы Ибраһимов.
«Төзелеш» — Фәнил Мөхәммәтшин.
«Башак» — Сәлимә Муллина...

Хәер, аларның барысын да санап тору кирәкмидер. Хикмәт исемнәрне атауда түгел, ә шул исемнәр, шушы бүлгәләү, яңача эшләү, тәртип-системадагы үзгәрешләр астында ни ятуда.

— Арендачылык ысулы, тәгаенләп әйтик, ни бирде соң сезгә?

— Иң беренче,— ди Хәсәнов,— җаваплылык хисе. Аннан соң оешканлык. Хәзер аларны бригадир эшкә куып йөрми, вакытында үзләре чабалар. Болар өстенә, бер-беренә салынмау да бар. Бер-икесе авырып китсә дә, алар үз эшләрен үзләре беләләр, вакытында башкаралар. Группада 10 кеше булса да, хәтта 6-7 гә калсалар да. Әле шунсы да бар: арендаторларның хезмәт хаклары да әйбәт, шуңа күңел биреп эшлиләр, кесә тутырып акча алалар. Бездә айга ярты миллионга кадәр акча эшләгәндә, күп кенә күрше хуҗалыкларда ул 50-60, 100 меңнән артмый.

— Боларын үзем дә чамалыйм...

— Ә җитештерү? Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү кайбер тармакларда бермә-бер артты бит. Менә бу ысулның көче кайда!

Әйе, хикмәт шунда шул! Җитештерү артмый торып, байлык каян килсен?! Америкаданмы, Япониядәнме? Европа илләреннәнме?? Алар бушка бирми ич! Товары өчен каерып ала.

Товары бар дәүләтнең акча-валютасы да бар!

Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруның дөнья экономикасында иң төп, иң зур проблемаларның берсе икәнен бу урында озаклап кабатлап торуның кирәге дә юк. Моны инде күптән һәм күпләр беләләр. Бары «Яңа тормыш»та шуны ачык аңлаулары һәм шуңа омтылуларын искә төшерү — икенче «җинел юл» эзләүчеләр өчен бер дә артык булмас кебек. Ә үзен аклаган аренда ысулын бередә сакларга тырышалар.

## Әзер ашлама

Рәфыйк Рәүфов тагы Кукмарага китте. Берлек эшләре белән. Без рәис урынбасары Альфред Баһманов белән Чарлы фермаларын карарга булдык.

Иң элек дуңгыз фермаларыннан чыгарылган тирес суын җыя торган казанубылманы, котлован карадык. Элек бу тирес-су елга, буаларга аккан, андагы балыкны, башка терлекне, җан ияләрен харап иткән. Моның өчен «Табигатьне саклау» экологик оешмалары зур гына штрафлар белән янаганнар, һәрвакыт тиргәп-кисәтеп килгәннәр.

— «Хуҗа»быз берчак уйга калды,— ди Альфред.— Ничек моннан котылырга? Котылырга гына түгел, тирес суын файдалы нәрсәгә әйләндерергә. Тирес — органик ашлама бит, ә тирес суы үләннәрне күкрәтеп үстерергә бигрәк тә әйбәт. Менә шулчак тирес суын җыя торган котлован казыдык, кырыена суырту насослары урнаштырдык. Фермалардан чыккан тиресне салам аша уздырып фильтрлыйбыз: сыегы котлованга ага, куесы җыелып кала. Тирес суын гектарына 10 тонна исәбеннән өч тапкыр кертәбез: язын, беренче һәм икенче чабудан соң. Күкрәп үсте люцерна. Аны тукландыру өчен ашлама сатып аласы да түгел.

Ә мин күлгә карап торам. Чүрәкәй үрдәкләр йөзә анда, кешедән бер дә курыкмыйлар. Тагы...

Мондагы каргаларга исем китте. Үзләре мич корымына ышкылгандай капкара. Юк, хәтта елтыр-кара, шома-кара, зәңгәрсу-кара. Ә менә гәүдәләре. Һәрберсе торна хисә каз кадәр бар. Дуңгызлар сарае тирәсендә яшәгәнгәме, дуңгыз кебек симергәннәр. Дөрес әйтәләр шул:

— Байның эте дә бай, тукның эте дә тук!

Ә монда — каргалар...

Күккә сыймый оча алар. Шуңамы, күбрәк җирдә йөриләр. Аяк астында яткан азыкка абынып, канатлары барын онытмасалар ярый. Канатлар бит очар өчен бирелгән.

Юлны дәвам итәбез.

Кояшлы гаҗәп матур көн.

Урманга кердек. Чикләвек куаклары, каен, усак, нарат-чыршы агачлары. Искитмәле саф, чиста, ачык һава! Күкрәгең тутырып сула да сула. Менә шушындый мизгелләрдә адәм балалары дөньяда яшәүләренә, исән, саутаза булуларына сөенеп бетә алмыйлар. Дөньялыктагы үкенеч-сагышларны, кайгы-хәсрәтләрне вакытлыча гына булса да онытып торалар. Аларның Тән-Җан-Рухтан торган субстанцияләре, шатлык белән өретелеп, балкып-янып тора. Яшәү — рәхәт ич!

— Яш-шә-ә-үү рәх-хә-әәт!!!

Әнә шундый әттәхият тә укып җибәрәсең мондый минутларда. Хиссият укыта аны. Яшәү шатлыгы укыта. Яшәү рәхәтеннән хет бүре булып ула. Хәер, бүреләр сагыштан улыйлар булса кирәк. Башкача булса, төнге сары сагышлы айга карап уламаслар иде.

Юлыбыз «Берлек»нең умарта оялары урнашкан урман аша уза.

«Яңа тормыш»ның урман авызыннан ерак түгел 50 умарта оясы бар. Быел ике центнердан артык бал суыртканнар инде. Теләгән кешеләргә сатып та бирәләр.

— Һәр оя 10-12 килограмм бал бирер,— ди карт умартачы Алексей Сергеевич Карлушин. Аңа ярдәмче итеп яшь егет Виталий Староверовны куйганнар. Карт һәм яшь умартачы икесе тыныч кына эшләп яталар. Бернинди ашыгу-каударлану юк. Хәер, умартачыларга хас гадәт инде бу. Син ашыгасың дип, умарта корты бал җыярга ашыкмый. Аның үз институты — устав, законнары бар. Әле бар балын кешеләргә җыясын белсә, бер чәчәккә дә утырып тормас иде.

Кешеләр генәме соң?

Әле менә кичә генә умарталыкка аю килгән. Ике умарта оясын аударып ук ташлаган.

— Соң умартачыларның этләре аюга өрми микәнни? Әнә, бер кашык бал өмет итеп килмәсәк тә, безне ничек өреп каршы алдылар. Чылбырыннан ычкынган «Каф тау арты җеннәре» диярсең! Әллә аю белән бер-берсенә кагылмаска килешү төзегәннәрме??

Дөрес, монда кабан дуңгызлары, пошилар да булгалый икән. Ә теге кәкре аяклы, симез табанлы, юан йонлач аяк-куллы шайтан беркемгә дә сиздермичә килеп чыга, ди. Килеп чыга да умарталарны аударып йөри. Тыңгысыз исерек бәндә кебек...

Нишлисең, кешеләр генә түгел, аю да бал ярата.

## Толлыда толлар юк

Без. Шөн ягы кешеләре, бу авылның исемен бервакытта да тулысынча итеп Татар Тулбасы дип атамадык. Кыска гына — Толлы! Хәтта мондагылар үзләре дә әлеге сала исемен Толлы дип кенә атый.

Бу авылга кайчан килеп утырганнар?

Моны анык кына белүче юк. Бәлки, 1552 елны Явыз Иван Казанны алганнан соң, ә бәлки иртәрәк — Бөек Болгар дәүләте чорларыннан. Ләкин шунысы билгеле: авылда өч зират бар. Икесе бик иске, соңгысы чагыштырмача яңа. Менә шушы зиратларның берсен «чирмешнеке» дип атыйлар. Мари зираты, димәк. Шулай булгач, бу урында кайчандыр марилар да яшәгән. Башта монда, бәлкем, Чирмеш Тулбасы булгандыр, ул хәзер Татар Тулбасына әйләнгән.

Татар телендә «Тулба» нәрсәне аңлата? Аерым бер диалекттагы ук савыты — садак сүзе түгелме бу тул + ба? Тутыруны, тулганны аңлатмый микән ул?? Ә бәлки, ул чирмеш сүзедер? Татар теле үзенчәлекләре ярдәме белән Толлыга әйләнгәндер...

...Толлы — хәзерге көндә бик матур авыл. Татар авылы. Ул Нократ елгасыннан ерак урнашмаган. Авыл аркылы инеш ага, төньякта текә таулар, кояш караган якта урманнар.

Иң сөенечлесе: карты-яше бергә яшәп яткан тулы тормышлы күркәм авыл ул. Тагы да сөенечлесе: монда Рәфыйк Рәүфов үзе сабый чагында кичергән һәм күргән ятимнәр һәм толлар юк. Булганы да сизелми. Ә теге вакытта һәр өйдә диярлек иде ич алар.

## Венгр казлары мамыклы

Альфред Бәһманов белән каз үстерү фермаларына килдек. Толлыда венгр казлары үрчетәләр. Мамыклы һәм тәмле итле данлыклы венгр казларын.

Бу болай башланган. Рәис урынбасары Альфредка бервакытны Башкортостанның Илеш районында булырга туры килгән. Шунда күргән ул әлеге йорт кошларын. Туган ягына кайткач, хуҗалык рәисе Рәфыйк Рәүфовка әлеге казларны асрап карарга киңәш иткән. Киңәшле эш таркалмас дигәндәй, сынап карарга була болар. Тегеләй һәм болай чутлап карыйлар да, Аллага тапшырып вә үзләренә дә ышанып, башта мең баш бәбкә алалар. Әмма эш уңышсыз башлана. Венгр казларыннан да төлке шулпасы исе килә башлый, чөнки мең бәбкә көзгә 30 гына казга әйләнә. Меңнән утыз? Аз бу, ифрат аз! Калган 970 е бер-бер артлы чиратлашып «теге дөнья»га китеп барганнар. Саубуллашмый һәм канат какмый гына...



Менә шушы инде ул данлыклы венгр казлары!

**Мидхәт Шакирҗанов** фотолары.

Шуңа да карамастан, рәиснең, урынбасарның, экономистның бу казларга күңеле кергән, кем әйтмешли: гыйшкы төшкән! Асрарга мөмкинлекләр бар ич: сулары дисеңме, азык-төлеге дисеңме. Бары тәҗрибә булмау гына эшне тиешенчә алып барырга мөмкинлек бирми. Беренче коймак төерле була, ди. Икенче тапкыр сынап карау теләге белән тагы алып кайталар казларны. Боларның аяклары җиңел була: тагы бер елдан 1400 дән 2800 гә житә алар. Бүген әнә ике казчылык фермасында 4000 баш каңгылдашып, бип-бип килеп яталар. Бер фермада арендачылар — Зарифовлар гаиләсе: ирле-хатынлы Рәкыйп һәм Рәсимә, уллары Раниф. Икенче фермада Миңнехановлар: Миңнулла белән Гөлбикә, уллары Флюр һәм кызы Гөлбизәр.

Ике бәпкә үлгән...

Рәкыйпның хатыны Рәсимә аларны шундук суеп чирләрен тикшерә һәм үпкәләрендә сары су таба.

— Үзе каз караучы, үзе врач минем хатын! — дип елмая ире Рәкыйп, Толлының элеккеге данлыклы көрәшчесе.

Ферма янына «Урал» мотоциклында «Вятка» берләшмәсе житәкчесе Галимжан Хәлимов килә. Ул Толлының элек бригадиры иде.

Галимжан белән күрешәбез. Дәү генә кулларын суза. Ул элегрәк көрәшеп йөрде ич. Хәер, Толлы ирләренең күбесе татарча көрәшеп караган һәм мәйдан тоткан кешеләр. Толлы Хәлил, Мөжип, Алфат — данлыклы батырлар иде бит. Хәзер инде олыгая төштеләр, ә Рәфыйк Рәүфов? Сабантуйларда бер генә батыр калмады ул! Читтәрәк җигүле ат уза. Рәфыйк Рәүфовның «Европа ат сагына» әсәрен яратып укуы турында әйткәне искә төшә, шуңамы аяк тирәсендә йөргән бәбкә-казлардан татарның яраткан малына күчеп, сорау бирәм:

— Атлар күпме Толлыда, Галимжан?

— 50 баш! — ди ул чын мәгънәсендә горурланып. — Унике биябез колынлады, тупырдап торган унике колыныбыз бар!

Шәп! Сыерлы авыл сыйлы булса, атлы авыл затлы ул!

— Атларны югалтмаска кирәк! — дип сүзгә кушыла Рәкыйп Зарифов. — Алар бензинсыз эшли торган җанлы тракторлар ич. Ягулыкка мондый кытлык, юклык көннәрдә бигрәк тә кирәк алар. Фермада без гел ат көченнән файдаланабыз. Очсызга да төшә алар. Печән бездә бетмәгән, ашат та рәхәтләнеп җик!

«Очсызга да төшә...» — дип уйлыйм эчтән генә. Акча санарга, табыш-зыянны аралый белергә өйрәнгән болар!

Альфред белән Галимжан агымдагы эшләр турында сөйләшүгә күчәләр, ә минем күз тагы казларга төшә. Яшел-сары бәпкәләргә — менә алар ашарга йөгерәләр, канат чыга башлаганнарына — алары суда коена, һәм! — ап-ак зуп-зур казларга — болары очып китәргә теләгәндәй канат кагына.

Ферма яннары гына түгел, Толлы урамнары, бөя-күлләре, инешләре дә венгр казлары белән тулган иде. Авыл кешеләренә аларны сатып та бирәләр икән.

Венгр казларыннан алган мамыкны Кукмара һәм Казанга озаталар. Җылы курткалар тегәр өчен. Кытайда һәм Венгриядәге кебек.

Без тагы юлда...

Руль артына утырган Альфред үз уйларына чумган. Минем уйлар әйләнә-тулгана да кагынып торган ап-ак венгр казларына кайта:

Венгр казларылай, ай, мамыклы,
Мамыккае җилгә очмасын...

## Мәчеттә кеше — мәче, эт түгел...

Альфред Баһманов белән башта Чарлыдагы иске чиркәүне карадык. Аны яңартырга йөриләр, әлегә үз поплары юк. Чиркәү ишек алдына элек музей оештырылган икән. Аның истәлеге булып, данлы «Аврора» крейсеры матрослары, чыгышы буенча Чарлы кешеләре булган Александр Егорович Богомолов белән Николай Григорьев-Казанцевларга куелган зур-зур гына бюстлар калган.

Чиркәү белән мәчет бер-берсенә мәче, эт түгел, икесе дә — Аллаһы йортлары. Бары Хак тәгаләгә сыгыну ысуллары гына төрле-төрле. Чиркәүне күргәч, үземне мөселман-татар санагангамы, Толлы мәчетен күрәсе килү, аның эченә керәсе килү бермә-бер артты. Һәр татар авылындагы мәчеткә тартылу — Ходайга Ислам аша килергә теләүчеләргә хас Җан-Рух омтылышы ул.

Мәчеткә безне әле чагыштырмача яшь булган, кырыкка да җитмәгән Хәниф Галләмов алып керде. Ачкычы анда саклана икән. Картлар авырсынганда, җомга көннәрне Хәниф манарага менеп азан әйтүне үз вазифасы саный.

Мәчет эче матур гына. Стена-диварларда яхшы язулар. Тынлык, чисталык, пакьлек монда.

Ахырдан Хәниф белән икәү манарага күтәрелдек. Артык биек булмаса да, моннан тирә-юнь уч төбендәгедәй күренеп тора. Әнә йортлар, хуҗалык биналары. Урман-таулар, читтәрәк Нократ җәелеп ага. Төньяк кырларда урман полосалары. Алар Киров өлкәсе, Вятские Поляны районы һәм Шөн яклары белән чик баганалары ролен дә үти сымак.

— Мәчетегез яңа әле. Нинди акчага төзедегез? — дим аска төшкәч.

— Аны колхоз төзеде, Рәфыйк абый Рәүфов төзеде, — ди Галләмов.

— Халык та акча җыйды... — дип куя, аңа каршы төшкәндәй, Альфред Баһманов.

— Әй! Рәзе ул акча белән генә мәчет салдырып була иде, ә? Рәфыйк абыйга Алланың рәхмәте төшсен, саулыкларыннан аермасын, һәр бүрәнәне, һәр тактаны китертте, карап эшләтте.

— Халык мәчеткә күп йөриме? — дип сорыйм.

— Азрак шул... Пенсиягә чыкканнар гына түгел, хәтта картлар да мәчет юлына бик атлыгып тормыйлар. Шулкадәр расхутлар ясап мәчет эшләт тә...— дип ризасызлана Хәниф.

— Теге 70 еллык атеизм идеологиясе үзен нык сиздерә әле.

— Ие шул. Нигә йөрмисез дисәң, әй, без аңа ияләнгәнмени. Элек динне сүгеп килделәр дә хәзер тагы күтәрә башладылар, диләр. Кай якка карарга белмәссең, диләр...

— Ә үзең? Син бит әнә яшь кеше. Мәчет сине ничек тартты??

— Мин мондый чагыштыру китерер идем, менә туйда утырасың. Башы бик тә культурный башлана. Матур гына утыралар, акрын гына сөйләшәләр, тыйнак кына көләләр. Инде әзрәк эчеп алдылармы, бер-берсен уздырып сөйләшә башлыйлар. Алар гына! Кешене тыңлау юк, ә инде суынып керү өчен тышка чыксалар, кызып ук китәләр, китә сүгенү, сугышып алырга да күп сорамыйлар. Ошамый бу миңа. Кешеләр түгел, мәче белән эт диярсең! Ырларга-мырларга гына торалар. Дин ашына барасың: барысы да тыйнак, тыныч, чиста, пөхтә. Кешечә сөйләшәләр. Телләрендә матур сүзләр генә. Инде мәчеткә килсәң, анда тынычлык, пакьлек сизәсең. Кычкырып сөйләшүче юк. Һәркемдә тәртипле сүзләр. Мәчеттә миңа иң ошаганы: бер-береңә хөрмәт, үзара тигезлек. Бу йортта Аллаһыга якынаясың, барыбыздан да өстен торган Иң Зур Көчне тоясың...

Хәниф Галләмов эшкә ашыга иде, ул жинел машинадан төшеп калды, без юлыбызны дәвам иттек.

Зур «расхутлар»га төшереп салынган бу мәчеткә йөрүчеләр саны, чыннан да, артсын иде. Моңа, һәрхәлдә, житәкчеләре Рәфыйк Рәуфов та сөенер иде. Ни генә димә — мәчет кешеләре мәче, эт түгел, фикердәшләр-кардәшләр бит...

## Американча ризык, татарча рухи азык

Кешеләрнең эшләү сәләте туклануга нык бәйле. Элек байлар үз болыннарына печәнгә төшкәндә, яллы эшчеләрне сыйлау өчен ат яисә сыер суйганнар. Һичьюгы зуррак үгез белән башмак тананы сугымга дип тотканнар. Печән өсте авыр эш, шуңа ярлырак кешеләр дә сарык суеп чыккан печәнгә. Сарыгы буаз икән, соңгы тәкәсен чалган.

— Ашлы утта торыр, ашсыз утырыр, ди...

«Яңа тормыш»та үз эшчеләрен ничек ашаталар? Шул чакта төпченеп, ашханәләрен дә күреп чыгыйк, дидек. Чарлыдагы ашханә чисталыгы, матурлыгы белән җәлеп итте. Рәсемләнгән, буялган. Ике зур-озын стенада буе белән пейзаж. Берсендә Нократ һәм иген кыры, икенчесендә иген кыры һәм наратлар. Тәрәзә янындагы диварда самавыр-үзкайнаткыч һәм кувшин белән чәчәкләр. Чарлы ашханәсендә Наташа Харжавина, Марина Карпова һәм Фирүзә Заболоцкая эшлиләр. Монда кызыклы яңалык шул: алар эшчеләрне тавык шулпасы белән сыйлыйлар икән! Америкадагы кебек. Американнар тавык шулпасы ярата ич! Хәер, андый шулпа безнең өйдә көн дә әләкми. «Яңа тормыш»та моның өчен 800 бройлер тавыклары тоталар. Аларны аерым фермада Валентина Староверова карый.

Толлы ашханәсендә без тамак ялгап ук чыктык. Дөресрәге, туйганчы ашап, чөнки котлитләре ашап бетермәле түгел иде. Кунаклар киләсен белеп ясаган кебек. Бу ашханәдә дә чисталык-пөхтәлек һәм! — әле болар өстенә — пешерүчеләрнең көләч йөзләре. Әллә ашап чыкканга, бәлки башка сәбәп тә булгандыр, алар миңа Чарлы ашханәсе кызларыннан күпкә сөйкемле тоелды. Шулай инде: кемгә ни ошый ди, татарга — ат!

Зөлфия Зарифова, Гөлшат Хажиева, Зөбәйдә Рәхмәтуллина пешергән ашларны мактап кына ашарлык.

...Без тагы юлда.

Тук тамак рухи азык эзли. Толлы клубын карарга булдык. Ничек микән монда мәдәният хәлләре?

Клуб агачтан эшләнгән. Иске инде. Клубтан бигрәк, ат сараена охшап тора. Толлыда мәдәният йорты салынырга тиеш булып та, ул тукталыбрак калган. Бу яктан Толлы халкы рәнжетелгән. Дөрес, урамнары асфальт белән түшәлгән инде. Элегрәк сарык башы кадәр ташлар гына җәелгән иде. Ямьсез юл иде ул.

Клубның эчен күрмәдек. Мөдир Фәнис Ризвановны борчып йөрисе килмәде. Ул бит көндез, төш турында түгел, ә кич вә төнлә эшләүче кеше.

Монда концерт-спектакльләр булмый дип кистереп әйтә алмыйсың. Әнә Җиңүнең 50 еллыгы алдыннан Казан язучыларын һәм артистларын чакыртып

алды рәис Рәүфов. Үзе авырып торса да. Чөнки Рәфыйк бик сәнгатьчел кеше. Әдәбиятны да нык ярата. Аның җаны матурлыкны тоя белә. Чын кеше һәрвакыт Яхшылык вә Матурлыкка омтыла ул. Тамак тәгамгә, бай күңелле инсан рухи азыкка тартыла. Рәфыйк Рәүфов моны да нык аңлап яши.

## Проблемалар, уй-хыяллар

Без рәиснең эш бүлмәсендә...

— Проблемалармы? — ди ул. — Бар инде алар, бар. Төзелеш начар бара. Без теләгәнчә түгел. Әллә ниләр төзәсе килә дә, акча авызлыклый, абзый. Тагы төзелеш материаллары җитешми. Бигрәк тә соцкультбыт объектлары төзелми. Болар өстенәме? Хәзер яңа техниканы юнәтү бик авыр. Янына бармаслык кыйбат алар, ә без җитештергән продукция, киресенчә, очсыз. Хәтта запчастьлар алырга да куркып торасың. Бер сегмент 2 мең сум. Ә бер пычкыда алар күпме! Гади генә сука тимере әллә ничә меңнәр. Санын-сумын атасам, шаккатарсың, абзый!

Шулвакыт телефон шалтырый. Рәис Рәфыйк Рәүфов трубканы ала:

— Тыңлыйм!

Кинәт кенә аның йөзе яктырып китә:

— Ә сезмени әле бу, Фатыйх Сәүбәнович!!

— Сибагатуллинмы? — дип сорыйм соңыннан.

— Әйе! — ди ул тагы да яктыра төшеп. — Кайчандыр без аның белән күрше генә колхозларда эшләдек. Акыллы җитәкче. Сабан туе батыры. Алып гәүдәле. Бик булдыклы кеше! Юкка гына аны Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры итеп куймадылар. Андый җитәкчеләр белән элемтәдә тору — үзе зур терәк...

Сүзне дәвам итәбез.

— Хыяллар дисеңме? Иң зур хыялым — «Яңа тормыш»тагы һәркем бу хуҗалык минеке дип йөрсен иде. Минем күмәк хуҗалыгым бу дип. Ул вакытта эшләве бермә-бер җиңел булыр иде. Бездә дә көч куеп эшләмичә генә нидер булдырырга теләүчеләр юк түгел. Үзләрендә гел дә ризасызлык. Бездә бары да ал-гөл димим. Шуңа карамастан, канәгать калыр урыннар да бар. Дөрес аңла, Рафаэль, мин үзебезнең кешеләрне бик тә яратам. Билләһи, барысы да туганнарым кебек! Рус һәм татар авылларындагы дуслыкны гына ал. Беркемне дә рус, татар дип аерып та тормыйлар. Чын дуслык бит бу! Ә шулай да эштә дилбегәне җибәрергә ярамый. Авызлыклап тотарга димим. Йомшаклык кирәкми. Мин берәүгә, аны колхоз председателе итеп куярга теләүләрен ишеткәч, әйттем: «Сиңа авыр булачак, йомшак характерлы кеше син». Йомшаклык кешеләрне аздыра ул.

— Диктатура шәбрәкмени җитәкчегә?

— Коры демократ кына кеше җитәкчелектә озак эшли алмый. Бигрәк тә колхоз рәисләре. Тиран булмасаң да, диктатура чараларын да кулланасың. Ләкин диктатураны мин бу урында тәртип-дисциплина булдыру, диктат дип аңлыйм. Диктатны үз эшеңне, планнарыңны, проблемаларны чишү буенча ашыгыч чараларыңны бирелгән властьтан файдаланып, вакыт-вакыт мәҗбүри рәвештә уздыру итеп аңлыйм. Боларны вакытында эшләмәсәң, соңга каласың. Соңга калуның хуҗалыкка зур зыяннар салуы бар, абзый. Җитәкче һәр тармак пульсын тоеп яшәргә, анда яшеренгән шартлаткыч хәлләрне алдан күрергә, минер кебек эзләп кенә торырга тиеш. Шуны сизденме — вакытында команда бирергә. Диктат инде, иккенчеләп әйтсәк. Җитәкчедә диктат юк икән, ул инде җитәкче түгел, ә чүпрәк. Халык бит иң беренче эш барганны хуплый.

— Ялмы? Хыялдан соң ял да кирәк инде. Сез шагыйрьләр хыялны ял белән рифмалаштырасыз бит: хыял — ял! Мин дә кеше кебек кеше. Башкалардан артык та, ким дә җирем юк. Элек эчкәләдем дә. Хәзер йөрәк кушмый. Шулай да гел эш белән генә гомер узмый: Вятка буена да төшеп утырасың, ауга-балыкка да йөрисең. Туганнарга, якыннарга аш-су мәҗлесләренә дә барасың. Якын дуслар белән урман-тугайларда утырган чаклар да булгалый... Мин тормышның үзе кебек үк катлаулы кеше. Мине идеаль бер бәндә дип кабул итә күрмә. Андыйлар дөньяда булмый дип уйлыйм.

— Ә ниндиләр була?

— Үз эшендә күп көч керткәннәр һәм ныклы көч куймаганнар, — ди ул бер як күзен кысып.

— Рәфыйк Рәүфов беренчеләре рәтенә керәме?

— Ансын кешеләр әйтер, Рафаэль! Ни генә дисәләр дә, туган ягымны яхшырту, матурлау, баету өчен мин аз тырышмадым. Тик шулай да язмаңда мине артык мактый күрмә.
— Менә монысы минем көчтә түгел инде.
— Ничек? — дип куя ул тагы күзен кысып. Вакыт-вакыт бер күзен кысып куя торган гадәте бар аның.
— Соң мин атналар буе сездән материал җыеп, күргән-белгәннәр белән илһамланып-тәэсирләнеп килә дә, беркөнне кинәт кен · өстәл артына утырып, ашамыйча-эчмичә, йокламыйча диярлек бер-ике тәүлек тоташтан язып, 50-60 битлек карамаланы эшләп тә куям. Минем уйларны, хисләрне монда инде беркем дә туктата алмый. Алар артык кайнар була, вулкан лавасы кебек тоташ агып тора.
— Шуннан?
— Эссе коймакны табасында ике-өч атна суыткач, салкын акыл белән, ләкин әсәр утын сүндермәскә тырышып акрын гына, ашыкмыйча акка күчерә башлыйм. Монысы иң озак, авыр, мәшәкатьле эш.
— Аңладым! Сезнең күбегез бер калыптан икән!
— Ничек?
— Бервакытны очрашкач, мәрхүм Хәсән Сарьян үзенең нәкъ шулай язуын сөйләгән иде. Ашамыйча, йокламыйча... Әсәр, күрәсеңдер, шулай гына туа. Сарьянның «Әткәм һөнәре», «Егет язмышы», «Бер ананың биш улы» повестьларын бик яратып укыган идем. Алай дисәң, безнең эш тә ашамыйча-йокламыйча чапсаң гына бара бит. Тамакны кысмасаң да, җәйге йокылар яртылаш кына — күпвакыт 4 сәгатьтән артмый.
Рәфыйк тагы үзалдына елмаеп куя:
— Әнә пенсиягә дә биш еллап кына калып бара инде. Саулыкны гына бирсен, шулчак озаклап йокларбыз әле. Ә эшләсе эшләр күпме? Әйе шул: проблемалар, уй-хыяллар...

## Президент килгән авылга

**И**дарә йорты бакчасы...
Рәүфов, Баһманов, Хәсәновлар белән мондыйрак гәп бара:
— Татарстан Президенты башка ил-республика башлыкларыннан кай ягы белән аерыла?
— Чит илләргә күп йөрүе беләнме?
— Юк, аңа караганда күбрәк йөрүчеләр бар.
— Зирәк политик булуы беләнме?
— Зирәген зирәк, ләкин андый зирәк президентлар дөньяда юк түгел...
— Мөлаемлыгы, кече күңеллеге беләнме?
— Андыйлар да шактый.
— Соң?
— Татарстан Президенты курыкмыйча халык арасына чыга. Ул авыллардан авылга йөри. Ә башкалар? Бармы алар арасында авылларга — халыкны туйдыручы игенче, савымчылар янына турыдан-туры йөргәне?
— Бәлки аның үзенең йөрүе кирәкмидер дә...
— Кирәк, бик кирәк!
Президент ике тапкыр «Яңа тормыш»та да булып киткән. Бер авыл-хуҗалыкта ике тапкыр! Беренчесе — янгыннан соң.
...Рәфыйк Рәүфов белән Толлы үрен төшәбез. Әлеге дә баягы УАЗикта.
— Синең «Чеченнар, Чечня һәм без» мәкаләсен ел башында «Ватаным Татарстан» газетасында укыдым, — ди ул. — Язганың миңа ошады. 28 июльдә шул ук газетада бөек биюче Рудольф Нуриев турындагы уйлануларны да бергәләп укыган идек. Бер кочак газета-журналлар алып кереп салган иде ул вакытта секретарь кыз...
— Рәхмәт! — дим Рәфыйкка.
— Беләсеңме... — Без аның белән беренче очрашуда ук бер-беребезгә «син» дип дәшәргә сүз куештык. Рәсми, арада киң коридор торган «Сез» түгел, ә бер-береңә тиң «Син».
— Әнә шул Чечня вакыйгаларыннан соң минем Президентыбызга хөрмәтем бермә-бер артты. Ерактан күрүче, сизгер, зур интуиция көченә ия булган политик икәнен аңладым...
— Суверенитет буенча да үз сүзен әйтә алды, — дим.

— Әнә шул бәйсезлек референдумы вакытында «Чечня суешы»н иң беренче Татарстанда башларга мөмкиннәр иде бит,— ди Рәфыйк Рәүфов сүзен дәвам итеп.— Хасбулатов, Шахрайлар Грозный вариантын башта Казанда сынарга, изге шәһәрне хәрабәләр хәлендә калдырырга каршы түгелләр иде ич.

— 1552 елдагысы да җиткән! — дим.

— Ә алар җиткән дип уйлыйлармы?

— Уйласалар, йөз елдан соң шул ук Чечняда сугыш театры оештырмаслар иде. Аларга нәрсә, бу сугышта сыңар керфекләре дә төшми, бөртек чәчләре дә коелмый.

Күпергә кердек. Үр артта калды.

Рәфыйк тагы сүз ката:

— Ә менә шушы хәлләрнең безнең башка да кара таш булып төшмәүнең кадерен беләбез микән? Шуның өчен тырышкан Кешегә рәхмәтебез бар микән??

— Адәм баласы яхшылыкны аңлап бетерми, шулай тиеш саный. Инде начарга килеп эләксә, бөтен дөньяга шар ярып кычкыра:

— Караул! Кыерсыталар! Изәләр-сыталар!! Суялар!!!

Рәүфов мине бүлә:

— Зарны кычкырсалар да, рәхмәтне бит аны эчтән генә әйтәләр.

— Аңлыйм: хөрмәт-симпатияң нык сизелә.

— Авыл хуҗалыгына булган карашы күнелләрдә өмет уята — ди ул.

— Әдәбият-мәдәнияткә дә ныграк игътибар бирсә...— дим.

Машина клуб каршындагы бакча янына туктый. Монда солдат һәйкәле һәм Ватан сугышында башын салганнарның исемлеге. Бакчага кереп Бикмөхәммәтов, Гайнетдинов, Газизуллин, Гараев, Ганиев, Гатин, Заһретдинов, Каюмов, Миннеханов, Мәҗитов, Салахов, Сафин, Хайруллин, Хаҗиев, Шәйхетдинов һәм башка бик күп сугыш корбаннарының исемнәрен укыйбыз. Барлыгы җитмешләп кеше. Бер уртача гына авылдан бит бу! Шулар арасында Габдерәүф Заһидуллин исеме дә бар. Рәфыйк Рәүфовның әтисе...

Кузгалып китәбез...

Ә кайдадыр Татарстанның икенче бер авылында сөйләшәләр:

— Кем килгән авылга?

— Гаҗәпләнмәгез: Президент килгән...

Аның өчен гадәти бер хәл бу. Бары ул барып чыккан як кешеләре генә дулкынлана, ниндидер яңа хис-тойгы, дәртләнү кичерә:

— Авылга Президент килгән!!!

## Текә күтәрелеш

Без тагы рәис Рәфыйк Рәүфов белән... Атнадан артык күрешеп-сөйләшеп йөрү вакытында әлеге кеше миңа ифрат та ошады. Ирләрчә матурлыгы белән ошады.

Уртача буйлы, таза гәүдәле кеше ул. Мәгърур-нык йөзендә көч-куәт, үз-үзенә ышанганлык һәм акыл сизелә. Кызыксынучанлык та бар анда. Мәрхәмәт-шәфкать тә сыйган. Үткенлек, үҗәтлек, татарча хәйләкәрлек тә чагыла аның күзләрендә. Шулай ук үзенә карату-буйсындыру көче дә юк түгел. Иртә белү көче бу.

— Аякка бастырды ул безне! — диләр Толлы кешеләре аның турында. Шушы татарча сүзләрне Чарлыда русча кабатлыйлар. Үзем ишеттем. Леонид Староверов әйтте. Шуны ук Сергей Соловьев кабатлады.

— Безнең күршедә генә үсте,— ди, Түбән Шөндә гомере буе укытучы булып эшләп, пенсиягә чыккан Мава ханым Әхмәтшина. Ул чыгышы буенча Толлыдан.— Мин Рәфыйк белән горурланам!

— Аның турында роман язсаң да була. Безнең Герой Таһир Галиәхмәтовка тиң колхоз председателе бит ул!— диде шул ук Шөн ягыннан Илфат Әлтафов.

Шушы ук сүзләрне Толлыда әйтүче дә табылды:

— Әгәр теге вакытлар булса, аңа бу эшләре өчен Геройны бирерләр иде.

Социалистик Хезмәт Героен, ягъни мәсәлән. Хезмәте булса да, социалистигы калмады бугай шул! Герое булса да — бирүчеләре юк хәзер. Ә «Хезмәт батыр»лары бар ич! Бар алар!!

...Рәфыйк Габдерәүф улы Рәүфов белән Толлы үрен менәбез. Текә күтәрелеш. Әмма машина яхшы тарта. Рульдә ул үзе. Шоферы «Волга» машинасын ремонтлый икән. Гомумән, якын тирәләрдә һәм авыл араларында йөргәндә, УАЗик «дилбегә»сен үз кулына ала ул.

Текә күтәрелеш...

Кинәт күнелгә ниндидер моң бәрә. Бу — машина тавышын да күмеп, Рәфыйк янынннан минем колакка иңгән моң икән...

Ничә сынадым инде, руль артына утырып тигезрәк юлга чыктымы, Рәфыйк күзләрен офыкка теки дә үз алдына гына моңлана башлый. Ниндидер көй-моң. Сүзләре юк. Әгәр моңын-көен сүзләргә салып әйтсә, ул болай җырлар иде сыман:

Толлы тавы — текә үр...
Текә үрдә ипләп йөр.
Сагынып искә алырсың бер,
Бераз вакыт читтә йөр.

Толлы тавы — текә үр...
Су буйлары тигезлек.
Шушы якның ямьнәренә
Ялгышып күз тигезмик!

Толлы тавы — текә үр...
Текә үргә күз текә.
Кешеләре текә түгел —
Хәтер калдырма тиккә.

Толлы тавы — текә үр...
Текә үрдән менә күр.
Кем соң кала кара гүрдән?
Исән чакта кайтып күр.

Толлы тавы — текә үр...
Шул үргә үрләрсеңме?
Язмышыммы шундый булган? —
Күрмәдем күрәсемне...

Кырык бердә туганнарның моңы бу.

Яуда башларын салган аталарның улларына күчкән моңы. Үз гомерләрен яшәп бетерә алмаганнарның моңы.

...Текә күтәрелеш...

Ай-һай, нинди авыр син!

Кайвакыт йөрәккәең дөп-дөп килә. Усал эт сыман, оясыннан — күкрәк читлегеннән атылып чыгар кебек тоела. Яисә шартлап китәр кебек...

«Яңа тормыш»тагы һәрнәрсәне: уңыш вә кимчелекләрне, шатлыгын вә кайгысын, барысын-барысын күңеленә тирән алып, үз йөрәгә аша уздырган арендачылар берлеге рәисе Рәфыйк Габдерәүф улы Рәуфов ике тапкыр инфаркт кичерде инде. Соңгысында шактый озак дәваланып ятты. Ә үзен һаман эш тартты. Әз генә рәтләнә башлауга, хәлдән тая-тая, бер менгәндә ун тукталып, авыл каршындагы текә тауга күтәрелеп карады. Пиклар-биеклекләр яулаучы альпинист кебек. Алай чагыштырсаң, Рәфыйк характеры белән, чыннан да, альпинист ул. Биеклекләр яулаучы кеше, «Яңа тормыш»ны текә күтәрелешкә илткән хуҗалык рәисе. Авылдашларының җитәкчеләре...

Текә күтәрелеш...

Авыр да син! Сине яуларга Ходай көч-куәт, саулык-сабырлыклар, озын-озак гомерләр бирсен. Сине яулау — зур җиңү. Ватан сугышы солдатлары яулаган җиңү рухы да бар анда. Аның кырларында мәңгегә ятып калганнар өчен дә яшәү вә эшләү бу.

Текә күтәрелеш!

Синең өстеңнән үткәннәргә күз салу һәм киләчәк офыкларга караш ташлау — үзе үк бәхет.

Бу дөньяда шуның өчен дә яшибез түгелме?!.

*1995 елның июль, август, сентябре.*

Шаһинур Мостафин

# ӘМАНӘТКӘ ТУГРЫЛЫК

...Юк, кайгырма, дускай, безнең гомер —
Ил гомеренең тик бер чаткысы.
Без сүнсәк тә, безнең кыюлыктан
Арта бара аның яктысы...
..................................................................
Чикләнсә дә гомер, яшьлек безнең
Эзсез сүнә, диеп уйлама!
Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда...

Әнә шулай дип язган Муса Җәлил 1943 елның октябрендә үзенең «Дуска» дип исемләнгән шигырендә. Әйе, дөньякүләм танылган каһарман шагыйрьнең һәм аның якын дусларының-көрәштәшләренең рухи ныклыклары яктысы еллар үткән саен көчлерәк-тулырак балкый, миллионлаган күңелләргә якыная гына бара. Инде менә М. Җәлилнең тууына 90 ел тулган көннәрдә, без, Муса белән бергә Алманиянең Плетцензее төрмәсендә 1944 елның 25 августында ярты сәгать (көндезге 12 сәгать 06 минуттан 12 сәгать 36 минуткача) вакыт эчендә фашист гильотинасында җырдай гүзәл гомерләре өзелгән Гайнан Кормаш, Фоат Сәйфелмөлеков, Абдулла Алиш, Фоат Булатов, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Атнашев, Сәлим Бохаров кебек фидакарь җаннарны тагын бер мәртәбә олылап, тирән юксыну белән искә алабыз. Аларның исемнәрен, изге дога кебек, һәрчак йөрәк түрләребездә йөртәбез. Дөнья тарихында тиңдәше булмаган олуг батырлыклары алдында, сүзсез калып, башларыбызны иябез...

Заманында Советлар Союзы Герое һәм Ленин премиясе лауреаты дигән югары дәрәҗәдәге исемнәргә лаек булган милләттәшебез — татар халкының бөек улы Муса Җәлил һәм аның көрәштәш дусларының кылган изге эшләрен, якты исемнәрен мәңгеләштерү, һәркемнең күңел түренә җиткерү юнәлешендә Җир шарының төрле төбәкләрендә яшәүче төрле милләт вәкилләре — язучы-эзтабарлар, шагыйрьләр, драматурглар, галимнәр һәм журналистлар (алар безнең Татарстаннан да дистәләп санала) гаять игелекле, саваплы эш башкардылар. Бер үк вакытта, биредә М. Җәлилнең, кырык үлемне кичеп тә, исән калган якын дусларыннан Рушад Хисаметдинов (1992 елның 29 августында Кыргызстанның Ош шәһәрендә йөрәк өянәгеннән 81 нче яшендә вафат булды — авыр туфрагы җиңел булсын...— Ш.М.), озак еллар Үзбәкстанның Каршы шәһәрендә гомер кичергән Фәрит Солтанбәков, Ташкенттан Гарәф Фәхретдинов исемнәрен аеруча тирән ихтирам хисләре белән телгә аласы килә. Җәлил һәм җәлилчеләр турында чын дөреслекне ачуга, көрәштәшләренең үлемсез батырлыкларын, рухи ныклыкларын раслауга алар үзләреннән биниһая зур өлеш керттеләр.

Хәзерге көндә борынгы Казан шәһәренең фронтовик-язучы Гадел Кутуй исемен йөртүче урамында, биш катлы таш йортның бер бүлмәле җыйнак кына фатирында «шушы мең-миллион мәшәкатьле дөньяны сыйдырып», җәлилчеләрнең якты рухларын кадерләп, көрәштәш дуслары турында гомере буе кайгыртыпянып яшәүче 76 яшьлек Әмир Галимҗан улы Үтәшевка да иң җылы сүзләрне

әйтергә тиешбез бүген. Аның белән мине туксанынчы еллар башында атаклы якташым Рушад ага Хисаметдинов таныштырган иде:

— Франциядә фашистларга каршы көрәштә зур батырлыклар күрсәткән легендар шәхес ул Әмир абыең!.. Озак еллар дәвамында хаксызга рәнҗетелгән, «оныттырылган» чын каһарманнарыбызның берсе... Әйдәгез әле, бергәләшеп, күтәрик әле үзен — кайтарыйк әле илгә, халыкка данлы исемен!..

Әмир ага Үтәшев белән соңгы биш ел дәвамында якыннан аралашуым-дуслашуым, андагы искитмәле тарихи язмалар, Франциядән җибәрелгән, КГБ архивларында дистәләрчә еллар яткан документлар белән танышуым нәтиҗәсендә, мин Рушад аганың батыр йөрәкле көрәштәше турында ихластан әйткән сүзләренең хаклыгына тагын бер мәртәбә ирәнтен ышандым...

Сугышка хәтле Ә. Үтәшев, Уфада кооперация техникумын тәмамлап, Татарстанның Арча районы үзәгендә, райпотребсоюзда баш бухгалтер урынбасары, аннары баш бухгалтер булып эшләгән. Фронтка да шуннан киткән. Алабугада политруклар хәзерләүче кыска сроклы курсларны тәмамлаган өлкән лейтенант Үтәшев (батальон комиссары) беренче сугышчан чыныгуны 1942 елның июне азагында Курск өлкәсендә ала. Хәлиткеч-җитди көрәшләрнең берсендә, дошман танклары белән «дуэль» вакытында ул, ике аягы да авыр яраланып, аңсыз хәлдә берничә тәүлек бомба чокырында ята. Һәм шул хәлдә дошман тырнагына килеп эләгә. 1942 елның 6 июленнән аның өчен газаплы әсирлек тормышы башлана...

Баштарак фашистлар Әмир абыйны Киевта, аннары Дарница, Владимир-Волынск лагерьларында яткыралар, соңыннан Польшаның Ченстохов лагерена күчерәләр. Яралары да төзәлеп бетмәгән Әмир абый биредә тифтән егыла. Немец офицеры, аның терелүенә өметен җуеп, мәетләр барагына чыгарып ташларга боера. Әмма дөньяда яхшы адәмнәр дә бар бит әле: таныш бер әсир-санитар Үтәшевнең документларын үлгән чуваш егете Александр Николаевныкы белән алыштырып куя да, Әмир абыйны эчләре китүче авырулар ята торган баракка күчерә һәм тифтән дәвалау чараларын күрә. Шулай итеп, Әмир Үтәшев Александр Николаев (Франциядә «Александр Николас», «Капитан Александр») булып китә. Французлар биргән барлык документларда аның исеме алга таба «Әмир» дип түгел, «Александр» дип телгә алына...



**Рәсемдә:** җәлилче-макизар Әмир Галимҗан улы Үтәшев үзенең хәләл җефете Рәйсә Йосыф кызы белән.

1943 елның маенда Ә. Үтәшевны Польшаның Едлинодагы хәрби әсирләр лагерена — «Идел-Урал» легионына китерәләр. Биредә ул, Рәхим Саттар, Әкрам

Мамлеев ярдәмендә, Муса Җәлил белән якыннан таныша һәм биредәге яшерен оешманың ныклы хәзерлекле бер әгъзасы булып китә.

— Легионда Синең яшерен эш алып баруыңның төп максаты — үзебезнең ватандашларны, ничек кенә булса да, партизаннар ягына алып чыгып, фашистларга каршы бергәләп көрәшү булырга тиеш! — ди Муса Әмиргә. — Мин Сиңа ышанам: башлаган эшебезне дошманны тәмам җиңгәнчегә кадәр дәвам ит... Дөнья бит бу, безне алда нәрсә көтәчәген бер Алла үзе генә белә...

Күңеле дөрес сизенгән икән шагыйрьнең. Озак та үтми, 10 августта, фашистлар М. Җәлилне һәм яшерен оешма әгъзаларының бер өлешен кулга алып, зинданнарга ташлыйлар. 1943 елның августында «Идел-Урал» легионының Көнчыгыш фронтка җибәрү өчен әзерләнгән өченче (штаб) батальонын, ашыгыч рәвештә ике эшелонга төяп (писарь Әмир Үтәшев та шунда була), немецларның көчле сагы астында, Франциянең Югары Луара департаментындагы Ле-Пюи шәһәренә озаталар. (Чөнки баштагы беренче, икенче батальоннардагы легионерлар, фронт сызыгына килүгә үк, немец офицерларын юк итеп, Витебск өлкәсендә һәм Көнбатыш Украинада партизаннар ягына чыккач, гитлерчылар тирән пошаманга төшә). Җәлилчеләрнең Франциядәге яшерен оешмасы житәкчесе буларак, Ә Үтәшев тиз арада француз партизаннары — макизарлар белән элемтәгә керә һәм легионерларның, бераздан, немецларны коралсызландырып, французларның Каршылык күрсәтү хәрәкәтенә бердәм рәвештә кушылуларын тәэмин итә. Бер үк вакытта Совет Армиясе офицеры да, Франция Эчке Көчләре капитаны да, татар һәм рус партизаннарының беренче группасы житәкчесе дә булган Әмир абый (французлар аны, хөрмәтләп, «Комбатан Волонтер» дип йөртәләр, үзләренең иң зур орденнары белән бүләклиләр), ике меңгә якын легионерны, макизарны Туган илгә исән-имин кайтаруда да һәм җәлилчеләрдән Габбас Шәрипов, кан кардәше, авылдашы Нигъмәт Терегулов, француз патриоткасы Мария Дебиезе белән берлектә, дөньяны тетрәткән «Моабит дәфтәрләре»нең беренчесен саклап калуда да чын Егетлек күрсәтә. (Безнеңчә, аларның һәркайсына — хәтта кайберләре инде үлгән булса да! — Россия, Татарстан хөкүмәтләре тарафыннан тиешенчә бәһа бирелергә тиеш. Әнә бит, Бельгия гражданины Андре Тиммермансны, «Моабит дәфтәрләре»нең икенчесен саклап калганы өчен, Совет хөкүмәте 1966 елда «Батырлык өчен» медале белән бүләкләде!)

Ә. Үтәшевне дә «бүләклиләр». Тик — башкача. 1945 елның 1 сентябрендә Әмир Галимҗан улын — Франциядәге ватандашларын Туган илгә алып кайтучы эшелон житәкчесен — совет-герман чигендә армия контрразведкасы кулга ала. Хәрби трибунал башта аны «Ватанга хыянәт иткән өчен» атарга хөкем итә, бераздан бу карар 25 елга иректән мәхрүм итү — каторга белән алыштырыла... Гаделлек, чын дөреслек тантана итсен өчен бик озак көрәшергә туры килә бу батыр йөрәкле, курку белмәс ир-атка. Үзеннән бигрәк, бер гаепсезгә төрмәләргә ябылган, лагерьларга озатылган сугышчан дуслары өчен борчыла, газаплана ул. Фашизмга каршы бергәләп көрәшкән иптәшләренең намуслы исемнәрен кире кайтарырга булышу, инде вафат ветераннарның якыннарына легионер-макизарлар турында чын хакыйкатьне ачу өчен, Әмир ага 1990 елның августында, француз теле белгече Надежда Татаренко белән бергә, махсус рәвештә Франциягә, Баинск, Ле-Пюи шәһәрләренә барып, якташларыбызның каһарманлыкларын раслаучы үтә мөһим гуаһнамәләр (документлар) алып кайтты...

Сүз уңаенда шунысын да әйтеп үтик: Франциядә аны, зурлап, милли Герой итеп каршылыйлар! Югары Луара департаментының «Трибуна» газетасы 1990 елның 3 август санында «46 ел узгач, Россия макизары Баинс янында сугышлар барган урында» дигән мәкаләсендә болай дип яза:

**«...Бу пәнҗешәмбедә Баинс шәһәренең мэры Мишель Декольн әфәнде, Казан кунагы Александр Үтәшевне аэропортта каршыларга дип, Парижга китте... Ярты гасырга якын вакыт узганнан соң, Россия солдаты кайчандыр сугыш кыры булган урыннарга, өч ватандашы күмелгән Вержезак зиратына әйләнеп кайта. Аның кайтуы Каршылык күрсәтү хәрәкәтенә, дөресрәге, Баинс янындагы сугышларга бәйләнгән. Бу хакта, Фернан Буатенең «Түгелгән канның таш шаһитләре» дигән китабын укып, төгәлрәк мәгълүматлар алырга була.**

**...Ле-Пюига килеп урнашкан һәм Каршылык күрсәтү хәрәкәтендә катнашучыларга каршы сугышырга тиешле немец гарнизонында хәрби рус әсирләре дә була. Дөресрәге, легионга көчләп кертелгән, җирле халык «монголлар» дип атаган татар әсирләре алар. Каршылык күрсәтү хәрәкәте ныгый барган шул чорда йөзләп әсир, гарнизоннан качып, Ружак һәм Иссенжо районнарында капитан Сегель житәкчелегендәге макизарларга (партизаннарга — Ш.М.) барып кушыла. Немецларга каршы Баинс шәһәре өчен барган сугышта һәлак булган алты партизанның да өчесе —**

**элекке легионерлар. Менә алар кемнәр: Андрей Аксенов — очучы, капитан; Газизжан Зөбәеров һәм билгесез солдат...**

**Ул сугышта исән калганнарның берсе — Александр Үтәшев. Легионнан качып, ул Каршылык күрсәтү хәрәкәте алып барган көрәшләрдә бик нәтиҗәле катнаша...»**

Шул ук газетаның 13 августта чыккан санындагы «Баинс: 1944 елгы сугышны искә алу» дигән язмага да күз салып үтик:

**«...Баинста һәлак булганнар монументы янына ике йөзләп кеше җыелды. СССРдан капитан Александр Үтәшев килү сәбәпле, быелгы тантана аеруча истәлекле узды. Каршылык күрсәтү хәрәкәте ветераннары, элеккечә, олы кунак янәшәсенә тупландылар...**

**Александр Үтәшев француз партизаннарының мөһим заданиеләрен үти — дошман турында тулы мәгълүматлар тапшырып тора. 1944 елның июль аенда ул, бик күп иптәшләрен ияртеп, макизарлар янына китә. Алар майор Когальон җитәкләгән отрядка барып кушылалар, бергәләшеп, немецларга каршы күп кенә бәрелешләрдә катнашалар...**

**Азатлык килгәннән соң, Франциянең Каршылык күрсәтү хәрәкәте җитәкчелеге бүләкләгән икенче Хәрби Тәрене дә алырга өлгермичә, Александр Үтәшев туган иленә — Советлар Союзына кайтып китә. Әмма анда аны «хыянәтче» дип, 25 елга хөкем итәләр...»**

«Левэй» газетасы шул ук елның 14 август санында чыккан «Каршылык күрсәтү хәрәкәте сугышчылары Александр Үтәшев янында» дигән мәкаләсендә, Әмир ага турында сүзне дәвам итеп, түбәндәгеләрне яза:

**«...Ле-Пюидагы яшерен оешма җитәкчесе Үтәшев СССРда 8 ел буена лагерьларда утырып чыкканнан соң гына реабилитацияләнә. Хәзер инде ул үзенең көрәштәш ватандашларын аклау чараларын эзли...**

**Һәлак булган иптәшләренең каберләренә чәчәк бәйләмнәре куйгач, карт солдат күз яшьләрен тыя алмады...**

**Һәйкәл янында соңгы сүзне Генераль совет вәкиле Прориоль әфәнде әйтте. Ул Үтәшев әфәндегә, көчле рухлы, изге-якты күңелле шәхес булганы һәм Франциянe дошманнан азат итүдә турыдан-туры катнашканы өчен кайнар рәхмәт белдерде.**



1994 елның 25 августында Казан Кремле каршындагы М. Җәлил һәйкәле янында үткән «Хәтер җыены»нда. **Рәсемдә:** Әмир ага Үтәшев *(уртада — эшләпәдән һәм күзлектән)*, Әминә ханым Җәлил *(уңда)*, Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев, Казан шәһәре мэры Камил Исхаков, җәлилчеләрдән Ибраһим Айнатуллов, Фәрит Солтанбәков h. б.

**«Сугыш Сезне бу якларга элек көчләп — мәҗбүри итеп китергән булса, бүгенге иминлек Сезне безнең департаментка олы кунак сыйфатында кабул итәргә ярдәм итте,— диде ул...»**

* * *

Гомумән, Франциягә бу баруында Әмир ага Үтәшев үзенең күптәнге танышы — сугыш чорында Югары Луара департаментындагы француз партизан отрядлары берләшмәсе командующие — отставкадагы подполковник Серж Запальский (псевдонимы — Жевольд) белән очраша, аның ярдәмендә күп кенә мөһим архив документларының ксерокопияләрен алып кайта. Хәер, КГБ архивында да С. Запальский әфәнде язган кайбер хатлар сакланып калган икән. Менә шуларның берсе — 1945 елның 5 апрелендә язылганы:

**«Париждагы Совет Хәрби Миссиясенә.**

**Немец армиясе подразделениеләрендәге хәрби әсирләр арасында Луара округы партизаннары белән ныклы бәйләнеш тотучы кызылармеецлар шактый иде. Аларның күбесе Татар легионын таркатуда булышлык күрсәтә. Соңыннан легионерларның бер өлеше француз партизаннарына кушылды.**

**Командирларын аеруча билгеләп үтәр идем:**

**1. Капитан Андрей Аксенов, 1913 елның 13 декабрендә Мәскәүдә туган. Хатынының адресы: Москва-112, Душевская, 7—11. Рус партизаннарының беренче группасын оештырып, аны 1944 елның 28 июлендә Ружак шәһәре янындагы урманга алып килде. Отряды белән гаять кыю сугышып, Югары Луара округындагы (Көньяк Франция) Баинс шәһәре өчен немецлар белән сугышканда 1944 елның 11 августында батырларча һәлак булды.**

**2. Капитан Александр Үтәшев, 1919 елның 15 сентябрендә Башкортстанның Благовар шәһәре янындагы Каргалы авылында туган, хатынының адресы: Татарстан Республикасы, Арча эшчеләре поселогы, Интернационал урамы, 35 нче йорт. Рус партизаннарының беренче группасын оештыручы һәм аның комиссары булды. Капитан Аксенов белән берлектә, ул группаны макизарлар янына, урманга алып килде. Андрей Аксенов һәлак булганнан соң, капитан Александр рус партизаннары группасын җитәкләде һәм сан ягыннан үстерде.**

**Үтәшев үз отряды белән Баинс шәһәре янындагы бәрелешләрдә катнашты һәм 22 рус солдатын әсирлектән коткарды. Аллегро, Монтан тирәсендә барган сугышларда да үзен уңай яктан нык танытты. Аннары Соги (Югары Луара округы) янында немец солдатларын һәм француз фашистларын эзләп табып, аларны кулга алуда турыдан-туры катнашты. Ле-Пюи шәһәрен азат иткән көндә аның группасында 118 ирекле сугышчы иде инде. Алар һәммәсе дә тәртипле, сугышчан хәрәкәтләр алып бару өчен ныклы әзерлекле иде. Өстәвенә, командирларын да хөрмәт итәләр иде.**

**Капитан Александр Үтәшевның отряды һәрвакыт соңгы тамчы канынача сугышырга әзер булуы һәм кыюлыгы белән француз партизаннарына үрнәк булды.**

**Легионны таркатудагы тырышлыгы өчен, партизаннар отрядын искиткеч оста оештырганы һәм җитәкләгәне өчен, Совет Армиясе офицеры Александр Үтәшевка француз армиясе капитаны дәрәҗәсе бирелде (Франция Эчке Көчләренең Келлерман батальоны буенча 1944 елның 2 августында игълан ителгән 2 нче номерлы приказы нигезендә — Ш. М.) һәм ул Франциянең Хәрби Тәре ордены белән бүләкләнде.**

**Курку белмәс батыр патриотларның ихлас ярдәме нәтиҗәсендә ирешелгән уңышларның аеруча мөһимлеген искә алып, Кызыл Армиянең Югары командованиесенә шул хакта җиткерүегезне сорыйм.**

**Подполковник ЗАПАЛЬСКИЙ».**

1990 елның 11 августында исә подполковник С. Запальский Баинс шәһәре бәйрәменә СССРдан Ә. Үтәшевның килүе хөрмәтенә үткәрелгән митингта, югарыда китерелгән сүзләрен куәтләп, болай ди:

**«...Минем дустым Үтәшевка — капитан Александрга — без тиешле хөрмәтне күрсәтергә бурычлыбыз. Сугышчан дуслыкка тугрылыклы булып калуы белән, үзенең искиткеч кешелекле эш-гамәлләре белән ул безнең һәлак булган иптәшләребез турындагы изге хатирәләребезне яңартты... Нәкъ менә шушында, дөресрәге, Ружакта, 1944 елның 26 июне көнне Вермахт карамагындагы рус солдатларын яңадан сафка кайтару стратегиясе эшләнде. Шуннан соң без Баинста немец-**

**ларны тукмауга керештек. Франция Каршылык күрсәтү хәрәкәтендә бу стратегия искиткеч зур роль уйнады. (Тик — шунысы кызганыч — бу хакта бездә аз беләләр әле.) Шушы уникаль стратегия ярдәмендә без макизарлар отрядларын коралы рус солдатлары (легионерлар — Ш.М.) хисабына тулыландырдык, дошманның сугышчан көчен киметтек, рухын сындырдык. Үзебез исә бик аз кеше югалттык. Әйе, без бу эшне оста башкарып чыктык. Немецларның Генштабы, аның вәкиле майор Шмелинг үзләренең җиңелүләрен танырга мәҗбүр булды... 1944 елның 12 августына чаклы рус әсирләреннән 188 кеше, безнең тарафтан бернинди басым ясалмыйча, үз теләкләре белән макизарлар ягына чыкты. Капитан Александр минем: «Партизаннарга каршы сугышудан баш тартсыннар!» — дигән әмеремне легионга җиткергәч, анда калган легионерлар бу фәрманымны берсүзсез үтәделәр. Немецларның армиясе таркала башлады. Легионерларның макизарлар ягына авышуы хәлне бөтенләй үзгәртеп җибәрде. 1260 партизанга каршы 286 немец белән 36 француз полицае гына торып калды. Шуннан соң алар безгә әсирлеккә бирелергә мәҗбүр булдылар...»**

Серж Запальский, моның белән чикләнмичә, Әмир Үтәшев артыннан күренекле язучы-җәлилче Рафаэль Мостафинга хат та юллый:

**«...Идел-Урал» татар легионында антифашистик оешма бар иде,— дип яза ул.— Ана капитан Александр Үтәшев җитәкчелек итте. Без аны Александр Николас буларак беләбез. 1944 елның мартыннан башлап, Үтәшев әфәнде безнең белән Александр Николас буларак хезмәттәшлек итте. Август башында, ягъни партизан отрядына күчкәч, ул шушы исемгә паспорт алды (немецлар туктаткан очракта күрсәтү өчен). Паспортны аңа мин үзем тапшырдым. Александр Франция гражданины булып санала башлады (моны раслаучы документлар хәзер дә Югары Луара департаменты архивларында саклана. Александр, эз яшерү өчен, «милләте буенча — алжирлы» булып теркәлде).**

Әсирлектән азат ителгәч һәм 352 нче номерлы совет батальоны оешкач, ул ФХК (Франция Хәрби Көчләре) капитаны булды һәм батальон командирының сәясәт буенча урынбасары булып хезмәт итте...»

* * *

Франциядән кайткач, Әмир ага Үтәшев канатларын тагын да җәеп, колачын киңәйтебрәк җибәрде. Радио-телевидение тапшырулары, газета-журнал битләре аша чыгышлар ясап, Идел-Урал төбәкләрендәге хәрби комиссариатлар, дәүләт куркынычсызлыгы комитеты вәкилләре белән элемтәгә кереп, үзенең сугышчан дусларын, легионер-макизарларны эзләүгә керешә. Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев белән дә очрашты ул. 1991 елның 24 декабрендә Казан Кремлендә җәлилче каһарманнардан ун кешене (**үлгәннән соң**) I дәрәҗәле Ватан сугышы ордены белән бүләкләү, искә алу тантанасында да катнашып, үз сүзен әйтте:

— ...Җәлилчеләрнең, легионер-макизарларның һәркайсы турында чын дөреслекне ачыклау буенча без, шул чор шаһитлары, бүген нык лап шөгыльләнмәсәк, иртәгә бу четерекле-мөһим эшкә, йә, әйтегез, үзләре теләп, кемнәр алыныр?! Шуңа күрә, эзләнүләрне тизләтик, асыл исемнәрен кайтарыйк күпне күргән, күпне кичергән мөхтәрәм ветераннарга!

1993 елның 21—24 апрель көннәрендә Ә. Үтәшев Франциядә фашистларга каршы көрәшкән легионер-макизарларның Беренче халыкара конференциясендә дә катнашып, эзләнүләрен тагын да киңрәк җәелдереп җибәрү өчен зур мөмкинлекләргә ия булды. Шул ук елның 6 маенда, Татарстан берләштерелгән Дәүләт музеенда җәлилчеләргә багышланган искә алу җыенында, Әмир аганың тырышлыгы белән, Каршылык хәрәкәтендә катнашучыларның «Кызыл ромашка» исемле ассоциациясе төзелде. Оешманың рәисе (президенты) итеп, бертавыштан, аның үзен сайлап куйдылар. Әлеге ассоциация Идел буе, Урал төбәге республика-өлкәләрендә яшәүче элекке легионерларны, макизарларны, хәрби тоткыннарны, партизаннар хәрәкәтендә катнашучыларны берләштерә...

Әмир Галимҗан улының турыдан-туры булышлыгы белән, легионер-макизарлардан байтак кешегә намуслы исемнәре кире кайтарылды, хәрби бүләкләре тапшырылды инде. Буадан — Ибраһим Айнатуллов, Азнакайдан — Гомәр Асибаков, Кукмарадан — Галимҗан Әхмәтҗанов, Гаян Әхмәтшин, Нургали Шәйдуллин, Баулыдан — Петр Долгов, Казаннан — Ризван Мөхетдинов, Башкортстанның Октябрьск шәһәреннән — Әлмөхәммәт Низаметдинов, Туймазыдан — Фәйзерахман Закиров һ. б. — әнә шундыйлардан...



1995 елның 15 февралендә, М. Җәлилнең туган көнендә, Кукмарада легионер-макизарларның I республика-зона «Хәтер җыены» үткәрелде. Аның барышында Түбән Өскебаш авылы урта мәктәбендәге «Җәлилчеләр музее»нда Кукмара районы хәрби комиссары Заһир Абдуллин яңарак кына исемнәре акланган макизарлардан «Халык мәгарифе отличнигы» Гаян Әхмәтшинга һәм колхозчы Нургали Шәйдуллинга «Бөек Ватан сугышында катнашучы» таныклыклары һәм бүләкләр тапшырды.

* * *

Инде бер матур гадәткә әверелгән: һәр елны 15 февральдә, 9 майда һәм 25 августта Әмир ага һәм аның көрәштәш дуслары Казан Кремле каршындагы Муса Җәлил һәйкәле янына җыелалар, башкарган эшләре турында хисап тоталар, кичекмәстән хәл ителергә тиешле мәсьәләләр турында сөйләшәләр, тоткан кыйблаларын дөреслиләр...

Ниһаять, мәңге эремәс булып тоелган торгынлык бозлары җеби башлады. Җәлил белән бергә Мәңгелеккә күчәр алдыннан батырларның һәркайсы үпкән изге Коръән Казанга әйләнеп кайтты. Үлемсезлеккә атлауларына нәкъ ярты гасыр тулган көндә — 1994 елның 25 августында көндезге 12 сәгатьтә Муса һәйкәле янәшәсендә ун каһарманның һәркайсы барельефтагы сурәт рәвешендә (скульпторы — В. Цигаль) торып басты! Җәлилчеләргә багышланган «Хәтер җыены»нда Әмир ага Үтәшев та чыгыш ясап:

— Бу көнне күрүем белән бик тә бәхетлемен! — диде. — Инде бүген Мусага һәм җәлилче дусларыма шатланып рапорт бирә алам: Едлинода сезгә биргән вәгъдәбезгә тугры калдык, башлаган изге, хак эшебезне ахыргача җиткердек — легионерларның өченче батальоны да ватандашларыбызга, французларга каршы корал күтәрмәде... Шуңа сөенәбез, горурланабыз: Сезнең батырлык онытылмый, йөрәкләрдән-йөрәкләргә, буыннардан-буыннарга күчә бара! Бу юнәлештә без дә — исән җәлилчеләр дә — көчебездән-сәләтебездән килгәнчә үзебездән өлеш кертәбез...

«Исән җәлилчеләр» дигәннән, биредә Гарәф Фәхретдинов, Фәрит Солтанбәков кебек олуг затларны истә тотып әйтә Әмир ага. Аларның җәлилчеләргә багышланган «Кайда минем Илем?» *(1994 ел, 8—9 саннар)*, «Үлем сәгатен көткәндә» *(1995 ел, 5 сан)* исемле документаль язмалары иң элек безнең «Казан утлары» журналында дөнья күрде. Рушад Хисаметдиновның магнитофон тасмасында калган аһәңле тавышы, аның атаклы сынчы-рәссам Бакый ага Урманче

белән булган мавыктыргыч-жанлы әңгәмәләре исә, галимә Флора ханым Урманче белән әдибә Азалия ханым Бадюгинаның уртак тырышлыгы нәтиҗәсендә, журналыбызны укучыларга «Дусларымның васыятен үтәдем» дигән документаль кыйсса рәвешендә барып иреште *(1995 ел, 9 сан)*. Әмир ага Үтәшев та бу өлкәдә җиң сызганып эшли хәзер... Күптән түгел генә аңа Франция хөкүмәте, ил алдында күрсәткән олы хезмәтләрен искә алып, махсус пенсия билгеләде. Бу хакта аңа Франциянең Россиядәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Пьер Морель әфәнде хәбәр итте (әлеге илче 1995 елның апрелендә Казанда «Француз мәдәнияте атналыгы» барган көннәрдә Әмир ага белән махсус очрашып, кирәкле документларны хәзерләп алып киткән иде — рәхмәт үзенә, сүзендә торган!) Әнә шулай, еллар үтсә дә, Франциядә Әмир ага Үтәшевны — Җәлил әйткәнчә, «эш күрсәткән ир»не онытмыйлар — ихлас күңелдән олылыйлар!

Бүгенге көндә дә гаҗәеп тынгысыз тормыш белән яши Әмир ага. Франциядә дошманга каршы иңгә-иң торып көрәшкән якын дусты Р. Хисаметдиновның үләр алдыннан аңа язып калдырган хат-васыятьнамәсен һәрвакыт хәтерендә тота ул.

«Кадерле Әмир! — дип язган Рушад ага. — **Газраил минем җанымны алырга берничә мәртәбә омтылыш ясап карады инде. Шуңа күрә Сиңа — ихлас дустыма — үтенеч-теләгем зурдан: йөрәгең типкәндә, башың эшләгәндә, колагың ишеткәндә, аяк-кулларың йөргәндә безнең легионер-макизар дусларыбызны (исәннәрен дә, үлгәннәрен дә!) барлаудан һәм аларны аклау өчен көрәшүдән һич тә туктама! Мин Сиңа ышанам...»**

Муса Җәлил кебек, Рушад дусты да аңа шундый зур ышаныч белдергәч, үтенечен җиткергәч, ничек тик кенә ятсын инде Әмир ага?! Һәм ул йокы-ялны онытып, көрәштәш дусларының язмышларын җиңеләйтү өчен, югары оешмаларга хатлар яза, аларның чын патриотлар икәнлеген раслаучы тарихи документларны туплап җибәрә, кирәк икән — теге яки бу төбәккә үзе үк барып чыга. Соңгы вакытта гына Ә. Үтәшев, шул максаттан, Казан — Чаллы — Азнакай — Баулы — Октябрьск — Туймазы — Бүздәк — Уфа — Казан маршруты буенча йөреп кайтты. Аңарчы Франциянең Баинс шәһәре янында барган сугышларда батырларча һәлак булган якын дусты — үз отряды сугышчысы Газизҗан Зөбәеровның гаиләсе янында — Башкортстанның Кыйгы районында булган иде. Татарстанның Буа районындагы Янтуган, Кукмара районындагы Зур Сәрдек, Ташлы Елга авылларында яшәүче макизарлардан Ибраһим Айнатуллов, Гаян Әхмәтшин, Нургали Шәйдуллиннарның намуслы исемнәрен кайтару өчен, шул төбәкләргә дә барып чыкты, очрашулар үткәрде. Хәзер исә Әмир ага Әстерханнан Хәбибулла Моратов, Башкортстаннан Әкрам Минһаҗетдинов, Татарстанның Буа районыннан Фазыл Хәйруллин, Әтнәдән Мөбәрәкша Хәсәновны аклау буенча ныклап шөгыльләнә. Бу эшләрнең һәммәсендә аңа кешелекле һәм уңган тормыш иптәше — якын дусты һәм киңәшчесе Рәйсә ханым, үз мәктәпләрендә «Елның иң яхшы мөгаллимәсе» исеменә лаек булган кызлары Әлфия, оныгы — яшь шагыйрә Кадрия бик теләп булыша.

Гомумән, бу күркәм гаилә бар яктан күпләрне сокландырып яши. Заманында Әмир абый, аклангач, Казан финанс-икътисад институтын тәмамлап, төзелеш оешмаларында баш бухгалтер буларак тырышып эшләгән — мактаулы исеме телдән төшмәгән. Рәйсә ханым исә, дүрт дистә ел дәвамында балаларга тәпле белем-тәрбия биреп, мәгариф өлкәсендә уңыш казанган. Инде күптән лаеклы ялда булсалар да, хәзер дә аларның һәр көне (кайчакта — төннәре дә!) адәм балаларына игелек кылып үтә. Әмир ага белән Рәйсә ханымда кешеләрне ярата белү таланты бар! Әтнәдә яшәүче һәм Үтәшевларның кунакчыл фатирына еш килеп йөрүче мөгаллимә Мәрзия ханым Хәсәнова (мәгълүм макизар М. Хәсәновның хатыны) әйтмешли, «бирелән җанга — җылылык, күңелләргә яктылык алып, Хакыйкатьнең кайчан да булса бер тантана итәчәгенә нык ышаныч белән чыгасың!..»

Соңгы вакытта Франциядәге Каршылык күрсәтү хәрәкәте ветераннарының «Комбатан Волонтер» ассоциациясе Әмир Галимҗан улы Үтәшевны, сугыш елларында фашистларга каршы көрәштә күрсәткән зур батырлыклары һәм макизарларны аклаудагы тынгысыз эшчәнлеге өчен, үзләренең «Почет билгесе» белән бүләкләде. Франциянең танылган фоторәссамы Нуак Каррау әфәнде, Париждан махсус килеп, фоторәсемгә дә төшереп алды Әмир аганы Рәйсә ханым белән.

«Комбатан Волонтер» ассоциациясенең Мәскәүдәге оешмасы җитәкчесе Олег Озеров, җәлилчеләрдән Фәрит Солтанбәков (хәзер Казанда яши), Гарәф

Фәхретдинов та атаклы макизарны зур бүләккә лаек булуы белән беренчеләрдән булып котладылар. Исән булса, Рушад Хисаметдинов та, изге әманәткә тугрылыгы өчен, Әмир дустына үзенең олы рәхмәтен белдерер иде...

Түбәндәге шигыремне исемнәре югарыда телгә алынган җәлилче каһарманнарга багышлыйм.

## Сез дә бит Җәлил шикелле...

Сез — Җәлилнең үзен күргән,
 Сез — Җәлилдән көч алган.
Шуңа күрә Тәмуг утын
 Сез исән-сау кичәалган.
Сез бит Җәлил турындагы
 Күптән көткән хәбәрне
Алып кайтып, үзгәрттегез,
 Илдәге күп хәлләрне.
Кара көчләр җиңелделәр,
 Балкыды нур — яктылык!
Җәлилчеләрнең йөзләре
 Бердән китте яктырып!
Сез дә бит, Җәлил шикелле,
 Батырлык эшләдегез:
Дусларыгызны акламый
 Иярдән төшмәдегез!
(Сез Хаклыкның Акбүз атын
 Ныклап иярләдегез,
Имансыз-кыйбласызларга
 Һич тә иярмәдегез!)
Сез бит гомерегез буе
 Дуслар өчен яндыгыз,
Яктыртып кара төннәрне
 Һәрчак алдан бардыгыз!
Сездән кучкән җылылыктан
 Терелде сулган гөлләр...
...Сезнең хакта, изге җаннар,
 Гасыр гасырга сөйләр!

(Сәхифәдә **Мидхәт ШАКИРҖАНОВ**, **Евгений КАНАЕВ** һәм **Владимир ВЫРУПАЕВ** фотолары файдаланылды.)



# ӘТИЕМ ӘСӘРЕ...

ҖӘДИДЧЕ ШАГЫЙРЬ РӘХИМ САТТАР ИҖАТЫ ТУРЫНДА
АНЫҢ УЛЫ, ФИЛОСОФ ИЛ САТТАР УЙЛАНУЛАРЫ

Әтинең кульязмаларын мин беренче тапкыр сугыш бетеп унөч-ундүрт еллар үткәч күрдем. Моңарчы аларның бар икәнен дә белми идем. Арада киптергеч кәгазе кисәгенә карандаш белән ашыгып язып куйган мондый юлларны очраттым:

Үпкә чертеп, йөрәк ярып
Көн үлә бит көн саен,—
Таба алмам бер җаен!

Ул чакта мин яшь идем әле. Кара диңгездә хәрби флотта җиде ел хезмәт итеп кайтып, университетта укып йөрим. Бу шигырь миңа сәер булып күренде. Мин бит филология факультетында укыйм. Шуңа күрәдер, мин бу шигырьне татар такмакларына охшатып алдым. Аларда да бит беренче өлеше икенче өлешенә ничектер туры килеп бетми. Ләкин, барыбер, шул ике өлеш арасында ниндидер аңлап бетермәслек бәйләнеш була. Мәгънәви яктан турыдан-туры бәйләнеш булмаса да, беренче өлешне укымасаң, икенче өлеше дә тулысынча ачылып бетми. Беренчесе икенчесенең яңгырашын көчәйтеп тора. Әтинең шигырендә дә шул ук хәл иде.

... Рафика апа, әтинең сеңлесе, ул чак Казанда яши иде. Мин,студент кеше, билгеле инде, аңа кереп йөрим. Шул бер кергәндә ул миңа:

— Әтиеңнең кульязмаларын ник алмыйсың?— дип аптырашта калдырды. Карале, әтинең кульязмалары бар икән бит! Без сугышка кадәр Зур Галактионов урамында тора идек. Әти, әби һәм мин. 1941 елны әти сугышка киткәч, без әби белән фатирны ташлап, Рафика апага — Яңа Кадый авылына киттек. Шуннан соң мин Казанга 1955 елны гына кире әйләнеп кайттым. «Әтидән нинди дә булса әйбер калган микән?» дигән фикер башыма килгәне дә булмады. Чөнки без Хәдичә әбием белән квартирны ташлап киткәннән соң аны немецлардан качып эвакуациягә килгәннәргә биргәннәр. Әнә шулар әтинең кульязмаларын саклап калганнар да инде. Бөтенесенме, әллә инде бер өлеше генә сакланып калганмы — монысы миңа бу көнгә кадәр билгеле түгел. Боларына да бик канәгать. Белмим, алар әтинең язу өстәле тартмаларында яткан микән, эвакуациягә килгәннәр аларның кыйммәтле әйбер икәнен белеп иске чемоданга тутырып куйганнар микән — ләкин чүпкә түкмәгәннәр. Шуның өчен аларга зур рәхмәт! Байтак еллар алар шул иске чемоданда, Рафика апаның чоланында ятканнар. Менә, ниһаять, алар минем кулыма килеп керделәр.

«... Көн үлә бит көн саен,— Таба алмам бер җаен!»— бу юлларны беренче тапкыр укыганда ук мин әтинең күңелен тоеп алган кебек булдым. Алар шундук хәтеремә сеңеп калдылар. Вакыт-вакыт, җае килгән чакта, күңелемдә кабынып китеп, алар яңадан калкалар иде. Һәм мин аларның мәгънәсенә төшенә бардым. Сиңа да, укучым, бу юлларны хәтереңә салып калырга тәкъдим итәм. Тормыш юлыннан атлый-атлый син аларның серенә төшенә барырсың. Күңел әшчәнлегенең аерылгысыз бер сыйфаты булып китәр алар.

Урта мәктәптә әти Уфада укыды. Аның тел һәм әдәбият укытучысы Нәкый ага Исәнбәт булган. Иҗат эше белән шөгыльләнү хыялы да шуннан кабынып киткән булса кирәк. Аннары әти Донбасста да эшләп кайта, Башкортстанның

Учалы районында урманчы булып та эшләп ала... Шунда ул егерме яшендә (1932 елны) өйләнә, аннары Даурия дигән якта хәрби хезмәттә була, 1937 елны Казанга гаиләсе белән килә, монда да берничә урында эшләп ала. Ниһаять, «Яшь сталинчы» газетасына эшкә урнаша.

Язучының, шагыйрьнең эше жиңел түгел шул. Бер яктан тормышны сиземли белү һәм язучылык һөнәренең югары таләпләре, ә икенче яктан — тормышыңның төпләнмәгәне, акча табу, гаиләңне туйдыру мәсьәләләре. Анысы гына да түгел: кайберәүләр бар шартлары булып та азапланалар. Чөнки үзең язган беркайчан да тулысынча канәгатьләндерә алмый. Кабат-кабат эшләп чыгып та, үз язганың белән тулысынча канәгатьләнә алмыйсың әле...

Иҗат эше ул — бик тә үзенчәлекле эш. Бер кабынып китсәң, күңел үз эшчәнлеген табигый ташкын сыман, синнән сорап та тормастан башкара тора. Күңел эшчәнлегенең ниндидер бер сәер мөстәкыйльлеге аякка баса. Һәм син бу эшчәнлекне туктата алмыйсың. Синең алдыңда киң мәйданлы чынбарлык яши. Шул чынбарлыкның агымына чумган синең күңелең. Һәм аның эчтәлеген айкап барган сымак ул. Күңел чынбарлыкның мәгънәви эчтәлеген актарып чыгып, үзе дә яңа күренешләр тудыра. Күренешләр син үзең көтмәстән, кинәт пәйда булалар. Тормыш күренешләренең мәгънәви офыгын ертып чыгып, син яшәешнең әле беркем тоймаган, кичермәгән тирәнтен мәгънәвилеген күрә башлыйсың. Һәм шул яңа мәгънәле күренешләрне сурәтләп бирәсе килеп тора...

Ә бит вакыт тар. Көн саен эшкә барасы бар. Анда бөтенләй икенче мәшәкатьләр, мәсьәләләр... Аларны чишәр өчен син җан көчеңне җигәргә тиеш буласың.

Әйе, иҗади яшәеш — ул бөтенләй икенче яшәеш. Ул — күңелең үз көче белән тудырган тормышта яшәү. Көндәлек яшәешеңнән ваз кичү. Шулай шул — ваз кичү! Үзеңнең шәхси тормышыңны инкяр итеп син яңа мәгънәви офыклар ача аласың. Синең күңелең яшәеш эчтәлегендә кемгә караганда да ныграк утырырга тиеш. Чөнки яшәеш агымының мәгънәви юнәлешен сиземләү зарур. Аның эшчәнлегенең асылы шунда да инде: яңа мәгънәви офыклар ачу! Кайчак шундый теләк туа: котылырга иде бу тормыш мәшәкатьләреннән! Котылырга иде көннең тарлыгыннан!

Ирландия католиклары: «Вакытны Алла иҗат иткән. Ул аны мул итеп иҗат иткән», — диләр икән. Вакытка караш һәм вакыт белән кеше шәхесенең мөнәсәбәтләре чор үзенчәлегеннән һәм аның идеологиясеннән килә. Һәм шул чор билгеләгән шәхеснең урыныннан. Христиан дине исә ике төрле вакыт турында сүз йөртә: мәңгелек вакыты һәм бу фани дөньяның вакытлы гына тормышы. Әһәмияткә ия вакыт — мәңгелек вакыты. Бу дөньядагы вакытның кадере юк. Кеше шәхесенең эше дә әллә ни әһәмияткә ия түгел булып чыга. Эш — вакыт агымыннан аерылгысыз. Бу дөньяга хас вакытның икенчел булуы фани дөньядагы яшәешне дә икенчел итеп һәм кеше кылган эшләрнең дә әһәмиятен түбәнсетеп күрүгә китерә икән.

Дини идеология кешене бу дөньяның иҗади көче итеп күрми. Шунлыктан шәхеснең вакыт белән мөнәсәбәтен билгеләгәндә ул вакытның шәхес өчен иң кадерле нәрсә икәнлеген танымый.

...XX гасырның утызынчы еллары. Казан. Әтием вакыт тарлыгыннан интегә. Вакытның бу дөньяда иң кадерле нәрсә икәнен бөтен җан көче белән тоя ул. Чөнки бу тормышны, бу чынбарлыкны ул үзе иҗат итә. Чор билгеләгән урыны шул аның. Заман тудырган идеология дә — шул. Чор гади кешедән, һәрбер кешедән иҗатчы булуны таләп итә.

### Көн үлә бит көн саен!

Шәхеснең вакыт белән мөнәсәбәтләренең үзенчәлеге дә уйландыра... Син үзеңне вакыт агымыннан аерып күрә дә, сиземли дә алмыйсың. Вакыт агымы һәм күңел агымы берләшәләр. Күңел чынбарлыкны иҗат итә башласа, әнә шулай була. Синең эшчәнлегеңнең шул чынбарлыкны иҗат итүе булган чакта. Күңел вакыт агымын сиземли башлый. Чөнки син чынбарлыкның нинди буласын, нинди булырга тиешлесен чамалый башлыйсың. Үз алдыңда куйган максатларың яңа чынбарлыкны булдыруга багышланган булалар. Вакыт агымы синең күңелеңнең эшчәнлегенең аерылгысыз бер өлеше булып китә. Вакыт агымына сыярга тырыша башлыйсың.

Кабатланып торган эшчәнлек исә вакытны үзенең бер аерылгысыз күренеше итеп сиземләми. Иҗат итү кешенең төп сыйфаты булып торса да. Чөнки кабатланып торган эштә вакыт агымы һәм кешенең аны тою хисе әле берләшмәгәннәр. Иртә-кичне генә белү әле ул вакыт агымын сиземләү түгел.

Күңел эшчәнлеге бай булган чакта гына һәм ул яшәешнең торышы белән тыгыз мөнәсәбәттә булганда гына күңел... вакыт агымының бармак аша үтеп киткәнлегенә өзгәләнә башлый. Димәк, кеше үз табигатенең асылын сиземли башлаган чакта гына. Үзенең төп сыйфатларын үзе уйлап чыгарган Иҗатчыга биреп, шул Иҗатчы белән сокланмаганда. Вакытны тирәнтен тою — үз-үзеңә кире кайту белән бер. Чөнки чын иҗат эшенең чиге юк, очы-кырые юк. Төбе юк. Чын иҗат эше кешенең бар көчләрен таләп итә. Көчләренең, сәләтләренең чиксез бай булуын. Дөнья чиксезлеге белән тиң булуын. Шуңа күрә утызынчы елларның кешесе вакыт белән тирәнтен дә, үзгә дә мөнәсәбәттә торган. Чор бу мөнәсәбәтнең үзенчәлеген үзе таләп иткән. Шәхеснең дөнья белән мөнәсәбәте шундый булган.

Көн үлә бит көн саен,—
Таба алмам бер җаен.

Язучы иҗаты... Әдип тормыш агымына битараф иҗатчы түгел. Матур тормыш турында сайрап яшәү дә түгел. Булган тормышка карата хөкем чыгару да түгел. Язучы эшчәнлегенең табигатеннән килгән төп максат — кешенең, кешелекнең яшәеш мәгънәвилеген сиземләп алу, шул мәгънәвилекне халыкка да сиземләп алырлык итеп тасвирлап бирү. Яшәеш мәгънәвилегенең дөреслеген, дөрессезлеген чамалау. Дөреслеген күңел эшчәнлеге белән раслау. Димәк, дөрес мәгънәвилекле тормышны халкы белән берлектә иҗат итү. Чөнки кеше бит ул — мәгънәвилеккә корылган җан. Кешелекнең яшәеше дә мәгънәвилеккә корылган. Шәхес үзенең бу мәгънәвилекле табигатен җәмгыятьтән ала. Бу дөньяга килгәч. Димәк, аның җанының мәгънәви эчтәлеге дөреслеккә корылмаган да булуы мөмкин. Димәк, җәмгыять тә үз тормышын булдырганда дөрес мәгънәвилекне бертуктаусыз эзләргә тиеш булып чыга. Язучы яшәешнең мәгънәви офыкларын ертып чыгып, яңа мәгънәви офыклар эзли, алга барган яшәешнең, вакыт агымында аккан яшәешнең мәгънәви эчтәлеген күңеле белән, күңел эшчәнлеге белән сиземләп ачыкларга омтыла. Димәк, аның күңеле, күңеленең эшчәнлеге үзен вакыт агымыннан аергысыз сиземли. Чөнки ул вакыт агымында узып барган яшәешне иҗат итеп бара:

Үпкә чертеп, йөрәк ярып
Көн үлә бит көн саен!
Таба алмам бер җаен...

**Ил САТТАР**



Солтан Шәмси

# ГАЛИҖӘНАБ КИТАП ЗАРЛАРЫ

**Татар әдәбияты кызыклы шәхесләргә бай. Бу айда үзенең 50 яшен тутырган язучы Солтан Шәмси дә, һичшиксез, нәкъ шундыйлардан.**

**Биектау районының Юртыш авылында туып, яшьтән үк авыр хезмәт тәмен татып үскән егет Казанда һөнәр училищесын тәмамлагач Казан һәм Мәскәү заводларында да эшли, Армия сафларында да булып кайта, аннан соң Мәскәүдәге Әдәбият институтын да уңышлы тәмамлый.**

**Солтан Шәмси иҗат иткән әсәрләр «Көмеш чылбыр» (1984), «Җәяүле буран» (1988), «Ут хәйләсе» (1994) һ. б. китапларда басылып чыкты. Ул тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли. Аның тәрҗемәсендә Г. Ибраһимов һ. б. татар әдипләренең әсәрләре рус телендә дөнья күрде.**

**Соңгы елларда Солтан Шәмси мәшһүр сәяхәтче Әхмәт ибне-Фазлан язмаларын эшкәртеп чыгарды, Ризаэтдин Фәхретдиннең «Алтын Урда ханнары» исемле хезмәтен русчага тәрҗемә итте.**

**Язучы, халкыбызның бай тарихын өйрәнеп, аның кызыклы сәхифәләрен, каһарман шәхесләрен бүгенге укучыга җиткерү максаты белән зур-зур фәнни-публицистик мәкаләләр дә яза һәм аларны көндәлек матбугатта бастыра тора.**

**Хәзер Солтан Шәмси Татарстан китап нәшриятының фәнни-популяр әдәбият редакциясе мөдире булып эшли һәм халкыбызның милли аңын үстерү юнәлешендә зур планнар белән яши, актив иҗат итә.**

**Тынгысыз җанлы һәм керсез күңелле каләмдәшебезне юбилее белән кайнар котлыйбыз һәм укучылар игътибарына аның яңа хезмәтен тәкъдим итәбез.**

## I

1992 елда республикабыз җәмәгатьчелеге татар басма китабының 270 еллык юбилеен билгеләп үтте. Шул көннәрдә әлеге олуг датага багышланган фәнни-гамәли конференция дә үткәрелде, соңрак Милли китапханә тырышлыгы һәм матди ярдәме белән аның материалларын Татарстан китап нәшрияты ике телдә бастырып та чыгарды. (Китапка хитаб (Слово о книге) Казан. 1994).

Әйе, татарның милли китабы озын да, фаҗигале дә, казанышлары белән горурланырлык та юл узган. Тик нәрсә соң ул милли китап? Китап белгече академик Ә. Кәримуллин аны болай билгели:

«...тегe яки бу халык тарафыннан чыгарылган барлык басмалар — кайсы телдә булуына, авторның кайсы милләт вәкиле булуына карамастан — шул халыкның милли китабы дип саналырга хаклы».

Димәк, китапның фәкать татар телендә басылып чыгуы әле төп күрсәткеч түгел. Бу очракта аның татарлар тарафыннан бастырып чыгарылуы һәм татар халкына хезмәт итүе мөһим.

Татар милли китабының бай тарихын барлый башласаң, татарлар тарафыннан чыгарылган бик күп китапларның башка халыкларга, бигрәк тә кардәшләребез төрки халыкларга да хезмәт иткәнлеген күрәбез. Алай гына да түгел, татар милли китабы татар теленнән башка гарәп, фарсы һәм урта гасырларда киң кулланышта булган — «төрки» телдә дә иҗат ителгән. Шуңа күрә дә кайбер халыклар татар китабын үзләренең милли китабы дип саныйлар. Аның белән горурланалар. Бу исә татар китабының билгеле дәверләрдә гаять зур роль уйнаганлыгын күрсәтә.

Әмма татарда басма китап барлыкка килгәнче үк, халыкның рухи ихтыяҗларын 9 гасыр дәвамында кулъязма китап канәгатьләндереп килгән. Билгеле булганча, китапка ихтыяҗ тусын өчен ул халыкның язуы булуы, укый-яза белүе, белемгә сусавы зарури. Ә төркиләрдә алфавит моннан 3 мең еллар элек үк барлыкка килгән. Күптән түгел матбугатта күренеп киткән хәбәргә караганда, галимнәр, ниһаять, борынгы этруск язуларын уку бәхетенә ирешкәннәр һәм ул язулар төрки телдә булып чыккан.



Монголиянең Селенга елгасы буендагы Налайха станциясе янында табылган Тоньюкук ташъязмасы.

...Этрусклар безнең эрага кадәр 7 нче йөздә үк Үзәк Италиядә (хәзерге Тоскана өлкәсе) гаять көчле һәм чәчәк аткан дәүләт төзүгә ирешәләр. 12 шәһәр-дәүләттән торган этрусклар союзы соңрак Рим тарафыннан буйсындырылса да, соңгысы бу цивилизациянең бәрәкәтле йогынтысын нык үзләштерә. Ә бит байтак заманнар Аурупа галимнәре төрки халыкларны кыргыйлыкта, артта калганлыкта гаепләп килделәр, хәтта «кешелек дөньясының соры кортлары» («трутни человечества») дип тә атадылар. Тик вакыт үзенекен итә, ялган мифлар акрынлап юкка чыга бара...

Шулай да төркиләрдәге безгә билгеле беренче китап — таш китап булган дип әйтәсе килә. Хәзерге Монголия җирләрендә табылган Күлтәгин, Мәгыйлән хан, Тоньюкук, Билге каган кебек затларга куелган рун язулы ташлар күк төрекләрнең тарихын тасвирлау белән беррәттән халыкка үгет-нәсихәт тә биргән, публицистик әсәр буларак та аңа хезмәт иткәннәр. Ачык даладагы бу ташны һәркем килеп укый алган. Формасы үзгә булса да, башкарган вазифасы ягыннан ул китап хезмәтен үтәгән.

Коры сүз сөйләмәс өчен Күлтәгин һәм Мәгыйлән хан хөрмәтенә куелган таш язмадан бер өзек тә китереп үтик (732 ел). Анда бөек төрек дәүләтенең җимерелүен автор менә нинди сүзләр белән ачынып яза (борынгы төрки телдән тәрҗемә):

«Төрек халкының бөтенесе шулай диде:
«Дәүләтле халык идем.
Кайда инде дәүләтем?
Хәзер кем дәүләте өчен тырышам?
Каганлы халык идем.
Кайда каганым?
Нинди каганга хезмәтемне, көчемне бирәм?»

Бу сүзләр, моннан 1263 ел элек әйтелсәләр дә, шактый гыйбрәтле һәм заманча яңгырыйлар.

Рун язуы шулай ук зур төрки дөньяның бер кыйпылчыгын тәшкил иткән болгар бабаларыбызга да билгеле булган. Төньяк Кавказ, Азак, Идел буйларында табылган әйберләрдә дә руник язмаларның очравы шул хакта сөйли. Дөрес,

гадәттән тыш зур каганлык — империянең чигендә яшәгән болгар кабиләләрендә руник язу актив кулланышта булган дип әйтүе кыенрак. Болгарлар төрки дөньяның көнбатыш чигендә, үзәктән еракта яшиләр.

Без белгән кульязма китап болгарларга ислам дине белән килеп керә. 922 елда Идел Болгариясендә исламны рәсми дәүләт дине буларак кабул итү Коръән, гомумән Шәрекъ китабы таралуга зур мөмкинлекләр ача. Моңа хәтле үк ислам диненә күчә башлаган болгар кавемнәре тормышына бу вакыйга гаять зур үзгәрешләр кертә. Шәрекъ илләреннән китерелгән кадерле китапларны күчереп язу шушы дәвердә башланып китә. Шулай итеп, болгарларның үз китап культурасына беренче адымнар ясала. Ул дәвердә күчерелгән китапларның күпчелеге дини ихтыяҗларны канәгатьләндерүгә хезмәт иткән. Әмма тора-бара болгарларның үз язучылары, галимнәре дә барлыкка килгән. Мәсәлән, болгар галимнәреннән шәригать белгече Әхмәд Болгари (XI йөз), тарихчы Йагкуб ибне Ногман (XII йөз) һәм тагын кайбер шәхесләрнең исемнәре тарихта сакланып калган. Ә инде XIII йөз башында үлемсез «Кыйссаи Йосыф» поэмасын иҗат иткән болгар шагыйре Кол Галинең исеме һәрберебезгә билгеле.

Ни кызганыч, бу дәвердән безгә бер генә китап та килеп җитмәгән. Шуңа да карамастан, безгә болгар китабының нинди(рә)к булуын күз алдына китерү кыен түгел, чөнки мөселман дөньясы белән тыгыз бәйләнештә яшәгән Идел Болгарстаны үз китабын Шәрекъ китабыннан үрнәк алып эшләгән. Шулай монгол яуларына кадәрге чорда ук Идел Болгарстаны китаплы, мәгърифәтле, югары мәдәниятк(ә) ия ил булып әверелә.

Тарихыбызның Алтын Урда дәверендә китап культурасы тагын да зур уңышка ирешә. Идел буенда булып киткән гарәп тарихчысы, сәяхәтче Ибне Гарәбша сүзләре белән әйткәндә ул заманда мәмләкәтнең башкаласы «Сарай (Бәркә) фәннең һәм бәрәкәтнең бергә тупланган җиренә әверелде, һәм кыска вакыт эчендә анда голәмаларның, бөек шәхесләрнең, филологларның һәм осталарның һәртөрле атаклы затларның яхшы өлеше җыйналды. Мисырның (Египет) күп халыклы өлешләрендә дә, аның авылларында да мондый хәлнең күрелгәне булмады[1]». Әлбәттә, Сарай Бәркәгә атаклы кешеләр мөселман илләреннән генә агылмыйлар — гаҗәеп бай һәм төзек кала, гөрләп торган мәдәният үзеге һәркемне үзенә тарта, язмышын сынап карарга чакыра.

Сарайда җирле халыкның үзеннән чыккан язучылар, галимнәр, күренекле дин әһелләре, китап күчереп язучы хаттат-каллиграфлар, алтын куллы һөнәр ияләре аз булмаган. Алтын Урданың бер өлешенә әверелгән Болгар олысыннан да атаклы кешеләр чыккан. Бу очракта исемнәр санап китү белән мавыкмыйча мәшһүр «Нәһҗел — Фәрадис» әсәрен иҗат иткән Мәхмүт бине Гали Болгари-Сараи исемен атау да җитәдер. Мәдәният һәм гыйлем үзәгенә әверелгән Сарай Бәркә шәһәрендә, гомумән, дәүләтнең төрле олысларында китапның нинди зур роль уйнавын, китап культурасының нинди камиллеккә ирешүен күз алдына китерүе кыен түгел.


Әмма ни аяныч, безгә тарихыбызны, гомумән мәдәниятебезне барлаган чакта еш кына «юк ителгән», «яндырылган», «көлгә әйләнгән», «сакланмаган» дигән сүзләр кулланырга туры килә. Үткәнебез зур һәм катлаулы булу белән бергә анда кайтара алмаслык югалтулар, фаҗигале сәхифәләр дә җитәрлек. Азмы безнең тарихта исемнәре генә сакланып калган затлар, әсәрләр, ядкярләр?! Ә китап — аеруча чыдамсыз, бик тиз юкка чыга торган нәрсә. Аны әле кадерләп, тиешле шартларда саклаганда да таманга туры килә. Ә инде бу хәзинәләр ятлар кулына калса, бигрәк тә мөселман мәдәниятен күрә алмаучы фанатиклар хөкемендә булса, аларның аңлы рәвештә юк ителгәнлеге беркем өчен дә сер түгел. Гөрләп торган Сарай каласы урынында хәзерге көндә япан кыр. Патша Федор Иванович заманында (Явыз Иванның улы, 1598 елда вафат) Сарай шәһәре биналарын җимереп, аның кирпечләреннән Әстерханда урыс ныгытмасы-крепосты корыла. Таш биналар, хәтта зираттагы кабер ташларына хәтле казып алынып, салына торган биналарның нигезенә түшәлгәндә кәгазь-күннән ясалган Галиҗәнап Китап ничек исән калсын!

Ә барыбер калган, аз булса да сакланган! Халык аны җаны кебек саклаган, кая күчеп китсә, шунда үзе белән алып барган, кадерле ядкяр итеп буыннан буынга тапшырган. Һәм ул китапларны халкыбызның фидакяр затлары — галимнәр, зыялылар, аңлы кешеләр җыя барган. Бүгенге көндә безгә билгеле күп китаплар — шушы изге эшнең нәтиҗәсе.

---

[1] Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. т. 1. Спб., 1884, 463—464 б.б.

Казан ханлыгы егылгач татарның милли китабы бигрәк тә авыр хәлдә кала. Татар халкының дәүләтчелеге юк ителәә, мәдәнияте, кинәт җир убылган сыман, упкын төбенә тәгәри. Һәм шушы һәлакәтнең нәтиҗәсен без бүгенге көндә дә бик ачык сизәбез. Әдәбият, тарих, гомумән фән-мәдәният өлкәсендә эшләүчеләр яхшы белә — татарда нәрсәгә тотынсаң шул юк. Булмаган түгел, юк ителгән,



| Начертание | Значение | | Начертание | Значение | |
|---|---|---|---|---|---|
| | русск. | лат. | | русск. | лат. |
| [illegible] | а, ӓ | a, ä | [illegible] | ä | ä |
| [illegible] | $б^1$ | $b^1$ | [illegible] | нт | nt |
| [illegible] | $б^2$, ӓ | $b^2$, ä | [illegible] | нч | nč |
| [illegible] | ҕ | ɣ | [illegible] | о, у | o, u |
| [illegible] | г | g | [illegible] | ӧ, ӱ | ö, ü |
| [illegible] | $д^1$ | $d^1$ | [illegible] | п | p |
| [illegible] | $д^2$ | $d^2$ | [illegible] | $р^1$ | $r^1$ |
| [illegible] | з | z | [illegible] | $р^2$ | $r^2$ |
| [illegible] | ы, і | y, i | [illegible] | $с^1$ | $s^1$ |
| [illegible] | $j^1$ | $j^1$, ɪ | [illegible] | $с^2$ | $s^2$ |
| [illegible] | $j^2$ | $j^2$, ɪ | [illegible] | $т^1$ | $t^1$ |
| [illegible] | k | q | [illegible] | $т^2$ | $t^2$ |
| [illegible] | к | k | [illegible] | ч | č |
| [illegible] | $л^1$ | $l^1$ | [illegible] | ш | š |
| [illegible] | $l^2$ | $l^2$ | [illegible] | | |
| [illegible] | лт | lt | | | |
| [illegible] | м | m | | | |
| [illegible] | $н^1$ | $n^1$ | | | |
| [illegible] | $н^2$ | $n^2$ | | | |
| [illegible] | ӊ | ŋ | | | |

2 С. Е. Малов

Борынгы төркиләрнең руник алфавиты.

безнең көннәргә килеп җитмәгән. Бүгенге көндә тарихи темада эшләүче татар язучысына Казан ханнарының сараен, утырган тәхетләрен күз алдына китерү өчен Төркия музейларында йөрергә туры килә. Шул ук вакытта Казан ханнарыннан берәүнең баш киеме Мәскәүдә саклана (ул «Казанская шапка» дип атала).

Хәзерге көндә урыс галимнәре тырышып-тырышып Явыз Иванның китапханәсен эзлиләр. Аның китапханәсендә Казан алынганнан соң алып кителгән китапларның да булуы ихтимал дигән имеш-мимешләр йөри. Әмма мин моңа ышанмыйм. Урыска татар китабының бервакытта да кирәге булмаган, ул аның кадерен белмәгән. Китап түгел, хәтта гарәп хәрефләре белән язылган һәр кәгазь кисәге аңарда нәфрәт уяткан, ул аны юк итәргә тырышкан. Бу сәясәт гасырлар буе дәвам иткән.

Мәсәлән, 1549 елда, Казан алынырга 3 ел калганда иң яхшы кульязма китаплар кәрван белән Кырымга озатыла. Тик юлда бу кәрван урыс казаклары кулына төшә, аннан Мәскәүгә озатыла. Әлеге китапларның язмышы, кайда саклануы бүгенге көнгәчә билгесез.

1593 елның 18 июлендә патша Федор Ивановичның указы игълан ителә. Бу указ нигезендә барлык татар мәчетләре «себереп түгелергә» («посметати») һәм киләчәктә мондый омтылышлар рәхимсез төстә бастырылырга тиеш була. (Татарстан, 9—10, 1992, 27 б.)

Романовлар династиясеннән булган беренче патша Михаил Федорович (1596—1645) татарларда борынгыдан калган китапларның, шул исәптән мөселман ханнарыннан калганнары да күп булуын ишетеп алгач, боларның муллалары котыртып бирәр фетнә-мазар күтәрә күрмәсен тагын дип, 1635 елда күп укымышлыларны үтертә, биһисап китапларны яндырта.

Шушы уңайдан «Яңа Тинчәле авылы тарихы»ннан өзек китерү дә урынлы булыр дип уйлыйм. Анда болай диелә: «Ул вакыт авылларда уку кайда, татарларның мәркәзе булган Казан шәһәрендә дә, Казан урыслар кулына кергәннән соң 200 елларга кадәр мәктәп ачып укырга ирек булмаган. Казанда иң әүвәл мәктәп ачып укыта башлаучы мулла Габделхәмит бине Мортаза 1210 һиҗриядә (1795 елда) Яңа Бистәдә имам булган кеше. Бу кешегә кадәр Казанда мөселманнарга мәктәп ачып укырга рөхсәт бирелмәгән». (Татарстан, 9—10, 1992, 27 б.)

1552 елдан соң дәүләтчелеген югалткан татарның милли китабы сату-алу мөнәсәбәтләреннән төшеп кала. Бу дәвердә кеше кульязма китапларны үзе өчен үзе хәстәрли, яза, күчерә, төпли башлый. Колониаль һәм милли изү шартларында хаттат һөнәре юкка чыга, китапларның сыйфаты шактый түбән төшә. Әмма шундый авыр шартларда да халкыбызның китапка хөрмәте һәм мәхәббәте кимеми. Киресенчә, кульязма китаплар мәчет-мәдрәсәләрдә күпләп туплана, милләтнең рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә хезмәт итә. Царизмның чукындыру сәясәте, миссионерларның эшчәнлеге көчәйгән саен халык үз диненә, китабына тагын да ныграк берегә. Өстәвенә хаҗга баручылар, сәүдә юлларында йөрүчеләр Гарәбстаннан, Төркиядән, Шәрекъ илләреннән китап алып кайтуны үзләре өчен саваплы эш дип саныйлар. Алып кайтылган китап тәрҗемә ителә, күчереп языла, кулдан кулга йөри. Гади генә гаиләләрдә дә кульязма китаплардан торган кечкенә китапханә булдырыла.

Әлбәттә, бу хәл фанатик урыс руханилары игътибарыннан читтә калмаган, алар халыкның рухын саклап килүче китапка, мөселман диненә каршы сугыш ачалар. 1740—1742 елларда Казан өязендә генә дә фанатик- рухани Лука Канашевич җитәкчелегендә 536 мәчетнең 428 е яндырылып юк ителә (татар халкы бу бәндәгә Аксак Каратун дип кушамат таккан).

## II

XVIII йөз башында беренче татар басма китабының дөнья күрүе милли китап тарихында яңа баскыч була. Әлеге китап Петр I нең 1722 елда оештырган Персия явына бәйле рәвештә барлыкка килә. Эш шунда ки, Петр I 106 мең кешелек гаскәр белән Идел буенча төшеп, Каспийның көньягына басып керә, Персиягә каршы сугыш башлый. Урыс гаскәре арасында 30—40 мең тирәсе татар солдатлары да була. Петр I сугыш хәрәкәтләре барган җирләрдә яшәүче инородецларны үз ягына аудару йөзеннән махсус «Манифест» яздырта һәм аны татар телендә бастырып чыгарта. Аннан соң кечкенә китапчык рәвешендәге шушы документ татар, нугай, кумык, карачай, азәрбайҗан, фарсы халыклары арасында таратыла.

Ни өчен «Манифест» татар телендә бастырылган дигән сорау туа? Чөнки татар теле Алтын Урда заманнарыннан бирле Шәрекъ илләре белән аралашу

теле буларак хезмәт иткән. Шушы традиция Алтын Урда белән Казан ханлыгы егылганнан соң да Русиядә дәвам итә. Әстерханда судного көйләнгән типография-басмаханәдә басылган шушы китапчыкны дөньяга чыгаруны тулысынча белекле татар кешеләре башкара. Академик Ә. Кәримуллин сүзләренә караганда, аның текстын Петр I нең яшерен киңәшчесе, тылмач, соңыннан Русиянең Ирандагы илчесе Тәфкилев дигән бер татар зыялысы татарчага тәрҗемә иткән. Шулай итеп, әлеге «Манифест» тулысы белән татарлар тарафыннан эшләнә: татар тәрҗемә итә, текстын басмаханәдә татар кешесе хәрефләп җыя, хәтта шрифтның рәсемнәрен дә урыска хезмәткә күчкән кырым татары Дмитрий Кантимер ясый, типографиядә басучылар да татарлар була. Шул сәбәпле бу «Манифест»ны татарның беренче басма китабы дип санарга нигез бар. Тик менә китапчыкның урыс патшасы башлаган басып алу сугышы максатларын аклау өчен чыгарылуы гына бераз кәефне кыра. Беренче басма китабыбыз тарихында да милләтебезнең авыр хәле бик ачык чагыла.

Шушы уңайдан урысның беренче басма китабы хакында да бер-ике сүз әйтеп үтү урынлы булыр сыман. Русиядә беренче басма китап, Казан ханлыгы яулап алынгач ук, 1564 елда дөнья күрә. Бу Иван Федоров бастырган «Апостол» исемле дини китап була. Шунысы кызык, чит ил тарихчысы Я. Пеленскийның «Россия» и Казань. Завоевание и империалистическая идеология (1438—1560-е годы)» исемле гаять кызыклы тарихи хезмәтен укыган чакта мин шундый фикергә тап булдым: «Задачи христианизации новоприобретенного Казанского края вынудило царя Ивана IV и (митрополита) Макария начать печатание книг в Москве, так как необходимо было много религиозных книг для вновь учрежденного архиепископства Казанского,— дип яза ул һәм нәтиҗә дә ясап куя.— «Апостол» Ивана Федорова в большей мере свидетельствует об участии правительства в выполнении программы обращения в православие татарского населения».

Димәк, Казан ханлыгын яулап алу, татарны тиз арада христиан диненә күчерү максатлары (моның өчен дини китаплар, догалыклар күп кирәк) урысның беренче басма китабы басылып чыгуны гаять тизләткән, ашыктырган булып чыга. Бу ике дата — 1564 елда басылган «Апостол» һәм 1722 елда татарчага тәрҗемә ителеп таратылган «Петр I Манифест»ы — дәүләтле урыс белән дәүләтен югалткан татарның язмышын бик ачык күрсәтә. Бу очракта, борынгы төрек автор кебек, ирексездән:

> «Каганлы халык идем.
> Кайда инде каганым?
> Нинди каганга хезмәтемне
> көчемне бирәм?» —

дип уйлап куясың.

Татарча беренче басма китапчыкның дөнья күрүе татар китабы тарихында мөһим бер баскыч булса да, шушы вакыйгадан соң бу өлкәдә эшләр тиз алга киткән дип әйтә алмыйбыз. Империя даирәләренә инородецларның китап бастыруы бөтенләй кирәк булмаган. Шулай да бу чорда халкыбызның аңлы кешеләре басмаханәләр ачарга омтылыш ясап караганнар, тик татар өчен һаман да «заманалар авыр, еллар ябык» килеш калган. Бары тик 1799 елда гына татарларга Казанда типография ачарга рөхсәт бирелә. Басмаханә оештыру эшенә фидакяр зат Габделгазиз Бурашов керешә. Һәм бер-ике елдан Казанда аның житәкчелегендә бастырылып чыгарылган китаплар күренә дә башлый. Алар арасында гасырлар буе мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек булып хезмәт иткән «Әлифба иман шарты белән» дә була. Дөрес, моңа хәтле дә Мәскәү университеты басмаханәсендә Сәгыйт Хәлфиннең «Әлифба»сы (1778), Казан гимназиясендә татар теле укыткан Исхак Хәлфин (Сәгыйтнең улы) тарафыннан тәрҗемә ителгән «...Русия империясендә вилаятьләрнең низам вә тәртипләре»н (1785), Екатерина II нең (Әби патша) китап бастыруны таләп иткән татарларның авызын каплау өчен бастырып чыгарган «Коръән»ен (1787) күрсәтергә мөмкин. Коръән белән сату итү Әби патшага шактый файда да китерә. Ә. Кәримуллин сүзләренчә, Коръәннең һәр данәсе 200 сумга сатылган. Ул вакытта ат якынча 2 сум торганын искә алсак, Коръәнне сатып алу өчен татарга зур бер көтү атлар кирәк булган.

Ләкин татар китабы басыла башлаганнан соң ике-өч ел да узмый, 1803 елда урыс миссионерлары, хакимият даирәләрен эшкә җигеп, бу эшне үз кулларына алуга ирешәләр. Габделгазиз Бурашов китап бастыру эшеннән читләштерелә. Татар матбагачылары өчен ачылган күк капусы кабат ябыла. Ә урыс басмаханәләре исә татар китабын бастырганда бәяне 9—10 тапкырга кыйммәтрәк

сорый торган булганнар. Шулай итеп, татар китабының язмышы кабат ятлар кулына кала һәм XX йөз башына кадәр татарларга мөстәкыйль басмаханә ачу рөхсәт ителми. Өстәвенә милли китапка карата цензура да гаять рәхимсез була, миссонерлар да аны гел күзәтеп торалар. Ә 1874 елдан алып цензура гомумән Казаннан Санкт-Петербургка күчерелә. Инде берәр китапны бастыру өчен рөхсәт алыйм дигән татар кешесенә, зур чыгымнар тотып, Нева ярларына барып баш иярге туры килә.

Тик патша хөкүмәте һәм урыс руханилары куйган бөтен киртәләрне җиңә-җиңә татар китабы барыбер чыга тора. Дөрес, аның репертуарының күпчелеген әле дини китаплар тәшкил итә. Академик М. Госманов әйтүенчә, бу дәвердә татар китабы хәтта халыкара аренага да чыга башлый, Урта Азия калаларына, якын һәм Урта Көнчыгыш базарларына үтеп керә. Казанда басылган татар милли китапларының конкурентлык мөмкинлеге аның нәширлек үзенчәлекләре белән аңлатыла. Казан нәширләре укыр өчен иң уңай булган «нәсх» стиле нигезендә бары тик татар басмаларына гына хас, Шәрекъ илләрендә «Казан хәрефләре» дип аталып йөртелгән аеруча матур шрифт уйлап табалар, ә ул шрифт белән басылган китаплар «Казан басмасы» дип аталалар[1].

### III

**1905** елның 17 октябрендә патша Николай II тарафыннан игълан ителгән «Об усовершенствовании государственного порядка» дип исемләнгән манифесттан соң гына Русиянең Казан, Уфа, Ырынбур, Әстерхан, Самара, Омски, Эстәрлетамак, Троицки һ. б. калаларында мөстәкыйль татар басмаханәләре эшли башлый. Шулай самодержавиегә каршы күтәрелгән халык массалары басымы астында патша хөкүмәте татарлар өчен дә ташламалар ясарга мәҗбүр була. Ирекктә сусаган татар галәме ашкынып үзенең милли тормышын җайга салырга, күп гасырлар буе бастырылып килгән мәдәниятен күтәрергә керешә. 1905 елгы инкыйлабтан соң елына 400—500 исемдәге татар китабы чыгып торган.

Чыннан да, бу елларда татар китабы милләт өчен ифрат зур һәм әһәмиятле хезмәт башкара, чын мәгънәсендә халыкны агарту, аның үзаңын үстерү, тарихи хәтерен яңарту белән шөгыльләнә. 1905—1917 еллар арасында татар зыялылары, гүя мондый мөмкинлекләрнең озакка сузылмаячагын сизенгәндәй, үз-үзләрен аямыйча ифрат күп изге эшләр башкарырга өлгерәләр. Бер 1913 елда гына да татарның 539 исемдәге китабы басылып чыга. Татар милләте Русия империясендәге иң укымышлы, мәдәниятле халыкларның берсенә әверелә.

Татар халкының гаять тиз дәрәҗәдә күтәрелүе, төрле өлкәләрдә әзерлекле кешеләре үсеп чыгуы, рухи яктан ныгуы патша хөкүмәтен бик нык борчуга сала. Һәм татарны ничек тә булса туктату, үсүенә киртәләр кую өчен 1910 елда Эчке эшләр министры П. Столыпин җитәкчелегендә Русия идарәче даирәләренең зур җыены — киңәшмәсе булып уза. Аның рәсми исемендә үк куелган максатлары ярылып ята: «Идел буе тарафында татар-мөселман йогынтысына каршы чаралар үткәрү буенча Махсус киңәшмә». Патша чиновниклары белән миссионерлар гына татарга каршы көрәшми. Бу көрәш рәсми төстә, дәүләт күләмендә алып барыла. Әлеге «Махсус киңәшмә» башка чаралар белән беррәттән хөкүмәт: «...инородецларны урыслаштыру, инородецларны урыс мәдәниятенә тарту эшен төгәлләргә тиеш; бу эш хөкүмәтнең ахыр чиктәге һәм шул сәбәпле киләчәктәге максаты булырга тиеш» дигән таләпләр куя.

Ләкин татар шундый авыр шартларда да китап бастыра, күп санда газеталар чыгара, милли мәктәбен ныгыта. Халкыбызның аң-белем дәрәҗәсен күрсәтү өчен бу очракта җәдиди мәдрәсәләрдән булган «Мөхәммәдия»дә (Казанда) нинди фәннәр укытылуын санап үтү дә җитә: урыс теле, арифметика, матур язу, рәсем (сызым) хисап-счет, география, физика (табигать белеме), геометрия, Русия тарихы, гомуми тарих, төрки халыклар тарихы, гыйлем һәм сыйныфлар тарихы, фәраиз (мирас бүлү кагыйдәләре), әхлак, гигиена (медицина), метрика, риторика (матур сөйләү), психология, логика, философия, укыту методикасы, педагогия, гарәп теле, фарсы теле, гарәп әдәбияты һ. б. (Татарстан, 9—10, 1992, 33 б.). Билгеле, мондый уку планнарын тормышка ашыру өчен бик күп китаплар, дәреслекләр, кулланмалар, уку-укыту әсбаплары кирәк булган. Һәм аларны милләт үз көче белән җитештергән, көче җитмәгәндә чит телдән тәрҗемә иткән. Шуларга тагын матур әдәбият әсәрләрен, әкият, җыр, бәет, публицистик җыен-

[1] Китапка хитаб Слово о книге. Казан, 1994, 29 б.

тыклар, әхлак, тәрбия мәсьәләләрен яктырткан төрле брошюралар һәм тарих китапларын да өстик.

Җыйнап әйткәндә 1917 елгы инкыйлабка кадәрге татар китабының эчтәлеге гаҗәеп дәрәҗәдә бай һәм күпкырлы булган, һәм ул халкыбызның дини-мәдәни-рухи ихтыяҗларын шактый тулы канәгатьләндергән. Шушы китаплар аша татар кешесе фән казанышлары белән дә, гомуми тарих белән дә, кешелек дөньясы тудырган рухани байлык белән дә танышып торган. Бу фикерне раслау өчен Казан уку-укыту округына кергән Вятка, Сембер, Саратов, Самара, Әстерхан губерналарының инспекторы Я. Д. Коблов фикерен китерү дә җитә. 1916 елда ул менә ни дип язган: «Русиядә Казан татарларындагы кебек грамота киң таралган бүтән халыкны күрсәтүе кыен. Укый-яза белмәгән татар кешесен бик сирәк очратырга мөмкин» (Татарстан, 11—12, 1992, 60 б.).

Татар матбугаты, басмачылык хәрәкәте сонрак дәверләрдә андый милли югарылыкка беркайчан да күтәрелә алмады. Шуңа күрә дә без XX гасырны тәмамлап килгәндә ул буынның фидакяр эшләре алдында сәҗдә кылабыз, калдырган мирасларына хәйран калып, анын янадан-яңа катламнарын ачабыз. Дөрес, татар халкы «кызыл» дәвергә аяк баскач та милли китапның аерым казанышлары булды, тик коммунистик идея түр башына менеп утырган дөньяда милли ихтыяҗлар һәрвакыт арткы планга күчәргә дучар ителде.

## IV

Күптән түгел 75 еллык юбилеен билгеләп үткән Татарстан китап нәшриятына 1919 елның 22 июнендә нигез салына[1]. РКП(б)ның Казан губкомы карары нигезендә Казанда РСФСР Дәүләт нәшриятының бүлеге барлыкка килә һәм шушы дата Татарстан китап нәшриятының туган көне санала. Әлбәттә, бу оешма буш җирдә барлыкка килмәгән. Октябрь инкыйлабыннан соң басмачылык бик нык үсеп китә, дәүләт оешмаларын инде әйткән дә юк, бик күп шәхси басмаханәләр дә китап бастыру белән шөгыльләнә. Әмма инкыйлабтан соңгы беренче елларда нәшриятлар эшендә нинди дә булса тәртип, оешканлык, система күзәтелми — һәрберсе мөстәкыйль рәвештә эшли. Тик һәр нәрсәне үз кулына алырга, бер үзәккә буйсындырырга, идея-тематик юнәлешне билгеләргә тырышкан большевиклар тарафыннан әле 1917 елның 24 ноябрендә үк Дәүләт нәшрияты турында декрет кабул ителә. Ләкин төрле кыенлыклар, беренче еллардагы буталчыклык, оештыру көчләре җитешмәү аркасында совет нәшриятлары сонрак барлыкка килә. Әйтеп үтелгәнчә, Татарстан китап нәшриятының эшчәнлеге 1919 елгы карардан соң башланып китә. Һәм бу эшчәнлек тулысынча Мәскәү контроле һәм күзәтүе астында бара. Башкасын әйткән дә юк, хәтта нәшриятның редколлегия утырышы беркетмәләрен дә үзәккә җибәреп торырга тиеш булалар.

Бу дәвердә нәшрият нигездә вакытлы матбугат һәм агитацион басмалар бастырып чыгару белән шөгыльләнә. Җитди китаплар бик аз басыла. 1919 елда гомуми күләме 228 басма табакка тиң 56 китап кына басылып чыга. Шушы санга урыс, татар, чуаш, мари, удмурт һәм башка телләрдә басылган китапларның да керүен исәпкә алсаң, татар телендәге китапка нинди өлеш тигәнен чамалавы кыен түгел[2]. Бу инде китап бастырып чыгаруның тукталып калыр хәлгә килеп җитүен күрсәтә. Чыннан да, гражданнар сугышы аркасында хәлсезләнгән ил нәшриятлары нигездә сәяси мәнфәгатьләргә хезмәт итәләр, башлыча агитация-пропаганда продукциясе бастырып чыгару белән шөгыльләнәләр.

1920 елның ноябрь аенда Казан дәүләт нәшрияты (Казгосиздат) Татарстан дәүләт нәшрияты (Таттосиздат) дип үзгәртелә. Мондый үзгәрешнең сәбәбе Татарстан автономияле республикасы барлыкка килүгә бәйле була. Чөнки автономияле республика оешу көн тәртибенә татар мәдәниятен үстерү мәсьәләләрен дә китереп бастыра.

Яңа барлыкка килгән нәшриятның эчке төзелешенә килгәндә аның нәшрият секторы ике мөстәкыйль бүлектән торган: берсе — Гыйльми үзәк дип аталган, икенчесе — әдәби ядкярләрне җыю, өйрәнү, бастырып чыгару, аларны урысчага тәрҗемә итү белән шөгыльләнгән. Ул бүлек гади телдә Лито дип йөртелгән.

Бу елларда Гыйльми үзәк аеруча нәтиҗәле эшли, зур активлык күрсәтә. Эш шунда ки, 1922 елдан аңа әдәбиятыбызның классигы, җәмәгать эшлеклесе һәм галим Г. Ибраһимов җитәкчелек итә. Ул үз тирәсенә татар һәм башка милләт

---

[1] Здравствуй, Книга. Казань. Таткнигоиздат. 1989, 37 б.

[2] Здравствуй, Книга, 45 б.

зыялыларын, галимнәрне туплый. Эш фәнни нигездә һәм уйланылган план буенча алып барыла. Гыйльми үзәкнең эшчәнлеге киң колачлы була, халык өчен кирәкле китаплар, дәреслекләр бастыруны ул һәрвакыт игътибар үзәгендә тота. Кыскасы, Гыйльми үзәккә тупланган татар зыялылары күп заманнар хәл ителмичә килеп, Октябрь инкыйлабыннан соң милләт алдында калкып чыккан мәсьәләләрне тиз арада җайга салырга керешәләр. Беренче елларда әле большевиклар партиясенең тормышның һәр өлкәсен үзәкләштереп бетерергә көче җитми. Шуңа күрә М. Худяковның «Очерки по истории Казанского ханства» (1923), Г. Газизнең (Гобәйдуллин) тарихи хезмәтләре кебек китаплар чыгып өлгерә.

Барлыкка килүенең беренче елларында Татарстан дәүләт нәшрияты китап һәм төрле брошюраларны татарча да, урысча да бер үк күләмдә бастырган булса, тора-бара татар китапларының саны шактый арта, ә урысчасыныкы кими төшә. Чөнки урысча китаплар РСФСРның башка калаларында да күп басыла. Ә Казан исә күтәрелеп килүче татар милләте ихтыяҗларын канәгатьләндерүне үз өстенә ала. Әйтик, әгәр дә Татарстан дәүләт нәшрияты 1922 елда урысча 42, татарча 32 китап һәм брошюра бастырган булса, 1923 елда бу саннар инде 18:46, 1924 елда — 21:100, 1925 елда — 14:334 кә җитә[1]. Саннардан күренгәнчә, бу елларда татар китабы алга таба зур адым ясый.

Шушы урында бер лирик чигенеш ясамыйча кала алмадым. Әлеге мәкаләне язганда миңа татар китапларының 1917—1929 һәм 1930—1940 еллар арасындагы библиографик күрсәткечне тулысынча карап чыгарга туры килде[2]. Дөресен әйткәндә, бу минем өчен үтә дә кызыклы һәм мавыктыргыч эш булып чыкты. Күрсәткечне бүлек артыннан бүлек карый башлагач, инкыйлабтан һәм гражданнар сугышыннан соң татар халкының нинди якты хыяллар һәм энтузиазм белән яшәвен, нинди ашкыну белән үз мәдәниятен, рухи һәм матди тормышын җайга сала баруын күреп сокланасың һәм бер үк вакытта көнләшеп тә куясың. Нинди генә китаплар чыкмаган да, нинди генә файдалы эшләр башланмаган ул елларда! Тормышның, мәдәниятнең, фәннең һәр өлкәсе буенча саф татар телендә күпме китаплар, дәреслекләр, уку-укыту әсбаплары, төрле брошюралар басылып чыгып торган. Шулай ук туган телне торгызу, аны чын мәгънәсендә дәүләт теле итү, яшәү мохитын киңәйтү буенча да дәүләт күләмендә зур чаралар күрелгән. (Бүгенге кебек күз буяу белән шөгыльләнү генә түгел!). Һәм бу эшләрнең эзе библиографик күрсәткечләрдә ярылып ята.

Мәсәлән, без анда татар телен гамәлгә кертү, аның абруен үстерү буенча түбәндәге китапларны, брошюраларны, материалларны күрәбез:

1) Татар телен гамәлгә кую турындагы декрет, карар, циркуляр һәм башка материаллар. Казан, 1925. 114 б.;

2) Татарстан Үзәк башкарма комитеты янындагы татар телен гамәлгә кую Үзәк комиссиясенең Татарстанның V Советлар съездына хисабы. Казан. 1925. 30 б.;

3) Татарстан Үзәк башкарма комитеты янындагы татарчалаштыру Үзәк комиссиясенең татарчалаштыру эшенең барышы һәм киләчәге турында. (ТҮБК. 12—13 март 3-сессиясендә ясалган доклад). Казан, 1927. 86 б.;

4) Шәймәрдәнов. Татар телен тормышка үткәрү эшенең хәзерге хәле һәм киләчәге турында. Татарчалаштыру Үзәк комиссиясе рәисе ип. Шәймәрдәновның Татарстан Үзәк комитетының III сессиясендә ясаячак докладлары тезислары. Казан. «Гажур», 1927. 31 б.;

5) Ф. Басыйров. Канцелярия өчен төрле дәфтәрләрнең һәм эш кәгазьләренең татарча үрнәкләре (1923). 41 б. (Татар телен гамәлгә кую мәркәзе комиссиясе нәшре) — 3000 данә.

Шушыңа өстәп тагын Җ. Вәлидинең 3 томнан торган «Татар теленең тулы сүзлеге»н (1927), Г. Габидовның «Русча-татарча сәяси лөгате»н (1918), М. Галинең «Газета укучылар өчен кесә сүзлеге»н (1928), Г. Беляевның «Крәшеннәргә татар-гарәп сүзләрен аңлатыр өчен сүзлек»ен (1929) һәм татар теле белеме буенча бик күп китапларны, дәреслекләрне, уку әсбапларын санап китеп булыр иде.

Әйе, ул елларда татар теленең абруен үстерү өчен зыялыларыбыз тарафыннан гаять күп эшләр башкарыла... Санап киткәннәргә тагын Г. Алпаровның «Татар теленең имла сүзлеге»н (1927), С. Атнагуловның «Татар әдәби һәм фән телен баету юлында яңа омтылышлар билгеләүнең төп принциплары» (1929) дигән хезмәтен, «Кесә өчен русча-татарча мөкәммәл сәяси лөгать»не (1918), «Русча-

---

[1] Культурная революция в Татарии (1917—1937 гг.). Казань. Таткнигоиздат. 1986. 190 б.

[2] Татарстан китаплары. Библиографик күрсәткеч. Т. 1, 1917—1924. Казан, 1979.

татарча сугыш терминнары сүзлеге»н (1926), «Имла сүзлеге»н (1928), Ш. Рәхмәтуллинның «Татар телен русларга, рус телен татарларга өйрәткеч»ен (1918), Г. Сәйфинең «Мәктәп лөгате»н (1918) һ. б. өстәргә мөмкин.

Ни өчен болай төпченеп озын исемлек китердем соң әле? Бүген кайберәүләр татар теленең абруен күтәрү, аның яшәү мохитын киңәйтүне, дәүләт теле дип игълан итүне яңа күтәрелгән мәсьәлә дип кабул итәләр. Баксаң, ул гаять иске мәсьәлә икән, ул бары тик дистәләрчә еллар бастырылып кына торган. Китерелгән исемлектән күренгәнчә, 20-елларда ук татар зыялылары ифрат зур эшләр башлаганнар, кайберсен тормышка да ашырып өлгергәннәр. Тик тоталитар режим гына бу изге эшләрне рәхимсез рәвештә туктаткан. Башлап йөрүчеләрне ГУЛАГ лагерьларында череткән, бөтенләй юк иткән.

Ул елларда басылып чыккан китаплар арасында тарихи темага багышланган басмаларның да байтак булуы игътибарны җәлеп итә. Әйе, тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Бу — мәгълүм нәрсә. Халык үз үткәнен белмәсә, ул инде *населениегә-гавамга* әверелә. Ул буын зыялылары моны яхшы аңлаганнар. Татар телендә бер-бер артлы тарихи хезмәтләр чыгып торган. Мәсәлән, Г. Гобәйдуллинның «Татар тарихы» (1925), «Татарларда сыйныфлар тарихы» (1925), В. Бартольдның «Төркестан тарихы» (1924), Б. Салиевның «Бохара тарихы» (1923), Ф. Сәйфи (Казанлы)ның «Россия тарихы» (1928), Нәүширван Зиннәтнең «Хәлифәтнең үлеме» (1924), шул ук Г. Гобәйдуллинның «Татар тарихы» (Иң борынгы заманнан алып XVII гасырга кадәр) дәреслеге (1922) һәм Г. Гобәйдуллинның балалар өчен язылган «Татарларның килеп чыгуы һәм Алтын Урда» (1925), «Борынгы болгарлар» (1924), «Пугачев явы» китаплары дөнья күрә.

Әмма китерелгән китаплар исемлеге бездә барысы да «ал да гөл» булган икән дигән ялгыш фикер тудыра күрмәсен. Совет властының беренче елларында чыккан китапларның күбесе, әлбәттә, яңа хакимияткә, аның идеологиясенә хезмәт иткән. Гражданнар сугышы тәмамлану белән дингә каршы язылган әдәбият күпләп чыгарыла башлый. Мәсәлән, Ф. Сәйфи (Казанлы)ның «Дин белән ничек көрәшергә» (1922); Чыгтайның «Мин нидән динсезләндем» (1924); С. Борһанның «Алласызлыкка таба» (Яшьләр арасында дин белән көрәшү юллары), 1927; «Дәһри түгәрәкләр өчен дәреслек» (1928), 311 бит; Гали Ибраһимовның «Дин халыкка әфиун» (1928), 97 бит һ. б. китап һәм брошюралар яңгыр булып ява, халыкның аңын агулый, аны ислам мәдәниятеннән, гасырлар буе милләтне саклап килгән гадәт, йола һәм традиция кыйммәтләреннән аерырга тырыша. Тик заманның тиз үзгәрә баруына, большевикларның тормышны бөтенләе белән үз контроленә алырга тырышуына карамастан татар милләтендә әле элекке традиция көчле була, инкыйлабтан соңгы беренче елларда нәширләр дин һәм тарихка багышланган җитди һәм хак хезмәтләр бастыру мөмкинлекләрен табалар. Шул елларда дөнья күргән китаплардан С. Бикбулатның «Дүрт хәлифә. Әбүбәкер вә Гомәр дәвере» (1918, 287 б.); М. Дибирдиевнең «Биназл Ислам» (Исламның нигезләре), 1918; В. Хангилдинның «Мәктәптә дин дәреслеге» (1919); Сәлах Камалның «Мосаввәр тарих ислам» (Исламның сурәтле тарихы) 1918; тарихи хезмәтләрдән В. Бартольдның «Кыскача ислам мәдәнияте тарихы» (Җ. Вәлиди тәрҗемәсендә) 1922, шул хакта сөйли. Ләкин 1922 елдан соң нигездә дингә каршы, аны тупас итеп сүгә торган дәһри-атеистик китаплар һәм брошюралар гына дөнья күрә. Гыйбрәт өчен мондый дәһри китаплардан да берничәсен атап үтик:

— Гали Ибраһим, И. Юмангулов. Алласызлар түгәрәкләре өчен дәреслек. (Крестьяннар өчен). М. 1930, 202 б.— 10 000;

— Уразага каршы җыентык. М. 1932, 118 б.— 10 000;

— Сәләх Җамалиев. Яшь буын өчен көрәш һәм диннәр. М. 1931, 54 б.— 8000;

— А. С. Уханов. Социализм һөҗүме һәм дин. Казан. 1932, 64 б.— 5000;

— Дингә каршы әңгәмәләр программасы. Дингә ышанучы хезмәт ияләре (мөселманнар) өчен. Казан. 1933, 32 б. (Сугышчан Алласызлар союзының Татарстан республикасы советы) — 3000 һ. б.

Шулай итеп китап аша халыкка дини тәрбия бирү мөмкинлеге бөтенләй киселә.

Мәкаләнең шушы җиренә җиткәч, бераз тукталып тын аласы килеп китте. Чөнки... югарыда санап үтелгән китап һәм брошюра исемнәреннән ниндидер катылык, катгыйлык, кыргыйлык, рухи дөньяны танымау, кешенең шәхесен изү салкынлыгы бөркелеп тора. Андагы «Алласызлар түгәрәкләре», «Уразага каршы җыентык», «Сугышчан Алласызлар союзы»... кебек сүзләр-гыйбарәләр мигә кадак каккан сыман тәэсир итәләр... Ә бит уйлап карасаң, халкыбызга шушындый идеология канаты астында, фикере буылган килеш ничә дистә еллар яшәргә туры килде.

Шулай да 20 нче елларда әле басылып чыккан китапларның 93—97 процентын саф татарча китаплар тәшкил иткән. Татарстан дәүләт нәшрияты чыгарган продукциянең гаять зур өлеше татарча дәреслекләрдән торган. Әйтик, 1921—1927 елларда алар 320 тапкыр басылып чыга. Һәм бу эш белән телгә алынган Гыйльми үзәк җитәкчелек итә[1]. Шулай ук авыл хуҗалыгына багышланган китаплар да күп чыгарыла. 1921—1925 еллар арасында 84 брошюра дөнья күрә, шуларның 70 е татарча була[2].

Бүгенге көндә бездә табигать фәннәре, техника өлкәсенә караган ВУЗ дәреслекләрен татарча да чыгару, фәнни терминологияне эшләү мәсьәләләре күтәрелә. Татар теленең яшәү мохитын киңәйтү өчен моның зарурлыгы көн тәртибенә куела. Бу юнәлештә инде кайбер эшләр дә күренә башлады. Сөенечле күренеш, әлбәттә. Тик шуны да онытмыйк: 20 нче еллар белән чагыштырганда милләтебезнең хәле ифрат аяныч, чөнки бу яктан татар бүген шактый артка алып ташланган милләт. Ул елларда милләтебездә саф татарча укыта алырлык, саф татарча итеп фән-техника буенча югары уку йортлары өчен дәреслекләр язарлык кешеләр аз булмаган. Мисал өчен шундый берничә дәреслекнең исемнәрен атап үтик. Әйтик, 1925 елны С. Әхмәднең «Татарстанның табигый географиясе», М. Габдуллинның «Радио сөюченең беренче китабы», Х. Мөштәринең «Җәбер» (Алгебра) дәреслекләре басылып чыга.

1926 — Г. Шнаси. Биология дәреслеге.
Г. Шнаси. Физика дәреслеге.
1927 — Г. Фәйзи. Минералогия һәм геология.
1928 — И. Бикчәнтәй. Метеорология һ. б.

Кыскасы, татар милләтенең үз кадрлары күп өлкәләр буенча саф татарча итеп дәреслекләр, фәнни хезмәтләр язганнар. Бер үк вакытта дөньяга киң караш тәрбияли торган фәнни-популяр хезмәтләр дә татарча басылып тора. Бу очракта Г. Сәгъдинең «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүе» (1926, 246 б., рәсемнәр белән) кебек кызыклы хезмәтен искә алып үтү дә җитә торгандыр.

Әйтеп үтелгәнчә, 1920 елда элекке Дәүләт нәшриятының Казан бүлеге Татарстан дәүләт нәшрияты исемен ала һәм ул республиканың төп нәшриятына әверелә. Ләкин 1923 елда республиканың барлык нәшриятлары диярлек бер канат астына туплана. Шулай Татарстан Матбугат һәм нәшрият комбинаты барлыкка килә. Яңа оешкан Комбинат дәреслекләр, урыс һәм татар телендә фәнни һәм матур әдәбият бастырырга, агитация-пропаганда өчен китаплар, брошюралар чыгарырга тиеш була. Тик тиздән бу иләмсез зур оешманың нәтиҗәле эшли алмавы үзен нык сиздерә. Кем әйтмешли, анда уң кулның ниләр кылганын сул кул белми башлый. Кыскасы, Комбинат белән идарә итү гаять катлаулы һәм кыен эш икәне ачыклана, ул бер урында таптана башлый. Монда Комбинатның берьюлы ике хуҗага — Халык мәгариф комиссариатына (Наркомпрос) һәм Халык хуҗалык советына (Совнархоз) буйсынуы да тискәре роль уйный. Эшнең артка китүе кайбер типографияләрне, бүлекчәләрне, оешмаларны Комбинаттан бүленеп чыгарга мәҗбүр итә.

Шулай берничә ел буе төрлечә эшләп караганнан соң, 1927 елның язында нәшриятлар, типографияләр өчен, ниһаять, тормышка ярашлы бер яшәү формасы табыла; аларның берсе — ТАССРның полиграфия промышленность берләшмәсе «Татполиграф», икенчесе — Дәүләт нәшрияты «Татиздат» булып китә. Соңгысы республикадагы барлык нәшриятларның вазыйфаларын үз өстенә ала. Шулай барлык нәшриятлар кабат бер канат астына туплана, аларның эшчәнлегенә әле 1923 елны ук барлыкка килгән Главлит контрольлек итә. Бу инде китап бастыру эшенең тулысы белән партия кулына күчүен, моннан соң бары тик коммунистик идеологиягә хезмәт иткән «кызыл» китапларның гына дөнья күрәчәген аңлата. Шулай итеп, иҗади көчләргә кабул ителгән фикергә карата шик белдерү мөмкинлеге калмый. Инде мили мәнфәгатьләрне кайгырту, үз тарихыңны халыкка житкерү, үзеңне үстерү, традицияләрне саклау кебек нәрсәләр арткы планга күчә, зур дорфалык һәм тупаслык белән эш иткән «кызыл дөньяга» аларның керәге калмый. Бу безнең милләт өчен генә түгел, СССР дип аталган тулай торакта яшәүче һәр халык өчен мәдәният белән рухның җимерелүгә таба юнәлеш алуы була.

---

[1] Культурная революция в Татарии (1917—1937 гг.), 191 б.
[2] Шунда ук, 191 б.

## V

Бүгенге көндә без озакка сузылган һәлакәт, инкыйраз дәвереннән әле чыгып кына киләбез. Халкыбыз үзенең табигый яшәү рәвешенә әйләнеп кайтырга тырыша, милли кыйммәтләрен торгызырга азаплана. Тик каршылык әле зур, «кызыл дөнья»ның инерциясе әле бик көчле, ул аңыбызга-каныбызга сеңгән.

Без бу дәвердән искиткеч зур югалтулар белән чыктык. Татар милләте өчен бу «кызыл дәвер» Явыз Иванның Казанны алуына тиң булды. Ул чакта халкыбыз үзенең дәүләтчелеген югалтса, татар җәмгыятенең барлык структуралары җимерелсә, морзалары «чабаталы» булып калса, хәзер без тарихи хәтеребезне һәм ана телебезне югалта язып калдык. Хәзерге көндә татарның яртысыннан күбесе милли яшәешнең нәрсә икәнен белми, ак белән караны аермый, 40% яшьләребез ят милләт вәкиленә өйләнә яки кияүгә чыга һәм... «оды туганның» саның үрчетә. Ана телен саклау, милли мәнфәгатьләр, халкының киләчәк язмышы, милләтеңә хезмәт итү дигән изге төшенчәләр бүген күпме татарны борчый икән. Бигрәк тә яшьләрне борчыймы, алар бу хакта уйланамы? Киләчәк бит аларныкы!..

Әлбәттә, милләтебез кабат аякка бассын, тулы канлы тормыш белән яшәсен өчен кирәкле шартларның бөтен бер комплексы эшләп торырга тиеш. Бу очракта иң әүвәл милли тәрбиянең яследән алып югары уку йортына кадәр эзлекле дәвам итүе шарт. Дөньяга килгән татар баласы туганнан алып белемен төгәлләгәнчегә кадәр ана теле, татар мәдәнияте мохитыннан аерылмаган очракта гына тулы милли тәрбия ала алачак. Бу юлда аның үзаңы дөрес формалашсын өчен милли әдәбият-сәнгатьнең дә тулы канлы тормыш белән яшәве сорала. Ләкин без әлегә татарны тәрбия кылуда бу шартларның тулы комплексы эшли дип әйтә алмыйбыз. Әлегә аның йә яслесе белән балалар бакчасы урысча, йә мәктәбе һәм югары уку йортында милли мохит, тәрбия житенкерәми. Еш кына гомумән барысы урысча алып барыла.

Милли кинобызның булмавы да зур югалтуга китерә. Ч. Айтматов әйткәнчә, бүгенге көндә милли киносы булмаган халык тулы канлы тормыш белән яши алмый. Яшь рәссамнар белән музыкантлар да милли традициядән аерылган хәлдә белем алып чыгалар. Соңыннан үз милләтенә әйләнеп кайту өчен аларга күп нәрсәләрне аңларга, моның өчен унар ел вакыт әрәм итәргә туры килә. Ә күбесе барыбер милли сәнгаткяр булып китә алмый кала, чөнки яшьтән нигез салынмаган. Менә шулай татар үзенең сәләтле шәхесләрен башка халыкка бирә бара.

Әдәбиятыбыз ни хәлдә? Өлкән буынга алмашка кемнәр һәм кайдан килә? Татар әдәбияты гомер бакый авыл хисабына үсте, шуннан ана яңа көчләр, яшь талантлар килеп торды. Авылда туган телнең чишмәсе, халык тормышы, милли яшәеш, гореф-гадәт. Әмма соңгы чирек гасырда хәлләр бик нык үзгәрде. Торгынлык елларында Мәскәүнең милли мәктәпкә каршы алып барган җимергеч сәясәте нәтиҗәсендә татар мәктәбе бик авыр хәлдә калды, ә шәһәрдә исә алар гомумән бетерелде, уку фәкать урысча гына алып барылды. Шул сәбәпле бездә шәһәрдә үсеп татар телендә иҗат итүче бер генә язучы да юк. Барысы да урысча иҗат итә. Урысча язсалар да, татар язучысы булып йөрергә дәгъвалары зур.

Татар телендә язучылар барысы да авылдан чыккан кешеләр. Уйлап карасаң, бу бик куркыныч хәл бит. Димәк, татар әдәбияты нигездә авыл әдәбияты икән. Ә авыл әдәбияты хәзерге заманның катлаулы таләпләренә җавап бирә аламы? Татар язучысының ярты гомере шәһәр мәдәниятен үзләштерүгә китә, беренче буын интеллигент буларак, ул катлаулы заманның социаль-психологик-фәлсәфи мәсьәләләренә җавап бирерлек белемне туплап өлгерә алмый. Моңа гомере җитми.

Соңгы елларда укучыларның әдәби зәвыгы да нык үзгәрде. Хәзер аны саф хыялга, фантазиягә нигезләнгән роман-повестьлар гына канәгатьләндерми, ул язучыдан тормыш фактына нигезләнгән әдәбиятны таләп итә. Хәзер әдәбияттан югары эстетик кыйммәтләр генә түгел, ә тормыш турында житди уйлану, анализ сорала. Шуңа күрә дә соңгы елларда укучының зәвыгы тарихи, фәнни, фәнни-популяр, документка нигезләнгән китапларга таба авыша. Укучы Китаптан анык, тирән фикер таләп итә, дөньяның фактлар аша ачылуын көтә.

* * *

Әйе, милләтне гасырлар буе саклап килгән Галиҗәнап Китапка бүген дә зур вазыйфалар йөкләнә, чөнки, әйткәнебезчә, татарда әлегә милләтне тәрбия кыла торган чараларның тулы бер комплексы эшләми һәм якын елларда моңа ирешү дә мөмкин булмаячак. Шуңа күрә хәзерге көндә татарның **милли китабы** халыкның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүче үтә дә үтемле һәм нәтиҗәле эш алып барырга тиешле.

Ә Китапның бүгенге язмышы аяныч. Татар милли китабыныкы икеләтә аяныч. 70 еллап дәүләт бюджетыннан ярдәм алып яшәргә өйрәнгән нәшриятлар хәзер бик авыр хәлдә калды, чөнки хөкүмәт аларга китап чыгару өчен акчаны бик ялындырып кына бирә. Үз хәле хәл. Нәшриятларга исә (бу очракта ике дәүләт нәшрияты — Татарстан китап нәшрияты (ТКН) һәм дәреслекләр бастыручы «Мәгариф» күздә тотыла) үз көннәрен үзләре күрү, базар мөнәсәбәтләрендә яшәү өчен әлегә тәҗрибә дә җитенкерәми, ясалма киртәләр дә күп. Ләкин төп бәла — кыйммәтчелектә, китап бастыруга киткән чыгымнарның басылган продукцияне сатканнан соң кире әйләнеп кайтмавында. Аннан соң дәүләт нәшрияты теләсә нинди китап бастырып турыдан-туры акча эшләү юлына баса да алмый, аның төп вазыйфасы милли ихтыяҗларны кайгырту буенча үз өстенә алган бурычын үтәү. Минемчә, мәсьәләнең бу ягын хөкүмәтебез игътибарга алмый диярлек. Шулай булгач, якын елларда дәүләт нәшриятлары әле хөкүмәтебез ярдәменнән башка эшли алмаячаклар.

Гомумән соңгы вакытта **т а т а р  м и л л и  к и т а б ы** өчен көтелмәгән, парадоксаль хәл килеп туды. Бер яктан, империя чылбырының бушый төшүе һәм шуның нәтиҗәсендә Татарстанның мөстәкыйльлек юлына басуы, милли аңның үсүе нәшриятларыбыз алдына бик күп яңа мәсьәләләре куйса, кирәкле китапларны мөмкин кадәр күбрәк чыгару бурычын йөкләсә, икенче яктан, нәшриятларның хәле элеккегә караганда күп тапкырга авырайды. (Торгынлык елларындагы финанс иркенлеген сагынып искә алырсың!) Шушы каршылык — үсеп киткән милли ихтыяҗлар белән аларны канәгатьләндерүдә китапның чикләнә барган мөмкинлекләре — көн тәртибенә килеп баскан мөһим мәсьәләләрнең берсе. Аның нигезендә игътисади кыенлыклар ятуы бәраүгә дә сер түгел.

Аларны ничек җиңәргә?

Бүгенге көндә Галиҗәнап Китапның язмышы өч хуҗа кулында: берсе — китапны бастыру өчен әзерләүче нәшрият, икенчесе — аны бастырып чыгаручы полиграфия оешмасы, өченчесе — китапны сатучы-таратучы оешма (Книготорг). Бер караганда, алар өчесе дә бер үк максатка эшләргә тиеш кебек. Асылда бу алай түгел. Әйтик, нәшрият, үз алдына олы максатлар куеп, милләт алдында торган мәсьәләләрне искә алып, мәдәниятебез үсеше өчен иң кирәкле китапларны гына чыгарырга омтыла, ди. Ләкин базар мөнәсәбәтләреннән чыгып караганда нәшрият чыгарган һәр китап та үтемле товар була алмый. Димәк, нәшрият мәнфәгатьләре китап сатучы оешма мәнфәгатьләренә каршы килә. Ә полиграфия оешмасы исә нәшрияттан бастыруы җиңел һәм чыгымнары-мәшәкатьләре азрак булган китаплар әзерләүне таләп итә.

Шулай итеп, китап язмышын, Крылов мәсәлендәгедәй, Аккош, Чуртан, Кысла кебек өч якка тарткалаучы көчләр хәл итә. Һәм бу хәлнең иң аяныч ягы шунда — бу очракта икътисади мәнфәгатьләр милли һәм мәдәни мәнфәгатьләргә каршы килә. Шулай Галиҗәнап Китапның мәдәниятебезгә хезмәт итү мөмкинлекләре шактый тарая һәм чикләнә бара. Кызганычка, иң кирәкле чакта, милли аң күтәрелгәндә.

Бу кыенлыктан ничек чыгарга мөмкин соң? Әлегә нәшриятлар, аның хәл ителгәнен көтеп ятмыйча үзләре әзерләгән китапларны сатуны, аны укучыга җиткерүне үз кулларына алырга тиешләр. Бу чара аларга кыен хәлдән чыгарга, һичшиксез, ярдәм итәчәк. Димәк, шушы юнәлештә хәрәкәт итәргә кирәк.



# БЕЗ — ТОРМЫШ ТЕАТРЫНЫҢ АРТИСТЛАРЫ

**Рәшит Ягъфәров 1946 елның 6 февралендә Пермь өлкәсе Барда районының Күчтәнти Баш авылында туган. 1964 елда Сараш урта мәктәбен тәмамлагач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем алган. Шул ук вакытта Актерлар йорты каршындагы сәхнә ветераннары оештырган театр студиясен тәмамлаган. Туган ягы — Бардада «Таң» газетасында, җирле радиотапшырулар редакциясендә эшләгән. Газета редакциясе каршындагы «Таң йолдызы» әдәби берләшмәсе белән җитәкчелек иткән. 1973 елда яңадан Казанга килеп, Мәдәният министрлыгы каршындагы мәдәни-агарту методик кабинетында методист булып эшләгәннән соң, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының, фольклор бүлегендә аспирантурада укыган, кандидатлык диссертациясе яклаган.**

**Шул институтта фәнни хезмәткәр Казан дәүләт педагогия институтының татар әдәбияты кафедрасы укытучысы. Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, «Мирас» журналы редакциясенең бүлек мөдире. Татар иҗтимагый үзәге вице-президенты. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты бүлек мөдире...**

**Хәзер рәсми эш урыны — Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре. Җәмәгать эшләре нисбәтеннән — БТИҮ рәистәше. Бөтентатар «Мәгариф» һәм «Мәдәният» бергәлекләре президенты.**

**Актив җәмәгать эшлеклесе, берничә китап һәм җыентыклар авторы, фольклорчы галим Рәшит Ягъфәровка 6 февральдә 50 яшь тулды. Шушы уңайдан хәбәрчебезнең аның белән әңгәмәсен урнаштырабыз.**

*— Рәшит, биографиягезгә, хезмәт юлыгызга күз ташлагач, бераз аптырап калырга да мөмкин: кем сез — галимме, фольклорчымы, язучымы, сәясәтчеме, мәгариф эшлеклесеме?*

— Мин, мөгаен, беренче чиратта Рәшиттер. Минем маңгайга язылган үз язмышым бар. Шул язмыш буенча йөримдер һәм төрле вазыйфалар башкарамдыр. Ләкин миннән торганы шул: кайда гына эшләсәм дә, милләтебез мәнфәгатен кайгыртырга тырышам.

Миңа эштән-эшкә күчеп, очып-кунып йөрүче кеше итеп караучылар да бар. Ләкин мин эштән-эшкә күчмим, ә эш урыннарын гына алыштырам. Төп эшем — татар мәдәнияте, ә инде эш урынын алыштыру ул кеше өчен гадәти нәрсә,

минемчә. Гомер буе бер урында гына эшләгән кеше калыплаша, шомара, миңа калса, яңалыкка омтылышы сүнә, инертлаша.

Әйтик, мин үземне фольклор белгече дип тә саныйм һәм халык иҗатын бик яратам. Элегрәк, мәсәлән, мин аннан башканы белми дә идем шикелле. Бөтен дөньяның барышы шушы фольклорга бәйләгән булып тоела иде. Хәзер милли сәясәт, мәгърифәт, мәдәният диңгезләрендә бераз чирканчык алгач, инде алай дип уйлый алмыйм. Халык хәтере, халык иҗаты милләтне милләт итеп яшәтүче төп факторлардан булса да, аның гомерен бер фольклор гына саклап кала алмый. Глобаль процесслар бар, сәясәт бар, милләт үсешенең башка төрле зарури шартлары бар. Шунлыктан, хәлбуки, мин халык иҗатын бик яратсам да, әйтик, «Халык җырларында каен образы» яки шуңа охшашлы башка матур темаларны гына тикшереп утыра алмыйм инде. Халыкның перспективасын, киләчәген тәэмин итү күзлегеннән карап зуррак гамәлләр кыласы, үзеңне зур авырлыклар алдында куеп булса да, милләт яшәеше өчен чарпалыш барган җирдә буласы килә.

Аннан соң «очып-кунып йөрүем» үз хасиятемнән дә киләдер. Эш урынында һәрчак — «суның чиста» булганын яратам. Ә бездә, бигрәк тә татар коллективларында, мәдәни мөгамәлә җитенкми. Милләтебезнең (зыялыларның да) әхлагы бозыла төшкән. Хөсетләшү, көнләшү, бер-береңнән нәрсәнедер күпсенү, гайбәт чәйнәү безнең кавемгә хас нәрсә. Мин андый «болгау сулы» коллективларда озак тора алмыйм. Тын кысыла һәм «чиста су» эзли башлыйм. Хәзер шуны аңладым: идеаль «чиста су» кайда да юк икән ул һәм тиз генә булмастыр да, мөгаен.

*— Сез үзегезне күбрәк фольклорчы саныйсыз. Хәзерге чорда фольклор югала, аның әһәмияте кими төште түгелме?*

— Шулай тоела гына. Халык исән булса, аның иҗаты да исән. Туган телен саклаган халык кына иҗатка сәләтле. Теле булмаса, иҗаты да, рухы да сүнә, башка милләткә иярчен булып җан саклау хәленә дучар ителә ул. Фольклор экспедицияләрендә шундый халәттәге татар төбәкләрен күрергә туры килде миңа. Әйтик, Мордовия, Свердловск өлкәләрендәге авылларда балаларның русча сөйләшеп йөрүләрен, бер генә татар уенын да, бер генә такмак та белмәгәнен күрергә туры килде. Бу инде безнең милләт өчен — югалган балалар. Тамырсыз яшәү һәм рухи мескенлеккә дучар буын.

Кайбер җирләрдә балаларны рус телендә һәм татар теленнән тәрҗемә ителгән әдәбият һәм фольклор нигезендә тәрбияләмәкче булалар. Бу — файдасыз шөгыль. Чөнки әдәбият, бигрәк тә фольклор, халыкның үз теле белән бергә генә яши ала. Дөрес, фольклор әсәрнең эчтәлеген якынча башка телгә тәрҗемә итеп була, ә рухын юк. Тәрҗемә ителгән фольклор ул әсәрнең җансыз гәүдәсе генә. Ә үленең кайчан терене тәрбияләгәне бар?

*— Татар фольклорының җыелу һәм өйрәнелү дәрәҗәсен ничек бәяләр идегез?*

— Җыелуы байтак җыелган. Әмма хәзер аны яңача, ягъни хәзерге техник җайланмалар — видео һәм кино ярдәмендә җыю-туплауны оештырып җибәрү мөһим. Җыелган материалларны компьютерга кертү мәсьәләсе дә бик актуальләшә. Хәзер бөтен дөнья видео, компьютер белән эшләгәндә, без татар фольклорчылары фольклор җыентыклары төзибез, аны өйрәтәбез дип, еллар буе архив тузаны эчендә утыра алмабыз бит.

Фольклорны өйрәнү бездә хәзер тиешле югарылыкка ирешеп килә. Х. Бәдиги, Н. Исәнбәт, Х. Ярми, Ф. Урманче, И. Надиров, Х. Мәхмүтов, Ф. Әхмәтова, Л. Җамалетдинов, Р. Мөхәммәтҗанов һ. б. фидакарьләребез хезмәтләре белән ул, башка күрше-тирә милләтләрнеке белән чагыштырганда, ярыйсы гына дәрәҗәле күренә. Әмма аның чын югарылыгы, минем уемча, халык иҗатының укыту һәм тәрбия системасына ныклап кертелү-кертелмәве белән билгеләнә. Бу яктан карaганда без әлегә мактана алмыйбыз. Урта мәктәп дәрәҗәсендә ул ярыйсы гына кертелгән булса да, югары мәктәптә эшләребез хәрти. Югары мәктәп өчен татар халык иҗаты буенча дәреслек тә, хрестоматия дә эшли алганыбыз юк. Дөресрәге, бервакыт дәррәү тотынган идек тә, соңгы елларда милли-сәяси даирәләргә кереп китеп, бу эшне онытып җибәрдек. Хәзер югары мәктәп өчен дәреслек һәм хрестоматияне төзү эшен кичекмәстән башларга кирәк.

Әйтергә кирәк, татар фольклорының күп жанрлары инде өйрәнелгән, күзәтүләр ясалган. Ә менә халкыбызның драма һәм уен фольклоры турында әлегә зур хезмәтләр юк. Мин хәзер фольклор хәзинәбезнең шул өлкәсенә кереп киттем.

Исән булып, эшләр әйбәт барса, якын арада үз эзләнүләремне халыкка житкерермен дип өмет итәм.

*— Рәшит, сез фольклорчы, ә үзегез соңгы елларда милли сәясәткә кереп киттегез. Бу ничектер көтелмәгәнчәрәк булды шикелле.*

— Барысы да шул фольклорчылыктан башланды инде. Мин халык иҗатын җыеп татарлар яшәгән күп төбәкләрне йөреп чыктым. Кайда да милләтебезнең кысылып, барлык мәсьәләләрдә дә башка халыкларга буйсынып, соранучы кыяфәтендә яшәвен күрдем. Болар минем йөрәкне нык әрнетте. 1988 елда, Казанда Татар иҗтимагый үзәге оеша башлау чорында, үзем дә сизмәстән милли хәрәкәткә кереп киттем.

Милли хәрәкәттә булу дәверендә мине татар халкын туплау-җыю мәсьәләсе кызыксындырды. Бу безнең халыкның язмышын хәл итә торган төп мәсьәлә икәне һәркемгә мәгълүм. Татар халкы үзенең тарихи язмышы белән территория ягыннан да, үзенең рухы, мәдәнияте белән дә бик таркалган халык. Төрле илләрдә, кыйтгаларга сибелгән. Шушы сибелгән халыкның рухи бергәлеген тудыру механизмнарын эшләү кирәк иде. Татар иҗтимагый үзәге оешу чорында без, шуның беренче этабы буларак, татар яшәгән төшләрдә ТИҮнең бүлекләрен оештыру эшенә керештек. Ул процесс бик тиз барды. 1989 ел ахырларында элекке СССР чикләрендә генә дә йөздән артык ТИҮ бүлекләре барлыкка килде. Әлбәттә инде, ТИҮ сәяси оешма да булгач, татар халкы үз мәркәзе тирәсенә мондый формада туплана башлагач, Россиянең махсус службалары бу күренешкә тиз игътибар итте. Россия өлкәләре һәм республикадагы бүлекләрне культура-агарту үзәкләре рәвешендә, ягъни мәгърифәт оешмалары итеп төзергә «установка» булды. Ләкин урындагы оешмаларны тудыручы милләттәшләребез белән без аңлашып эш иттек. Бәйләнешләрне, эшләрне төрле юнәлешләрдә алып бардык. Шулай итеп беренче мәртәбә ничә йөз еллар буе сибелеп яшәгән татарның җәмәгать тәртибендә туплана башлавына шаһит булдык. Бу процессның ныклы идеологиясен дә булдырырга кирәк иде. Татарстан күмәк информация чаралары житәкчелеге белән дә бу турыда аңлашу таптык. Телевидениедә милли берләшү проблемаларына багышланган «Кардәшлеккә чикләр юк», радиода «Кардәшлек» тапшырулары «Ватаным Татарстан»да «Милләттәшләр авазы» чыгарылышлары берләшү идеясен нығытуда зур роль уйнадылар.

Җәмәгать тәртибендә тупланунын икенче этабында без милләт вәкилләренең профессиональ нигездә берләшүен күз алдында тоттык һәм кичекмәстән бу эшкә тотындык.

1992 елның гыйнварында без, бер төркем мәгърифәтчеләр, Казанда татар укытучылары һәм тәрбиячеләренең корылтаен җыеп, Бөтентатар «Мәгариф» бергәлеген оештырдык. Аннан соң мәдәният һәм сәнгать әһелләренең «Мәдәният» бергәлеген хасил иттек. Соңрак татар галимнәренең «Фән» бергәлеге һәм татар журналистлары бергәлекләре оешты. Бу процесс алга таба да дәвам итәр дип уйлыйм.

Хәзер бу туплаппы процессын, безнең карашыбызча, Татарстан хөкүмәте тулысынча үз кулына алырга тиеш.

Дөрес, хөкүмәтебез каршында бу эш белән шөгыльләнергә тиеш булган структуралар бар кебек. Әйтик, президент аппараты каршындагы милләтара мөнәсәбәтләр һәм җәмәгать оешмалары белән бәйләнеш бүлеге һәм Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты. Әмма алар әлегә татар халкы берләштерүне, туплауны тулысы белән үз кулына алырлык дәрәҗәдәге структуралар түгел. Дәүләт күләмендә андый структура булдыру өчен, күрәсең, хөкүмәтнең татар халкы язмышына карата позициясе, гомумән, республикада ачык милли сәясәт булырга тиеш. Ә Татарстан мөстәкыйльлегенең, түрәләребез әйткәнчә, «милли билгесе юк». Монда рухи бөлгенлеккә төшкән төп халык — татарларның да, инде тормышыбызның барлык сфераларын да яулап алган урыс халкы мәнфәгатьләре дә тигез куелган. Димәк ки, татар халкының алга таба да ассимиляцияләнүенә юл ачык дигән сүз. Ни гаҗәп, телне, милләтне саклау буенча законнар, дәүләт программалары кабул ителүгә карамастан, республикада татар мәнфәгатен кайгырту «татар өчен гамәл калсак, урыс ни әйтер?» дигән беркатлы «идеология» белән алып барыла. Республикада шундый сәясәт хөкем сөргәндә башка кыйтгаларда яшәүче татар мәнфәгатен кайгырту турында нинди сүз алып барырга мөмкин?

Әйе, республикабыз — күп милләтле. Аларның һәрберсе турында кайгырту булырга тиеш. Әмма шул бергә яшәүче халыкларның бер-берсенең милли

тормышына комачау итмичә, бер-берсенең үсешенә ярдәм итеп, яхшы мөгамәләдә торуның тәгълиматен булдырырга, шуны тормышка ашыруга юнәлдерелгән дәүләт идеологиясе урнаштырырга тырышу юк. Хәзерге хөкүмәтебез милли сәясәте, әлегә дә баягы, «урыс ни әйтер?»гә генә корылган.

Минем уемча, хәзер республикада дәүләти милли сәясәт булдырылмаса, татар мәнфәгате һаман көчле идеологик машинасы булган урыс халкы белән «тигез» күрелеп, шул рәвешчә милләтебезнең ассимиляцияләнүе дәвам итсә, гомумән, дәүләт тарафыннан милләтне саклау буенча чаралар күрелмәсә, татар, иртәме-соңмы, 1990 еллар башындагы кебек, тагын бер кузгалыр. Монысы инде милләтләр арасында гаделлек урнаштыру төсен чынлап алуы мөмкин. Мин бу күтәрелешнең якынайганын ничектер күңелем белән сизеп торам. Әйтик, соңгы елларда милләт язмышы, татар тарихы, аның рухи мәдәниятенә багышланган дистәләгән җыеннарда, конференцияләрдә булырга һәм аларның байтагын оештырырга туры килде. Берсендә генә дә бүгенге хөкүмәтнең татар халкы язмышына карата алып барылган сәясәте хупланганы юк диярлек.

*— Сез Бөтентатар «Мәгариф» бергәлеген оештыруның да башында торган кеше. Бу оешманың максатлары нидән гыйбарәт?*

— Аны без татар халкының мөстәкыйль мәгариф системасын барлыкка китерүдә бер терәк булыр дип оештырган идек. Ул үзен аклады. Башта ул ТИҮнең «Мәгариф» комитеты буларак эшләде. Соңыннан, корылтай уздырып, мөстәкыйль җәмәгать оешмасы булды. Гомумән, ул татар мәктәпләре, гимназияләре ачу вакытында зур эш алып барды. Рәсми мәгариф органнары «Мәгариф»челәр эшенә таянып эшләде. Милли мәгарифне торгызуның теоретик нигезләрен эшләүдә дә өлешебез булды дип әйтә алам.

Үз вакытында без, берничә мәгърифәтче җыелып, «Татар мәгарифен үстерү концепциясе» проектын эшләргә булдык һәм аны төзеп матбугатта бастырып чыгардык, фикер алышулар үткәрдек. Соңыннан милли мәгариф системасын барлыкка китерүнең фәнни нигезен тәшкил иткән бу документ Татарстан мәгариф министрлыгы коллегиясендә кабул ителде, соңыннан «Мәгариф турындагы закон»га да нигез булып ятты. Шулай итеп, җәмәгать тәртибендә эшләнгән нигезләмәләребез мәгариф буенча дәүләт сәясәтен билгеләүче мөһим документка әйләнеп куйды.

Халыкның милли мәгариф системасын барлыкка китерү ул киләчәк буынга балалар бакчасыннан алып югары уку йорты һәм аспирантурага кадәр үз туган мохитендә һәм телендә белем һәм тәрбия бирү өчен тулы шарт булдыру дигән сүз. Ә территория ягыннан, татар уку йортының кайдалыгына карамастан, методик үзәге Казанда булган халык мәгарифе белән җитәкчелек итү системасын төзү күз алдында тотыла. Һәм бу система татар яшәгән бөтен төбәкләрне дә үз эченә алырга тиеш. Әйтергә кирәк, хәзергә Россиядәге хокукый башбаштаклык хөкем сөргән заманында бу шартларны булдыру бик авыр. Әмма алга китеш сизелә. Республикада моннан биш еллар элек туган телдә уку бары тик урта мәктәп дәрәҗәсендә генә булса, хәзер инде урта махсус һәм югары уку йортлары дәрәҗәсенә күтәрелеп килә. Татар милли университетын төзү дә тормышка ашу стадиясенә керде. Моны мин республика мәгърифәтчеләренең зур казанышы дип бәялләр идем. Алдагы көндә үз республикабызда үз телегездә диссертацияләр язып, аны үз телебездә яклауны; үзебезнең югары мәктәпләр министрлыгын да булдырып, анда Югары аттестация комиссияләре дә оештыруны максат итеп куярга тиешбез.

Төрле халыкларның мәгариф системасы укмашкан республикада татарның үз мәгариф системасын бүлеп алу мәҗбүрият булачак. Ни өчен? Чөнки, алдарак әйткәнемчә, Татарстан дәүләте үзенең эчке һәм тышкы сәясәтендә татар халкы мәнфәгатен приоритетлы итеп куеп җиткерә алмады. Димәк, татар милли мәгарифе, өстенлекле урында торган рус мәгарифе белән керешкән хәлдә, тиешле дәрәҗәдә үсә алмаячак. Бу обстановкада, милли мәгариф, халыкның язмышын билгеләүче төп фактор буларак, һичшиксез, башка халыкларның мәгариф системасыннан аерылырга тиеш. Укытуның эчтәлеге, тәрбия системасы, методика юнәлешләрендәге милли бүленешне эшләве авыр да түгел кебек. Ә мәктәп, институт биналарын шушы процесс белән бәйләнешле рәвештә бүлүләр авырлык белән барганы күз алдында. Тотылган чыгымнарны укучы балалар һәм яшьләрнең милли нисбәттән пропорциясе нигезендә бүлү турында сүз чыкса, «интернационалист»лар бугазга ябышырга әзер. Бу республикабызда шулай, ә Россия җирендә, бу турыда сүз кату белән үк, «Карабах оештыручы»га әйләнәсең. Ни

генә булмасын, халкыбыз яшәсен, башка милләтләр тарафыннан «йотылмасын» дисәк, үзебезне башка халыкларга каршы куймыйча, мәгарифебезне гадел шартларда аерымландыру юлыннан барырга да барырга кирәк. Ахыр чиктә бу мәсьәләдә милләтара аңлашу барыбер киләчәк. Чөнки «һәр милләтнең үз мәгариф системасы була» дигән нәрсә ул дөнья цивилизациясендә аксиома һәм бернинди дә каршылыкка очрамый. Без дә ул көнгә киләчәкбез.

*— Рәшит, сез Бөтентатар иҗтимагый үзәген оештыруда һәм хәзергәчә аның эшен алып баруда катнашкан кеше. Әйтегез әле, бу оешманың тормышыбызда нинди роле булды һәм аның алдагы язмышы ничек булыр?*

— ТИҮ татар милли хәрәкәтенең 1980 еллар ахыры 1990 еллар башында яңа көч белән күтәрелеп китүендә зур роль уйнады. Республиканың мөстәкыйльлек юлы белән китүендә дә аның роле бәхәссез. Ул оешмаган булса, мөстәкыйльлек турында бүгенге декларациябез дә, Конституциябез дә булмас иде. Ләкин ул хәзергечә Татарстанның милли дәүләт сәясәтенә тәэсир итеп торучы көч була алмады. Хәлсезләнде. Моның сәбәпләрен төрле кеше төрлечә аңлата. Күпләр: «Россиянең махсус службаларының эше булды, ахрысы»,— диләр. Анысы да булгандыр, Россия дәүләтенең кайсы чорда, кайсы җирдә җимерү эше алып бармаганы бар? Шунда гынамы сәбәп? Минемчә, төп сәбәпне иң беренче үзебездән эзләргә кирәк. Бердәм, кардәшлек кадерен белә торган фикердәшләрне, милләтне беркем дә читтән торып тарката алмый. Димәк, сәбәп иң беренче үзебезнең рухыбызда, фигылебездә, гамәлебездә.

Шунысын да әйтергә кирәк, тора-бара җитәкчеләребез гамәлләрендә татар кешесенә хас булган «чабатаны түргә элү» галәмәтләре күренә башлады. Җитәкчелек итәргә хәленнән килгәннәр аз санда булса да, җитәкчелек итәргә теләге булганнар артык күбәйде. Аларның байтагы үз оешмаларын төзеп, төрле «түрәләр» булдылар. Анда инде кайсы оешма нинди фиркага буйсынырга тиешлеге турында сүз китте. Бик җаваплы сәяси моментларда да аларны тулысынча берләшкән бер көч итеп оештыру мөмкин булмады. Шундый буталчык заманда да мин башта ук оешкан «традицион ТИҮ» (бервакыт яңа ТИҮ төзибез дип йөрүләр дә булды бит), нинди генә авыр моментлар булса да, салкын акыл белән, шапырынмыйчарак эшләүчеләр белән бергә булдым.

Хәзер «ТИҮ бетте, ТИҮ таркалды» дип лаф оручылар бар. Мин шуның эчендә йөрүче бер кеше буларак әйтә алам: ул бетмәде, аның Казандагы традицион үзәге сакланып калды. Ә вакытында «Үзәк»не үз кулларына алып, җитәкчелеккә менеп утырып, милли хәятебезне, милли дәүләтебезне тиз генә «мүкләп-чутлап» куярга йөрүчеләр акрынлап тындылар. Милли дәүләт өчен көрәшнең әле дәвамлы булачагын алар да шәйләде, күрәсең. Татар иҗтимагый үзәге хәзер республикада милли сәясәт буенча фикер туплау урыны, милләттәшләребез мәнфәгате буенча көндәлек эшләүче, милли мәсьәләләр буенча һәркем консультация ала, армиядә балаларын югалтканнар, чит илләрдән куылганнар, дәүләт аппаратларыннан җавап таба алмыйча интегүчеләр, гаделсезлек корбаннары булган милләттәшләребезнең киңәш-табыш итү урыны буларак яши һәм милләтебезгә хезмәт итә. Сакчыларга, милициягә ялынмыйчы, пропуск системалары — сират күперләре аша түгел, адәмчә генә кереп киңәш-табыш, җан тынычлыгы алып китәрдәй Казанда тагын нинди җир бар милләттәшләребез өчен? Юк бит. Шуның өчен ТИҮне мин изге җир дип саныйм. Үзен татар дип санаган кеше, төрле гайбәтләргә бирелеп, ана тел-теш тидерергә тиеш түгел.

*— Сез алдарак, үземне зур кыенлыклар алдында куеп булса да, милләт мәнфәгате өчен чаркалышлар арасында буласы килә, дидегез. Бу ТИҮдә эшләүгә дә кагыламы? Анда эш алып баруның төп авырлыгы нидә?*

— Беренче чиратта, хөкүмәт даирәләрендәге кайберәүләрнең һәм күпчелек халыкның бу эшнең кирәклеген кирәк дәрәҗәдә аңламавында. Кайчак миннән: «ТИҮдә күпме акча аласың?» — дип сорыйлар. Анда акча түләү юк. Бары тик, техник хезмәткәрләргә генә түләү бар. Анысы да даими түгел. Ул бит игāнә акчасына торучы оешма.

Минем, мәсәлән, ТИҮдә хезмәттәшлек иткәнемне бер генә «шеф»ымның да (өйдәгесе дә!) хуплаганы юк. Хәтта Бөтендөнья татар Конгрессында эшләгән елларымда да ТИҮдә йөргән өчен кырын карау сиздем. Бер карасаң, татар Конгрессы да, нигездә, Татар иҗтимагый үзәгенең җирле бүлекләре аша җыелды бит. Конгрессның да, ТИҮнең дә Россиядә һәм БДБ илләрендә нигезләнеп эшләүче оешмалары уртак. Бергә кулга-кул тотынып эшләргә генә кирәк, югыйсә.

Хөкүмәт даирәләрендәге күп кешеләр өчен без — «ТИҮчеләр», әлбәттә инде, «тамга салынган» адәмнәр. Күрмәмешкә салышу, фикерне үткәрмәү, санашмау, «чабудан тартып тору» һәм, гомумән, безнең белән «ара саклау» табигый бер хәл. Аңа без күнеккәнбез дә инде.

Боларның сере, мөгаен, төптәрәк, без белмәгән җирдәдер. Кайдадыр кемнәргәдер «установка» куялар. Юкса, үз милләте өчен дип йөрүчеләргә мондый караш булырга тиеш түгел иде.

Әйтик, миңа заманында «Татар мәгарифен үстерү концепциясе»н, «Татар мәдәниятен үстерү концепциясе»н төзү белән җитәкчелек итәргә (соңгысын билгеле галим Д. Исхаков белән берлектә) туры килде. Без боларны карусыз эшләдек. Авыр эшләнде, күп энергия, вакыт китте. Аларның милли мәгариф, мәдәниятне күтәрү юлларын билгеләүдә файдасы булганын да белеп-күреп тордык. Әмма югары структуралар бу идея-концепцияләрне тартып алды да, безне алга таба гамәли эшләрдә катнаштырмады. Соңыннан ишетәбез: теге министрлык концепция төзегән, монысы программа төзегән... Хәтта бер министр урынбасарының, «концепция минем тарафтан эшләнде» дип, эшләүчеләрнең исемен сызып конкурска җибәрү очрагы да булды...

*— Әйдәгез, Рәшит әфәнде, бераз «яктырак» темаларга күчик әле. Сез әле театр студиясе бетергән кеше дә, шагыйрьлек сәләтегез дә бар бит әле.*

— Театр студиясе дигәннән... 1967—69 елларда Актерлар йортында Сәхнә ветераннары оештырды аны. Кәшифә Тумашева, Касыйм Шамил, Асия Масаутова, Хәмит Төхватуллин, Екатерина Гарданова лар укыттылар. Укып чыгучыларга нинди дә булса таныклык бирә алмасалар да, театр серләренә ныклап төшендек. Кайберләребез турыдан-туры театрларда эшләп китте. Мин исә М. Җәлил турындагы «Моабит дәфтәре» дигән фильмда эпизодлар уйнау (1968 ел), Пермь өлкәсендәге Барда халык театрының артисты булудан гайре гамәл кыла алмадым. Хәлбуки, урта кул артист булырга чамам булса да, язмышым икенче юлдан китте. Минем театр буенча белемем алга таба татар халкының театр сәнгатен, уеннарын тикшергәндә ярап куяр дип уйлыйм.

Шигырь дигәннән... Анысын да онытып булмый — яшьлек хыялларыннан килә торган нәрсә. Хәзер Казанда шигырь китабы чыгарам дип йөрү мөмкин түгел. Аның каравы туган ягымда, Барда нәшриятендә китабымны бастырып чыгардылар.

*— Рәшит, сезнең эшчәнлек колачыгыз бик киң. Башкарган хезмәтләрегез, гомумән, белгечлекләрегез арасында берәр уртак момент, сыйфат бармы?*

— Кемдер әйткән, бит: дөнья сәхнә, без тормыш театрының артистлары дигән... Бар эштә дә яхшы актер булырга тырышырга кирәктер, минемчә. Артистланырга түгел, ә актер булырга! Тәкъдим ителгән мөхиткә (аны русча «войти в предлагаемые обстоятельства» диләр) җаның-тәнең белән кереп, шул тормышта яшәп китәргә кирәк. Шунда гына эш майтарып була. Барлык эшләрдә дә әнә шулай яхшы мәгънәсендә «образга керергә» тырышам. Әгәр артистлансаң, көт тә тор, мәгънә чыкмый.

Мин актер иҗаты белән шагыйрь иҗаты арасында да тыгыз элемтә барын тоям. Һәр шагыйрьдә артист сәләтенең булуы шарт дип табам. Әгәр дә шагыйрь илһам килгән вакытта хыялы белән образга керә алмаса, ул шигырь тудыра алмый. Шигырь язганда шагыйрь көнкүрештән тулысы белән аерылып, хыялындагы дөньяга китә һәм, чын актер шикелле, шунда «яши» башлый. Шагыйрь шул халәттә булганда гына чын шигырь тудырырга мөмкин.

Башка өлкәләрдә дә, сәясәттә, милли хәрәкәттә дә үз ролебез бар безнең. Әйтик, кайбер милли түрәләребез, (алар кайчак үзләрен милли хәрәкәт башында дип тә тоя) безнең эше дәүләт структураларыннан читтә эшләүчеләрне «урам сәясәтчеләре нәрсә кыра алсын» дип чиртеп сөйләшергә ярата. Билгеле ки, бу оста актер түгел, бу артистланып йөрүче генә. Милли хәрәкәттәге чын көрәшче — ул нинди вазифада булуына карамастан, сәхнә теле белән әйтсәк, «партнерын тоя» һәм, үз образы буразнасында калып, сәясәт-спектакльнең логик тәгәлләнешенә омтыла. Һәммәбез дә бу тормышта шундый актер булып кала алсак, без милләт буларак, үз максатыбызга ирешербез.

# «МӘГАРИФ» — БИШ ЯШЬЛЕК АКСАКАЛ

Мөдәррис Вәлиев (Салих Маннапов) — «Сезгә ышанам», «Тамыр тирәнлеген яфрак тоя» китаплары белән укучыларга яхшы таныш исем. Соңгы елларда каләмдәшебез матбугатта татар китабы язмышына кагылган чыгышлары белән дә еш күренә. Бу гаҗәп тә түгел: моннан нәкъ җиде ел элек Мөдәррис Вәлиев Татарстан китап нәшриятында баш редактор итеп билгеләнгән иде. Соңрак тагын да җаваплырак эшкә — яңа оешкан «Мәгариф» исемле дәреслекләр һәм балалар китабы нәшриятын җитәкләргә алынды. Ул — Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редколлегиясе әгъзасы.

Шулай итеп, «Мәгариф» нәшрияты директорына без берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек. (Сез аның рәсемен журналыбыз тышлыгында күрәсез):

*— Исегездәме, бервакыт Сез, Фатих Әмирханның моннан 70—80 ел элек язган сүзләрен «казып чыгарып», яңа нәшриятлар ачуны хупламаган фикер-дәлил китергән идегез. Инде, үзегез шул эшкә алынгач, үзгәрмәдеме ул караш? «Мәгариф» исемле нәшрият төзелүенә ничек карыйсыз: бу авыр заманда акланамы-юкмы «матбага ачып уйнау»?*

— Чыннан да, Фатих Әмирхан нәкъ безнең көннәр хакында яза сыман бит: «Икмәк бәһасе тагы арткан... Һич акча түткәрер хәл юк... Китапны гаять кыйммәт сатканда гына аның расходын каплау мөмкин булачактыр. Ләкин халыкның бөтен кайгысы бары кара икмәк тирәсендә әйләнергә мәҗбүр бу елларда кыйммәт бәһа түләп китап алырга теләүче бик аз табылачактыр. Шунлыктан хәзер... нәшрият эшен башлау барып чыкмаска охшап торадыр...» Бу сүзләрне мин, моннан 5—6 ел элек, матбугатта Татарстан китап нәшриятына карата шактый ямьсез һәм авантюристик чыгышлар күбәйгәч, искә төшергән идем. Ул чакта берәүләр сусыз юып, җилсез киптермәкчеләр иде: нәшриятның кәгазен безгә бирегез, ул инде тәмам банкротлыкка чыккан, ә без, имеш, дәүләттән бер тиен акча алмыйча, иртәгәдән тау-тау китап чыгарырга керешәбез...

Фатих Әмирханның хаклыгын вакыт тагын бер кат раслады. Бүген Татарстанда китап чыгару хокукы алган йөзләгән «нәшрият» бар. Ә кайда ул — вөгъдә ителгән татар китаплары? Юк, ул чактагы фикерем тамчы да үзгәрмәде. Бүгенге көндә милли нәшрият дәүләт ярдәменнән башка тернәкләнә алмый. Чөнки татарның зыялы байлары юк әлегә. 7 миллион укучысы да юк татарның. («Казан утлары»н өенә яздырып алучылар санынча гына ул, минемчә.)

«Мәгариф» нәшриятына Татарстан хөкүмәтенең махсус карары юл ачты. Әмма бу — хәтта бик әйбәт карарларны, хәтта кануннарны да кәгазьдә калдыра торган кырыс һәм кысыр заман...

Әлбәттә, мәсьәләгә киңрәк караганда, төрки халыклар тарихында иң фаҗигале сәхифәләрнең берсе — татар язмышы булса, татар тарихында иң авыр сынауларга дучар ителгәне — мәгаен, галиҗәнаб Китаптыр. Мәгърифәтле халыкның беренче китабы дәреслек, тәүге ачылган басмаханәләре арасында исеме үк күпне аңлата торган «Мәгариф» нәшрияты була. (Быел ул якты учакның кабынуына — 90, ә рухи дәвамчысы — «Мәгариф» нәшриятының кабат торгызылуына 5 ел тула. Шуңа күрә «Мәгариф»не без *«5 яшьлек аксакал»* дип атыйбыз да.) Дәреслекләр һәм балалар китабы бастырган, татарның күңелен, аңын агартуда

фидакарь хезмәтләр күрсәткән затлы нәшрият бу. Галимнәр, Тукайның үзе исән чагына бөтен китаплары диярлек шул матбагада дөнья күргән, диләр. Барча-барча учаклар сүнеп беткәндә дә, «Мәгариф» сакланырга тиеш иде кебек. Юк, Сталин хакимияте моңа юл куймый, мал-мөлкәтен тартып алып, милләткә түгел — юлбашчыга хезмәт итүчеләр кулына бирә. Татарның мәгърифәт кояшы бату «Мәгариф»ләрсез калганнан соң башлана.

Шулай, тарих кабатлана. Тукайчалап әйтсәк, халкыбызның «уянгач беренче эше» — «Мәгариф» нәшриятын яңадан торгызу-тергезү булды. Җитмеш ел буе өзелеп торган тәсбихнең, ниһаять, бер буыны ялганды. Татар телен дәүләтле итү юлында әлегә иң зур, иң җитди адым — «Мәгариф» нәшриятының аякка басуы, дияр идем.

— *Җитмеш ел буе дәреслек чыгару белән Татарстан китап нәшрияты, аның зур булмаган бер редакциясе шөгыльләнгән. Шуңа күрә күңелгә бер «җайсыз» сорау килә: махсус нәшрият төзү ихтыяҗы бар идеме икән?*

— Әйе, барлык кыйтгаларга сибелгән халкыбызның бердәнбер китап чишмәсе булып «Татиздат» — Татарстан китап нәшрияты калган иде. Катлаулы чорлар аша шул авыр йөкне иңнәренә салып бер ялгызы үтә ул.

Ә дәреслек чыгару белән «бер кечкенә редакция генә» шөгыльләнде дигәндә, сөйләүчеләр кайбер детальләрне «онытып» җибәрәләр. Кулъязманы редакцияләү — бик мөһим процесс, әмма ул әле китап нәшер итү кебек зур эшнең башы гына. Дәреслек чыгару белән Татарстан китап нәшриятының да барлык службалары шөгыльләнә иде.

Иң мөһиме шунда, без милли мәгариф системасы яңарып (ә бәлки әле яралып кына?) килгән дәвердә яшибез. Яшерен-батырын түгел: әлегә ул стихия рәвешендә бара. Фәлән кадәр татар мәктәбе ачылуны үз казанышы итеп күрсәтергә теләүчеләр күп... Әмма чын яңарыш фидакарь укытучыдан һәм яхшы дәреслектән башлана. Халык педагогикасы, тарих, икътисад һ. б. бик күп юнәлешләрдә яңа дәреслекләр кирәк. Ә дәреслек — күмәк хезмәт җимеше. Күз тимәсен, безнең көчле авторларыбыз бар. Әгәр шул эшкә күңелен баглаган махсус нәшриятыбыз булмаса, бу авыр заманда дәреслеккә лаеклы игътибарны, сан һәм сыйфат үзгәрешләрен күтәргә мөмкин түгел иде.

Без тарих белән мактанмыйбыз, бүгенге куанычыбызны гына уртаклашабыз. «Мәгариф» нәшриятының кыска вакыт эчендә башкарган хезмәтләре — укучы кулында. Сан ягыннан бу — 300 исемдә, 7 миллион данәдән ашып киткән китап хәзинәсе дигән сүз. Эчтәлеге-юнәлеше белән бу — бишектән алып, татар мәгърифәтенең барлык баскычларын иңләп-атлап узучы һәм гомер буена озатып барасы дәреслекләр, мәктәп һәм гаилә китапханәләре өчен нәфис һәм фәнни-популяр әдәбият, укытучылар өчен әсбаплар. Югалган буыннарны кайтару юлында туган тел ачкычы буласы әлифбалар, үзөйрәткеч һәм сүзлекләр. Инде югары мәктәп (вуз) студентларына да татарча дәреслекләр әзерләп чыгару чиркančыгын алдык. Мәктәптә төгәл фәннәрне (мәсәлән, физиканы) үз ана телебездә иҗат ителгән дәреслекләрдән укыту мөмкинлеге туып килә. Тәнкыйть сүзенә мохтаҗ булсалар да, татар әдәбиятыннан, татар тарихыннан яңа дәреслекләр — бик күтеп алынган хезмәтләр. Гомумән, без Рәсәйнең чын тарихы Казанда язылырга һәм «Мәгариф» нәшриятында басылып чыгарга тиеш дип саныйбыз.

«Мәгариф — азатлык юлында беренче адым». — Гаяз Исхакыйның бу сүзләренә бөтен хәлебез сыйган да беткән, минемчә. Милли ренессанс «Мәгариф»тән башлана, дибез икән, һич арттыру булмас.

Китап — кайчандыр мәгърифәтле, китаби татарның артта калуы, чикләнгәнлеге, җәберсетелүе күрсәткечене әверелгән иде. Бигрәк тә соңгы җитмеш елда, белгәнебезчә, китап һәм мәктәп аша яшь буынга ят рух сеңдереп киленде, милләтнең тамырына балта чабылды. «Мәгариф» — иншалла, татарның киләчәгенә хезмәт итәсе, XXI гасыр баласына остаз буласы нәшрият.

— *Әдип иҗаты бала күңеленә нәкъ менә мәктәп дәреслеге аша керә һәм тамыр җәя. Ә балалар китабы үзе — иң үтемле, иң тәэсирле дәреслек бит әле ул. Шуңа күрә «Мәгариф» нәшриятында китап чыгару язучылар өчен аеруча мәртәбә (престиж) булыр дигән өмет бар иде...*

— Без «Мәгариф»не нәкъ менә «дәреслекләр һәм балалар әдәбияты нәшрияты» итеп торгызу белән мәшгульбез. Милли әдәбият — рухны ныгытучы дәреслек, һәм әдәби китапны дәреслеккә каршы кую мәгънәсезлек булыр иде.

Әгәр бала милли әдәбиятны дәреслекләрдә чагылып киткән кыйпылчыклар хәлендә генә хәтерләп калса, дәрестә «үтелгән» күләмдә генә рухын баетса, шактый авыр хәл туарга мөмкин. Мәктәп һәм авыл китапханәләрендә дә татар китабының хәле бик аянычлы икәнлеген беләбез.

Мәгълүм ки, безнең нәшриятның һәм шулай ук «Казан утлары» журналының иң якын дуслары, иң актив укучылары — укытучылар. Без бит бергәләшеп мәктәпкә, яшь буынның рухын тәрбияләү өлкәсенә, ахыр чиктә милләтебезнең яшәве һәм сакланып калуына хезмәт итәбез. «Мәгариф» китапханәсе» сериясеннән дә, аерым басмалар рәвешендә дә кайбер хезмәтләр дөнья күргәли. «Хан кызы» исемле мөнәҗәтләр җыентыгы белән Рәсәй күләмендә үткәрелгән китап конкурсында катнашып, 90 нәшрият арасында өченче урынны алдык.

Хәтерләсәгез, иң беренче китапларыбызның берсе — «Бишек җырлары» иде. Тукай заманындагы «Мәгариф» рухында «Бала күңеле» сериясен тергезәбез. Кыскасы, әлеге юнәлештә үз юлыбыз, үз йөзебез табылып килә. Теләк зур, кызыклы идеяләр бар. Тик бу эшне әлегә автор яисә заказчы тапкан химая-хәер акчаларына гына алып барырга мөмкин. Әйтик, Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дигән мәшһүр хрестоматиясен әзерләдек,— әмма бастырып чыгара алырбызмы,— безнең мәктәпләрдә Тукай хрестоматиясе «үтелми». Тукайның иганәчесе (спонсоры) да юк. Кызганыч хәл. Күңелне иң рәнҗеткәне шул: милли әдәби китап, хәтта сүзлек бастыру да «Мәгариф» нәшриятына яла ягу өчен нигез була ала торган вәзгыятьтә яшибез...

— *Кыскасы, безгә дәреслек чыгарырлык та акча бирмиләр әле, дип әйтергә телисез инде. Алайса менә мондый сорау. Шушы кытлык заманында «Мәгариф» нәшриятының аерылып чыгуы Татарстан китап нәшриятын тагын да көчсезләндерде, дигән фикер ишетелгәли. Чынлап та, нәшриятлар икәү булды, ә татар китабын бастыру икеләтә кимеде бит.*

— Әйе, «Мәгариф»не Татарстан китап нәшриятының (һәм язучыларның) авызындагы соңгы кабым икмәкне тартып алучы итеп күрсәтергә тырышу бар. Әмма моның сафсата, коткы сүз генә икәнлеген күрсәтү өчен дәлилләр эзләп тә торасы юк.

Беренчедән, Татарстан китап нәшрияты икегә бүленмәде. Аны «төп йорт» дип шартлы рәвештә атасак, бу төп йорттан «Мәгариф» бер тиен акча һәм бер бит кәгазь дә алып чыкмады. Бөтен бирнәсе — нәшриятта дәреслекләр редакциясе кыскару нәтиҗәсендә «артып калган» хезмәткәрләр иде. (Әлбәттә, алар үзләре зур хәзинә буларак яңа нәшриятның нигезен тәшкил иттеләр!). Кыскартулар, заман таләбе буенча һәм кризистан чыгу максатында, «Мәгариф» төзелгәнче үк башланган иде инде. Чираттагы генсекның «хезмәтләрен» бастыру өчен иң яхшы кәгазьне ашап ятучы сәясәт редакциясен ябу, мәсәлән, нәшриятның күкси башлаган һавасын шәп кенә бер җилләтеп алу булды... Дәреслек кебек четерекле, нәзберек басмадан котылу исә Татарстан китап нәшриятының икенче кулын да чиште: әйдә, булган кәгазенне, акчаңны, талантыңны бер йодрыкка туплап, әдәби һәм фәнни китаплар, классик мирасны гына чыгаруга юнәлт.

Татарстан китап нәшриятына дәреслек өчен бирелә торган дотацияне яисә табышны алып киттеме «Мәгариф»? Нәшрият хуҗалык исәбендә эшли (ягъни, үз көнен үзе күрә) иде ул чакта. Чыгарган китапларының алтыдан берен генә тәшкил итсә дә, дәреслек (балалар китабы өлешенә дә керә-керә!), яхшырак һәм кыйммәтлерәк кәгазьдә, катыргы тышлы һәм күп төсле итеп басылу аркасында, ул заман акчасы белән 1 миллион сум саф табыш алып эшләүче нәшриятка һәр елны шул кадәр үк зыян сала иде. (Сүз уңаеннан әйткәндә, Татарстан китап нәшриятына беренче тапкыр хөкүмәт дотациясе «Мәгариф» аннан «аерылып чыккач» кына бирелде. Һәм, инде дәреслекләр чыгарудан котылса да, Татарстан китап нәшрияты бүген «Мәгариф» белән бертигез дәрәҗәдә бюджет акчасына мохтаҗ).

Татар китабының санын «Мәгариф» нәшрияты киметтеме?

Дөрес, кәгазьдә генә «төзелгән» нәшриятның эше 1992—93 уку елына дәреслекләр чыгаруны өзүдән башланып китте. Ләкин бер-ике ел эчендә, эш күләме белән, «Мәгариф» олы агасы — Татарстан китап нәшриятын куып җитте һәм хәтта узып китәргә мәҗбүр булды. «Мәҗбүр» дигән сүз сәерсендермәсен: дәреслекләргә ихтыяҗ (ягъни тираж) елдан-ел арту нәтиҗәсендә туган мәҗбүрият иде бу. Соңгы елларда өр-яңадан язылган дәреслекләр саны да ике-өч тапкыр артты. Әлбәттә, бу эш фәрман белән түгел, дәрман белән бара. Бер еллык күләмне майтарып чыгу өчен, «Мәгариф» нәшриятына, әле типографиягә түләүне сана-

мыйча, бүгенге бәяләр белән 7 миллиард сумлык кәгазь, катыргы кирәк. Хөкүмәткә рәхмәт — ярдәменнән ташламый. Әмма бюджетның юрганы кыска — дотация дигәннәре эш күләменең яртысын да искә алып бетерә алмый. Татар мәктәбен дәреслексез калдырмас өчен, «Мәгариф» нәшрияты бүген әҗәткә кәгазь ала-ала, типографияләр алдында муеннан бурычка бата-бата эшли.

«Мәгариф»нең әтәче дә кукәй сала дип уйлау каян килә? Күрәсең, безнең карусыз, сукранусыз гына эшләвебез сәбәпчедер. Матбугаттагы һәм төрле җыелышлардагы аһ-зар язучыларның матди хәле тирәсендә барса, сүз үзеннән-үзе Татарстан китап нәшрияты хәлләренә тоташа. Язучыларга хәер өләшергә түгел, аларның китабын чыгарышырга кирәк. Ә бу эшне нәшриятлар көчле булганда гына башкарырга мөмкин. Югыйсә, китап чыгарудан өметен өзгән кайбер авторларда мифик «байлык»ны бүлешү инстинкты да уянып алгалый: нәшриятка дәүләт биргән акчаны язучыларның баш санына бүлеп таратсаң, күпмешәр тияр икән, янәсе.

«Мәгариф» нәшриятына өмет белән төбәлгән карашларны да аңлап була: татар китабының яңа сулышы ачылырга тиешле мәйдан ул. Мәгәр комнан бау ишәбез дип вәгъдә бирүчеләр — без түгел. «Мәгариф» — шундый ук проблемалар йомгагы ул. Һәм ул йомгакны сүтә башлауга, милли дәреслекнең чияләнгән төеннәренә килеп төртеләсең. Дәреслек бастыру кебек авыр йөкне үз өстенә алган нәшрият булмаса, әлеге мәшәкатьләр тумас та иде кебек тоела. Нишлисен, ашаган белми — тураган белә. Дәреслек чыгарудан күргән зыянны (!) каплау өчен бюджетта билгеләнгән акча мокытның төн йокысын качыра. Ул болай фикер йөртә: чыгарган китабы өчен тиешле хакны нәшрият айлар буе кайтарып ала алмый, әмма, ни гаҗәп, үҗәтләнеп дәреслек бастыруын дәвам итә. Бурычка чума-чума дәреслек чыгару нигә кирәк?! Димәк, монда «что-то не так».

Әйе, бу — мокыт логикасы. Ә инде бер яктан «милләт» дип лаф оручы, икенче яктан аның нәшриятына күпсенеп, зәһәр көнчелек белән караучыны очратасыз икән, белеп торыгыз: сезнең алда — мөнафикъ бәндә.

Татарга ике нәшрият күп түгел; Татарстан китап нәшрияты белән «Мәгариф» нәшриятын мин бер сәгатьнең ике угына охшатам. Ул укларның кайсысы зур (минут саный), ә кайсысы кече (сәгатьне күрсәтә) икәнлеге әллә ни мөһим түгел, әмма икесенең берсе булмаса — сәгать ялгыша, үз хезмәтен үти алмый башлый. Узышсалар да, аларның берсе икенчесен узып китә алмый — чөнки вазифалары төрле, максатлары уртак. Бу «уклар» бер-берсенә каршы да юнәлмәгән: эштәге кыенлыкларны бер-беребездән күрмибез, ярдәм итешеп, аңлашып яшибез. Гомумән, Татарстан китап нәшриятына карата без һәрвакыт «күршең бай булсын» дигән мөнәсәбәттәбез...

— *Сезнең фикерегезчә, татар китабының хәлен яхшырту өчен нинди кичектергесез чаралар күрү кирәк?*

— Юри генә санап карадык: без түләгән салымнар акчасына (700 миллион сумга!) шактый саллы һәм яхшы тиражлы тагын 15—20 ләп китап чыгарып була икән. Ул китапларны Салым инспекциясе нәшер итмәс шул инде...

Көчле чагыштырулар эзләмичә, татар китабын бастыру эше хәзерге көндә... җил тегермәнен хәтерләтә, дияр идем. Ягъни, финанс «җиле» аз гына исми торса, нәшрият канатлары хәлсезләнеп, туктап кала. Әлбәттә, җил тегермәне — тел тегермәне генә түгел: нәшрият «ташы», аксый-туксый әйләнсә дә, рухи икмәгебезгә кирәсе «ак он»ны азмы-күпме тарта әле. Әмма китап һәм дәреслек бастыру эшен *Дәүләт программасы* дәрәҗәсенә күтәрмәсәк, ул икмәк шактый юка һәм ачы булачак. Ә милләтнең яшәү сагында барыбер Китап тора!

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ТАЗА ОРЛЫКЛАР

(ДҮРТ ТОМЛЫК ӘСӘРЛӘР ҖЫЕНТЫГЫ БАСЫЛЫП ЧЫГУ УҢАЕННАН ЯЗУЧЫ АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ ИҖАТЫ ТУРЫНДА УЙЛАНУ)

*Кыйбла булып изге җилләр исәр,*
*Дөрес иман иңәр гомергә.*
*Уйчан күзле романтиклар үсәр,*
*Таза орлык чәчик бу җиргә.*

Гамил Афзал

«Таза орлык чәчик бу җиргә». Намуслы һәр каләм әһеленең изге хыялы, олы бурычы әнә шул. Аллаһы Тәгалә әдиплек таланты белән бүләкләгән икән, син дөрес иман белән генә эш итәргә тиеш.

Аяз Гыйләҗевнең дүрт томлык әсәрләр тупланмасын (Әсәрләр. Дүрт томда. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1994.) укыган кеше әйтер: автор иманын җилләр агымына карап алыштырып торган әдип түгел икән. Каләменнән чәчелеп калган таза орлыклар, алардан үсеп чыккан шытымнар әдип йөргән сукмакларның йөз кызартмаслык олы юлларга барып чыкканлыгын күрсәтә. Бу сукмаклар ахыр чиктә Аяз Гыйләҗевне хакыйкать биеклегенә алып килгәннәр.

Бездә «совет хакимияте елларында татар әдәбияты социалистик реализм методы белән үсә» дигән ышану яшәп килде. Шулай икән, димәк, ул тормышны инкыйлабый үсештә сурәтли, аның герое коммунизм төзүче уңай каһарман була, әсәрләре укучыларны марксизм-ленинизм рухында тәрбияли дигән сүз. Күпчелек каләм әһелләре өчен, әлбәттә, мондый таләпләр канун иде. Алар шушы кысалар эчендә урнашып, бик ансат кына каләм кыштырдатып килделәр. Ник язмаска: үткәрелгән идеяләре рәсми карашлар белән туры килгәч, әсәрләреннән басылмау куркынычы юк. Идеология чиновниклары алдында йөзең ак. Шулай булгач, орден-медальләр дә, мактаулы исемнәр дә сине үзләре эзләп табар. Тынычлап кына, артык эзләнеп азапланмыйча гына яшә дә, яшә. Ләкин чын талантлы кешеләр алай ваемсыз була алмыйлар. Алар кайвакытта, үзләре өчен илһамлану чыганагы булмау сәбәпле, каләмнәрен куйдылар. Икенчеләрен исә әдәбияттан читләшергә мәҗбүр иттеләр.

Афзал Шамовны гына алыйк. Ул егерменче-утызынчы елларда (әле социализм кеше өчен чын-чынлап бәхет китерәчәк дигән ышаныч белән яшәгәндә) «Рәүфә», «Днепр буенда», «Бер мәхәббәт турында», «Ана», «Госпитальдә», «Кыз урлау», «Туйда» кебек әсәрләр бирде. Болар — аның иҗатының асылын билгеләүче повесть-хикәяләр иде. Әлбәттә инде, социалистик реализм әсәрләре. «Кыз урлау» хикәясе генә, соңгы абзацын исәпкә алмаганда, реализм белән язылган. А. Шамовның төп мәүзугы — гражданнар сугышы вакыйгаларын һәм егерменче елларның авылын сурәтләү. Дөрес, Ватан сугышы елларында да аның каләме бераз йөгерекләнеп алды. Ләкин бу язучыбыз егерменче-утызынчы еллардан соң иҗатта шактый «арып» калды. Һәрхәлдә, ныклы кул белән башланган иҗаты үсеш кичермәде. А. Шамовны коммунистлар партиясе идеологиясен үз күрмәде дип тә әйтеп булмый. Киресенчә, үзенең эшчәнлеге белән ул шул идеяләргә нык тугры икәнен раслады. Тик колхоз төзелеше, ару тормышлы, эшлекле авыл кешеләрен кулак дип атап җәберләү һәм башка күренешләр аны «Рәүфә» кебек шактый талантлы язылган бүтән әсәрләр иҗат итәргә рухландырмады инде. Ә бит аның «Кояшлы яңгыр» (К. Нәҗми), «Тын елгада» (Г. Толымбай) кебек

әсәрләр язарга кулыннан килә иде. Әллә ул андый нәрсәләрдән тәм тапмады, әллә башка сәбәп булды — А. Шамов язучы буларак шактый сүлпәнләнде.

«Казан утлары»нда басылган (1971 ел, 1 сан) эпиграммасында шагыйрь Зөлфәт бер дә юкка гына болай дип язмады:

Сүзләр сирәк төшә, юкса
Каләм төшмәгән кулдан.
Хәтта ки Афзал Шамов та
Язган заманнар булган.

Әдәбияттан читләштерелгән әдипләрне дә байтак санарга мөмкин. Шуларның иң характерлысы, мөгаен, Сирин Батыршиндыр. 1970 елда гына үлсә дә, 1931 елдан бирле бу шагыйрьнең оригиналь шигырьләр җыентыгы чыкмый. Дөрес, шәхес культы фаш ителгәч, 1959 елда аның егерменче-утызынчы елларда язылган әсәрләреннән торган бер китабы чыгарыла.

Якын итеп кенә бер сүз әйтим:
Сукалы карт, тормышыңны суксын яшен!
Иске тормыш
Үлә,
Үлә,
Үлеп бетә,—

дип язган Б. Сирин дә, шулай итеп, совет әдәбияты өчен кирәксезгә әйләнде.

Язучыларның билгеле бер кагыйдәләргә таянып иҗат итәргә тиешлекләренең бер файдалы ягы да булды. Каләм әһелләре, әйтәсе фикерләрен яшереп, сүз араларында гына җиткерергә тиеш булдылар. Бу хәл аларның сүз белән эш итү осталыкларын арттырды. Әлеге җәһәттән караганда, әдәбиятта үзенчәлекле язучылар барлыкка килде. Ә. Еники, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, Ә. Баянов, Р. Батулла һәм тагын кайбер каләм әһелләрен шулар рәтенә кертергә мөмкин иде. Дөрес, алар бернинди дә оешкан төркем тәшкил итмәделәр, һәрберсе аерым-аерым, бер-берсеннән мөстәкыйль иҗат итте. Берләшү турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Биредә дә аларны бергәрәк карау — иҗади хасиятләренең үзенчәлеге нигезендә генә була ала. Бу язучылар социалистик реализм әдәбияты диңгезе эчендә, шулай әйтергә яраса, тәнкыйди реализм утраучыкларын барлыкка китерделәр. А. Гыйләҗевне бу мәсьәләләрдә «максималист» дип атаган Р. Мөхәммәдиев хаклы иде. (Казан утлары, 1980, № 10, 138 б.) Р. Мостафин исә аның иҗатын «кырыс реализм» буларак бәяләде. (Казан утлары, 1983, № 7, 179—182 бб.) Г. Афзал да бу язучыбызның иҗатындагы төп пафосны шактый дөрес тотып алды:

Син бик усал, ач арыслан кебек,
Усаллыгың җитәр йөз елга.
Юаш кына малай идең элек,
Усаллата икән бу дөнья.

Халык шагыйре Г. Афзал үз каләмдәшен «усал» дип кенә әйтеп калмый, бу сыйфатның аңарда ни өчен барлыкка килүен дә аңлатып бирә: «усаллата икән бу дөнья». Шулай, иҗат ул — шәхси үткәнеңнән, биографияңнән аерылгысыз. А. Гыйләҗевтә җәмгыятькә карата булган «усаллык» барлыкка килүнең сәбәпләрен без чын-чынлап бары тик аның «Йәгез, бер дога» әсәре басылып чыккач кына аңладык. Ул Казан-Свердловск-Петропавел-Карабас-Актас-Волынка-Майкудук-Чиләбе-Казан маршрутын, тоткын буларак, рәшәткәле вагоннарда, кысан машиналарда, урыны-урыны белән җәяүләп тә узган икән. Ни өчен? Бары тик сталинчыл режимны, халыкны изүнең бу рәвешен мактамаганы, шуны ныгытуга өлеш кертмәгәне өчен. Егерме ике яшьлек егет, шул рәвешле, яманаты чыккан 58 нче маддә буенча гаепләнеп, илнең каймагы булган меңнәрчә-меңнәрчә шәхесләр арасында, чыннан да, хакимиятнең тоткан юлына аңлы рәвештә каршы булган кешегә әверелә. Аның: «Акылны төрмә кебек баета торган мәктәп юк»,— диюе шуңа ишарә. Бу «мәктәптән» А. Гыйләҗев менә нинди сабак алып чыга: «Октябрь — дөньяның иң хурлыклы, иң кара сәхифәсе ул. Нәрсә ул пролетариат диктатурасы? Тормыш кануннарын ертып-ертып алга үткән, өскә күтәрелгән берәүнең чикләнмәгән власте ул. Ил каршында да, Алла каршында да җавап бирмәячәк явыз шәхеснең өстенлеге».

Чыннан да, уйлап карыйк. Моңарчы Октябрь инкыйлабы, хезмәт ияләре бәхете өчен ясалды, дип аңлатылып киленде. Әмма бәхет кеше сөякләренә

нигезләнә алмый. Халыкның иң хезмәт сөючән, эш рәтен белүче, иң акыллы, иң сәламәт өлешен юк итеп төзелгән җәмгыять ничек инде бәхетле дип атала алсын? Әйбәт әйберне бик тырышып мактауның кирәге булмый, ул үзе турында үзе сөйли. Ә җирнең алтыдан бер өлешендә ленинизм-сталинизм байрагы астында төзелгән, моңарчы тиңе булмаган төрмәне мактау өчен ниләр генә эшләмәделәр?! А. Гыйләҗев «Йәгез, бер дога»да шуның шыксызлыгын ача. Әйе, Ленинның да, Сталинның да рухи атасы Карл Маркс иде. Бу алманлы яһүднең явызлыкта шигърият күрүе кемгә генә мәгълүм түгел. «Рәсәйнең татарларны яулап алуы үтә уңай күренеш»,— дип язып чыккан ул кешенең шәкертләре аңа тугрылыклы булып калды. Чөнки Явыз теория явыз гамәлләр нигезенә генә чәчәк атарга мөмкин. А. Гыйләҗев бер урында Көнчыгышның бөек фәлсәфәчесе Конфуцийның мондый сүзләрен китерә: «Черек агачтан асыл сурәтләр юнып булмый». Шуның кебек, К. Маркснның талап алу сугышларын хуплавы беренче социализм иленең үз эчендә һәм аның тирәсендәге халыкларга күпме күз яше, җәбер китергәнлеген барыбыз да күреп тордык. Кешелекнең яшәү рәвеше, гамәле, фәлсәфәсе мәңгелек кыйммәт булган дингә нигезләнергә тиеш.

Аяз Гыйләҗев тә, мәхшәр газапларын үтеп, җирдәге тормышның бик күп якларын тирәнтен тәфтишләгәннән соң шушы карашка килгән икән, монда хикмәт бар. «Динсез диярлек гаиләдә үссәм дә,— ди ул,— Коръән укый башласалар, тәнемә каз тиресе чыга. Тел музыкасын, Коръән сүзләренең яңгырашын гипнозга тиңлиләр. Коръән аятләре адәм улларын йә кузгаталар, йә тынычландыралар. Бераү дә битараф кала алмый». Язучы хаклы, Коръән Кәрим — кеше өчен туры юлның, изгелекнең, саф күңеллелекнең ачкычы, фатиха бирүчесе, юл күрсәтүчесе.

Автор бу әсәрен «Йәгез, бер дога» дип исемләгән. Үзе белән бергә җәберзолымны, михнәт-хәсрәтләрне бүлешкән кешеләрне җентекләп искә төшергәннән соң, «күчкәннәр вә калганнар рухына», ягъни үлгәннәр һәм исәннәр намена дога кылырга өнди. Без, әсәр белән танышу барышында, әдипне искә төшерүче итеп кенә түгел, бәлки үзе яшәгән алтмыш биш елга, андагы хәл-әхвәлләргә акыллы бәя бирүче буларак күрәбез. Аерым кеше язмышларын чор кичергән фаҗигаләр эчендә карау аңа әүлияләрчә киң күңелле булырга ярдәм итә. Ул үзен саткан, юк гаепләрен бар итеп кара яккан, кимсеткән кешеләрдән өстен булып кала, күңелендә аларга кинә сакламый. Үзенекедәй язмыш кичергән кешеләр — аның өчен изге, гөнаһсыз. Ун миллионнарча кешеләрне шундый «мәктәп» аша уздырган илнең киләчәге ничек хәерле булсын? Дөресендә, ленинчыл-сталинчыл хакимият үзен юк итүчеләрне әнә шулай төрмә «университетлары» ярдәмендә тәрбияләде. А. Гыйләҗевнең уйланулары шундый нәтиҗәләргә китереп чыгара. Үз заманын яхшы аңлап, аңа бүгенгедән торып бәя биргән, алай гына да түгел, киләчәктәге офыкларның кайбер төсмерләрен дә күрсәткән әдибебезне, фикер хәзинәләребезне баетканы өчен, тәкъдир итәргә генә кала.

Аяз Гыйләҗевнең дүрт томлыгына керергә өлгермәгән бу роман-хатирә аның иҗатын аңлауга тулаем ачкыч булып тора. Аны укымый һәм андагы һәрбер фикер турында тирән уйланмый торып, А. Гыйләҗевне һәм шәхес, һәм әдип буларак тулы аңлармын димә. Укучылар даирәсе боларны белми дә калыр иде — Аллага шөкер, сүз ирекле килде һәм хакыйкатьне ачып салу мөмкинлеге туды. А. Гыйләҗевкә килгәндә исә, ул дөреслекне икрар итүнең аз гына мөмкинлекләрен дә файдаланырга тырышты. Бу очракта М. Әмирнең сүзләре искә төшә. «Безнең авыл кешесе» әсәрендә ул Миргали турында болай ди: «Алдына алган теләгенә ирешү өчен ул законнарның йә астыннан, йә өстеннән үтеп китәргә кирәк була аңа». Шуның төсле, А. Гыйләҗев тә заманында цензорларның уяулыгын йоклатырлык мөмкинлекләрне бер дә кулдан ычкындырмаган.

Әйтик, «Үги ана яфраклары» хикәясе бер дә сәясәткә кагылмаган кебек. Унтугыз битлек әлеге хикәя мәхәббәт турында поэма булып яңгырый. Ул — А. Гыйләҗевнең чын мәгънәсендә сүз рәссамы булуын раслый торган әсәр. Аның төп каһарманы яшь егет Галимҗан өчен бу көн гадәти генә көн түгел — ул кичен сөйгәне Сөмәя белән мәхәббәттә аңлашырга тиеш. Шуңа күрә ул комбайннан ашлык ташу кебек тузанлы эшкә дә ап-ак күлмәк киеп чыккан. Менә ни өчен ул бүген һәр нәрсәдә шагыйрәнә матурлык күрә. Ашлык төялгән машинасын басуда үсеп утырган матур үләннәр янында туктатып алырлык дәрәҗәдә күңеле нечкәргән аның. Әнә ул күзлүт үләненә соклана. Бу чәчәккә шундый исем кушкан борынгы кешеләрнең күзәтүчәнлегенә шакката, вак зәңгәр чәчәкләрне кеше күзенә охшата.

Әсәрдә Галимҗанга капма-каршы итеп Хәнәфи образы куелган. Чөнки бу соңгысы матурлыкны күрү, аңлау мәсьәләсендә саңгырау, колагына сыер баскан

бер кеше. Әлеге үлән турында да ул: «Күзлутмы, чүзлутмы, сыер аны авызына бөтерә дә тыга»,— дип, күренешне бөтенләй гадиләштереп аңлый. «Чәчәген белмим, әмма ачы бал исе килә! Берәр җамыякны тиңкәйтеп җибәрергә диген син! Менә булыр иде эш!» — дип тә өсти. Ягъни, чәчәкнең исе дә анарда хәмер эчәсе килү теләген уята. Әнә сугышка кадәр үк төзелгән иске җил тегермәнен дә сүтеп алырга кызыга ул, күпме утын әрәмгә ята, ди. Әмма Галимҗан өчен җил тегермәненең мәгънәсе күпкә олырак. Ул аңа авылның сугыш кырыннан әйләнеп кайтмаган 75 кешесенә һәйкәл итеп, изгеләштереп карый.

Укучының болай уйларга да хакы бар: кыз белән егетнең иң кадерле көне сурәтләнгән бу әсәргә нигә соң әле автор шушы тискәре Хәнәфине китереп керткән? Ни хаҗәте бар аның? Халык җырыннан бер генә сүзне дә төшереп калдырып булмаган шикелле, сүз бара торган сәнгатьчә камил әсәрдә дә бер генә нәрсә дә артык түгел. Хәнәфи образы бигрәк тә. Дөрес, беренче карашка, ул гашыйк Галимҗан образының күңеле матурлыгын тирәнрәк ачу өчен генә кертелгән кебек. Аның иң олы вазифасы, чыннан да, шуннан гыйбарәттер. Ләкин әдип аңа тагын да әһәмиятлерәк бүтән бурыч та йөкли. Бу тупас күңелле, хәмергә хирeслектән тәм табучы кеше вакыт-вакыт йомры-йомры гына итеп үтә дөрес һәм вакытлар өчен гаеп саналырдай сүзләр дә әйтеп ташлый. Галимҗанга ул, мәсәлән, болай ди:

— Синең урыныңда булсаммы мин? Төкерер идем авылына. Тормышмыни бу, яшәүмени? Шәйхулла типкесендә йөр инде.

Ә Шәйхулла (колхоз рәисе) кем типкесендә йөри? Әнә районнан ашлык тапшыру өчен 5 удар көнлек игълан иткәннәр, ул шуны үтәү өчен җан-фәрман чаба. Димәк, ул да эшне үз дигәненчә генә, җай гына, кирәк булганча оештыра алмый. Шундый «удар» көннәр бөтен эшне чуалта, һәммәсен ритмнан чыгара, аннан соң шуның нәтиҗәсен ел буе төзәтергә туры килә. Ә өстәгеләрнең анда гаме юк. Аларга «штурмовщина» вакытында, тисә тиенгә, тимәсә куянга дигәндәй, тагын да өстәнрәк бирелгән күрсәтмәләрне үтәргә генә кирәк.

Ул елларда кешенең кемлеге эшли белү белән түгел, яши белү белән билгеләнә иде. «Яши белү» тегенә дә, бусына да оста җайлашуны аңлата иде. Урыны-вакыты белән өстәге кешеләргә карап җайлаша, шәкелеңне үзгәртә алмыйсың икән, башлыкларыңа, ничә очрасалар да, җиргә иелеп баш имәсәң һәм синнән «түбәннәр» сиңа шуны ук эшләмәсә — кешеләргә хакимлегеңне кулыңда озак тотмыйлар. Шул рәвешле: түрә — үзеннән кечерәкләргә хан да, хөкемдар да. Бу вәзгыять «Балта кем кулында?» романында бик гыйбрәтле гәүдәләнгән.

Роман тукымасында заманыбызның асылын аңлау юнәлешендә геройларның тирән уйланулары табигый урын ала. Менә Фәридун Фазлыев исемле кешенең яшәү мәгънәсе турындагы уйланулары. Алар кешенең усал табигатьле булып үзгәрә баруына иҗтимагый аңның дөрес юнәлештә тәрбияләнмәгәнлеге сәбәпче икәнен төшендерә. «Менә мин,— ди ул,— озак елларга кадәр кешенең яшәү рәвеше — көрәш дип, ышанып яшәдем. Адәм балалары көрәшергә тиеш һәм вәссәлам! Шулай дип укыдык, дөнья маңгайга бәрә-бәрә һаман шуны тукыды. Бәхет дигән мөкатдәс сүз телдән төшеп кала язды, аңа бары тик өзлексез көрәш нәтиҗәсендә генә ирешеп була дип ышандык. Һәм бүтәннәрне дә шуңа ышандырырга тырыштык».

Уйлап карасаң, бу сүзләрдә хаклык ярылып ята бит. Социализм җиңә барган саен, илдә сыйнфый көрәш кискенләшә, дигән ялган тәгълимат белән коралланган сталинчылар шулай өйрәттеләр, илнең бөтен тормышын шуңа кордылар. Мондый шартлардагы кеше, тамагы тук, өсте бөтен булса да, тулы бәхеткә ия дип санала аламы? Матди тәэмин ителгәнлек өстенә тулы сәяси һәм рухи ирeклелек булганда гына камил бәхет урнаша ала. Автономиягә генә ия татар халкына да сан бар идемени ул елларда?!

«Торгынлык» дип аталган чор кешеләре... Алардан кемне генә әсәр үзәгенә куйсаң да, теләсә кайсы кеше мең төрле җепләр белән җәмгыятьнең бихисап катлауларына бәйләнгәнгә күрә, брежневчылар идарә иткән унъеллыкларның хикмәтләрен ачарга мөмкин булыр иде. А. Гыйләҗев, үз өстенә гаять җаваплылык алып, романда шуңа омтылыш ясый. Әсәрдә кемгә генә тукталма — үзе бер сюжет сызыгын алып китәрлек язмыш. Тик шулай да аларның барысын бер җепкә тезүче, ансыз роман оеша алмый торган бер образ бар, ул — Нәҗип Нургалиев. Югары техник белемле, утыз өч яшьтә. Нәҗип тормышта үз заманы кануннары белән каршылыкка керә. Алдындагы дивар шулкадәр нык һәм биек ки, аны әйләнеп үтү яки берәр ярыгын табып чыгып китү мөмкин түгел. Җәмгыять алдындагы «зур гөнаһы», кара күләгә булып, һаман артыннан калмый. Чөнки ул бер җыелышта дөреслекне ярып салган: завод директорын милләтләргә

бердәй карамауда гаепләгән, хуҗаның шундый эшләрен күреп тә дәшмәгән партком секретарен «ваемсыз», профком рәисен «чүпрәк» дип атаган. Шуның өчен өметле инженерны эшеннән чыгарып ташлыйлар, тәүбәгә килмәгәч, төрлечә тинтерәтә башлыйлар. Аның сәламәтлеге кыл өстендә булуын белеп торуларына карамастан, Иван Иллорионович, Наум Фогельсон кебек — муеннары җитәкчеләр ягына кәкрәеп каткан — врачлар Нәҗипне хәтта армиягә алырга яраклы, дигән ялган нәтиҗә чыгаралар. Шулай да, Нәҗипнең хәле армиялек булмагач, аңа «психик авыру», дигән мөһер сугалар.

Рәсми оешмалар кушканнан аз гына тайпылып сөйләшкән яки эш иткән кешене юләр дип атау — аның белән көрәшүнең иң җиңел юлы. Янәсе, юләр ни сөйләмәс! Үзләренең табиплык намусларын атлап чыккан шифаханә чиновникларын Нәҗип тә «козгыннар оясы» дип атый. Әлбәттә, табипларның барысы да андый түгел. Бар аның халыкка тугры хезмәт иткән өчен үзе үк сигез ел төрмәдә утырып чыккан Фәридун Фазлыев һәм Фаина Марковна кебек, кешенең җанын дәвалардай осталары. Әмма шул ук Фәридун әйткәнчә, «җәмгыять җинаятьчеләрдән түгел, гаделләрдән арынырга, намуслылардан котылырга теләгән» илдә игелекле кешегә баш калкытырга ирек бирмиләр. Номенклатура — бары үз даирәсен генә кешегә санаучылар төркеме.

Әсәр герое Нәҗипкә килгәндә, ул шушы номенклатура эченә үтеп керергә тели. Шундагы кешеләр бәхетеннән үлеп көнләшә, яхшы фатир, дача, машина, мәҗлесләр, көньяк курортлары аның җанын бимазалый. Шуның өчен борчылып, аның сәламәтлеге какшый. Нәҗип — катлаулы холык иясе. Шул ук вакытта бу образ үзенең һәм намуслы кешеләрнең авыр хәленә карата булган протестын киң итеп күрсәтә алмый. Чөнки, күренгәнчә, Нәҗипнең бөтен хәрәкәтен барлыкка китерүче көч шактый зәгыйфь, ягъни ул — нигездә, үзенең шәхси тормышын яхшыртырга булган омтылыш. Мондый тар максатка ул кадәр зур күсәккә тотынмыйча да ирешергә мөмкиндер. Әсәр героена кайбер юлларны күрсәтүчеләр дә була. Ләкин Нәҗипнең ялгыз көрәштәге уңышсызлыгының төп сәбәбе — аның эш-хәрәкәтләрендә эзлеклелек, мантыйк булмауда. Шул ук вакытта холык-фигыль бөтенлеге җитенкерәмәү — аның бәхетсезлеге. Әлбәттә, бу очракта без авторга нигә бу образны тегеләй, яки болай итеп сурәтләдең, дип дәгъва белдерүдән ерак торабыз. Чөнки, башкача булганда, әлеге күп яктан гыйбрәтле сюжет барлыкка килә алмас иде. Кеше характеры ахыр чиктә язучыга үзен борчыган әһәмиятле фикерен әйтү чарасы икәнен хәтердән чыгармаска кирәк. А. Гыйләҗевнең каләме мондый нәтиҗә чыгара: «власть ике төрле була ул, берсе аның күзгә күренә, икенчесе күренми».

Кечкенә генә промбаза директоры Фәтхулла абзыйлар, кибет башлыгы Вафа Сафичлар, әнә ни рәвешле шәһәр башлыкларын бармак очларында биетәләр! Чын хакимият — әнә шул матди байлыкларга ия кешеләр кулында. Боларында да, тегеләрендә дә оят дигән нәрсә бөтенләй юк. Без нәкъ шундый күренеш белән Р. Мөхәммәдиевнең «Кенәри — читлек кошы» романында да очрашкан идек. Мондый «яшь белүчеләр» өчен, дөрестән дә, Н. Хрущев әйткән «безнең буын кешеләре коммунизмда яшәр» дигән сүз тормышка ашкан...

Аның каравы, хакимият башында тотынып тору өчен, аларның күзләренә генә карап торучы тугрылыклы кешеләре бар. Бөтен гаделсезлекне алар шушылар кулы белән башкара. Шәрехли башласаң, явызлыклар өчен җавап бирүчене эзләп табу мөмкин булмый. Ник дигәндә, өстен катлау гөнаһсыз сабый булып кылана, ә балта белән эш итүчеләр исә — исемсез. Моннан бер генә нәтиҗә ясарга мөмкин: балтаны (хакимиятне) халык үз кулына алырга тиеш. Әнә шул вакытта әлеге корал бары тик хезмәт кешесе мәнфәгатьләренә генә хезмәт итәр. Тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин да, дөнья белән саубуллашканда, «балтаның явызлар кулында булуына» борчылды бит.

Кызганыч, бу дүрттомлыкта А. Гыйләҗев драматург буларак тәкъдим ителмәгән. Ә бит аның бу жанрдагы табышлары чәчмә әсәрләрендәгеләре белән тыгыз үрелеп бара. Шуның өчен без сүз уңаеннан бу хакта да фикер йөртүне табигый дип саныйбыз.

Прозадагы кебек үк, драма әсәрләрендә дә А. Гыйләҗев кешене вакыт белән аерылгысыз тыгыз бәйләнештә карый. Вакыт исә һәр нәрсәгә үз билгеләрен сала. Кешеләр аның алдында көчсез булып кала. Хәтта илленче елларда яшәгәннәр белән сиксәненче-туксанынчы дистәләрдә гомер итүчеләр арасында да аерма бихисап. А. Гыйләҗевнең пьесаларын бер-бер артлы укып чыккач та, иң әүвәл вакыт һәм кеше дигән, ягъни мәңгелек сорауларның берсе тирәсендә фикер йөртәсең. Прозасындагы кебек үк, аның драма әсәрләрендә дә конфликт ачык төсмерләнә, пьесаларының җегәрен дә фикер көрәше, аның тирән мәгънәлелеге

тәэмин итә. Шул ук вакытта аларда фәлсәфә өстенлек ала. Бу үзенчәлек аның барлык әсәрләренә дә хас. Менә шуларның берсен — «Күтәреп искән җил» комедиясен карыйк.

Әсәрдә гәрчә көлкеле ситуация алынса да, аның төбендә җитди фикерләр ята. Комедиянең гаять күп сыйдырышлы жанр булуы биредә мең дә беренче тапкыр раслана.

Җил — татар әдәбиятында Кол Галидән үк килә торган, олы мәгънәләр белдерергә хезмәт итүче деталь. А. Гыйләҗев тә аны әлеге комедиядә уңышлы куллана. Әсәрдә вакыйгалар сиксәненче еллар башында бара. Бу — ил белән җитәкчелек итүдә гаять җитди ялгышлар җибәрелгән чор. Аның иң зур афәте кешеләрне психологик һәм аң ягыннан гарипләндерү иде. Бик күпләр эшләмичә ашарга, җайлашырга, җилнең кайсы яктан искәнен чамаларга, борыннары белән кем ягыннан нинди җил килүен сизеп, үзенә файдалы кешеләр ягына авышырга өйрәнделәр. Боларның һәммәсе аерым кешеләрнең үзаллы эшләргә омтылышын йогәнләде, иң әшәке сыйфат — икейөзлелек тәрбияләде. А. Гыйләҗевне дә шушы нәрсәләр борчый. Чорның тагын бер гарип күренеше — кайбер кешеләргә ясалма рәвештә абруй тагу, шуларны бүтәннәр өчен табынырга яраклы шәхес итеп күрсәтергә тырышу булды. Пьесада сурәтләнгән ферма мөдире Фәрханә — шундыйларның берсе. Ул җитәкләгән коллективны ничектер бер тапкыр районда алдынгы итеп күрсәткәннәр дә, шуны әллә ничә еллар буена үрнәк итеп күрсәтеп баралар. Ә Фәрхәнәнең үзен исә «бөек хатын» дип атарга ук җөрьәт иткәннәр. Аны төрле җыелышларның түренә утырталар, сөйләр өчен нотыкларын язып ук бирәләр, ягъни үзең уйлап баш ватарга да кирәкми. Көннәрдән бер көнне ачык һавада уздырылган митингта сөйләгән вакытта аның кулындагы кәгазен җил очыртып алып китә. Г. Афзал әйткән «кыйбла булып» искән җил аңа, шулай итеп, кешеләргә үз сүзләрен сөйләү мөмкинлеген тудыра. Ләкин бу кешенең җәмгыять өчен файдалы эше булмаган кебек, башкаларга кирәкле сүзләре дә юк икән.

Кәгазьдән карап сөйләү — ул утызынчы елларда кереп киткән яман гадәт. Аңа кадәр кешеләр, шомамы-кытыршымы, укып түгел, уйлап сөйләгәннәр! Аларның нәрсәгә сәләтле булуын бер-ике авыз сүз әйтүгә үк чамалаганнар. Утызынчы еллар урталарында исә, сүз сөйләү иң хәтәр бер эш булып әверелгәч, кешеләр ялгыш фикер әйтүдән куркып, әйтәсе сүзләрен төзәтеп-шомартып алдан ук язып куя торган булып киткәннәр. Тора-бара инде аларны бу мәшәкатьтән дә азат иткәннәр, нотыкларны әзер килеш кулларына тоттыра башлаганнар.

А. Гыйләҗев чаңны бик вакытлы суккан булып чыкты. Хәер, «Өч аршын җир», «Өтәч менгән читәнгә», «Җомга көн кич белән» әсәрләре белән ул мондый чаңны даими кага килде. Повестьта сурәтләнгәннәр нигезендә драматик фаҗига итеп эшләнгән «Өч аршын җир» әсәре иҗат ителүеннән соң дистә еллар үткәч кенә сәхнәгә күтәрелгән икән, димәк, бу пьеса ул еллардагы идеология куштаннарының бәгыренә үк булып кадалган диган сүз. Адаш дип исемләнгән персонажның сүзләреннән моны шактый үтемле сизәргә була. «Бел, авыл халкы җәберҗәфаны байтак кичерде. Шактый еллар безне кешегә дә санамадылар. Соңгы сыныгыбызны сыпырып алып чыктылар, налог, заемнар белән интектерделәр... Түздек... Без түзәргә өйрәнгән. Әле безнең көн дә килер, дип түзәбез! Дөньяда гаделлек диган нәрсә дә калгандыр ләбаса. Бетмәгәндер ич ул!? Шул ышаныч барга түзәбез». Әнә шундый киләчәккә ышаныч хисләре белән тәмамлана әлеге трагедия.

Мирвәлине үз хуҗалыгына ут төртеп, авылдан чыгып китәргә мәҗбүр иткән сәбәп аңарда шәхси милекчелек хисенең көчле булуында гына түгел. Моны аның социаль хәле белән генә аңлату берьяклылыкка илтә. Ни өчен дигәндә, яшьлеген чын авыл хезмәте белән үткәргән Мирвәли күмәк хуҗалыкта да шулай ук тәм табып эшләр иде. Аның күңелен ахыр чиккәчә бер нәрсә кимсетә, ул да булса, атасыннан калган мал-мөлкәтне нишләтү мәсьәләсен хәл иткәндә, авыл активистлары Мирвәлинең фикерен сорап та тормыйлар, аңа әзер карарны гына җиткерәләр: һәммәсен күмәк хуҗалыкка бирәсең, бетте-китте! Болай итүләре нык рәнҗетә һәм Мирвәлидә уй-ниятләрне уята.

Инкыйлаб — өстен катлауларны хезмәт ияләре белән тигезләде, кешеләрне бәяләүдә төп күрсәткеч булып аларның җәмгыять мәнфәгатьләренә хезмәт итүе торды. Бу әнә шулай гадел җәмгыять булырга тиеш иде. Тик киресе килеп чыкты, совет хакимияте елларында кешеләр арасында яңа тигезсезлекләр дә барлыкка килде. «Бал кортлары белән янәшә» драмасындагы персонаж — хезмәтеннән ялга киткән офицер Ханзафар Вафичның хирург Зәки Әхиярович белән сөйләшүен тыңлау никадәр ямьсез тойгы калдыра. Ханзафар гади кешеләргә ярый торган

табипларга шикләнеп карый. Таныш булмаган доктор үзен карый башлаганчы, Ханзафар ага үзенең кем булуы, кайда эшләгәнлеге, орденнары турында арттыра-арттыра җиткерергә тели. Ягъни кем икәнен белсеннәр дә, ага үзенең шәхесенә бәрабәр зур игътибар күрсәтсеннәр! Җиренә җиткереп дәваласыннар өчен ришвәт төртү дә аның күнегелгән гадәте. Шушы Ханзафарның — совет хакимияте шартларында үзен өстен катлау вәкиле дип санап килгән типның — күңелен ачып салуы җанны тетрәтеп җибәрерлек ачыш булып яңгырый. «Тигезлек харап итә! Тигезлек кирәкми, ярамый. Зарарлы ул! Тигезлек яраса, миңа йолдызлар такмаслар иде. Мин гади авыру гына түгел! Гыйбадларга моны тирәнтен төшендер».

Без хәзер җәмгыятьнең сыйнфый яктан катлы-катлы булып әверелә баруын ачыграк тоябыз. Ләкин бу катлаулану җитмешенче-сиксәненче елларда ук барлыкка килгән иде. Ул чакта өстен катлау булган номенклатура моны бик күзгә ташланмыйча эшләде. Хәзер исә шул ук кешеләр, пәрдәләргә төренмичә генә, меңнәрнең күз алдында, халык өлешенә карап, байлык туплыйлар. Аяз Гыйләҗев боларны шактый элегрәк күрде, тәфтишләде, әсәрләрендә шуларны халык хөкеменә чыгарды. Бу аның соңгы утыз елда җәмгыятьне тирәнтен өйрәнүен, аңлавын күрсәтә иде. Ул өйрәнү бездәге социализмның күз буяу, алдау икәнлеген ачыклауга китерде. Иҗатта гадел булуы А. Гыйләҗев каләмен саташтыра алмады. Аның әдәбиятта гына түгел, җәмгыятьтә тоткан урыны да әнә шуның белән билгеләнә.

А. Гыйләҗевнең дүрттомлыгына кергән әсәрләр — совет хакимияте чорының сәнгатьчә тарихы, ахыр чиктә аның ни өчен җимерелеп төшүенең тирән итеп аңларга ярдәм итә торган әдәби елъязма. Килер буыннар бу әсәрләргә еш мөрәҗәгать итәрләр әле. Чөнки аларның кыйммәте бүгенге көн белән генә чикләнми. А. Гыйләҗев чәчкән таза орлыкларның яңа буыннар күңелендә бәрәкәтле үсентеләр бирәсенә безнең ышанычыбыз зур.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН.**

## Хөрмәтле укучыларыбыз!

**Билгеле булганча, 1996 ел өчен «Казан утлары» журналына язылуда без еллык подписка игълан иткән идек. Бер ел өчен язылып куйган әбүнәчеләрнең өенә безнең журнал, көтелгән кунак һәм дус булып, ел дәвамында килеп торачак.**

**Ярты елга гына язылып калучыларның исә исенә төшерәбез: «Казан утлары» журналы алга таба да өегезгә даими килеп торсын дисәгез, икенче яртыеллыкка да язылырга онытмагыз, дуслар!**

**Язылу бәясе — 12 мең сум.**

**Журналыбызның индексы — 73210.**

**Журнал битләрендә сезне алга таба да кызыклы сәхифәләр көтә. Язылыгыз, укыгыз, гел бергә булыйк!**

# ФАҖИГАЛЕ ЯЗМЫШ



Бу фоторәсемдә сез шагыйрь Фәрит Ибраһимовны хатыны Фатыйма белән күрәсез. Миңа аны Фәритнең кыз туганы Дильнавез Ибраһимова җибәреп, хатында абыйсының фаҗигале язмышы турында да язган иде.

Ф. Ибраһимов билгесез шагыйрь түгел, шигырьләре татар поэзиясе антологияләренә кертелгән. Иҗаты турында матбугат битләрендә мәкаләләр дә булды. Укучылар аның яшь кенә килеш «Уйларым» (1912), «Өмидемнең нурлары» (1912) исемле ике шигырь җыентыгы чыгаруын, шигырьләре һәм поэмалары «Аң», «Сөембикә», «Ак юл», «Балалар дөньясы» журналларында, «Кояш», «Сибирия» гәзитәләрендә, «Көрәш җырлары» (1923) исемле җыентыкта басылуын да беләләр булыр.

Биредә мин Ф. Ибраһимовның биографиясе һәм иҗаты турында сөйләргә җыенмыйм, бары әлеге фото һәм хат уңае белән шагыйрьнең фаҗигале язмышы турында гына берникадәр фикер әйтеп үтмәкче булам.

Ф. Ибраһимов 1893 елның 1 февралендә Лаеш өязе Түбән Ырга авылында (хәзерге Татарстанның Балык Бистәсе районы) Таҗетдин хәлфә гаиләсендә дөньяга килә. Фәритнең үз әнисе ул кечкенә чакта ук үлеп китә, малай үги ана кулында үсә. Күрәсең, үги ана тәрбиясендә бик җиңел булмагандыр, тормышның җәфасын ул сабый чакта ук татыгандыр. 1913 елда «Ак юл» журналында гаять кызганыч эчтәлекле «Үги бала» исемле шигырь бастыруы шуңа ишарә.

Хәлфә баласы буларак, Фәрит бик иртә белем алган булса кирәк, чөнки ул туган авылыннан бик яшьли чыгып китеп, Урал, Себер, Кыргызстан якларында балалар укытып йөри, ягъни үз көнен үзе күрә.

Беренче империалистик сугыш та аны читләтеп үтми, бу сугыштан ул бер кулы яраланып кайта.

Ф. Ибраһимов биографиясенең тагын да фаҗигалерәк еллары шәхес культы чорына, 1937 елларга туры килә. Бу вакытта инде ул — экономика фәннәре кандидаты, Сәмәрканд Коммунистик университетында кафедра мөдире, укытучы-доцент. Үзбәкстанның 15 еллыгы уңае белән документлары «Хезмәт батыры» исемен алу өчен Мәскәүгә җибәрелгән була. Ф. Ибраһимов бер кафедра утырышында университетның ректорын тәнкыйтьләп чыгыш ясый. Моның нәтиҗәсе аңа бик кыйммәткә төшә. Ректор аның лекциясенә читтән бер студентны кертеп утыртып, анардан Ф. Ибраһимов өстеннән шикаять яздыра һәм укытучы марксизм-ленинизм теориясен дәресендә бозып аңлата, дигән нәтиҗә чыгарта. Бу шикаять партия комитеты утырышында тикшерелә, нәтиҗәдә укытучы-доцент эшеннән һәм партиядән чыгарыла, фәнни дәрәҗәсе алынып, эше НКВДга тапшырыла, аңа «халык дошманы» дигән мөһер сугыла. Мәскәүгә үтенеч җибәрсә дә, файдасы булмый, тикшерү өчен үтенеч кире ректорга кайтарыла. Сигез ай эшсез йөргәннән соң, Ф. Ибраһимовны «кара машина»га утыртып алып китәләр. Йөрәге авыру килеш ул Себердә елдан артык урман кисә. «1939 елда сөрген срогын тутырып безгә кайтканда, тешләре дә коелып беткән иде»,— дип яза сеңлесе. Кайткач та ул бер кайда да эшкә урнаша алмый, кайда барса да аны «халык дошманы» дип эшкә кабул итмиләр. Гаиләсе таркала, фатиры югала. Бу кадәр нахак рәнҗетүләргә, ничә ел эшсез йөрүләргә кешенең ничек йөрәге түзсен — ул 1943 елда Сәмәрканд өлкәсенең Хатырчы дигән район үзәгендә эшсез йортында вафат була, Хатырчы зиратына күмелә.

Татар шагыйренең язмышы менә шулай тәмамлана. Туганнарына тоткынлыктан җибәргән хатында шагыйрь болай ди:

Эссе кояш калкып чыгар микән,
Эретер микән калын карларны,
Булыр микән чишеп җибәрүче
Богауланган аяк-кулларны.

Ташламагыз мине, туганнарым,
Чыгарыгыз баткак эченнән,
Дошманнарым төртеп төшерделәр,
Чыга алмыйм, килми көчемнән.

**Фатыйма ИБРАҺИМОВА.**

*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

## ТАТАРСТАН — ЕВРОПА ХАЛЫКАРА ОЕШМАСЫНДА

Татарстан Дәүләт Советына Татарстан Республикасының Европа регионнары Ассамблеясе әгъзасы итеп кабул ителүе турында шатлыклы хәбәр килде. Бу хактагы карар әлеге оешманың башкарма органы утырышында Берлинда кабул ителгән.

## ТР ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ СЕССИЯСЕНДӘ

17—18 гыйнвар көннәрендә даими эшләүче парламент сессиясенең беренче утырышы булды.

Сессиядә катнашучылар иң элек Кизләрдә һәм Первомайское поселогында (Дагыстан) һәлак булганнарны бер минутлык тынлык белән искә алдылар. Аннары көн тәртибе расланды. Аеруча мөһим мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Законнары проектлары тикшерелеп, тиешле карарлар кабул ителде.

Сессиядә депутат Ф. Сафиуллин тәкъдиме белән, ТР Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин чыгыш ясады. Ул Казан дәүләт университеты базасында Татар гуманитар институтын булдыруга әзерлек эшләре турында сөйләде.

Әлеге депутат тәкъдиме белән сессиядә көн тәртибенә «Төньяк Кавказдагы вакыйгалар турында»гы мәсьәлә дә кертелгән иде. Шуңа бәйле рәвештә ТР Дәүләт Советы Төньяк Кавказда 1996 елның гыйнварындагы хәрби вакыйгаларга карата махсус белдерү кабул итте. Әле тарихи документ һәр ике якны да «сугыш хәрәкәтләрен кичекмәстән туктатырга һәм сөйләшүләр алып баруны башларга» чакыра.

Сессиядә әйләнә-тирә мохитны һәм табигый ресурсларны саклау буенча да җитди сөйләшү булды. Аерым алганда, Башкортстандагы нефть үткәргечендәге авариядән соң, Татарстан хөкүмәте күргән чаралар турында белдерү ясалды. Әлеге мәсьәлә буенча ТР Дәүләт Советы карары кабул ителде.

## МИЛЛИ ГАИЛӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

25 гыйнварда Татарстан Дәүләт архивының утырышлар залында Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының киңәйтелгән бюро утырышы булды. Көн тәртибенә «Милли гаилә: бүгенгесе һәм киләчәге» дигән тема куелган иде. Утырышта катнашкан әдәбият һәм сәнгать, мәгариф һәм медицина белгечләре, шәһәр хакимияте һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре татар гаиләсенең бүгенгесенә һәм киләчәгенә борчылуларын белдерделәр, рухи кризистан чыгу юллары турында үз фикерләре белән уртаклаштылар.

## МӨХӘРРИРЛӘР СЕМИНАРЫ

29 гыйнвар — 2 февраль көннәрендә Казанда республикабыздагы шәһәр-район газеталары мөхәррирләренең бер атналык семинары булып үтте. Аны Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы һәм ТР Дәүләт Советы каршындагы республика курслары оештырган иде.

Мөхәррирләр алдында ТР Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев, ТР Премьер-министры урынбасарлары И. Хәйруллин, А. Габетдинова, Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов, Россия Дәүләт Думасы депутаты О. Морозов һ. б. чыгыш ясады. Алар республикабыздагы сәяси-икътисади хәл, соңгы сайлауларның йомгаклары һәм бүгенге матбугат актырта торган проблемалар, шуларны хәл итү юллары турында үз фикерләре белән уртаклаштылар. Матбугат иреге һәм демократия мәсьәләләренә дә зур игътибар юнәлтелде.

## АЧЫКТАН-АЧЫК СӨЙЛӘШҮ

22—23 гыйнвар көннәрендә Казан дәүләт технология университетының актлар залында «Югары класс укучыларына, махсус урта һәм югары уку йортларында белем алучыларга татар телен укыту проблемалары»на багышланган фәнни-гамәли конференция булды. Анда Казан шәһәре хакимиятенең мәгариф идарәсе җитәкчеләре, галимнәр, татар теле белгечләре, укытучылар чыгыш ясады. Татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү максатында куелган бурычлар һәм шуңа ирешү юлында булган кыенлыклар турында да ачыктан-ачык сөйләшү булды.

*ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ ДӨНЬЯСЫНДА*

## АКСАКАЛ ӘДИП БЕЛӘН ОЧРАШУЛАР

22 гыйнварда Казан Кремлендә Татарстан Президенты М. Шәймиев, 95 яшь тулуы уңае белән, халык язучысы Гомәр ага Бәшировны кабул итте. Очрашу вакытында әдәбиятыбыз аксакалы һәм республикабыз җитәкчесе җәмгыятебезнең көнүзәк сәяси һәм социаль проблемаларын тикшерделәр. Гасыр яшьтәше Г. Бәширов татар халкының рухи тормышы турындагы фикерләре белән

уртаклашты. «Үз Ватаның өчен, халкың өчен горурлык хисләре тәрбияләү — әдәбият һәм сәнгатьнең торышына да бик нык бәйләнгән. Бу өлкәдә күп эш башкарырга кирәк, ә моны дәүләт органнары булышлыгыннан башка эшләп булмый»,— диде Гомәр ага. «Иң яхшы милли традицияләрне һәм дәүләтчелекне тергезү — бер чылбыр буыннары»,— дип аның белән килеште М. Шәймиев.

Җөмһүриятебез Илбашы өлкән әдипкә нык сәламәтлек, бәхет, киләчәктә дә иҗади уңышлар теләде һәм актив җәмәгать эшчәнлеге, республикабызның көндәлек эшләрендә зур кайгыртучанлык күрсәтеп, ихлас күңелдән катнашуы өчен кайнар рәхмәт белдерде.

* * *

29 гыйнварда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында атаклы язучы Гомәр ага Бәшировның 95 яшьлек олуг юбилеена багышланган зур тантана булды. Юбилярны котларга Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, Россия Федерация Советы Рәисе урынбасары В. Лихачев, ТР Дәүләт Советы Рәисенең беренче урынбасары Р. Харисов, ТР Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин, Казан шәһәре хакиме К. Исхаков һ. б. килгән иде.

Кичәне Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев ачып җибәрде һәм алып барды. Өлкән каләмдәше һәм якташы хакында олы сүзне Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов әйтте. Гомәр аганы якташлары — арчалылар, Яңасала авылы игенчеләре, «Компрессормаш», Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәләре коллективлары һ. б. зурлады.

Аннары республикабыз сәнгать осталарының зур концерты булды.

## ИҖАТ ОСТАХАНӘЛӘРЕНДӘ

«Шигърият остаханәсе»нең чираттагы утырышы, индивидуаль семинар рәвешендә, «Сөембикә» журналы редакциясендә үткәрелде. Анда яшь шагыйрәләрдән Чулпан Зариф һәм Флера Гатина шигырьләре тикшерелде. Остаханә җитәкчесе — Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев, шагыйрьләр Рәдиф Гаташ, Зөлфәт һәм «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Роза Туфитуллова, шигырьләргә җентекле анализ ясап, уңышлы дип табылганнарын матбугатка тәкъдим иттеләр.

## ТУГАН ТУФРАК ТАРТА

Танылган шагыйрь, прозаик һәм драматург — Татарстан Җөмһүриятенең милли китапханәсе директоры, Татарстан халык депутаты, М. Җәлил премиясе лауреаты Разил Вәлиев Түбән Кама районында булып, якташлары белән очрашты. Шәһәрдәге 1 нче мәктәптә, педагогия училищесендә һәм язучының туган авылы Ташлыкта булган кызыклы очрашулар бик күпләрнең күңелләрен баетты.

## БЕРЕНЧЕ ТАТАР ФИЛЬМЫ ТӨШЕРЕЛӘ

Бу көннәрдә мәркәзебез Казан шәһәренең Үзәк мәдәният һәм ял паркында, Казансу елгасы буендагы иркен мәйданда «Болгарның җылы җилләре» дип исемләнгән беренче татар фильмын төшерү бара. Әлеге тарихи-нәфис фильмның баш режиссеры Булат Мансуровның (бер үк вакытта ул, язучы Гәрәй Рәхим белән бергә, әлеге картинаның киносценариен да язган шәхес) әйтүенә караганда, өч сериядән ошбу тасма быелның ахырына кадәр Казанда һәм чит илләрдә төшерелеп бетачәк һәм 1997 ел башында тамашачылар хөкеменә тапшырылачак. Фильмның баш операторы — Дилшат Фәтхуллин. Әлеге картинада танылган татар артистларыннан Шәүкәт Биктимеров, Илһам Шакиров, Ренат Тажетдинов, Әзһәр Шакиров, Алсу Гайнуллина, Хәлим Җәләлов, Ренат Ибраһимов һ. б. катнаша.

## КҮҢЕЛЛӘРДӘ — СӘЙДӘШ...

Татар халкының атаклы композиторы һәм дирижеры Салих Сәйдәшевның тууына 95 ел тулу уңаеннан, Татарстанда байтак кына чаралар уздырылды. Шуларның берсе — бөек композиторның иҗат эшчәнлегенә багышланган фәнни-гамәли конференция аның үз йортында — музеенда үтте. Бирегә Сәйдәшнең дуслары, композиторлар, музыка белгечләре, фәнни хезмәткәрләр, язучылар килгән иде. Музыка белгечләреннән Р. Исхакова-Вамба, З. Сәйдәшева, М. Фәйзуллаева, О. Егорова, композиторның туганы, медицина фәннәре докторы И. Әхмәров һ. б. чыгышлары тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты.

Фәнни-гамәли конференция җыр-музыка белән тәгәлләнде. Р. Халитов җитәкчелегендәге халык уен кораллары оркестры С. Сәйдәшев әсәрләрен башкарды.

«Сәйдәшем...» дигән исем астында К. Тинчурин театрында узган искә алу кичәсенә дә халык бик күп килгән иде.

* * *

Екатеринбургта да, С. Сәйдәшевның туган көненә багышлап, өлкә радиосы аша, Россиянең атказанган артисты Даут Бикбов катнашында музыкаль тапшыру яңгырады. Екатеринбургтагы татар-башкорт мәдәнияте үзәгендә татар якшәмбе мәктәбе укытучысы Роза Шәңгәрәева С. Сәйдәшевка багышланган искә алу кичәсе үткәрде.

# ПӘЙГАМБӘРНЕҢ УЕ

Чаллы рәссаме Ильяс Фәйзуллин әсәрләрендә реалистик колачлылык, куәт бар. Аның тарихчанлыгы исә — бүгенге сәнгать тудырган һәм кайвакыт төп җисемне белмәүдән һәм турыдан-туры тасвирлау авырлыгыннан куркып юнәлттерелгән идеальләштерү, җайлаштыру вә бизәкләү кебек компромисслы алымнарны танымый. Бу юлда аның остазлары: XIX гасыр рус рәссамнәре Крамской, Ге, Боголюбов, Верещагин вә беркадәр «академиклар». Ул да алар иҗатына хас борынгы чорларны, тарихи образларны үз заманына якынлаштыру, бүгенге чор проблемаларына, кичерешләренә тәңгәлләштерү ысулын куллана; каһарманнарның йөзләрен бүгенге кеше, үз чордашларының иконографиясен файдаланып сынландыра. Әсәрнең яңалыгы, стиле консерватив нигездә булган хәл, мөселман-шәрекъ темасында, Рәсүл образында... Ислам традицияләре буенча, рәссам пәйгамбәрләребезнең йөзен пәрдә белән каплап, яисә нур белән күмеп, күрсәтмичә сурәтләргә тиеш иде. Дини даирәләрдә, әлбәттә, бу таләпләр бүген дә зарури... Ләкин үзирекле рәссамнең үз кодрәте, үз идеалы, дине вә иманы бар, дигәндәй... Хәлбуки, XX гасыр иҗат кешесе, бөек иманулар, бөек шәхесләр, рухи тәгълиматлар һәм аларны тудыручылар мохитын читләтеп үтә алмый... Икенче меңъеллыкны йомгаклау чорында акыл кешелекле яктыга өндәгән, аңа әхлак-сабырлык биргән, бәхетле итәргә тырышкан фидакарьләрне яд итә, аларга мәдхия җырлый. Согуд Гарәбстанының пейзажына иңдерелгән Рәсүлебез сыны да әнә шундый рухи ихтыяҗлар нигезендә барлыкка килгән... Рәсүлнең япма ябынган, мәңгелек ташлар, контрастлы канәфер-көмеш төсләр, таучүллекләрдән табигать базисына иңдерелгән мәһабәт гәүдәсе картинаның алгы планында сурәтләнгән. Адәм тарафыннан рәнҗетелгән, гарьләнгән Рәсүл, кан тамырлары калкып торган ябык кулын иягенә куеп, уйга талган. Аның баш яулыгын, итәк, җилән күләгәләп үткән уйлары, әлбәттә, камил булмаган кешелек токымы, аның фаҗигасе, киләчәге хакында... Рәссам гаризонт сызыгын, махсус рәвештә, түбән итеп, аска төшереп сурәтләгән. Бу алым пәйгамбәрнең бөеклеген, аның уйларының илаһилыгын, шәхесенең вак-төяк ихтыяҗлардан өстен булуын ассызыклый. Еракта — кальга күренеше, уңда — зәңгәр таулар мәрҗәне, аста — комлы чүлләр, барханнар, аларны ярып баручы,— рәсүлебезнең уена тиң,— алга ургылган кәрван... Күләмнәрнең (алда — тау, аста — казанлык) контрасты исәбенә, дөнья чайкала, убыла сыман... Без дә үзебезне изге нәбинең ташкын-ташкын уй сөреме эчендә чайкалган кебек тоябыз. Сәяси тетрәнүләр нәтиҗәсендә актарылган татар мохите дә бүген шундый рухи үзгәрешләр кичерә түгелме соң? Ничек яшәмәк кирәк? Ил вә шәхес бәхетле булсын өчен нинди игелекле юллардан бармак кирәк?!

Тәңрем, бир ярдәмеңне!..

Пәйгамбәрнең уйлары зур, мәһабәт, киң — ул илләрне, чүлләрне, адәм, бөҗәкләрне галәмгә алып чыга.

**Карина БУЛЫЧЕВА**

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Ильяс Фәйзуллинның «Мөхәммәт пәйгамбәр» картинасыннан фотокүчермә.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** әдәби тәнкыйтьче, «Мәгариф» нәшрияты директоры Мөдәррис Вәлиев.

# ҖӘЛИЛЧЕЛӘР — КӨРӘШТӘШЛӘР




**1994 елның 25 августында Казан Кремле каршындагы Беренче Май мәйданында Җәлилче каһарманнарның мемориаль барельефларын ачуга багышланган «Хәтер җыены» булды. Барельефларның авторы — заманында М. Җәлил һәйкәлен иҗат иткән сынчы В. Е. Цигаль. Мәгълүм булганча, моннан ярты гасыр элек Алманиянең Плетцензее төрмәсендә Муса белән бергә әлеге фидакарь затларның башлары фашист гильотинасында киселгән иде. Рәсемдә (сулдан — уңга) — җәлилчеләрнең мемориаль барельефы:**

**ГАЙНАН КУРМАШ**
1919, 27 февраль — 1944, 25 август
**ФОАТ СӘЙФЕЛМӨЛЕКОВ**
1916, 16 июль — 1944, 25 август
**АБДУЛЛА АЛИШ**
1908, 25 август — 1944, 25 август
**ФОАТ БУЛАТОВ**
1913, 23 февраль — 1944, 25 август
**ГАРИФ ШАБАЕВ**
1907, 15 декабрь — 1944, 25 август
**ӘХМӘТ СИМАЕВ**
1915, 28 декабрь — 1944, 25 август
**АБДУЛЛА БАТТАЛ**
1916, 1 май — 1944, 25 август
**ЗИННӘТ ХӘСӘНОВ**
1916, 16 декабрь — 1944, 25 август
**ӘХӘТ АТНАШЕВ**
1917, 12 декабрь — 1944, 25 август
**СӘЛИМ БОХАРОВ**
1916, 15 июль — 1944, 25 август

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог